# КАЗАН УТЛАРЫ

2. 1991



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1991

2

ТАТАРСТАН ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

З. МАНСУРОВ. Хозыр галәйһес-сәламне әзләү. *Поэма* . . . 3
Г. АХУНОВ. Гомер юлы. *Роман* . . . 19
М. МӘҺДИЕВ. Ачы тәҗрибә авазы. *Истәлекләр* . . . 93
Г. МӨХӘММӘТШИН. Тәрәзәләр язга карый. *Шигырьләр* . . . 118
Л. ХӘМИДУЛЛИН. Офыктагы рәшәләр. *Эссе* . . . 121

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. ХИСМӘТУЛЛИН. Аһ, сызлый, сызлый җаным . . . 156
Ф. ӘХМӘТОВА. Казанда таңнар ни төсле? . . . 165

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ЮНЫС. Исабәт . . . 173
Р. МОСТАФИН. Тәнкыйтьченең акылы . . . 179

МӘДӘНИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Гаяз Исхакыйның Ф. Әмирханга хаты . . . 183
Җ. МИҢНУЛЛИН. Латин әлифбасы . . . 185

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 189
Тышлыктагы сурәтләр . . . 192

*Баш мөхәррир*

**РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН**

*Редколлегия*

**ГАРИФ АХУНОВ**
**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**ФЛҮС ЛАТЫЙФИ**
*(җаваплы сәркатип)*
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
**ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**МАРАТ МӨЛЕКОВ**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
**РАШАТ НИЗАМИЕВ**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**ГӘРӘЙ РӘХИМ**
**КОЯШ ТИМБИКОВА**
*(бүлек мөхәррире)*
**МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ**
**ТӘУФИКЪ ӘЙДИ**
*(бүлек мөхәррире)*
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066.
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-07-09,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият,
очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа Г. АХУНОВА «Дороги судьбы»; окончание повести-воспоминаний М. МАГДЕЕВА «Глас горького опыта»; эссе Л. ХАМИДУЛЛИНА «Марево на горизонте»; поэма З. МАНСУРОВА «Поиски пророка»; стихи Г. МУХАМЕТШИНА.
«Публицистика»: статья Р. ХИСМАТУЛЛИНА «Вся душа моя изнылась...»; статья Ф. АХМАТОВОЙ о народном художнике ТССР, заслуженном художнике РСФСР, лауреате Государственной премии ТССР им. Г. Тукая скульпторе, живописце Баки Урманче.
«Литературная критика»: статья М. ЮНУСА о проблемах современной татарской литературы; статья Р. МУСТАФИНА «Ум критика».
«К истории культуры»: письмо Г. Исхаки Ф. Амирхану.
Латинский алфавит.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: из археологических раскопок — древняя керамическая татарская посуда; портрет известного татарского писателя М. Хабибуллина.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов
*Хезмәткәрләр:* Р. Вафина, Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина

Производствога бирелде 12.12.1990 ел. Басарга кул куелды 25.02.1991 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 41199. Заказ Д-617. Бәясе 1 сум 50 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1991 ел

# Зиннур Мансуров

## Хозыр галәйһес-сәләмне эзләү

ПОЭМА

*«Пәйгамбәребез, галәйһес-сәләм, әйтте: бу тормыш — бер сәгатьлек, шунлыктан аны изге эшләргә файдалан».*

Борынгы кабер ташыннан

*Минем җанкәм ялгыз башы —*
*Хозыр булсын юлдашы...*

Татар халык җырыннан

### Бисмилла урынына

Эзләү алдыннан уйланып тору

Беләсеңме, бәндәм, беләсеңме —
кемнән ятим калган бала без?
Арабызда үзен артыксынып,
юкка чыккан Хозыр бабабыз!

Денсезләнеп калган дөньялыкта
күптән күренгәне юк аның.
Юксынырбыз бер чал юлаучының
ярабызны килеп юганын.

Кыркапкадан инде кермәячәк
фәкыйрь кыяфәтле аксакал.
Искәртүләр генә исебездә:
«Букчасына, барып, акча сал...»

«Сәламләми үтмә сәләмәне —
Хозыр Ильяс була күрмәсен!»
Этләренә хәтле әйтелгәндер:
«Хәерчегә,— диеп,— өрмә син...»

...Ялварадыр Хозыр ярдәменә
гаҗиз кеше: «Очрар көннәр бир!..»
Күрмәгәнме изге көтүчене
Байлар Сабасында кемнәрдер?

---

**Зиннур МАНСУРОВ** *(1949)— шагыйрь, «Кул бирәм», «Йөз суы», «Юлын белгән арымас» һ. б. татар, рус телләрендә дөнья күргән шигырь, публицистика китаплары авторы. Казанда яши.*

Кермәгәнме Урыс Мулласына[1]? —
Юкса анда
күпне белгән «кызыл погон» бар.
Кимсендереп торыр кыяфәтен
Үзгәртмәде микән пәйгамбәр?!

Ялгышкандыр: миндәй ябагайга
ярашырлык ярлы юк, дисә.
(Хәерлегә булсын...) Хәерчелек
хәттин ашкан бездә югыйсә.

Кабатлады күпләр кабергәчә
«Иза вакыйгатин» сүрәсен.
Мөхтәрәмнәр хәтта мохтаҗланды —
шагыйрь Дәрдемәндтән сора син...

...Кая киткән, эзлик, кая киткән
Кол Галине күргән картыбыз?
Борчылуны белмәс бәндәләрнең
бәгырендә бүген каты боз.

Бәлаләргә тарган балаларын
ничә чыгарышкан ак юлга!..
Мәңгелеккә барыр мөсафирның
югалуы сыймый акылга.

Күзебезгә ничек күренмәсен
үлми яши торган изге җан?!
Әбелхәят фани адәмнәргә
аны илче итеп иңдергән.

Яралардан типчеп яратылган
җанны кыйган чакта яманлык,
мәңгелекнең ярлы мөсафиры
япсын иде җылы ямаулык.

Кая киткән, эзлик, кая киткән
иман нуры чәчкән пәйгамбәр?
Сантыйларга кулын селтәгәнме:
«Минем монда нинди файдам бар?!»

Кермәгәне өчен колхозына,
тиңләштереп корткыч кулакка,
Хозырыңны совет хөкүмәте
әллә сөрде микән ГУЛАГка?!

Япканнардыр бәлки японнарның
шпионы, диеп, бу мажик?!
«И м п е р и я  з л а» исеменә
юкка гына лаек булмадык...

Яклаганы өчен яхшылыкны
«сары йорт»та башы чермиме?
Читлекләрен аның ачтыралмас
хәтта сабый чакның Сим-Симе.

[1] Авыл исеме.

Черетерләр яисә «Череккүл»дә,
бүтәнчәрәк фикер йөрт кенә.
Пенсиясез калган пәйгамбәрне
тыктыларммы картлар йортына?!

Җәрәхәтле җаным җәһәннәмле
җирне инде ничә айкады.
Кешеләрдән бизгән күңелдәшең
күренмиме сиңа, Ай кызы?

Күрәсеңдер, күркем, күрәсеңдер
янындарак торгач алланың.
Кешелекнең кысан күңеленә
син үзең дә сыя алмадың.

Илкәеңә сине иңдерергә
иртә әле, иртә, и җаным!..
Алыплардан тартып алганнардыр
иманасы белән ...иманын.

Имансызны бер ни имәндерми,
тотып көчләр иде... Ай кызын.
Тормышларны күреп торасыңдыр —
сөйлим бугай сиңа артыгын...

Хәлифәләр хәтта хәсисләнде —
кая карый икән бу алла?!
Партбилетлы «пөхтә» пәйгамбәрләр
бик күп бездә, бәгърем, буталма.

Иләсләрне изге иләмәнгә
әйләндерми калын каш кына...
...Парламенттан сорыйм пәйгамбәрне:
— Килеп чыкмадымы каршыңа?

Юлбарыстай халык югалганны...
Кемне генә борчыр бу маза?!
Сөргендәге Намус суратендә
пәйда булмаганмы БМОда?

Серләшергә садә сөргенчене
сыендырган мәллә Кар кеше?!
Куаладык картны... күңелләрдән,
кемгә төшәр аның каргышы?!

Җаныбыздан сөреп җаһилләрчә,
күпме көрәшкәнбез пәрмә-пәр.
Истәлегең булып исәннәргә,
чәчкәң[1] генә калыр, Пәйгамбәр...

## Беренче баб

Акчәчәкләр итәгендә
израп йоклый иркә җил...
Төшләренә, тәшвишләтеп,
керә микән иргәҗел?!

Кәүсәрсулы касәләрдән
ширбәт белән яшь ага.
Әлмисакта әлгәрләрем
әверелгән ... чәчкәгә.

[1] Пәйгамбәр чәчәге (ромашка) күздә тотыла.

Каршысында карачкыдай
кеше-кара күренсә,
каферләрнең карашыннан
күңеленә кер кунса,
иргәҗелем ирексездән,
әйе, гөлгә әйләнгән.
Ярый әле җанын җиргә
иңдерерлек җай калган.

...Ыругдашлар эргәсендә
эргәзембай чәчәге...
Күңелләрнең күләгәдән
күзсенерлек саф чагы!

Гөлстанда нинди генә
хәшәрәтләр яшәми!..
Чәчәкашар чирүенә
чәчәк ни дә, чәчән ни.

Ашамасмы яәҗүҗ-мәәҗүҗ
хуҗаларча хуш күргәч,
милләтләрең мәңге-мәңге
«чәчәк атып» утыргач...

Кешесыман кыяфәттә
кечелекле көч идең;
иргәҗелем, җанкаеңны
нишләп гөлгә күчердең?

Дәверләрнең дәрвишедәй,
чәчәннәрчә дәш әле:
җиңелмени җиребездә
чәчәк булып яшәве?

Гаярьлектән гаҗизләнү
җиңел түгел һичкайчан.
Чәчәгеңне чәнечкеле
итмәгәнсең ичмасам...

Әйтәсеңдер: «Әрем белән
тәрем булып...» — дип син дә.
Кычыткылы кычытканнар
үсә... чәчәк төбендә.

Иргәҗелгә иркә җилләр
сыенганда кич булып,
кисекбашлар очынгандай
итә, изге киселеп.

Сыртларына сурәтләнгән
адәм башы сөяге...
Иргәҗелем, исләремә
төштең инде син тагы!

Күбенешкән күбәләкләр
йөртә икән кем башын?!
Чалымнардан чамалыймын
кәрлә кавем көндәшен...

Чырайсызлар чирүенә
чыкмагансыз чәчрәп тә!..
Чәчәннәрең чәбәләнә
чәнчә чаклы чәчәктә.

Эргәзембай әзәрләнә,
әзәрләнә әле дә.
Чәберчеккә «Чәбә!» диеп
булмый чәчәк хәлендә.

Дөресләнмәс дөньясына
иман нуры чәч, әйдә...
Элгәрләрем әверелә
алмас инде чәчәнгә.

Гөлдән — көлгә,
гөлдән — көлгә —
язган шундый юл гына.
Иргәҗелем, ирексездән
калдың кемнәр кулына?

Кешесыман кыяфәттә
кечелекле көч идең;
җәзаланган җан-тәнеңне
җәһәт гөлгә күчердең.

Күчендеме күңелеңнән
кодсиятле[1] хәзинә?..
Хозурында хыялыйдай
тору үзе хаҗ миңа.

Нәүрүзләрдә, нәүмизләнеп,
синнән саныйм ел башын.
Әлмисактан аерылмас
Хозыр булса юлдашың,
хәкимлектән хәкыйрьлеккә[2]
хәтле төшәр идеңме?
Иргәҗелем, рәнҗетәмдер —
инде гафу ит мине.

Нәсыйхәтче нәбиебез
гаиб әле үзе дә.
«Көтүче»не көтәләрдер
юкса хәзер йөз өйдә.

Күрәзәләр күрсәтешсә,
кайтыр идем яшь чакка!..
Юксылларның юлбашчысы
һиҗрәт кылып чәчәккә,
кешелекнең качкыныдай,
җанын асрап ятмыймы?
Денсезләнгән дөньясында
ят иде шул, ят иде...

[1] Изге.
[2] Буйсынучанлык.

## Икенче баб



— Хозыр Ильяс камчы селтәр иде дә,
карлар-бозлар китә башлый Иделдә!..—

Сөйли миңа күпне күргән Ак әби:
Бозлар белән серле саллар ага,— ди.—

Учак яна салмак йөзгән салларда;
берәү, икәү, өчәү — җитми саннар да...

Көн-төн ага Хозыр Ильяс учагы,
кыйбла якка карый салның оч ягы.

Саллар ага, димәк, илдә иминлек,
учак яна — әле илдә иман нык.

Салчы бабай укып кала салават:
«Кала саен, сала саен сәлам әйт!

Әһле ислам исән-имин Иделдә,
үзем генә агып төшәр идем дә...» —

Әби сүзе әзгә генә өзелә. —
... Сәлам салын көтә-көтә күз кылә.

Нәүмиз итеп, ничә нәүрүз үткәндер?!
Хозыр бабай, салың бәйләп, ут яндыр!

Камчың селтә, көтәм айның бишен дә...
Җаным җайсыз, әллә ничек буш шунда.

Карлар-бозлар киткән саен бул ярда,
саллык сөян бардыр әле Болгарда.

Нәгъръә орып, саллар көтеп торганда,
сәлам салыр иде... Салам торхан да.

Салга сәҗдә кыла алмыйм һай күптән!
Хәбәр бирер рух бит үзең... гаиптән.

...Гариб затны гарәп көтә — аваз юк;
акмый инде изге утлы намазлык.

Иман нурын имдәй эчкән хуш чагым!..
Хозыр Ильяс, җитми җанга учагың.

Инде синнән ничә нәүрүз сал алмыйм.
Хәлләр «изге» — иман бездә — чамалыйм...

## Өченче баб

Көтелмәстән, картлач, көтүеңдә
камчың төшкән ай-һай кыйммәткә!
Кыйссаларга кергән «кыланыш»ың —
хакмы-юкмы — хәзер кем әйтә?!

Кыйнагансың, имеш, көтүеңә
килеп кергән колхоз үгезен.
...Асылырга яисә атылырга
хөкем иткән Хозыр үз-үзен.

Җан-фәрманга чабып, җантимерләр
килеп җиткән җәһәт ГПУдан:
«Коммунистик нәсел калдырасы
үгез җәнапларын кем куган??.»

...Читләшкәннәр бәет чыгарырга
«моның ише корбан» турында.
Залимнәрчә кыскан заманасы —
эчтән кабатланган ырым да:

*Кызыл болыт киләдер,*
*кызыл болыт астыннан*
*кызыл сыер киләдер:*
*мөгезе күккә терәлгән,*
*җилеме җиргә терәлгән;*
*бер имчәгеннән кан килә,*
*бер имчәгеннән май килә.*
*Шуны аша да шуны эч, —*
*Көтүчегә тимә,*
*кагылма!..*

Башлануын шулай башлангандыр
контр көтүченең кыйссасы.
«Корткычланган» рәсүл кыйссасының
бихисаптан күбрәк хыйссасы.

...Җыенының закон җыентыгы —
китап белән башын төйгәннәр.
Дәлилләүче
гамәл дәфтәренә
язып куйган фәлән-төгәннәр...

Бигөнаһны белми Бикчәнтәев,
йодрыкларын эшкә җигәдер.
Кушбугазның күпме кушаматы:
«Молотобоец», «Колун», «Живодер»...

Царизмны сагыныр Царевскийдан
күбрәк таба ахры татымны:
«Беләсеңме, борчый, беләсеңме,
хәтта... кояштагы тап мине!..»

«Шан-шәрәфле» шымчы шәмсебезне
черетер иде, ябып карцерга.
Кодсиятлек тулы күзләреңнән
мәхрүм итәр мәхлук карчыга.

«Имгәтмичә генә иманыңны
куып чыгаралмам өч төндә.
Үтенечең булса, үтерермен
канлы намазлыгың өстендә...

Коммунаның корткыч көтүчесе
күреп калсын миннән игелек.
Әмма...
Мәслихәтче Себер мәсҗедләре
манарасын кисәр иң элек!..

Әҗәлеңнән әүвәл әҗәтеңне
түләп кую монда йоладыр.
...Үгезеннән гафу үтенмәсә,
Гайсә киткән җиргә юл алыр...»

«Тәңребезне инде тәкъдирләмәү
ихтыярың, илаһ хакимдар.
Инсаннарны хәлаль иманыннан
аерырга кемнең хакы бар?!»

Алтатарлы сорау алучылар
алай артык авыз ачтырмый:
«Ачыкларбыз әле ачыкканда,
андый чакта бетләр ач тормый...»

Чиркәүләрдә,[1] имеш, чирләмәссең,
«Череккүл»дә алсаң чирканчык.
...Җәлладлардан җаның җәфаланса,
җәсәдеңә була җир тансык.

Имләүләрне белмәс имансызлык
имәнечрәк икән мең чирдән.
Алтатарлы сорау алучылар
күпкә мәкерлерәк Мөнкирдән.

Ипи-тозга алдап, иблислеген
чыгар гына — чыга нәҗес тә...

Әверелмәс адәм фәрештәгә,
әрекмәннән үсмәс кәбестә.
Имгәтелеп килгән иманыннан
иләмәннәр яза, яза ил.
«Империя зла» ипләшкәндә
изгеләнмәс инде Газазил.

Куркытылган көндәм көнелләргә
илаһ нуры үтми — көбәле.
Ачынулы җаннар ачыкканда,
сиңа, Иблис, ипи күп әле.

## Дүртенче баб

Намус җаннан кадерле

Имансызлык коммунасы
була икән катилле.
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Колымада калымлыга
казыйлардыр каберне.
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Мондый мәхшәр булмагандыр
Октябрьгә кадәрле.
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Консыз-кансыз катилләрнең
күпме сүзе «к о н т р»лы.
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Казаматлы каза килә,
иблис итсә казыйлык.
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Белә җиһан җанны болай
күпләп кырган кай илне?!
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Туганнарым — тузаннарым,
Сезгә — киек каз юлы...
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Сөмсез дөнья, денсез дөнья,
күлмәкләрең, һай, керле.
Шәһитләрнең шәһадәте:
НАМУС ҖАННАН КАДЕРЛЕ!..

## Бишенче баб

Күгәрекле сырхау күнелләргә
Өммелхәер[2] йөри им көйләп.
Бәлаләрдән чыккан балаларын
сайлап ашый тора инкыйлаб.

---

[1] Зиндан сыйфатында файдаланылган чиркәүләрне күздә тотып әйтелә.
[2] Изгелек анасы.

Балаларын ашый инкыйлаб

Көпә-көндез әкият сөйләүчене
тотып ашый икән Ак бүре...
Әүлиядай чынын әйтүләрнең
нигә ачы була ахыры?!

Бүтәннәре белән буташтырмыйк —
изге бүре шуңа базамы?
Исәнгерәү итәр имансызлык
ашагандыр җиде баҗаны.

Болгатасың, диеп, булмастайны,
килешмичә, кемдер йөз чыта.
Абызкаем, бүре авызына
эләкмәгән «артык» Йосыф та.

Балаларын ашый большевизм —
аңышмыйча тора Ак бүре.
«Кызылларча» яза казаматта
Мөнкирләрнең канлы акбуры...

Кассапчысы һәйбәт кәсепләнә,
кыяфәте шундый җиңүле!..
Алыпларын сайлый халыкларның —
Рәсәеңнең киңдер җен юлы.

Лагерьдагы дегет лагунына
ләгыйньлеккә юлны ач кына...
Сөннәтенчә бүлми сөякләрне —
барсын уртак тәре астына!

Пайтәхеттә соңгы пәйгамбәрне
фида итәр фәрман язсалар,
өметсезне имләр Өммелхәер
бөтенләйгә безне ят санар.

## Алтынчы баб

Ачәрвах карары

Гасабилән, кассап, гасабилән,
корбан бәйрәмендә ит төтми.
Тыяргадыр бала төшерүне —
хатын-кызлар бер дә интекми.

Каруланган «кызлар» карыныннан
күпме җаннар китте гарешкә.
Кичекмәстән киртә куелачак
гөнаһ булган мондый гарь эшкә.

Бишьеллыкта тума бирмиенчә,
гыйш-гашрәттә яшәп яталар.
Йөкләмәләр биреп йоклатырга,
тулгаклаудан туймас зат алар.

Корбан кирәк — йола — корбан кирәк,
җиде көнлек балаң булуга.
...Гаиләсенең үтәп гакыйкасын,
атакае барыр бу юлга...

Кысмырланма, кассап, кысмырланма,
киләчәккә карап эшлә син.
Мыскыллама тоткын мөслимәне —
көмәненә кадәм төшмәсен.

Өлешеннән калмас Өммелхәер —
түшәгеннән төшми... түл җыйсын.
Онытмастыр олуг атабызга
балалата ясак түлисен.

## Җиденче баб

Богауларга түзгән болгарларны
сөрдең, гәүр, аттың, астың да...
Күнеккәндер инде көнкүрмешкә
культларының култык астында.

Казаныңны Иван казаматка
әйләндергәч, якты көн нигә?
Карышмасаң Рәсәй карынында,
караңгыга күзләр күнегә.

Мәхлуклашып беткән мәхрүмнәргә
күлмәк кебек якын таш капчык.
Түрәләрсез бер көн торалмагач,
ничек инде шуны ташлап чык?!.

Әлмисакта әллә алыпларга
җәбер-золым җене кагылган?!
Өзәңгегә күнгән өзгәләнми:
дөнья бара, диеп, кай юлдан!.

Коллыгына күнәр колонистның,
түзәр... ирлегендә ир юкка;
ияләләр авыр ияләшә
кисәк кенә килгән иреккә.

Өзәләнеп тормый үзирәккә —
канга сеңеп калган мәхрүмлек.
Төрмәләрдә черетү тәҗрибәсе...—
о, бу эштә бездәй маһир юк!

Хаталыктан хали халыкларны
читлекләргә тыгып илә дә...
«Империя зла» исеменең
исе озак яшәр илләрдә.

Инсаният әле интегәчәк
оныталмыйча мондый «зур ат»ны.
Күзләрендә йөртер Хозырыбыз,
мәңге йөртер канлы сурәтне.

Төрле-төрле Рәсәй төрмәләре
туганнарның булсын төрбәсе.
Тәрҗемәи хәлен төрмәләрдә
үткәргәнгә килер түр башы,
килми калмас...

## Сигезенче баб

### Пәйгамбәрнең Нәсихәгә күренүе

Үлә-үлә, үлә-үлә,
үтелгәндер бар этап...
Хозырыбыз хәзергәчә
пәйда булмый: «Пәри, тап!»

...Кәрәкәшле карьясеннән
күргән аны Нәсихә;
пәйгамбәрне ашамаган
«партбилетлы ач юха!..»

Буташтырган, буташтырган
башны бөек болганыш.
«Танышыбыз» Танайдагы
Шиһабетдин булган ич.

Көтүлеккә «катафалк»
килеп киткән ул көзне...
Үтергәннәр — үгисеткәч
«октябрят» үгезне.

Әбелхәят аермасын
мәңге яшәр шаһиттән...
Нәсихәбез пәйгамбәрне
кырда күреп аһ иткән!

Әйтәсездер: әкиятне
безгә сөйләп торма да.
Ышанмаган — ышанмасын —
бу хәл булган тырмада.

Нәсихәнең нәрсәдәндер
дулап киткән тайлары.
Буып алган дилбегәне
ычкындырыр җай бармы?!.

Бригадирга, боргаланмый,
барган иде эш сорап...
Инде мәнә «кырыкмыш»ы
китте кырдан өстерәп.

Тиле тайның тарпан[1] төсле
тыелмастай җен чагы!
Сызландырып сыдырыла
кызның калкым имчәге.

Тырмаларны тыркылдатып,
томырыла — түз генә.
Ташлы төштән сөйрәлгәндә,
ай-яй, авыр тезенә!

Кыза кызый, кыза кызый:
«Кулым гына таймасын...»
Кинәт кемдер килеп тота
тыелгысыз тай башын.

Җөрьәтләнеп, җиргә җәһәт
төрткәч яшел таягын,
димче дәрвиш, дәшми-тынмый,
тарап тора тай ялын.

Нәүмизләнгән Нәсихәбез
шундый изге йөз күрә!
Нәсыйхәте — насыйбыдыр —
тәнкәенә йөгерә...
«Күрәчәгең күлмәкләрең
күңелеңдә ю, бала!..»

Кырда картлач кинәт калкып,
кинәт күздән югала.

## Тугызынчы баб

### Канлы авыз

Касыйдәләр ява кассапчыга,
кәфенлеге кызыл бәрхеттән...
Әлмисакта, Адәм, илаһыбыз
сине оеш каннан бар иткән.

Октябрьнең таңын аттырганнар,
бастырылып, озы-ын төн чыкты.
Йа раббием, каннан яратылган
күпме кешең канда тончыкты!

Җантимерләр итлек җыйнаштырды,
капылт кына менеп болдырдан...

[1] Кыр аты.

Илаһыбыз, имеш, инсанына
Ата ятратканда «Б у л!» дигән.

Большевизм затлы балыкларны
байтак тотты, дөнья болгатып.
«Хәлифәләр» хәләл халыкларны[1]
һәлакәткә илтте «Б у л м а!» дип...

Канлы авыз

...Кассапчының хәле кәйләнүгә
мордар китеп барыр алдыннан,
ырудашлар ихлас ыргылышты:
«Каным бирәм, аллам, ал миннән!»

«Икеләнми, икмәк, икеләнми,
йөрәгемне әзер бирергә!»
«Бөеремне бирәм боерсалар —
дөнья кимер, әйдә, бер иргә...»

Иләмәнгә, имеш, иярләшкән
илдәшләрне бизәр билге бу...
Кешеләрне колдай кешәнләгән,
«Бардыр — бердер!» диеп, бил бөгү.

Ләгыйньчәлек илне ләббәйкәгә
әйләндереп куйган лабаса.
Куркытылган күндәм күңелләрне
гаҗәпмени һаман ләм басса.

...Кассапчының кәүсәр касәсендә
каннар канга кат-кат катышты.
Макмырлаткан мәхшәр мәкереме —
имсез хаста иртән кан косты.

Күзәттеңме, Хозыр, күзәттеңме,
күргәнсеңдер син дә, Ай кызы:
кәсебеннән качкан кассапчының
канлы килеш калды авызы...

## Унынчы баб

Кадак

Тәкъдирендә адәм тәганәсе
нинди генә хәлгә тап булмый!
Кассапчының табут капкачына
кагар өчен... кадак табылмый (?!)

Пәйгамбәрне, әнә, п ә й г а м б ә р н е
кадаклаган чакта... табылган.
Казаматлар кору казанышын
яулаганда байлык тау булган...

Искәрткәләп тора исәрлекләр
иманлыга илдә сан югын.
Кадаклаган кансыз кадимилек
Таһир белән Зөһрә сандыгын.

---

[1] Совет власте елларында дистәгә якын халыкның юкка чыгуына ишарә.

Табутына йозак табылмаса,
казаларың кайтыр — көт кире.
Кадак кайда, казна, кадак кайда,
кадак?.. Кадалышып киткере!

(Имансызны инде имәндермәс
«катыкул»ы кире кайтса да.)
Казачының үзен кадакларлык
кадак кына бардыр Гайсәдә...

Югалышып калмыйк, юксылларым,
көннәр кичеп кадак очында.
«Атакай»га берне арттырыгыз
кадакланган телләр өчен дә.

«Казаларың» өчен казаматка
«кыстырылган» кырыс Былтырым,
ярыкларын капла, ярыкларын,
өркемичә укып бер ырым.

Табындырган затка табылырмы
табу сала торган табутлар?!
Бәгырендә ята бәндәләрнең
бәхилләшә белмәс таш потлар.

Табындырган затның табутына
сыяр иде илаһ азгын да.
«Катыкул»ның күпме катилләре
атылгандыр «ата» алдында...

Элэкмичэ итче элмэгенэ,
Иблис ибен тапкан анда да.
...Кадакларым юк, дип, казыйларны,
әйдә, казна, әйдә, алдала...

Уянмасын өчен уҗарлыгы,
җирәндереп хәтта... җир өен,
җырлашырга кала җыйнаулашып
бәддогалы бишек җыруын.



## Унберенче баб

*Әлли-бәлли итәр бу,*
*әмеренә китәр бу;*
*каргышларда кыйналып,*
*кыяматкә җитәр бу.*

*Араларны өз инде,*
*бутән ачма күзеңне;*
*төкәндердең тәмамән*
*түбәләмә түземне.*

*...Халык үлеп йоклады,*
*кулы кулга йокмады;*
*«Татлы-тәмле» өнендә*
*аздан ... телен йотмады.*

*Йокламыйдыр өрәгең,*
*кавемеңә кирәк син;*
*күпләр, казып алырга,*
*кайрап тора көрәген.*

*Һәркем туган телендә*
*каргый: «...Кабат терелмә!»*
*Үҗәтләнеп уянсаң,*
*Хозыр йоклар ... тегендә.*

## Уникенче баб

Юылган сурәт

Сусаганмын Хозыр сурәтенә —
күпме күздән эзләп карадым.
Билгесезлек арты билгесезлек
алып килә миңа һәр адым.

Нәсыйхәте истә Нәсихәнең:
«Шәрифлекне күздән шәйлә син...»
«Чалдон»нарда [1] әүвәл чалымлыймын
шомландыргыч шәфәкъ шәүләсен.

Күпмесендә, кадир, күпмесендә,
күпмесендә күрмим... сер затын!..
Юксыллыкта кан-яшь югандырмы
күзләрдәге Хозыр сурәтен?!

Изаланган җанда изгелеккә
урын бармы, аллам — чамала...
Телебездән гөл-бал тамызганда,
күңелләрдә кайный... сумала.

Күңелләрнең төбе күренмәле,
маңгай күзе — ботак тишеге...
Китерсәләр, канлы күлмәгенә
сәҗдә кылыр идем һич югы.

Тәүбә, тәүбә, тәүбә, тәүбә, тәүбә —
сөйлим бугай сезгә кәфер сүз.
Вөҗүденә сыймас вөҗданыбыз
гомер кичерәдер көфүсез [2].

## Унөченче баб

Каргалган авыллар

Каргагансың карьяләрне,
Хозыр хәзрәт, һай ачы:
«Алтмыш өйле Көтернәсең
алты өйгә калсачы!..»

Каргагансың, күрсәтмәгәч
мөсафирга миһербан...
Авылларда алынмады
инде ничә мең корбан!

Салаларны Себеренә
сөрмәдеме советлар?!
Раслагандыр ристаннарың:
илдә... ике Сәет бар.

Рәсмиятле Рәсәебез
белә ничә Сөн барын.

[1] Себергә сөрелгәннәрне халыкчарак атау.
[2] Җисмани тиңдәшсезлек мәгънәсендә.

Күпме авыл төштә күрә
Себердәге сыңарын...

*...Яңавыл,*
*Кушкул,*
*Тугыз,*
*Турай,*
*Ушмы...*

Башкарактыр, башкарактыр
«катр»дагы Көтернәс.
Мөсафирны мәсхәрәләп,
анда әнчек эт өрмәс.

Бормыйлардыр — бирмиенчә
хәерчегә ямаулык...
Каргалмаган карьяләрнең
күпмесендә иман юк!

Сакны — Соктан, Сокны — Сактан
аерырга с ү з җиткән.
Айлап-еллап аерганнар
вөҗданыңны вөҗүдтән.

Тәхеттәге «теләнчеләр»
талап алган барсын да.
Кара көйгән баганалар
гына авыл башында.

Тарханнарны тиранныбыз
таркаткандыр иң элек.
Карьяләрне каргышлавың
ышандырмый, ИЗГЕЛЕК!..

## Ундүртенче баб

Өммелхәер анабызны өнәмичә,
санламыйча «сары йорт»ка сөргәндә,
хәкимнәрнең хикәятен хәтерләдем:
КАРТка киңәш сорап килгән бер бәндә...

### *Киңәш сораучы*

Балачакта, билләһидер, белмәгәнмен,
Ана хакы биниһая зур икән!
Инде нишлим, Нәсыйхәтчем, инде нишлим —
киңәшеңә күңел-калебем зарыккан.

Болайлыгын белгән булса балакае,
йөртер иде иңбашына утыртып...
Атам вафат. Анам гарип. Үзем буйдак.
Ничә еллар яшим инде ут йотып.

Чәбәләнер чәчкәйләрен, читенсенми,
гомеремдә инде ничә кат тарыйм.
Кушучымда тәгам-тәбә куырыйммы —
Ана хакын ничек итеп кайтарыйм?!

## Изгелек әҗере яки бер тулгак хакы

Аяклана алмавының аянычын
әманәттәй әйтте әни ачылып:
«Карусызым! Карыйлыкка карамыйча,
барып кына кайтыр идем хаж кылып...»

Кышның кече кырлачында китканлектән,
карурманнар кичтем, көн-төн көрт ярып:
чайкалмыйча чүллекләрне чакрымладым,
инәемне иңбашыма күтәреп...

Әүлиядай әнекәем әйдәкләсә,
әлхәрәйгә әйләнергә әзер мин.
Биргәнмендер, Бабакаем, биргәнмендер
игелекнең икеләтә әҗерен?!

### Пәйгамбәр

Барсын беләм, балакаем, барсын беләм —
көенечең күңелеңне тырныйдыр.
Вәләкин...
Тормыштагы бөтен, бөтен тырышлыклар
Т а б у ч ы н ы ң ... тулгагына тормыйдыр,
тул-га-гы-на тормыйдыр...

## Нәтиҗәсез эзләү соңында

### Кыяматтә көткән... күрешү (?!)

...Куркытасың күптән күренмичә —
хикәяткә «һиҗрәт» кылдыңмы?!
Хозурыңа, Хозыр, хәзерләнәм,
Көтернәскә кабат кил инде!

Хәйранланма, хәзрәт: хәерчене
хәлле халык һаман яратмый.
Иманнарын Иблис имгәткәндер,
ярлыкасаң иде, йа рабби!..

Күңелләрнең төбе күренмәле —
карьяләргә кереп, калдыр им.
Вөҗданнарын хәләл вөҗүденә
кире кайтарсаңчы, кадирем...

Күрсенәсең бугай Коръәнеңә:
«Минем монда нинди файдам бар...»
...Кыяматтә генә күрешергә
язган мәллә безгә, пәйгамбәр?!

Тупсалардан сөрдек «теләнче»не,
сөмсез сүзебезне йөз әйтеп:

«Күренәсе булма күзләремә,
кит, кит, бабай, йөрмә йөдәтеп!..»

Тукышулар һаман тукталмыйдыр —
тагын нинди кансыз чорда без?
Ярдәмчесез япь-яшь ятимәне
көн дә, көн дә Айга сөрәбез.

Бәддогадан түбән бәндәләрнең
көн дә корбан сорый вак җаны.
Бүртенешкән бүтән бүреләргә
ашатабыз җиде баҗаны.

Алыпларны, аллам, Алыпларны
кара кабергәчә кем ега?
Йомакайлар изге Йосыфыңны
көн дә ыргыталар коега.

Зобанилык Таһир-Зөһрәләрне
тора һаман суга ташлатып.
Күңелләрдән көн дә куалыйбыз
Хозырильяслыкны... таш атып.

Изгелекле Ата эзләренә
өммәтсезлек көн дә көл сибә..
Пакьләндергеч Хозыр пәйгамбәрнең
ясинчысы
яши
кешедә.

*1989—1990*
*Пицунда — Казан — Ялта*

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

## Гариф Ахунов

# ГОМЕР ЮЛЫ

РОМАН



Сугыш ветераннарына орденнар тапшыруны аңа бит колхоз җитәкчесе булганы өчен йөкләмәделәр, үзенең дә фронтовик булганы, унтугыз яшеннән яраланып һәм контузия алып кайтканы, ул гына да түгел, бүгенгесе көндә Югары Совет депутаты булганы өчен йөкләделәр.

Айтуганов ничектер җыйнакланыбрак китте, сүзен үлчәп кенә, кирәклесен генә әйтә башлады:

— Ил картлары, әбекәйләр! Бу җыелышта ветераннарга илнең хөрмәте турында сүз барды. Беренче хөрмәт менә шушы инде: Югары Совет фронтовикларны Ватан сугышы ордены белән бүләкли. Олылый безне. Рәхмәтен белдерә. Менә шулай. Без әле, иптәшләр, льготалар тәртибен белеп бетермибез икән. Авыл белән шәһәр арасындагы аерма турында да уйламыйбыз, ахрысы. Шәһәр җирендә яшәгән ветераннарның сыеры да, сарыгы да юк бит. Сезнеке бар. Шулай булгач, шәһәрдә көн иткән ветераннарга бирелә торган бәләкәй генә итне дә җәлләп утырмыйк инде. Сез, бәлки, әйтерсез, сыер-сарыкны бит аны без үзебез асрыйбыз, үз кулыбыз белән туйдырабыз, диярсез. Бусы дөрес, тик мин бер нәрсәне онытмавыгызны үтенер идем: мал-туарыгызга печәнне бит колхоз бирә. Колхозда бүгенгесе көнне эшләп торучыларга күпме печән бирелә, ветераннарга да шулкадәр үк. Утынны да башкалар белән тигез кайтартабыз. Бу соң, төптәнрәк уйлап баксаң, сез әйткән льгота түгелме? Менә хәзер сезнең үз Советыгыз булды, гозерегез белән шунда мөрәҗәгать итә аласыз. Ул Советка мине дә сайладыгыз, рәхмәт. Бергә-бергә хәл итәсе мәсьәләләр күп, ветераннарның пенсиясе аз, моның белән канәгатьләнеп тору ярамый, Совет исеменнән югары органнарга язарбыз. Ил төкерсә, күл була, ди, башка урыннардан да язсалар, Министрлар Советында ул мәсьәләне карамый калмаслар. Кем ничек уйлыйдыр, белмим, әмма дә ләкин мин үзем шулай уйлыйм. Демократия заманында, үзгәртеп кору дип адым саен трибуналардан

Ахыры. Башы 1 санда.

кычкырган заманда, ветераннар читтә калырга тиеш түгел. Түгел! Инде килеп, идарә ветераннар өчен нәрсә эшли ала, диярсез. Газдан файдаланган өчен — льгота. Моңарчы без газны авылга баллоннарда кайтарттык. Хәзер менә Уренгойдан килә торган газ магистраленә торба тоташтырдык. Ул безгә бер миллион сумнан артыкка төште. Төшсен — колхозчының маңгай тире ул бәһадән кыйммәтрәк. Бер нәрсәне дә кызганмаска. Идарәнең карары шундый. Әнә белгечләр йорт саен ун метр озынлыгындагы газ торбасы куеп йөриләр, тиздән кирпеч кайтартабыз, газ мичене, фундаментка урыннарыгыз көйләнгән булсын. Өйләрегезне тиздән утын яки күмер белән җылытып чиләнмәссез, газ белән җылытырсыз. Монда кайбер иптәшләр сүз кузгатты, колхоз идарәсе ни өчен хисап бирми, диделәр. Без хисап бирергә теләмәгәннән түгел бу, хисап әзер, хисап докладын без идарәдә укып, тикшереп тә чыккан идек инде, әмма хисап бирү көнен партком берәр айга чигереп торырга карар кылды. Моның сәбәбе берәү өчен дә сер түгел, мин инде лаеклы ялга китәрмен, дигән идем. Юк, ди партком, авылларга газ кертеп бетерми торып китмисең, ди. Ә мин коммунист кеше, партком карарына буйсынмый хәлем юк.

— Дөрес!

— Партком акыллы эшләгән!

— Җибәрмибез!— дип залның төрле ягыннан кычкырган тавышлар ишетелде, аннары, һәммәсе бер сүздә икәнне белдереп, дәррәү кул чабып алдылар.

Айтуганов залның тынганын сабыр гына көтеп торды.

— Инде минем сезгә, кордашлар, ил агалары, и шулай ук өлкән апалар, гозерем дә бар. Сез барыгыз да ишетеп тордыгыз, Ветераннар советының уставында, файдалы эш белән шөгыльләнергә, дип язылган. Сүз җир казу, эскерт өю яки урман кисү турында бармый. Яшьләргә акыл бирү, балаларыбызга уңай йогынты ясау турында бара сүз. Моны шулай ук, улымның улын, кызымның кызын балалар бакчасына илтергә, юлда аңа акыллы сүзләр сөйләргә кирәк, дип кенә дә аңларга ярамый. Гаилә тормышының мәгънәсен иң тирән аңлаган кеше — өлкәннәр. Гаиләнең төп максаты — тәрбияле, итагатьле балалар үстерү. Ә бала үстерүнең иң зур мәктәбе — ир белән хатынның, икенче төрле әйткәндә — ата белән ананың бер-берсенә булган дөрес мөнәсәбәте. Халык аны гади генә итеп татулык дип атый. Без, өлкәннәр, яшь гаиләләрне күздән ычкындырмасак иде, гаиләләрне саклау ягында торсак иде.

Менә мин карап утырам сезгә сәхнәдән, барыгыз да матурлар, җыйнаклар, ыспайлар. Өлкәннәрчә җыйнак, өлкәннәрчә ыспай. Арагызда инде бик олыгайганнар да бар, әмма арагызда әле кулыннан эш килерлекләре дә аз түгел. Әнә бер почмакта посып кына Гөлсаимә утыра. Аңа әле 56 яшь кенә. Сау-сәламәт. Колхозның пекарьнясын салып бетереп киләбез. Мин әле аның пекарьняны штукатурлавына өмет баглап торам. Пекарьня никадәр тизрәк өлгерсә, шулкадәр тизрәк ипиле булабыз. Бик олыгаймаганнар бүтән эшләргә дә кушыла алыр иде. Моннан тыш — дәүләткә артык итеңне, сөтеңне тапшыру да бик мөһим. Әнә узган елны Әсмабикә түти ике мең литр сөт сатты дәүләткә, ә без аңа дәүләт бәясе белән унбер центнер бодай бирдек. Бу хәтле икмәкне сугыштан соңгы елларда бер гаиләнең түгел, ун гаиләнең дә алганы юк иде.

Сезгә мәгълүм: бездә картлар йорты бар. Карар кешесе булмаганнарны бушлай асрыйбыз. Анда торганнарның яннарына бару, хәлләренә кереп, сөйләшеп утыру — үзе бер гомер. Күмү йолалары онытылып бара, килен төшерү, өйләнү, туй үткәрүнең халыктан килә торган борынгы йолалары юкка чыга — аларны бары тик өлкәннәр кулы белән генә яшьләргә кабат кайтарырга, тагын да мәгънәлерәк итеп үткәрә башларга мөмкин.

Айтугановның тавышы салмак, чын-чынлап ихтирамлы иде. залдагылар аны тып-тын тыңлады. Әйтергә теләгән уйларының тыңлаучыларга барып җитүе Фәһим абзыйга рәхәт, иртәнге якта күңелендә туган шик-шөбһәләре таралган иде. Ул бер генә мизгелгә туктап, хәл җыйды, кесәсеннән кулъяулыгы чыгарып, маңгаена баскалап, салкын тирне сөртте, аннары — кулъяулыгын янә дә кесәсенә салып, сүзен дәвам иттерде:

— Иптәшләр, сүземнең ахырында минем сезгә бер соравым бар: больница безгә кирәкме-юкмы?

Залдан күмәк рәвештә: «Кирәк!»— дип кычкырдылар.

— Әһә, кирәк дисез, алайса. Ә бездән аны алмакчылар иде. Таулы Төбәктә больница бар, Балдамардагы участок больницасы артык бит, диделәр Казанда. Ә без бирмәдек, саклап калдык аны. Врачлыкка үзебезнең авыл егетләрен-кызларын укытып кайтардык. Ә менә авылыбыздан әлеге больница хакында ямьсез сүзләр язып җибәргәннәр.

— Кем язган?— диде Зөлкарнәй карт.

— Купай Кәлимулласы язган. Ундүрт хат — уйлап кына карагыз.

— Сөбханалла!

— Әбәү җаным, денсез икән?

— Нигә чарасын күрмисез?

— Без әле аңа ярдәм дә бирмәкче идек, профсоюз каршы килде, эшләрлек әле ул, дөньяны бозып ятмасын, диде.

— Бирмәгез ярдәмне ул тәрегә!

— Ачтан катсын!

— Бүлнискә дә салмагыз, алай эшәкеләнгәч.

Айтуганов залдагыларның ярсуын тыңлап бетерде.

— Больница мәсьәләсендә безнең фикерләр бер үк икән. Әле генә әйтелгән ваклыклар, хөсетлелекләр ошамый миңа. Картларга врач кирәк. Дөресме? Дөрес, дисез. Жалучылар кирәкмидер дип беләм. Картлар йорты — сезнең кулда. Кайчагында анда ике кеше була, шул ике кеше дөнья бетереп талаша. Ә миңа, казый булып, аларны килештереп йөрергә туры килә. Нәрсә җитми безгә? Нигә бер-беребезнең тормышын ямьсезлибез? Сүзем шул: хокукларыбызны да, бурычларыбызны да өйрәнеп бетерик. Ветераннар Советы аркылы үзебезгә дә, колхозыбызга да файдалы эш эшлик.

Шәлле бүрек кигән Пәтихәттәй кул чабуларны да уздырып, җилкенеп кычкыра:

— Энем җаным, Фәһимулла, китә күрмә бездән. Ходай сиңа берүк сәламәтлек бирсен. Теләктә торырбыз. Әнә шул газын кертканче генә булса да китмә, җәме.

## 3

— У-уу, Данияр Дәминев! Нинди җилләр ташлады безнең якка корреспондент халкын? Сезне бит әле Мәскәүдә, үзегезнең гәзиттә бер-ике ай утырып эшли дигәннәр иде. Ничек килеп чыгасы иттегез?— дип тәнәфес вакытында ихлас бер киң күңеллелек белән сәламләде корреспондентны Айтуганов.

— Әнә шул Мәскәүдән туп-туры сезгә килдем инде, өйгә дә кереп тормадым. Гәзитләр кара буяудан туйды, Сталин да, Брежнев та — барысы да туйдырды. Үзбәкләр касәфәтеннән дә ардык, Чернобыль вакыйгаларыннан да. Гарык без. Яңарак материал эзлибез, Фәһим абзый. Миңа шундый задание бирделәр, дегеткә буялган материал алып кайтма, хуш исле материал алып кайт, диделәр. Шунда мин председатель Айтугановны искә төшердем. Барыйм әле, мин әйтәм, карыйм әле — нилэр җимертеп ята икән минем күптәнге танышым... Килсәм күрәм, Айтуганов идарәдә юк, ветераннарга акыл өйрәтеп ята,

имеш...— Данияр, калын сары чәчләрен артка чөеп, көлеп җибәрде.

— И Дәминев, сөйләп тә карыйсыз инде, телегезгә шайтан төкергән!— дип, Айтуганов та көлде.

— Шайтан минекенә түгел, сезнекенә төкергән, Фәһим Сабирҗанович. Чатлы-ботлы агач кебек, кирле-мырлы сөйләгән картларны нишләттегез, сары май итеп эреттегез бит, ә? Культура сараеның түшәме җимерелә дип торам — ничек кул чаптылар! Төгәл сөйлисез, киңәшеп сөйлисез, сезнең төсле итеп Үзәк Комитетта да сөйли алмыйлардыр...

— И әйтеп тә карый инде тәмле телле татар!— диде Айтуганов, күңеле булып.— Йә, ярый, кайчан килдегез? Күпмегә килдегез? Урнаштыгызмы әле, юкмы?

— Килүен бүген килдем. Беркая да урнашмадым әле. Борчылмагыз, дүрт-биш көнсез китәргә исәп юк, корреспондент кисәгенә бирәр аулак бүлмә табарсыз бит?

— Табарбыз. Хәзер бирәр чынаяк чәй эчеп алыйк та колхоз яшьләренең концертын карыйк.

Айтуганов чәй янында парторг Сираҗиевны, авыл Советы председателе Мәгъсумовны корреспондент белән таныштырды.

— Менә, егетләр, үзешчәннәрне яхшы әзерләмәгән булсагыз, беттек, Дәминевнең күзе очлы, каләме үткен, «Советская Россия»дә карикатурагызны күрергә әзер торыгыз,— диде.

Концертны бергәләп карадылар.

Көчле ут белән яктыртылган сәхнәгә бала итәкле җете сары күлмәк, зәңгәрсу камзул, чигүле читек кигән, ике толым кап-кара чәчен күкрәге өстенә кайтарып салган сылу кыз чыгып басты.

— Оһо! Әнә нинди гүзәлләр дә бар икән әле авылда!— дип әйтеп салганын сизми дә калды Дәминев.

— Әкрен, Айтугановның килене ул, Сания,— диде Сираҗиев.

Санияне сәхнәдә күреп дулкынланган тагын бер кеше бар иде залда — кайнанасы Сөембикә. Кием килешә соң килененә! Матур төсләр, ут яктысында балкып, аның нәфис буй-сынын, алсуланып янган бит алмаларын, томыраеп карый торган зур кара күзләрен ачып җибәргән иде.

— Һай аллам, бигрәкләр дә матур инде күлмәге! Андый кием киертсәләр, мин үзем дә, билләһи дип әйтәм, җитмеш алты яшем дип тормасыем, сәхнәгә чыгып, бер күренеп төшәриием,— дип пышылдады аның күршесендә утырган Бибиҗамал карчык.— Шулаймы, Сөембикә?

— Белмим шул,— диде кайнана.

Аның күңелендә борчылу бар: килене, кичен балалар бакчасыннан кайткач, берничә көн рәттән төнге уникеләргә хәтле Муса Җәлилнең «Вәхшәт» шигырен ятлады. Сөембикә ханым, режиссер булып, тавышны кайчан көчәйтергә, кайчан әкренәйтергә, кайчан шом салырга икәнен өйрәтеп торды. Өйдә чакта Сания бик яхшы сөйли иде. Ләкин... өйдә бит ул. Анда сиңа кырыкмаса-кырык күз текәлеп карамый. Ә монда җиде авылдан җыелган халык. Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, корреспондент та килгән икән әнә. Сөембикә ханымнардан ике генә эскәмия алда, Фәһимнәр, Мөхәммәтләр, Мәгъсумовлар белән утыра. Алга иелә төшеп, сәхнәгә төбәлгән, килене Сания аны күреп каушап калмаса ярар иде.

Сөембикә ханым борчылып утырган арада Сания сәхнәнең алдынарак килде, микрофонга сөйли башлады.

...Күктән кояш карый. Елгада дулкыннар шаулый. Ана кочагында бала үрсәләнә. Җибәр, әнием, мине, җибәр, минем уйнасым килми. Түз, балам, хәзер бетә, түз, балам. Исерек күзле майор балага писто-

леттан ата. Баланың муеныннан кан агып төшә. Ана белән сабый авалар. Кояш, син шаһит бу вәхшәткә... И дөнья, мондый вәхшилекнең азагы булырмы?!

Сания, сөйләп бетергәч, зал беркавым онытылып торды: гаепсездән ауган, нахакка һәлак булган ана белән сабые аларның йөрәк бәгырьләренә барып кадалган иде. Исләренә килгәч, дәррәү кул чаптылар. Озаклап, дулкынланып алкышладылар сөйләүчене...

Бер кыз молдаваннар биюен биеде. Саллы нык адымнары, таза гәүдәсе белән сәхнәне тутырып йөрүе корреспондентка ошагандырмыюкмы, Фәһим Айтугановка ул бик ошый, менә шундый тап-таза гәүдәле, сәламәт рухлы кызлар колхоз йөген тартып баралар, калага китеп, үз дәрәҗәләреннән түбән эшкә ялланмыйлар.

— Бу кыз кайда эшли?— дип сорады Дәминев.

— Ындырда. Ашлык кабул итә.

— Сәхнәгә дөрес чыгаргансыз.

— Ник алай дисез?

— Кычыткан чыпчыгы кебек эшсез сикергәләп йөрүче нечкә сыйраклар ошамый миңа. Эшен дә эшли, кирәк икән, күңел дә ача белә торган яшьләр кирәк. Фамилиясе ничек әле. Ясәвиевамы?

— Әйе.

— Ә сезнең килен кайда эшли?

— Балалар бакчасында. Тәрбияче.

— Улыгыз аның клубта вакыт уздыруына каршы килмиме?

— Бездә принцип бер генә: башкаларны кузгатыйм дисәң, үзең башлап йөр. Минем кызым авыл мәктәбендә укыта, олы улым «Яңа көч» колхозында председатель...

— Ничек председатель? Аны бит инде төшергәннәр.

— Ә сез каян беләсез?

— Мин шуның өчен килдем дә инде сезгә,— дип әйтеп салды Дәминев.

Айтуганов югалып калды: менә нәрсәдә икән хикмәт! Шул минуттан башлап, Фәһим абзыйның концерт каравы карау булмады. Ул Дәминевкә әллә ничә сорау бирде. Аларга янәшәдә утыручылар карангалый башлады. Айтуганов сөйләшүдән туктарга мәҗбүр булды. «Улымны төшерә алмадылар. Әмма секретарь аңа ел буе канығачак»,— дип әйтәсе бик килгән иде, тыелды. Аңлатып торырга кирәк булачак, ә сәхнәгә инде яңа бер башкаручы чыккан иде.

Мөлаемлыгы ташып торган яшь кенә кыз. Өстендә ап-ак күлмәк, төз матур аякларын балкытып торган ак туфли, башы яланбаш, чәчләре аксыл-сары, иң өстенә сибелгән. Ул сәхнә алдына килеп басуга, халык җанланды, гөр килде.

— Нигә халык бик җанланды?— диде Дәминев, сөйләшергә ярамаганын онытып.

— Тыңлагыз, актыктан әйтермен,— диде Айтуганов.

Кыз җыр башлады. Аның көмеш тавышы Дәминевны шундук үз дулкынына бөтереп алды.

> Ялгыз көймә бөтерелә
> Һәм чайкала Иделдә.
> Зур дулкыннар күтәрелә
> Күңелемдә минем дә...

Зал аһ итте.

Сәбәбе залда утыручыларга ачык: Лираның ире узган елны асылынып үлде. Хатын авырлы булып калды. Баласын ире үлгәч тапты. Чишмә суларыдай чылтырап, табигый булып ага торган тавышын авылдашларыннан кызганмыйча, инде ничәмә еллар җырлап килгән

бу моңсу бала, ире фаҗигале үлем белән дөньядан китеп баргач, ел буе клуб тирәсенә чыкмады, авыр кайгысын йотып, сабыр гына яшәде — авыл больницасында шәфкать туташы вазифасын башкарды. Бүген шул фаҗигасыннан соң беренче мәртәбә халык алдына чыгуы. Кешеләр ул җырлаган җырны байтактан ишетеп киләләр, радиодан да, сәхнәдән дә тыңлыйлар, ләкин әле бу тикле дә дулкынланганнары юк иде. Бүген Лира аларга отып алган җырны түгел, гүяки үз фаҗигасын сөйли иде. Моңлы күкрәк тавышын кешеләр өзлексез тыңларга, бер дә аерылмыйча тыңларга әзер иделәр.

Зал тынган, зал да җырга йотылган иде.

— Ник шулай?— диде Данияр Айтугановка.— Ни өчен халык моны шулай кабул итә?

— Ире үлде аның. Фаҗигале үлем белән. Бик яратышып торалар иде.

— Ах, шулаймыни?! Күреп сөйләшергә буламы аның белән?

— Әкренрәк. Сабыр итик.

Лира инде икенче җырын башлаган. Залда үзәкләрен өзеп, «Бөтен нәрсә сине хәтерләтә» дигән җыр, сөйгән ярын мәңгелеккә югалткан кешенең сагыш җыры агыла иде...

...Данияр Дәминев юкка-барга җебеп төшә торган егет түгел. Тормышны ул көрәш дип карый. Ә көрәштә җитез акыллы, максатчан кешеләр җиңә. Данияр шундый кешеләрне эзли.

Ихтирамга лаек журналист булып өлгергәнче аңа байтак кына җәфа чигәргә туры килде.

Данияр үги әни кулында үсте. Экиятләрдә сөйләнә торган убырлы карчык түгел иде аның үги әнисе. Фронтовик Хисамга ул аның беренче хатыны баладан үлгәннән соң чыкты, ә үзе аңардан кыз бала тапкач, сугыш яраларыннан хәлсезләнгән саңгырауланып калган Хисамын җирләде. Хисамның ике улы — Урал белән Данияр, Хисамнан тапкан Рәмзия — өч бала берьюлы Хәтимәттәй өстенә өелеп калды.

Уралга да, Даниярга да уку әллә ни тәтемәде — җиде класс белән калдылар. Әниләренә ярдәм итәргә кирәк иде.

Урал үсте, арка-җилкәсе калынайды. Кызларын кияүгә бирми калудан курыккан солдаткалар: «Йа ходаем, кемнәр бәхетенә шулай баһадир булып үсә икән бу бала?»— дип, аңа сокланып карыйлар иде.

Унтугыз яше тулган көнне Уралны флотка алдылар, ә ул, анда өч ел хезмәт итеп, безкозырка тасмаларын җилфердәтеп авылга кайтып төште.

Шул ук елны флотка Данияр китеп барды.

— Кара инде, ә? Монысының бит буе да әллә кем түгел, барыбер флотка алалар. Хисам балаларының үзәге таза булып чыкты,— дип баш селкеп тордылар Алмалы кешеләре.

Үги әнисен, абыйсы белән сеңлесен сагынып, атна саен хат язып торды Данияр. Абыйсы аның бер генә хатын да җавапсыз калдырмый, тик ул бик кыска яза: яхшы хезмәт ит, әниебезгә кызыллык китермә, янәсе. Ә бишенче класста укыган сеңлесе Рәмзия, абыйсы Уралдан аермалы буларак, хатны бик иркенләп яза, еракталы бәләкәй абыйсына авыл хәлләрен төкми-чәчми җиткерә, ә бу исә Даниярның туып-үскән авылы Алмалыны барлык матурлыгы белән, чишмәләре һәм су буе таллары белән күз алдына китерергә җитә кала, сеңлесеннән хат алган көн Данияр өчен бәйрәм була иде.

«Бәләкәй абый, сине бик сагындык, бик тә күрәсебез килә. Хатыңны мәктәпкә алып барып укыган идем, укытучылар кулданкулга йөрттеләр. Әдәбият укытучысы Һидият абый әйтте: «И дә килештереп язган, уку гына эләкмәде балакайга, уку да эләккән булса, язучы чыккан булыр иде Даниярдан»,— ди. Абый, тагын да яз шун-

дый матур хатларыңны. Синнән хат алган көнне әни бик сөенә, хәтта аягы сызлаганны да онытып тора. Яз, яме, Бәләкәй абый»,— дип ялвара Рәмзия. Хатның ахырына олы абыйсы Урал авылда җырлап йөргән җырларны язып җибәрә.

Карурманнар якты була, шомырт чәчәк атканда,
Төнлә төшләремдә күрәм, югалтам таң атканда.

Ай булмагач, төн караңгы, кырларда кунам инде,
Сине уйлап, ямансулап, дивана булам инде.

Данияр аңлап ала, абыйсы гашыйк булган. Тиктомалдан кеше җырлап йөри димени? Шомырт чәчкәләре, урманнар, таңнар белән саташа димени? Берәр нечкәбиле аның күңеленә кереп утырган. Җырлар шуны әйтеп тора, җырны алдый алмыйсың. Данияр сеңлесенә хат язган чакта әйтә, сеңлем-матурым, үскәнем, тагын яз әле җыр, ди. Авылда чакта исе дә китмәгән, аларны бар дип тә белмәгән кеше, хатларда килгән җырлардан дулкынлана... Ихтимал, авылын сагынуыдыр. Бәлки, алай гына да түгелдер...

Сабый чакта ук аның җанын урталай телделәр. Биш яшендә аны үги әнисе калага илтеп балалар йортына бирде. Ул анда русча сөйләште, русча укыды. Аннары үги әнисе Даниярны Алмалыга алып кайтты, авылда ул укуын татар телендә дәвам иттерде. Алмалыдан әллә кайларда, диңгез дулкыннарын ярып барган корабта аның исенә сеңлесе язган хатлар, алардагы җырлар килеп төшә икән, аның күңелендә рус теле түгел, әткә-әнкәсенең теле уянган дигән сүз.

Аларның хәрби бурыч үтәргә чыккан кораблары, бер атнадан тагын яр буена кайтып, матросларны коры җиргә чыгаргач, Данияр белән могҗиза булды. Шәһәрнең кечерәк кенә бер бакчасында ул күке кычкырганны ишетте. Икенче җәй инде аның күке тавышын ишеткәне юк иде. Диңгез дулкыннары арасына каян килсен инде күке — анда бит акчарлаклар гына чыелдап балык аулыйлар. Анысы аның көн саен була торган гадәти күренеш. Ә күке? Күкене ул авылда, анда да урманда гына кычкыра дип белә иде. Баксаң-күрсәң, шәһәр бакчасында да кычкыра икән күке, һәм ул, җитмәсә әле, сеңлесе Рәмзиянең әнисе җырлаган җырларын, хат белән килгән җырларны күңелдә яңарта иде:

Кычкырмачы, күке, әй каршымда,
Кычкырсана агач башында.
Кычкырмасаң да, күке, әй каршымда,
Хәсрәтем күп башымда...

Данияр флотта туган-үскән авылының җырларын ишетергә, колагы белән түгел, җаны белән ишетергә өйрәнде.

Бүген Лира җырлаган сагышлы җырлар аның әнә шул флоттагы ямансу вакытларын кабат исенә төшерде. Җырның кодрәтенә әллә нинди дөньяларны тергезә алуына ул исе китеп, онытылып утырды...

## 4

Айтуганов корреспондент Дәминевне колхозның кунак йортына үзе илтеп куйды. Зур гына өч бүлмәдән торган агач йортта хәзергә беркем дә юк. Әмма аның мичләре ягылган, кунак йортын карап торучы Нәсимә җиңги, председатель боерыгын үтәп кичкә итле аш, бәрәңге боламыгы, тозлаган кәбестә ише нәрсәләрнең барысын да әзерләп киткән иде.

— Өйдә әле минем мәшәкатьле чак, газ кертү өчен махсус мич чыгарып йөриләр. Шушында без тамак ялгарбыз. Аннары бирегә аулак, сөйләшәсе сүзне дә икәүдән-икәү генә сөйләшеп булыр,— диде Айтуганов.

Икесе дә тормышта тәпсерләп торуны өнәми торган гади кешеләр, бергәләп, әллә ни арада табын әзерләделәр. Әчкәреге бүлмәдән Фәһим абзый бер шешә, ике рюмка табып алып чыкты.

Бер-ике рюмканы тотып, яңа иттән пешерелгән җимле ашны сугып куйгач, Айтуганов сүз башлады:

— Концерт барган чакта вәземләп сорашу уңайсыз иде, Данияр. Корреспондент халкының вак-төяк өчен генә кузгалмаганын беләм мин. Әйтегез әле: килүегезнең төп сәбәбе нәрсә?

— Башка кешегә булса, чишелмәс идем, Фәһим Сабирҗанович. Сезнең сер саклый торган кеше икәнлегезне белгәнгә күрә әйтәм: мин улыгыз Галинур мәсьәләсе буенча килдем.

— Әллә обком җибәрдеме?

— Киресенчә. Чукмарлы кешеләре, бер йөздән артык имза куеп, безнең газетага хат язганнар. Обкомны гаепләгәннәр.

— Райкомны түгелме?

— Юк шул. Нәкъ менә обкомны. «Өлкә комитеты юл куя, шул сәбәпле Таулы Төбәк райкомы колхоз җитәкчесен кимсетә, мөстәкыйль эшләргә ирек бирми», дигәннәр. Мине бирегә «Советская Россия» җибәрде. Хәлләрне өйрәнеп, мәкалә язып кайтырга.

Айтугановның йөзеннән, күзгә күренеп, яктылык узды.

— Ә шулай да... гаделлекне табарга теләүчеләр бар дисез, ә?

— Гаделлекне табарга теләүчеләр бар гына түгел, күп алар, Фәһим Сабирҗанович. Тик хәзергә көч һаман да аппаратчылар кулында әле.

Айтугановның Дәминев белән иркенләп, җан ачып сөйләшү теләге туды.

— Данияр, тагын бер сорау бирсәм, гаеп итмәссезме?— диде ул, корреспондентка дустанә карап.

— Гафу-мазарларны бер читкә куеп торыйк, Фәһим Сабирҗанович. Мин эш эшләргә килдем. Шулай булгач, күпме телисез, нәрсә телисез — барысын да сорагыз. Минем дә сездән сорыйсы сорауларым күп бүген. Рәхмәт, вакыт соң дип тормадыгыз, олы башыгызны кече итеп кердегез. Тыңлыйм сезне, әйтегез соравыгызны?

— Сезне, Данияр, әйтик, газета Галинур эше белән җибәргән. Ягъни «хат юлга чакырды» дигән рубрикага мәкалә язарга. Нигә сез туп-туры Галинурга бармадыгыз, миңа килдегез?

— Секрет фирмы!— дип көлеп җибәрде Данияр, аннары кинәт җитдиләнде.— Һәркемнең үз алымы. Минем урында башка берәү булса, ихтимал, эшне Галинурдан башлар иде, кем белә, бәлки, туп-туры Таулы Төбәк райкомына килеп, Тимергалиевне допрослар иде. Ә мин бөтен нәрсәнең нигезле, төпле булуын яратам. Минем өчен улы Галинур турында әтисенең ни уйлавы мөһим. Райком үз мәнфәгатен кайгыртa, яшь җитәкче Галинур Айтугановның да, һичшиксез, үзен яклыйсы, кимчелекләрен танныйсы килмәве мөмкин. Ә менә сез, кырык еллык партстажы, шундый ук эш тәҗрибәсе булган кеше, улыгыз хакында йөрәгегезгә таянып, ни әйтә аласыз? Объектив, бары тик объектив бәя генә! Бу минем өчен бик кирәк. Мин язасы мәкаләнең юнәлешен бүген шушы сорауга ничек җавап бирүегез билгеләячәк.

Эшләрнең шундый борылыш алуы Айтугановны тирләтеп җибәрде.

— Бер сүз белән, бәлкем, мин бу сорауга җавап та бирә алмам, Данияр. Үз тормышымнан бер кыйсса сөйләп карыйм. Кем белә, бәлкем, шул сезнең сорауга җавап булып чыгар...

1944 елның җәендә мин, контузия алып һәм кулым яраланып, фронттан кайтып киләм. Ике палубалы ак пароход, ике йөздән артык яралыны төяп, Ока елгасыннан Горький каласына кайта. Пристаньнар безне кабул итми, Горький шәһәренә бишме-алтымы чакрымнар кала, безнең пароход елга уртасына якорь салды. Ярадылар да, пароход командасы да төнлә йоклады, таң атып, кояш чыга башлаганда пароходта купкан ыгы-зыгыга уянсак, ни күрәбез: безнең өскә баржа килә, печән төягән, печәне дөрләп яна.

Ара ерак түгел, команда якорьны күтәреп өлгерә алмаячак. Баржа туп-туры килә.

— Ә баржада кеше юк микәнни?

— Юк. Суга сикергәннәр булса кирәк. Команда хәвеф хакында беркемгә бер сүз әйтмәсә дә, паника бик тиз таралды. Шау-шу купты. Бетәбез! Менә шунда бер могҗиза булды: яр буенда ялгызак кара катер тора икән, каяндыр бер елгачы килеп чыкты, катерга сикерде дә алып китте тегене. Якынлашты буксирга, борыныннан әкренләп этә-этә барып, аргы як ярга алып китте бу моны. Алып китте, илтеп җиткерде, катерга ут капкач, үзе суга сикерде.

Ишеткән һәм укыганнарыннан бик тиз нәтиҗә чыгара белүче Дәминев:

— Бер кеше, димәк, бөтен бер пароходны һәм ике йөз яралыны коткарып калды?— диде. Бераз торгач, өстәде: — Сез, бер председатель бөтен бер колхозны коткара ала, әгәр райком секретаре бөтен бер колхозны коткарырдай председательнең кем икәнен танымый икән, бөтен районны җимерә ала, димәкче буласыз түгелме?

— Бик дөрес. Менә шуннан минем председатель улым Галинурның һәм райком секретаре Тимергалиевнең кем икәнлеген үзегез чамалап карагыз инде, мин сезгә бүтән бер сүз дә әйтә алмыйм...

5

...Кунак йортының биек тәрәзәсеннән идарә бинасы күренә. Бинаны ак кирпечтән салганнар. Дүрт колоннасы бар. Алар гүяки бөтен йортны тотып торалар. Колхозны тотып тору өчен дә колонналар кирәк.

Шул фикер Даниярның күңеленә кереп утырды да, тәнгә кадалган шырпы кебек, чыкмый гына бит: кем икән колхозларның терәге, колонна баганалары?..

Данияр, куен дәфтәрен алып, шул сорауны язып куйды.

Кунак йорты өч бүлмәле. Иҙәнендә келәм, караватлар шәһәрчә — полировкалы. Тумбочка өстендә — төсле телевизор. Ни өчен шулай затлы бу кунак йорты? Килгән-киткәннәрнең яшәве җайлы булсын өченме, әллә, менә без нинди мул яшибез, дип башкаларга күрсәтер өченме?

Кунак йортының стеналары нараттан, бүрәнәләре тигез итеп юнылган, шомартылган, матур итеп мүкләнгән. Стенага да, түшәмнәргә дә буяу-мазар тимәгән. Агачның тынга иркен, ягъни сулыш ала икәнен белеп эшләгәннәрме, әллә буяу кызганганнармы? Монысы икенче сорау. Юк-бар сорау түгел. Чөнки кунак йортлары булмаган колхозлар хәзер сирәк, тик алар таза бүрәнәдән салынган булсалар да, түшәмнәрен акка, бүрәнәләрен, идәннән башлап, дүрт-биш ниргәгә хәтле сарыга буяган. Җәйге эссе көннәрдә андый йортларда сулыш кысыла, ярты сәгать эчендә шабыр тиргә батасың...

Шуларны уйлый-уйлый, Данияр электр бритвасы белән озаклап кырынды, битенә одеколон сипте, җылы свитерын киеп, тунын алырга гына үрелгән иде, ишектән өстенә сырма кигән, башына күперәп

торган мамык шәл бөркәнгән илле яшьләр тирәсендәге [illegible] кына бер җиңги килеп керде.

— Сөбханалла, кунак килгән икән! Менә мин тушы йортның караучысы-багучысы булам инде. Исемем — Нәсимә. Синеке ничек? Данияр? Матур исем биргәннәр әтиләрең. Яшьләрнең исеме хәзер Рабирт та Альбирт, Марыс та Ганыс. Үзебезнең татар исемнәре дә бик матур кана, татарның шул инде, тиле таш җыя дигәндәй, яңгыравыклы, колак ишетмәгәнне куйдырырга азаплана. Гайфетдин белән Сәйфетдин дип куйса, баласының укасы коелыр дип курка. Син, Данияр энем, үпкәләмә тагын, күп сөйләшә торган апаны биргәннәр икән, дип. Ирем Исхак аз сүзле минем. Бер матурга бер ямьсез, бер баллыга бер тәмсез, дигәндәй, дөнья бизмәне үзе тигезли ул. Иртән ничәдә, көндез ничәдә, кичен ничәдә тамагыңны туйдырырга икәнен әйт, төп-төгәл үтәрмен, ач йөретмәм, әмма мин белеп торырга тиешле, ни өчен дибәйтеп әйткәндә, мин кунак йортын гына түгел, идарә йортын да карыйм әле.

Бик кызу сөйләгәннән соң ул аз гына тын алды да тагын тезеп китте:

— Казаннар килгән дигәченнән йөгереп төшүем ие әле. Барлык эшеңне әнә шунда бер бит кәгазьгә язып, поезд расписаниесе кебек, ишеккә кадаклап куй: кайчан мичкә ягасы, кайчан йоклысы, кайчан торасы, кайчан урамда йөрисе... Ә мин йөгердем, наныем, Казаннан килгән осталар өебезгә газ миче чыгара, Исхагым фермада, терлекләре янында, ә миңа суын-мазарын җылытып, кирпечен биреп торырга кирәк. Мин киттем, язып калдырырга онытма, яме.

Данияр, авыл кешесенең ихласлыгыннан, беренче мәртәбә күргән кешесенә бөтен тормышын сөйләп чыга алуыннан үз алдына елмаеп, Нәсимә апа әйткәннәрне бер бит кәгазьгә вәземләп язды да, ишекнең коридор ягынаябыштырып, урамга чыкты.

Трактор табаннары белән тигезләнеп, җәяүлеләр киләп сарып йөрүдән шомарып беткән кышкы юлдан атлады ул. Юлның ике ягыннан биек рәшәткә-койма сузыла, рәшәткәнең эчке ягына күккә-биеккә ашкан тупыллар тезелеп киткән — яшь әле алар, гигант җилпәзә сыман тоелалар. Алма бакчасы җитмеш тугызынчы елның зәмһәрир суыкларыннан корыган һәм төбе-тамырлары белән йолкып ташланган зур япанда кул-аяк тимәгән кершән төсле ак кар ята, шул карны ярып, телогрейкалы унлап ир-ат бүрәнә юанлыгы торба сөйриләр. Бу инде шул Нәсимә җиңги әйткән газ торбалары. Уренгойдан килә торган газны Айтуганов кырык чакрымнан, төп магистральдән Балдамарга китертә. Шуңа бер миллион акча тоткан. Бу сүз инде Казан түрәләренең теленнән төшми, шуны, әбиләр тәсбих тарткан төсле, җыелыш саен әйтеп торалар...

Телогрейкалы егетләр сузган торба белән кунак йортындагы пөхтәлек ничектер Дәминевның күңеленә янәшә урнаштылар. Болар барысы кешеләргә уңайлы булсын өчен эшләнә. Шулай булмаса, Фәһим абзый — инде алты дистәсен тутырган кеше — нигә шул торбалар белән чиләнсен икән? Эшләсен эшләгән, тартасы йөген тарткан — санаторийларга барып, тиешле-тиешенчә ял итеп кенә ята алмас идемени? Аның колхозына бит болай да газны баллоннар белән Казаннан ташып торалар, шуның өчен идарә махсус машина бирә. Өйләрнең күбесен күмер ягып җылыталар, батарей куйганнар, тагын ни кирәк? Юк, ул һаман риза түгел, аңа һаман нәрсәдер җитми. Әнә бит ветераннар җыелышында да газ кертүне, больницаны, картлар йортын кузгатты. Киңәш-табыш корды. Күрәсең, Айтуганов бернәрсәне дә күз буяу өчен, әйбәт булып күренер өчен эшләми, ихластан эшли...

Дәминев, рәшәткә буена сөялеп, торба сөйрәүче егетләрне озак кына күзәтеп торды, аннары аның уйлары кече Айтугановка — кол-

хозыннан китәргә тиешле Галинур Айтугановка барып тоташты. Анысы да булсынга йөриме? Әллә анысының үз исәбе үзендәме? Халык әйтә, оясында ни күрсә, очканда шуны куа, ди. Унсигез яшенә тикле Галинур әтисе йортында яшәгән, Казанның Авыл хуҗалыгы институтында укыган чакта да гел кайтып йөргән әтиләренә. Әтисе аңар нинди киңәшләр бирде икән? Монысын Галинурның үзеннән сорыйсы булыр. Данияр, блокнотын алып, аны да язып куйды. Галинурны Чукмарлы кешеләре урыныннан алдырмыйча саклап калганнар. Чукмарлының усал дигән даны күптән билгеле. Ат караклары белән күмер яндыручылар, зимагурлар белән лашман тартучылар Чукмарлыдан чыккан. Таулы Төбәкнең өч мәчетен салдырган алпавыт — Чукмарлыныкы. Патша заманында Чукмарлы мәдрәсәсен мыскыллаган, анда погром оештырган өчен барлык төбәктән иганә җыеп Санкт-Петербургка хәтле барып җиткән Бикмурза да — шушы авылныкы. Чукмарлы ямчылары Таулы Төбәк белән Казан арасында ат куганнар.

Чукмарлы халкы Галинурны җибәрмәс өчен җан талаша икән, бернинди үгетләүләргә, куркыту-янауларга да бирешми икән, моның сәбәбе ачык: димәк, Галинур Чукмарлы халкына кирәк. Шуны да аңламаслык җитәкче микәнни Тимергалиев?

Үзләрен һәрвакыт хаклы дип санарга күнеккән кешеләр коточкыч, ди Толстой, алар гаепсезләрне, изгеләрне хөкем итәргә, хәтта ки Аллаһы тәгаләнең үзен дә гаепле дип санарга батырчылык итәләр, тик алар дигәнчә генә булсын да өстенлек алар ягында калсын. Мондый өстенлек кемгә кирәк? Бигрәк тә хәзерге төсле ачыктан-ачык сөйләшә торган бәйсезлек заманында...

Данияр, Дәүрән елгасы аркылы салынган күперне чыгып, тау башына күтәрелә башлады. Үр өстеннән карыйсы килә иде аның авылны. Колагына кошлар чыр-чуы ишетелде. Туктап тыңлап торды. Каян килә бу чыр-чу? Әле яз җитмәгән, февральнең уртасы гына. Башын боргалап, кошлар тавышын эзләде. Тапты. Тау битендәге искерәк бер йорт каршында кәкре-бөкре булып үскән карт өянкегә чыпчыклар җыелган, кояш җылысын сизеп, шулар дөнья куптара икән. Кыегыннан күккә сузылган антенна колгасының аратасына ике карга кунган, башларын әле аска иеп, әле күтәреп, әлмәндерек атыналар, ул да түгел, тамак төбе белән каркылдашып алалар.

Өйдән башына яулык өстеннән мескен бүрек кигән бер карчык чыкты, кулына тоткан пумаласын болгап, кычкыра башлады:

— Көш, нәгаләтләр, көшш! Нәрсә сез, башыгыз беткерләре, үлем чакырып утырасыз?

Каргалар, карчыкны мыскыл иткәндәй, колга өстендә атынуларын дәвам иттерделәр.

Тау ягыннан киң табанлы галәмәт дәү чанага өеп кызыл кирпеч төягән чылбырлы трактор үкереп төшә башлады. Аның артыннан дәү кырмыскаларны хәтерләткән «Беларусь» тракторлары бер-бер артлы тырылдашып килеп чыкты.

Каргалар канат җилпеп очып киттеләр.

«Каргаларына хәтле карыша, замананың үзгәрүен менә шуннан аңла инде»,— дип уйлады Данияр, үргә күтәрелгәндә.

Үр өстеннән авыл уч төбендәге төсле күренә: түбәсен кар баскан йортлар, авылны аркылыга ярып узган агачлар аллеясе элекке алпавыт утары хәтле ак ташпулат — колхоз акчасына салган урта мәктәп бинасы, культура сарае, янгын каланчасы, идарә йорты...

Айтуганов моннан кырык ел элек кабул итеп алган авыл нинди иде икән?..

...Җәй иде ул чакта. 1944 елның җәе иде. Дөнья яшеллеккә күмелгән. Кояш елмаеп карый, агачларда кошлар сайраша. Балдамар авылының кайчандыр мулла йорты булган мәктәп ишегалдына халык агыла. Ямаулы чалбар, терсәге тишелгән иске күлмәк кигән үсмерләр, таякка таянган картлар, бөкрәя төшкән карчыклар, сап-сары чабатаны ак йон оекбаш өстеннән киеп куйган киленнәр мулладан калган кое бурасына, келәт төпләренә килеп кунаклыйлар. Әлегрәк килгәннәр сүз куерта:

— Бу Гитлер дигән мәлгуньнең бер дөмегер көне булырмы икән?

— И, әйтмә инде, күрше, кайчан муены астына килер шул нәгаләтнең?

— Адәм каны җирдә ятмас, Галимәбикә, килер бер көн, аллаһы боерса, килми калмас. Ходай бар ул, тол катыннарның күз яше, аналарның каргышы бер тотмаса, бер тотар.

Ишегалды тыгызланып тулды инде — кешеләр әле һаман килә. Хатын-кызлар урамы-урамы белән, ирләр аерым-аерым килә. Инде утырыр-торыр урын да бетте, иске келәтле, өч торык лапаслы йорт сыйдыра алмагач, кешеләрнең күбесе урам якта торып калдылар.

— Килә! — дип, бала-чага кычкырып узарга да өлгермәде, озын торыклы җирән кашка җигелгән кара тарантас капка төбенә җитеп туктады, тарантастан өстенә брезент кожан кигән аксак аяклы бер кеше төште. Әлеге җирән кашканы авылның ат караучысы Хабул карт койма буена китереп бәйләде, йөгән тезгенен дугадан чишеп алып, атның аркалыгын бушатып, җирән кашка алдына бер кочак яшел печән китереп салды.

Җәй. Күктән кояш карап тора, койма буенда җирән кашка печән күши, кошлар сайраганы ишетелә...

— Җәмәгать, «Сабанчы» колхозы кешеләре, бабайлар, әбиләр, апалар һәм җиңгиләр, и шулай ук үсмерләр! Дәхи дә килеп сугыш кырыннан яраланып кайткан фронтовиклар! Бүгенгесе көнне илдә явыз фашистларга каршы канлы сугышлар барган чорда, сез илне, бигрәк тә фронтны азык белән туендырып торучылар, үзегезнең упшы собраниегезгә җыелдыгыз. Көн тәртибе мәгълүмдер дип беләм: персидәтел сайлау. Моңынчы колхозны тартып килгән Шаһгәрәев Шаймурат чирли — фронт яралары кузгалган. Сталбыт, безгә яңа кеше сайларга кирәк. Мин картлар белән дә, райкумдагы җаваплы иптәшләр белән дә сөйләштем. Сабирҗан абзыйның фронттан кантузин булып кайткан Фәһиме кулай булыр, диделәр. Сез ничек карарсыз моңа? Мин үзем, тушы авылның төп үз кешесе, Айтугановныкыларны энәсеннән җебенә тикле беләм. Бабалары Айтуган — револютсә корбаны, әтисе Сабирҗан, сталбыт, гражданнар сугышында катнашты, Балдамарда силсәвит рәисе булып эшләде, Фәһим үзе менә, күреп торасыз, бу сугыштан яраланып, сталбыт, ранный булып кайтты... Әй, кайда син, Айтуганов Фәһим? Сабирҗан абзый улы, торып бас әле, күрсен әле сине авылдашлар...

Өстенә яшькелт гимнастерка, шундый ук төстәге галифе чалбар, аягына чолгау урап, калын табанлы солдат ботинкасы кигән, сул кулын марля белән бәйләп муенына аскан ап-ак чырайлы, чандыр бер егет ишегалды чирәменнән торып баскач, халык аһ итеп куйды:

— Җаныкаем, бигрәкләр дә яшь бит.

— Унтугыз яше дә тулмаган түгелме соң әле?

— Малайны күрәләтә ут эченә салмагыз! — дигән тавышлар ишетелде.

Бәхәсләшә торган заманмы? Сугыш вакыты. Сайладылар. Кәнсәләргә алып кереп, кулына пичәт тоттырдылар. Җитәклә!

Район вәкиле тарантасына менеп утырды да китеп барды.

Фәһим Айтуганов, унтугыз яшьлек егет, әле кулындагы ярасы да төзәләп житмәгән фронтовик, ач-ялангач Балдамары белән, салам түбәләре астыннан каш җимереп карый торган йортлары, күтәрәмгә калган 37 аты, зур йортта ягарга утыны булмыйча, мунчага күчкән гаиләсе белән торып калды.

1944 нең җәе. Күктән кояш карап тора. Дөнья яшеллеккә күмелгән. Тирәкләрдә кошлар сайрый. Өйләренә, дөресрәге — мунчага кайтып керсә, әнисе Гөлйөзем елап утыра. Тугыз яшьлек энесе Фатыйх белән биш яшьлек энесе Раушан әниләренә сыенганнар.

Фәһим ишекне ачык кергә, әнисе башын күтәрде, күз яшьләрен сөртә-сөртә, гаҗиз тавыш белән:

— Нәрсәләр күреп риза булдың, балам? Башларыңны өтермәндә черетәсең киләмени? Дөньяда без барлыкны уйламадыңмыни? — диде.

...Дәминев үр өстеннән Балдамарга озак карап торды. Моннан да төзегрәк, моннан да матуррак авылны аның ил буйлап йөреп тә күргәне юк әле. Киночыларны алып килергә кирәк, тарихын белергә кирәк, документаль фильм төшерергә мөмкин булыр. Җәен, күкрәп үскән агачлары, ак ташпулатлары — мәктәбе, культура сарае, идарә йорты, каланчалары, кызылга буяган калай түбәләре, агарып күренгән шифер түбәләре, Терлекчеләр каласы, машина-трактор парклары, мастерскойлары, больницасы, Дәүрән елгасы, ун чакрымга сузылган болыннары, таллыклары белән теләсә кемнең күңелен үзенә тартырдай авыл бу. Һәм шушыларның барысын бер кеше, фронттан яраланып кайткан кеше юктан бар иткән.

Моннан биш-ун еллар элек шулай дип әйтеп кара. Авылдагы шушы муллыкны бер кеше юктан бар иткән дип газетага язып кара — каты шелтә эләктерәсеңне көт тә тор. Нишләп аны бер кеше эшләсен? Боларның барысын партия эшләде, партия барлыкка китерде, партиянең зирәк җитәкчелеге аркасында совет крестьяннары якты мул тормышка иреште, дип язарга кушарлар, язмасаң, совет чынбарлыгын дегеткә буяучы булып калырсың. Газета саен синең исемеңне төрләндерерләр, шулхәтле дә төрләндерерләр ки, сине урыныңнан алып ташламый торып тынычланмаслар иде...

Җитәкчегә җитәкчелек итү мөмкинлеге тудырган төп шарт — аның ирекe, бәйсезлеге. Кеше үзенең гомере ни бәя, эшләгән эшенең ни бәя торганын, яшәү шартларының күпмегә төшкәнен ачык белергә тиеш. Кеше экономик мәсьәләләрдә дөм-сукыр булса, судагы балык кебек йөзә алмый, аның үзе эшләгән өлкәдә тир түгүе мәгънәсезгә әйләнә. Менә шушыларны председательләр эшенең нигезе итеп алмыйлар, колхозны күтәрү, экономиканы ныгыту хакында баш ватканда алар логика чылбырыннан кешене төшереп калдыралар. Фәһим Айтуганов өзлексез, көне-төне үзе җитәкләгән авыллардагы кешеләрнең матур һәм мул яшәүләрен генә түгел, дөрес яшәүләрен дә уйлап эш итә, күрәсең. Бервакытны Сыктывкар шәһәренә мәкалә язарга баргач, бер урманчы карт Данияргa гомергә онытылмаслык сүзләр әйткән иде: «Әгәр кеше дөрес яши икән, ул үз-үзенә бүләк». Данияр тирән мәгънәле бу сүзләрне күңелендә озак вакытлар кабатлап йөрде. Нәрсә дигән сүз ул — «дөрес яшәү»? Әчми дә, тартмый да, эшләгән яхшылыгы шуннан артмый да дигән сүзме? Югарыдан нәрсә кушалар, нинди сукмактан барырга әмер итәләр — шуны үтәп тору дигән сүзме? Юк, юк, тагын бер тапкыр — юк! Дөрес яшәү — намусың кушканча яшәү. Менә нәрсәне күз алдында тота урманчы. Әгәр син намусың кушканча яшисең икән, илгә дә, коллективыңа да, үзеңә дә хилафлык китерә алмыйсың. Данияр кичә, ветераннар җые-

лышында, Фәһим Айтуганов сөйләгән сүзләрдән нәкъ менә шуны аңлады.

Даниярның уйлары отыры тармаклана барды.

Кешенең кимчелеге була, кеше гел нурдан-яктыдан гына тормый. Ләкин кимчелек белән кимчелек арасында аерма бар. Нинди кимчелекне гафу итеп була, ниндиен гафу итеп булмый?

Комсызлык начар, аны гафу итеп булмый. Ярамый да гафу итәргә. Комсызлар авылны эчтән таркаталар, кешеләрне бер-берсе белән дошманлаштыралар, чөнки «ике бөркет сугышса, ябалакка җим була». Кешеләрнең үзара талашып, бозылышып йөргән чакларында, комсыз кеше үз оясына мал ташый. Мал бит әллә каян, күктән төшми, колхоз милкеннән алына.

Үз кыйблаң булмау — шулай ук гафу итеп булмаслык кимчелек. Бу сыйфат үзе артыннан бик күп төрле башка кимчелекләрне ияртеп килә: ялагайлык, ләббәйкәлек, килешеп-ярашып гомер итү һәм башкалар, һәм башкалар.

Үзбаш эшләмәү, мөстәкыйль фикер йөртә белмәү, институтта укыганны, райкомда ишеткәнеңне кабатлап йөрү дә — бик зур кимчелек, андый җитәкчеләр, гадәттә, кыюлар һәм мөстәкыйль эшләргә теләгәннәрнең юлына аркылы төшәләр, инициативаны буалар, шәхесне танымыйлар.

Уйлары шул урынга килеп җиткәч, Дәминев учы белән маңгаена сугып куйды. Райком секретаре Тимергалиев белән колхоз председателе Галинур Айтуганов арасында килеп чыккан бәрелешләрне менә шул җирлектән эзләргә кирәк түгелме икән?..

Бу инде язылачак мәкаләнең нигезе була ала.

Шушыларны үзе өчен ачыклап бетерсә, Дәминев инде Морат Баянович белән аяк терәп сөйләшә алачак.

## 7

Даниярның күптән сынаганы бар: шәһәрнең сулышы нинди икәнен беләсең килсә — базарына бар, авылның нинди икәнен беләсең килсә — кибетенә кер.

Ишек өстенә «Промтоварлар» дип мөһер сугылган таш кибеткә керде Данияр. Күзе киштәләрдәге бала-чага киеменә, ситсы товарларына, эшкә кия торган кыска туннарга, кирза итекләргә төште. Аларның берсенә дә тукталмады. Ярты кибетне алып торган, агач рамнар эчендәге зур мотоциклның артына чыгып, аның кайбер детальләрен «барларга» кереште. Ныгытып кереште — идәнгә утырып. Биредән аңа прилавка артында басып торучы кибетчеләр дә, әйбер алырга килгән җиңгиләр дә аермачык күренә, сөйләшкәннәре аермачык ишетелә иде.

— Тәгъзимә, җаныем, карасана, менә бу ал бумази читсың күлмәккә ярамас микән? Кичәгенәк тә кергәниеем, син югында карап та чыгып киткәниеем, гел дә менә күңелемә ятып тора шул читсың.

Түгәрәк йомры гәүдәле кибетче — яшь кенә хатын, ак халатының чабуларын җилфердәтеп, «читсы» сораучы янына килеп җитә:

— Бумы? Бу, Гыйшкыҗамал түти, суйган да каплаган бу. Ничә метр үлчим?

— Ничә җитәр дип уйлыйсың? Белсәң аны син беләсең инде. Югары Камышлылар әйтә, Тәгъзимәнең күзе шундаен да очлы, бер күз сирпеп алу белән катыллар аягына ничәнче размирлы калуш, ирләр башына ничәнче размирлы кәләпүш кирәген әйтә дә бирә, диләр. Югары Камышлының Бәтел белән Түбән Камышлының Чүкеч Пәрдеш бәхәсләшкәннәр...

— Нәрсә дип бәхәсләшкәннәр?

— И нәрсә дип сорап торган булма инде! Нәрсә дип булсын — Балдамар сатучысы Тәгъзимә әйбәтрәкме, Акчуртан сатучысы Әлмирә әйбәтрәкме дип?

— Соң шуннан, шуннан? Әйбәтлекне нәрсә белән үлчәгәннәр?

— Кайсысы ирләр киеменең размирын белә дип инде. Чүкеч Пәрдеш оттырган. Икесе дә бергә ике кибеттә булганнар: синнән дә, Әлмирәдән дә аякларының да, башларының размирын белешкәннәр. Син әйткәне түтелке-түтелке булып чыккан.

— Нәрсәдән бәхәсләшкәннәр?

— И нәрсәдән дип сорап торган булма инде! Хәзер нәрсәдән бәхәсләшеп була? Җартыдан, әлбәттә! Бәтел карт Чүкеч Пәрдештән оттырган җартысын таптыра башлаган. Давай булгач, давай — бирмәскә нисмиеш права! Ник бәхәсләшкәненә нират булган Чүкеч Пәрдеш. Каян аласың аны җартыны хәзер — күзгә кырып салырга да җук бит ул. Ничә кибет арасында килеп сарганнар болар, аракы сата дип даны чыккан Сәрвәриягә дә кереп бакканнар, җук булгач җук — вәссәләм! Пириструйке дигән закун бетерде бит ул җарты-мортыны.

— Суң шуннан, нәрсә белән беткән суң бәхәсләре?

— Нәрсә белән бетсен! Бәтел картның үзенә ялына башлаган Чүкеч Пәрдеш. «Менә сиңа җегерме тәңкә акча, теләсәң каян тап үзең!» — дигән. Ә тегесе Бәдыйгелҗамал корткасының утын-мазар апкайттырасы булса дип яшереп саклаган җартысын җегерме сумга сатып алган, ди.

Икесе бергә кибетне яңгыратып көлделәр.

— Ул котырган сыер сөтен бетереп бик яхшы иттеләр, хатыннарның җаны канат какты. Урамда, кибет төпләрендә болагайланып йөргән ирләребезне эзләп теңкә корымый, ичмаса, — диде йомры гәүдәле сатучы.

— Җук, алай ук дибәйтеп бетермә әле син, Тәгъзимә. Бетермә-әә. Җарты дигән чалмалы баш минем утынымны да апкайттыра, капка баганамны да утырттыра, печәнемне дә кайтарып аудара торганые. Сезгә ярый ул, гүәрдин күк ирләрегез булгалларга, ә мин, сугыш беткәннән бирле тол катын, нишлим хәзер? Җук, безнең ишеләрне ике кулсыз итте пириструйке. Өченче көн Казаллар кайткаллар ие. Җир тишекләренә керердәй булдым, тәки таба алмадым. Ә үзләре сумкасын тутырып алмасын, әфлисунын, әчтерхан чикләвегенә тикле алып кайткаллар. Бер ыстакан әче бал да капмыйча, авыз-борын төяп китеп бардылар, бәгырь итләрем. Акчурталларга тентү кергән, ике кешенең бал мичкәсен алып чыккаллар. Алып чыгып кына калсалар бер хәл ие әле, малакаем, балта белән бәреп ваткаллар — әче бал исе бөтен авылга таралган. Ул гынамы! Өстәвенә — икешәр җөз тәңкә ыштыраф салгаллар. Ыштыраф салучылар кем диген? Үзебезнең колхоз мөртәте — Чокыр башы Моталлипның кызлар чырае күрмәгән чулак Шаңгәрәе бит. Таулы Төбәккә барып, милитсе чикмәне кигән булалар да, кулларына пугач тотып, адәм куркытып җөриләр, әдәм тәганәләре! Менә нинди көннәргә калдык, Тәгъзимә, пиристройке дигән закунсыз закуннар аркасында.

«Бер генә җулга калдыр инде, энем Шаңгәрәй, син бит чит кеше түгел, үзебезнең Балдамарныкы!» — дип ялыналар икән тегеңгәргә. Кая ул! «Малчайт!» — дип кенә кычкыра ди. Урысча белә, янәсе, бук писере! Татарчасын рәтләп сөйләшә белмәгән башы белән урысчага үрелгән була икән әле, гарьлегеңнән үләрсең, валлаһи! Үзебез гаепле, урысча белмәсә, кеше булмас, эт типкәсендә җөрер дигән булып, балаларыбызны урыс-унтагай мәктәпләренә тыгып бетерәбез дә, аннан ары аларның «Малчайт!» дип кычкырганнарына гарьләнеп йөрибез...

— Карале, Гыйшкыҗамалттәй, без бит әле төп эшебезне оныттык. Күлмәккә дигән алсу бумазины ничә метр үлчә дигән идең әле?

— Нинди бумази, нинди күлмәк ул тагын?! — диде тәмам ярсынып җиткән Гыйшкыҗамал түти. — Берсе бер күземә күренми, берсенең бер кирәге җук. Әнә Казаллар апкайткан күлмәкләрем дә сандык тулып җата. Хуш, сау бул, җәме! — дип, ишекне дөбердәтеп ябып чыгып китте...

Данияр мәкаләләрен, очеркларын гел русча язса да, соңгы елларда бик бирелеп татар китапларын укый, гаиләдә һәм иптәшләре арасында гел татарча сөйләшергә тырыша, «әткәм-әнкәмнең телен» ярыйсы ук яхшы үзләштердем дип, күңеленнән тын гына куанып йөри иде, кибеттәге сөйләшүне ишеткәч, таң калды. Менә сөйләшеп карый икән авыл халкы! Менә күрсәтә икән татар теленең ачылыгын, чәч пәкесе кебек үткенлеген.

Шул уйлары белән, үзе дә сизмәстән, әкрен генә баш чайкыйчайкый, идәндә, мотоцикл яшьнеге артында утырып тора иде, кибеткә тагын бер хатын килеп керде. Монысы Гыйшкыҗамал түти яшендә түгел, монысы әле, күп булса, кырык яшьләрендәдер, киемнәр моның чекерәеп күзгә кереп тора, билне бик хәтәр кысып, ак каеш белән буган, аягында биек үкчәле ак туфли, кулында ридикюль.

— Тәгъзимушка, чибәркәй, нинди яңалыкларың бар, матурчик? — дип шыкы-шыкы басып прилавка алдында йөренеп алды ул.

Данияр чак кына көлеп җибәрмәде. Монысының сөйләшүе күңелне болгатыр дәрәҗәдә төче иде. Шәһәрчә иде.

— Мин сораган теге хушбуй кайтмадымы әле, Тәгъзимушка?

— Юк шул әле, Фаина ханым. Сез сораган «Париж-Москва» духие кайтмады әле. Базада гел вәгъдә итәләр, гел сүзләрендә тормыйлар, — диде сатучы Тәгъзимә. — Башка нәрсә кирәк түгелме соң, Фаина Фәттаховна?

— Юк, Тәгъзимушка, башкасы кирәкми. Кстати, ишеттеңме, Галинурны эшеннән алганнар икән бит?

— Кайсы Галинурны? — диде сатучы хатын, йөзенә аптырау галәмәте чыкты.

— Соң кайсы дип, Фәһим Сабирҗановичның олы улын инде. Кеше сөйли, имеш, эчә икән, хатынын кыйнаган икән, эшен райкомда тикшерәселәр икән, ди. Карале, нинди акыллы, нинди пөхтә малай иде. Балдамарда чакта. Әлкәш булган диген, ә?!

— Болар барысы да гайбәт, Фаина Фәттаховна. Моннан бүтән кешегә сөйләмәгез берүк.

— Бетте, җаным, бетте, Тәгъзимушка, яратмыйм гайбәт сөйләгәнне. Гайбәтче корткаларны җен урынына күрәм. Карале, чибәр кызый, Айтугановны пенсиягә җибәрәселәр, имеш, ди. Малаен тәрбияли белмәгән, үзе җитәкләгән колхозда, ягъни безнең «Сабанчы»да кодакодагыйлык оештырып ята икән, дип гәзиткә язганнар диме, обкомга хат җибәргәннәр диме? Шул сүз дөрес микән?

— Барысы да гайбәт, Фаина Фәттаховна. Заманында синең турыда да, үзен врач дип йөри икән, врач булыр өчен, институт бетерергә кирәк. Ә ул сестра-нәнке генә, дип сүз чыгардылар.

— Чыгарырлар, җаным, чыгарырлар, институт бетергәненне белә торып, юрамалый, киметеп сөйлиләр, күпсенәләр. Әнә бит Фәһим Сабирҗановичның кияве Максудны да институт бетермәгән, фельдшер, имеш, күршем Нурлыгаянушка әйтмешли, өшегән кишер дигән булалар. И гайбәтче дә халык! Юк, дускаем, яратмыйм гайбәтчеләрне, җен урынына күрәм. Әле менә беркөнне генә сөйләп тордылар, теге бик нечкә тавыш белән җырлый торган, егетләрнең ушын ала торган Лираны әйтәм, әнә шуның ире хатынының клубларга чабып, теләсә кем белән авыз ерып сөйләшкәнгә, дөрес булса, хыянәт тә

иткәнenә түзә алмыйча асылынып үлгән, диләр...

Монысы чамадан тыш иде инде. Кичә җанында иң изге тойгылар уяткан җырчы турында ямьсез сүзләрне тагын да тыңлыйсы килмичә, Данияр мотоцикл артыннан кутәрелде:

— Тәгъзимә, әйтегез әле, бу мотоцикл күптән кайттымы сезгә, запчастьләре бармы аның? — диде.

Сатучы Тәгъзимә дә, «гайбәтчеләрне җен урынына күргән» Фаина Фәттаховна да кинәт югалып калдылар.

— И җаным Тәгъзимә, әйтмисең дә, әллә ниткән чит кеше бар икән бит, — дип, Фаина Фәттаховна сатучыны шелтәләп алды һәм битен-башын сыпыргалап ашык-пошык кына чыгып китте.



## 8

«Советская Россия» газетасының үз хәбәрчесе булып билгеләнгәннән соң Даниярга Россиянең аркылысын-буен йөреп чыгарга туры килде. Урта полосада халык әле һаман да авыр яши, йортлар җимерек, каралты-кура кечкенә, эшләп тапканны бөрәмтекләп кенә тоталар, бер дә узынып чамалары күренми. Данияр үзе өчен үрнәк итеп халык тормышын саный, каян күтәрелгәннәрен онытып, айга сикерергә азапланган түрәләрне ихтирам итми.

Идел буйларында да ярлы авылларны байтак күрде Данияр, аларның нигә ярлы икәнлекләрен өйрәнде, шулар аркылы «Сабанчы»га килеп чыкты. Килеп чыгуы да очраклы түгел, Айтугановны ул обком пленумнарында күзәтеп йөри, ул сөйләгән сүзләргә колак сала, гомумән, ул хәзер аның игътибар үзәгендә. Шәһәр зыялысы төсле затлы киемнән, кайчан карама, ак күлмәктән, костюмына туры китереп таккан пөхтә галстуктан, республика җитәкчеләре белән дә, колхоз хуҗалары белән дә ипле генә сөйләшә, коңгырт күзләренең почмагында вак җилпәзәләр булып посып торган хәйләкәрлек, сынап-тикшереп карау аның тәҗрибәле кеше икәнен әйтеп торалар. Ләкин ул, Данияр уенча, күңелендәгесен тышка чыгарып аударырга ашыкмый. Обкомның бер пленумында Таулы Төбәк районы «Сабанчы» колхозы председателе Фәһим Сабирҗанович Айтугановка сүз бирелгәч, биш йөз кеше сыешлы конференцияләр залы тынып калды, игътибар трибунага чыгып баскан председательгә, аның биек маңгаена, алсуланыбрак киткән озынча йөзенә төбәлде. Данияр күрде, журналистлык тәҗрибәсе, очлы күзе белән күрде: президиумда күршесе белән тоташ сөйләшеп утырган обком секретаре да, сөйләшүдән туктап, бөдрә чәчле башын трибунага таба борды.

Менә шунда Данияр председатель Айтугановның ни уйлаганын, күңелендә ни йөрткәнен үтемле итеп сөйли белүен, залны тыңларга мәҗбүр итә белүен күрде. Юк, Айтуганов, үзен алга чыгарырга теләп, оратор булып кычкырмый, ул зал белән киңәшә, бергәләп уйлый, бергәләп нәтиҗә чыгара, нәтиҗәләрен үзе җитәкләгән «Сабанчы» колхозы мисаллары белән беркетә бара иде.

Данияр «Сабанчы»ның ничек миллионер булып китүе белән күптән кызыксына, тик әле аның моңа ничек ирешкәнен белми, белә дә алмый, ул хакта бит юл уңаенда, хәл-әхвәл сорашып, әңгәмә корып торудан гына әллә ни белә алмыйсың, моның өчен «Сабанчы»ның үзенә барырга, һәммәсен үз күзең белән күрергә, кешеләре белән якыннан танышып-аралашып яшәргә кирәк. Әнә шул аралашып яшәүгә вакыт җитми аптырата. Әзерләнеп кенә бетәсең — Мәскәү сине йә Чабаксарга, йә Йошкар-Олага, һич югы рейд бригадасы белән Иделне өйрәнергә җибәрә. Ә «Сабанчы», якында гына булса да, гел кала килә.

Ниһаять, менә җай чыкты. Кулына хат тоттырып, аны райком секретаре белән председатель арасында килеп чыккан конфликтны ачыклап, мәкалә язып кайтырга җибәрделәр.

Данияр хәбәрче булып эшләү дәверендә секретарьларның төрлесен күрде. Бар аларның зирәкләре — районга гомерлеккә килмәвен аңлап, кешеләр белән кешечә мөгамәлә кылганнары. Болары белә: секретарь булып пычагым да кыра алмыйсың. Утызынчы елларны урта хәллене нигезеннән кубарып, Себергә кудылар. Шуннан бирле авылда тәртип юк, җан теләп эшләү юк, сеңерең өзелгәнче тартсаң да, кендегеңнән югары сикерә алмыйсың. Чөнки Мәскәү обком өстеннән, обком райком өстеннән, райком председательләр өстеннән командалык итеп килә һәм киләчәк.

Райком секретарьларының икенче берләре, үзләрен дөньяның кендеге санап, кабыкларыннан чыкканчы тырышалар. Алар өчен крестьянны кайгырту түгел, югары оешмалардан мактау сүзе ишетү кадерлерәк. Мондыйларны ахыр чиктә үкенү, дөньядан күңел кайту, җан газаплары көтә...

Тимергалиев шуларның кайсысына керә — Дәминев моны ачыкларга тиеш. Ачыклау Тимергалиев белән сөйләшкәнче булса әйбәтрәк, чөнки секретарь үзен беркайчан да екмаячак...

Дәминев уенча, Тимергалиев Таулы Төбәккә көтмәгәндәрәк килгән. Райкомның элекке секретаре Баязит Ханзафаров — авыл хуҗалыгы белгече, агроном, ә беренче секретарь постына килгәнче колхозда парторг, совхозда директор, райкомда идеология секретаре булып эшләгән. Ул гынамы? Ханзафаров шушы якларда туып үскән, иген игүнең инде серләренә төшенеп җиткән булган. Командалык алымының хәвефле нәтиҗәләрен үз җилкәсендә татыган җитәкче буларак, ул сак эш итәргә, ватмаска-сытмаска өйрәнгән, аның эзләнүчән тынгысыз табигате Таулы Төбәкнең уңдырышсыз көлсу туфрагында да уңыш үстереп була икәнне исбатлап биргән иде.

Партия өлкә комитетында аңа өмет багладылар: дәүләт мәнфәгатен дә, халык мәнфәгатен дә екмый торган секретарь үсеп чыкты, дип докладларда исемен зурладылар. Аның эш тәҗрибәсен башкаларга да күчерергә әзер иделәр. Тик көтмәгәндә эшләр кире якка сүтелде дә китте. Ханзафаров, үзен партия эшеннән җибәрүләрен сорап, обкомга, туп-туры Беренченең үзенә гариза язып бирде. Аптырадылар, җибәрмәскә теләделәр, сәбәбен белгәч, җибәрми булдыра алмадылар. Ханзафаров шикәр авыруы белән интегә икән. Димәк, ул өзлексез үзен кайгыртырга, режим тотарга тиеш булып чыга. Ә райкомга кем генә килми — өлкәдән дә, үзәктән дә; барысы белән бергә булырга, мәҗлесләр үткәрергә, табын өстәлләре янында армыйталмый «эшләргә» кирәк бит инде. Әгәр шуны булдыра алмыйсың икән — син нинди секретарь? Шикәр авыруы белән көне-төне киңәшмәләрдә дә утыра алмыйсың. Тәүлекләр буе иген басуларында да йөрүе кыен. Иң авыры — син диета сакларга, үзең белән сумкада ризык һәм чәйле термос йөртергә мәҗбүрсең. Вакчыл кеше кебек, урык-сурык, үзең белән йөрткән сумкадан ашарга тотынгач, синең нинди абруең кала?

Китте Ханзафаров. Кешеләрнең сәламәтлеген кайгырта торган урынга, өлкә профсоюзларына күчте.

Таулы Төбәкне алдынгылар сафына алып чыга язуын истә тотып, иң зур корылык килгән елны өлкәне коткарышканы өчен, Казанда аңа кирәкле кешеләр өчен дип саклана торган фондтан квартир бирделәр, әйбәт фатир, яхшы планировкалы, совмин аппараты өчен эшләнгән йорттан. Хатыны сөенде, балалары сөенде, Ханзафаров үзе генә сөенмәде, чөнки әле генә күкрәп торган секретарь, беренче кул партработник, әкренләп онытыла, бер дә булмаган кебек, юкка чыга

бара иде. Секретарь чагында көннәр буе чылтырап торган телефон зеңгелдәүләре туктады, урындагы кешеләр генә түгел, аның янында секретарь чакта туктаусыз бөтерелгән туганнарына тикле онытты аны. Ялагай булганнар икән, үзләренә кирәккә тасма телләнгәннәр.

Аны онытмаган бердәнбер кеше корреспондент Дәминев булып чыкты.

— О-оо, Баязит Харисович! Сезме бу? Хәлләрегез ничек? Нигә шалтыратам дисезме? Сагындым. Акыллы кешеләр сагындыра бит ул, хе-хе-хе. Серьезно. Сезгә барып чыгарга мөмкин түгелме? Дачага укмыни? Ярый, алайса, мәшәкать булмаса, дачада очрашыйк. Хәзер мин машина гына чакыртам да. Ярый, ярый, гаиләгезне дә алырга була. Тик, чурр! Безгә икәүдән-икәү генә сөйләшергә кирәк.

Ханзафаровның дача дигәне профсоюз дачасы булып чыкты. Аны быел шунда беркеткәннәр икән. Идел буенда, Боровое Матюшино ягында. Элек хөкүмәт дачалары Аккош күле буенда иде. Игнатов дигән обком секретаре ул якларга оргсинтез заводы салдыргач, җилле көннәрдә завод төтене һәм төрле агулы исләр Аккош күле буендагы урманнарга, дачаларга чаклы килеп җиткәч, республика җитәкчеләре, ул урыннарда язучыларның иҗат йорты белән пионер лагерьларын гына калдырып, менә шушы яңа урынга күчеп килделәр. Ике бүлмәле фин йорты булып чыкты дача дигәннәре, бик тә тыныч һәм аулак урында икән.

Машинадан төшүгә, Ханзафаровның хатыны махсус кибеткә азык-төлек алырга китте. Ханзафаров белән Данияр икәү генә аулакта торып калдылар. Даниярның күңеленә китереп суккан беренче тойгы Ханзафаровның ничектер кечерәеп калуы, ябыгуы, битенә күп булып җыерчыклар кунуы иде. Секретарь чагында ул алсу янып торган шома битле, ирен читләреннән елмаю китми торган ягымлы чырайлы, корсак шәрифләре дә түгәрәк булып, үз кадерен белеп, дәрәҗәсен саклап сөйләшә торган олпат кеше иде. Секретарь чагында ул бер мәлне унбиш көнләп больницада яткан иде, хәлен белешергә баргач, Данияр аны шаяртып: «Корсак шәрифләре кимемиме соң?» — дип сораган иде, Ханзафаров көлемсерәп болай диде: «Хатыным әйтте, зинһар, корсагыңны киметә күрмә, район халкы алдында бер авторитетың да калмас, дип әйтте». Боеккан Баязит Харисович, күзләренең җетелеге сүнгән. Кешене, күрәсең, ике нәрсә тотып тора: сәламәтлек һәм дәрәҗә. Ханзафаров өчен инде хәзер боларның берсе дә юк иде.

Өмет иткән сөйләшү була алмады.

Ханзафаров хәбәрче дусты Дәминев биргән сорауларга кыска гына итеп: әйе, юк, була, булмый, дип бер генә сүз белән җавап биреп утырды. Ул хәзер дә елмая, ләкин инде бу көр күңел белән, рәхәтләнеп, җәелеп елмаю түгел, моңсу елмаю иде.

«Нужәли барлык секретарьларны да шул язмыш көтә?» — дип борчылып уйлады Данияр ул чакта.

— Карагыз әле, Баязит Харисович, Таулы Төбәккә, сезнең урынга килгән секретарь нindirәк кеше? Холкы-фигыле дигәндәй... Шундый зур районны җилкәсендә күтәреп бара алырлыкмы ул?

— Мин бит аны белмим. Аны бит каяндыр читтән китерделәр. Эшләп карасын, күрербез... — диде Ханзафаров.

Данияр көткән җавап түгел иде бу. Ул-бу булмагае дип, саклаunion кына әйтелгән җавап иде. Аның яңа секретарьны белмәве мөмкин түгел, чөнки бу эшкә аны ул үзе тәкъдим иткән, диделәр.

Бу хәл Дәминевне аптырашта калдырды. «Димәк, партработниклар, урындык биләп утырган чакта гына гайрәтле, урыннарыннан очтылармы, алар үз фикерләрен дә әйтә алмый торган мескен булып калалар икән...» — дип нәтиҗә ясады ул.

Дәминев кунак йортына әйләнеп кайтканда, Нәсимә җиңги, мичләрне ягып томалаган, табын әзерләргә керешкән иде.

Йомшак мич җылысына җаннары рәхәтләнеп (батарей җылысы бөтенләй башка бит ул!), бала чактагы авыл өйләрен искә төшереп алды Данияр:

— Менә җәннәт кайда икән ул! — диде.

Нәсимә җиңгинең чырае иртәнге яктагы кебек үк ягымлы, сөйләшүе теле-телгә йокмас дәрәҗәдә тиз һәм үткен иде.

— Кече атны макта, олы атны җик, дигәннәр. Авылны мактасагыз да, авылда тормыйсыз бит әле, әз генә аң керә башладымы, шәһәр ягына койрык тайдырасыз, — дип рәхәтләнеп, чын көлү белән, үз итеп көлде Нәсимә җиңги.

Ул өстенә ак халат кигән, бу кием аңа бик тә килешә, ихтимал, ак халатның килешкәнен ул үзе дә беләдер, инде илле ике яшендә булса да җәт-җәт кенә атлап йөри, иреннәре ачылганда, ике көмеш теше күренеп китә иде.

— Менә, энем Данияр, алдан-ала кисәтеп куям, мин аш-су остасы түгел, гаеп итештән булмасын. Менә тушыларны әзерләдем мин сиңа, яратсаң ашарсың, яратмасаң ашамассың. Улым Әдһәм белән ирем Исхакка нәрсә пешерсәң дә ярый, эш кешеләре сугып кына куялар, ә сиңа болар, бәлкем, гүпчи дә ярамас. Тәмсез булса, әйт, яшермә, персидәтелебез Фәһим абзый сиңа, мужыт, яңа бер пувыр табар, — дип тәлинкә белән ашны, ярмаланып пешкән ап-ак бәрәңгене, симез сарык итен өстәлгә китереп куйды.

Дегет төсле куе итеп чәй ясап китерде Нәсимә җиңги.

Даниярның сынаганы бар — аш тәмле булса да, аның шулай икәнен белеп торсалар да, аш осталары иң әүвәл үзләренең кимчелекләрен әйткән булып, пешергән ризыкларын башкаларның тел тидерүеннән саклап калалар. Бу, күрәсең, халык йолаларының бер төре, үз-үзеңне тәнкыйтьләүнең, гади һәм тыйнак булуның бер рәвешедер.

— Бик тәмле ризыкларың, Нәсимә җиңги, телеңне йотарлык, перәметеки патшалар ашы! — диде Данияр һәм шул сүзе белән ул кунак йортын караучының сүз сөйләшү аппетитын кузгатып җибәрде.

— Әйдә, шулай дигән бул инде. Безнең Балдамарда Сәләхи Сәлимҗаны барые, әнә шул Сәләхи Сәлимҗаны әйтә торганые: мактыйлар сине, күзгә карап мактыйлар, син моның җүкә чөй икәнен дә беләсең, әммәдәхи шуңа биреләсең, ник дип әйткәндә, кага торгач, керә бит җүкә чөй. Мин дә шулай, картым Исхак белән улым Әдһәм җүкә чөй каксалар, ашны тагын да тәмлерәк итеп пешерергә тырышам: итен күбрәк салам, суганын-борычын да җәлләмим, озаклап кайнатам, ә теге хитрыйлар минем йомшак якны беләләр, җүкә чөйне кагыпмы кагалар! Ә бит мин кунак йортына эшкә килгәнче авылның күз өстендәге кашы ием, тракторчылар бригадасының хисапчысы булып тордым заманында, яшелчәчеләр бригадасында башлык булып эшләдем. Идарә йортында идән юармын да, кунак йортында аш пешереп торырмын, дип башка да китергән югые минем. Персидәтелебез бик тәмле телле. Менә ул инде җүкә чөйне кага белә. Мактый башласа, сусыз юа, җилсез киптерә. Шулай бер көнне яшелчә бакчасыннан арып-талып, аякларымны көч-хәл белән сөйрәп кайтып киләм. Карасам — каршыма ук Фәһим абый килә. Без аңардан никтер шүрлибез. Әллә оялабызмы? Ул килгәнне күрсәк, капка артынамы-каямы качып калырга тырышабыз. Кием ямьсездер күк тоела, куллар да юылмаган кебек. Бу юлы килгәнен күрми калдым, күрәсемә күрәдер инде. Туктатты, хәлләрне сорашты, аннан ары килеп әйтә бу: син, ди, Нәсимә сеңлем, ди, бик авыр эшләрдә йөрдең моңынчы, ди, әллә җиңелрәк эшкә күчеп карыйсыңмы, ди. Нинди

сүз ул, Фәһим абый, мин әйтәм, җиңел эш? Әллә, мин әйтәм, сез минем эштән канәгать түгелме, дим. Юк, ди бу, канәгать мин синең эшеңнән, әниең мәрхүм дә бик уңган, бик йөрәкле, бик намуслы кеше ие, син дә аның төсле, ди. Бу миңа идарә йортын тәкъдим итә. Йа ходаем, персидәтел ярдәмчесе итеп чакырмый торгандыр бит? Чакырса — бетте баш. Җыен ир-ат арасында ничек утырырсың? Өйгә кайтулар, өйдәгеләрне вакытында ашатулар бетә бит инде аннары. Нинди эштер бит әле, Фәһим абый, дигән булам. Әллә, мужыт бөтенләй дә мин эшли алмый торган эштер ул. Юк, ди бу, син эшли ала торган эш ул, Нәсимә сеңлем, ди, заманында әниең Галимәбикә ул эшне гөлләр кебек итеп башкара торганые.

— Пәрәмәч-күмәч, Фәһим абый, минем әни идән себереп, идарә йортын җыештырып торды бит ул. Әллә, ходаем, бер аллам, мине дә шул эшкә чакырасыңмы? — дим.

— Нәкъ шул эшкә, — ди бу, малакаем, күзен дә йоммый әйтеп тора.

Гарьләндем, үпкәләдем, шулай да бик артык сиздермәдем.

— Дәрәҗәлерәк эш юкмы соң, Фәһим абый? — дидем.

— Идарә йортын күз явыңны алырлык чиста итеп тоту — безнең колхоздагы иң дәрәҗәле эш, Нәсимә, — ди бу миңа. — Мин бит ул эшкә булыр-булмас җиңгиләрне чакырмыйм, үз йортларын да чиста итеп тота белмәгәннәрне. Сине чакырам, Галимәбикә кызын. Әниеңә алмаш итеп. Галимәбикә мәрхүмә, урыны җәннәттә булсын, минем дәрәҗәне бик тә күтәрде. Аның кулы тигән төш көлеп тора торганые. Ул — авылда гаделлекнең, намуслылыкның үрнәге булды. Аңа карап мине дә намуслы, диделәр. Намуслы булмаса, үз янына шундаен да намуслы кешене алмасые, диделәр. Әниең Галимәбикә янына әтиең Һашимулланы чакырып алдым. Унҗиде ел буена идарәнең атын карады, утынын кисте, әниең белән бергәләп, колхозның намусын саклашты. Әтиең дә гүр иясе, әниең дә, мин аларны сагынам, башкаларга дан итеп сөйлим, мин алар белән горурланам. Казан каласыннан килсәләр дә, Мәскәүнең үзеннән килсәләр дә, идарә йортына аяк басу белән түрәләр үзгәреп китә торганнарые, башкача, ихтирам беләнрәк сөйләшә башлый торганнарые. Мужикны тәмәке тарттырмады ул идарә йортында, пычрак алып керттермәде. Берәрсе, читтән килгәне, төпчеген ташлап карасын, Галимәбикә күрше андый мәнсез адәмне утлы табага бастыра торганые.

Алардан соң әллә ничә кеше алмаштырдым, юк, якын да килерлек түгел, әниең белән янәшә куярлык түгел. Йә эш рәтен белмиләр, йә телләре авызларына сыймый. Нишлисең, киләсеңме? Өзеп кенә әйт, юкса, бүген үк шул урынга икенче кеше эзли башлыйм, — ди.

Нәсимә җиңги тагын бер мәртәбә келтерәп кенә көлеп куйды.

— Тәки ышандырды, тәки тушы урынга беркетеп куйды, инде менә иялләштем, башка эшкә кул да бармый, теләк тә юк. Персидәтелебезнең әйткән сүзләре хәзер инде дөрес тә кебек тоела — үземне гел аның уң кулы, ярдәмчесе итеп тоям. Казаннарга китеп, кайтмыйчарак торса, борчылам, ул-бу булмадымы икән, дим. Алтмыш яше тулган көннәрдә халык арасында сүз чыкты, пенсиягә китә икән, диделәр. Куркуга калдым. Яңа килгән кеше Фәһимулла абый кебек гадел булырмы? Ул китсә, авылларга газны кем кертеп бетерер? Пекарьни бинасын кем өлгертер? Кешенеке кештәктә, үземнеке үзәктә, диләр бит. Бөтен авыл белән кайгыга калдык. Аллага шөкер, китмәде, аллага шөкер, эшли. Китми калуы Галинур аркасында. Әгәр дә мәгәр райком аның улына каныкмаса, китәдерие персидәтелебез, ике дә уйламый китәдерие, улы белән берьюлы гына китәсе килмәде, шуңа күрә генә «Сабанчы»да торып калды. Китсә, бетка-

ниек, аның кебек тә колхоз җанлы, аның кебек тә кешеләрне кайгырта торган бүтән персидәтел әйләнә-тирәсендә дә юк, булмас та...

...Данияр Дәминев язу өстәле янында, кунак йортының биек тәрәзәле иркен бүлмәсендә япа-ялгызы гына калгач, Нәсимә җиңгинең гадәти бер нәрсә генә итеп, юл уңаенда гына сөйләп ташлаган сүзләрен күңеленнән үткәреп, аларның мәгънәсен уйлады.

Дөньялар үзгәрә. Ул белгәннән бирле генә дә җир йөзендә күпме яңалык булды. Аттан тракторга күчтеләр. Авылга йөк машиналары кайтып тулды. Басудагы чүп үләннәрне Данияр белән аның абыйсы кулдан утыйлар иде. Хәзер кулдан утамыйлар. Кырларны очкычлар эшкәртә. Болынны чалгы белән чапмыйлар, печән машиналары чаба. Тегермәннәрне авыл инешләреннән җыелган буа суы әйләндерми, электр әйләндерә. Ике канатлы аэропланнарны реактив очкычлар алыштырды. Кеше галәмгә очты, Айга менде, Венерага, Марска юл алды.

Ә күлмәкне һаман энә белән тегәләр. Идәнне чүпрәк белән юалар. Бәрәңгене һаман гап-гади пычак белән әрчиләр.

Дөньяда, җир йөзендә үзгәрми торган нәрсәләр бар. Кешегә мөнәсәбәт, кешене кеше итеп карау үзгәрмәскә тиеш. Әллә ниткән машиналар да моны алыштыра алмый. Менә шушыны аңламаган председатель, шушыны аңламаган райком секретаре, шушыны аңламаган совмин председателе, ниһаять, шушыны аңламаган Үзәк Комитет секретаре эшне җайга сала алмый. Эшләмичә, тир түкмичә, берни дә бармый. Бирәү дә сиңа әзерне китереп куймый. Эш эшләргә кирәк — тир түгәргә. Муллык шуннан башлана — югарыдан китергән, ел саен өстәлеп тора торган карарлардан түгел. Әмма эшләр кеше кайгысын кайгырткан чакта гына алга барачак.

Күлмәкне энә белән тегү, идәнне себерке белән себерү — могҗиза! Бернинди заман җилләренә дә бирешми торган хакыйкать. Моны Айтуганов күптән аңлаган, моңа Айтуганов күптән үз башы белән барып җиткән. Фәһим Айтугановка Нәсимәләр кирәк. Эти-әниләре башкарган кара эшне, дәрәҗәсез дип саналган эшне тартынмыйча, оялмыйча, ышанып башкара, намус белән башкара торган кешеләр кирәк. Гаделлек кирәк, җәптәшлек кирәк, эшкә җанны биреп, яратып карау кирәк.

Ихтимал, Фәһим Айтугановның ничәмә-ничә еллар «Сабанчы»ны дөрес итеп яшәтүе, җиде авылны үзенә берләштергән зур бер колхозның дәүләттән инде утыз ел буена бер тиен дә акча-ссуда алмыйча, үзен-үзе туйдырып, киендереп, йорт-җирле, каралты-куралы була алуы, культура сарае, шифаханә, аптека, терлекчелек комплексы кебек, ягъни сугышка кадәр крестьянның төшенә дә кермәгән корылмалар булдыруы — хуҗалыкның барлык тармакларына ышанычлы кешеләр куеп чыга алуыннан киләдер...

Тәрәзәдән кояш карый. Данияр килер алдыннан берничә көн элек кенә ишеп-ишеп яуган кар, дулап узган бураннар кунак йортының ишегалдына көртләр өеп киткән иде. Утын сараена бара торган юлларны да кар күмгән иде. Нәсимә җиңги киез итек белән кар ярып узган тар гына сукмактан башка нәрсә юк иде. Күрәсең, кинәт бик күп булып яуган карны күрәп, юл салырга көче җитмәгәндер, бәлки, вакыты булмагандыр.

Данияр чоланнан зур агач көрәк табып алып ишегалдына чыкты — кар көрәргә тотынды. Күптән көрәгәне юк иде карны, күптән сулаганы юк иде шул хәтле дә саф-таза һаваны. Бераздан ул мавыгып китеп, өстендәге тунын да салып ыргытты, перчаткаларын да салып ташлады, битләре алсуланып кызыша башлаганчы, күңеле булганчы көрәде карны.

Юлларны арчып, утын лапасы янына җиткәч, туктады, көрәгенә

гаянып, эшләгән эшеннән бик тә канәгать булып карап тора башлады. Шул чагында капкадан колакчын бүрекле, сырма фуфайкалы, киез итекле берәү килеп керде:

— У-һу! Безгә монда эш тә калмаган икән ич инде, — диде.

Кызу килгән булса кирәк, тирләп киткән иде, башыннан бүреген салып, тирләгән маңгаен сөртеп алды. Егет егерме яшьләр тирәсендә, чәче бакыр, бите аксыл иде.

— Исәнмесез, абый,— дип баш селкеп кенә исәнләште ул, аннары лапасның йозагын ачып, эченә керде, сырмасын, перчаткасын салып, сарык йоныннан бәйләгән күперенке калын фуфайка киде, брезент бияләй киде — алар шунда лапаста ук иде, — кулына калун балта алып, утын ярырга кереште.

Данияр аның үз эшен белеп, тоеп эшләвенә сокланып карап торды. Стена буена тигез итеп өйгән әрдәнәдән бер түмәркәне ала да шуңа калун белән китереп суга, каен пүләне урталай ярыла да китә. Шап та шоп оча пүләннәр.

Данияр, беркавым сүзсез генә күзәтеп торганнан соң:

— Әллә сез Нәсимә апаның улы Әдһәм буласызмы? — дип сорады.

— Әйе, — диде егет, эшен дәвам итеп.

— Әниегезгә ярдәм итәргә килдегезме?

— Әйе.

— Кайда эшлисез?

— Заправкада.

Мондый бер генә сүзле җаваплар Даниярны канәгатьләндермәде, аның күбрәк беләсе килә иде.

— Мин Казанныкы. Корреспондент. Сезнең авылга килдем әле менә, — диде сүзне җайлап җибәрер өчен.

— Беләм, — диде егет, утын яруыннан туктамыйча.

— Алай икән. Һм... — дип сүзсез калды Данияр Дәминев һәм Әдһәмне сөйләштерүнең әмәлен эзләп соңгы омтылышны ясады:

— Өегезне утын белән ягасызмы? Ташкүмер беләнме?

— Икесе белән дә.

— Утын күпме китә бер кышка?

— Бер машина.

— Ә ташкүмер?

— Ул да бер машина.

— Кыйбат торамы бер йөк ташкүмер?

— Ничек туры килә: дәүләт хакы белән егерме сум, кулдан алсаң — бер йөз дә илле таңкә.

— Шулай укмыни? Ә сез гел кулдан аласызмы?

— Элек, перестройка чыкканчы складта да була торган иде, хәзер гел кулдан. Перестройка бит барлык нәрсәне спекулянтлар кулына тапшырды. Утынны алар сата, йөге — бер йөз илле сум, ташкүмерен — алар. Аракы булып аракы алар кулына күчте, авылда шуны каладан алып кайтып, сатып ятучылар бар, — дип кинәт ачылып китте Әдһәм.

— Сезнең кебек тәртипле авылда да спекулянтлар бармыни?

— Бездә түгел ул, күршеләрдә.

— Шуннан аласызмы?

— Алмый кая барасың? Кунак килә, бәби туып сөендерә, чәчү бетә, урак тәмамлаган көн була — шунда бераз күңел ачкан булабыз.

Бу күңелсез тема иде. Данияр көтмәгән тема.

— Димәк, сез үзгәртеп корудан канәгать түгел? — диде Данияр.

— Ә мин алай дип әйтмәдем.

Данияр көлеп җибәрде дә сүзне икенчегә борды.

— Димәк, Әдһәм, сез бер елга ягуга гына да өч йөз сум акча тотасыз?

— Шулай килеп чыга.
— Ә электр өчен аерыммы?
— Аерым.
— Күпме инде анысы?
— Айга өч сумнар тирәсе. Анысы күп түгел.

Данияр уйга калды. Ул әнә Казанда өч бүлмәле квартирада тора. Утка, суга, үзәктән ягып җылытуга, газга җиде-сигез сум акча түләп бара бер айга. Ә монда аена шундый ук нәрсәләр өчен егерме биш сум! Уты белән егерме сигез сум! Күбрәк шул, күбрәк. Аена кырык сум пенсия алып торганнар, караучысы булмаганнар ул егерме сигез сумны түләсә, үзенә торырга күпме кала — уникe суммы? Пенсионерларның сыер-сарык асрарга кулыннан киләме? Айтугановның бер миллион акча тотып колхозчылар йортына газ кертергә биш ел буена армый-талмый чабуын менә ни өчен хуплый икән колхозчылар. Менә ни өчен алар аны пенсиягә чыгармаска тырышалар икән. Картлар белән карчыкларның үз председательләренә ходайдан сәламәтлек теләүләре менә хәзер аңа аңлашылды.

Көненең бушка үтмәвенә, бер көн эчендә генә дә авыл белән нык-лап танышуына күңеленнән риза булып, Дәминев «Вакыт» программасын карап утыра иде, ишектән Фәһим абзый килеп керде.

— Ни хәлләрең бар, Данияр? Мине югалткансыңдыр инде. Гафу ит көне буена ялгыз калдырганым өчен. Бик тә тәҗел бер йомыш килеп чыкты. Улым Галинур янына барырга туры килде, — дип сүз башлады ул. Данияр аның йөзе борчулы булуын, күзләренең дә башка вакыттагы кебек балкып тормавын, ирен кырыйларына поскан елмаюының юкка чыкканын күрде.

— Галинурның хәле ничек? Таза-саумы? — дип сорарга ашыкты Дәминев.

— Таза-сау. Сәламәтлеге зарланырлык түгел. Тик менә колхозында күңелсезлек килеп чыккан...
— Нинди күңелсезлек?
— Бухгалтеры агу эчеп үлгән.
— Ир-атмы, хатын-кызмы?
— Кияүгә чыкмаган кыз.
— Галинурның гаебе юктыр бит?
— Минемчә, юк. Тик ул борчыла. Районнан халык тикшерүчесе килеп төшкән. Төштән соң райком секретаре Тимергалиев тә килде.
— Сез сөйләштегезме соң алар белән?
— Сөйләшмәдем. Минем сөйләшү анда урынсыз булыр иде. Мин улымны гына тынычландырдым. Андый чакта яннан бер юатучы кирәк. Чөнки, үзең беләсең, болай да райком бәйләнеп торган чакта, шундый вакыйга Галинур кебек яшь кешенең йөрәгенә китереп сугуы мөмкин.

— Тимергалиев әнә шул үлемне козырь итеп алып, Галинурның эшен күпертмәсме? Сез ничек уйлыйсыз, Фәһим Сабирҗанович?
— Ул инде, Данияр, Тимергалиевнең кем булуына бәйләнгән. Усал ният белән тотынса, күпертә ала, билгеле. Галинурның бу эштә бер гаебе булмаса да, тәрбия эшләре дөрес куелмаган, баш бухгалтерга басым ясалган дип, тагын әллә нәрсәләр дип, эшне катлауландырырга да, дөп-дөресен, гаделен эзләп табарга да була. Әйтәм бит — Тимергалиевнең кем булуына бәйле бу эш...
— Алай булгач, миңа «Сабанчы»да бүтән вакыт уздыру кирәкмәс, иртәгә иртүк — «Яңа көч»кә, Галинур янына китәргә кирәк, — диде Дәминев.

# Дүртенче бүлек

## 1

Тукта, бәла каян башланды соң әле?
Райком эшләрен тапшырган чакта Ханзафаров әйтте аңа:
— Мин, Морат Баянович, Таулы Төбәктә унҗиде ел тир түктем, районның утыз биш хуҗалыгын тауга алып менәм дип сеңер өзелгәнче тарттым. Булмады, барып чыкмады! Чыгачак та түгел! Чөнки крестьян бик озак хокуксыз яшәде, эшләгәненә тиешле түләү ала алмады. Хәзер ала, ләкин хәзер аның җаны бозык — ул урлашырга, үз көнен үзе күрергә өйрәнеп җитте. Аның ул психологиясен сугып чыгарганчы — ай-һай!— белмим, күп еллар узачак әле.
— Нишләргә соң миңа?— диде Тимергалиев.— Синнән мирас булып калган бозык крестьянны дөрес юлга чыгарыр өчен нинди чаралар күреп карарга? Син нәрсәне эшләп бетерә алмадым дип үкенәсең, Баязит Харисович?

— Эшләп бетерә алмадым, дип бер нәрсәгә дә үкенмим. Мин райком эшенә килеп, сәламәтлегемне бетергәнемә генә үкенәм. Әгәр илдә нинди дә булса, кискен бер үзгәреш тумаса, син дә минем хәлдә калачаксың. Илле ел буена хокуксыз яшәтеп, өстән гел кычкырып торып, җиреннән биздерелгән крестьянны син дә, маңгаеңда җиде мөгезе булган Мөхәммәт-әмин дә аякка бастыра алмаячак. Рас син инде бу эшкә риза булып кергәнсең икән, нервыңны ватмас өчен, гаиләңә кайгы-хәсрәт китерер дәрәҗәдә сәламәтлегеңне югалтмас өчен, мин сиңа менә нәрсә эшләргә киңәш итәм. Иң әүвәл үзеңә йорт сал: бәла-казалардан качып ял алырлык резиденцияң булсын. Мин казна йортында яшәп ялгыштым. Монысы булды — бер. Икенче килеп, алдынгыларга исәп тотып ялгыштым. Ник диген? Алдынгылар районда бармак белән генә санарлык. Нибары өч колхоз, ике совхоз — Таулы Төбәктә, дәүләттән бурыч сорамыйча, үз көнен үзе күрә. Калганнары — муеннан бурычта. Дәүләт ул бурычны кайчан да булса ярлыкар, алар өстеннән алып ташлар дигән өмет белән яшиләр. Шулай булгачыннан, үзеннән-үзе аңлашыла, урта кулларга таян. Планны алар үти, йөкләмәләрне алар башкарып чыга. Алдынгылар алар гел үзләренчә, гел башкача. Алдынгылар алар түрә-кара килгәндә алма итеп күрсәтергә генә ярый. Хуҗалыкларында аларның күзгә ташлана торган нәрсәләр эшләү кирәк, берәрсенә күрсәтергә кирәк булганда дип әйтүем.
— Ягъни ниндирәк нәрсәләр?
— Әйтик, культура сарайлары, комплекслар, мәктәпләр. Акчалары бар, кулларыннан килә, салсыннар шәһәрдәге төсле биналар, авылның тышкы кыяфәтен үзгәртсеннәр.

Таулы Төбәктә аталы-уллы Айтугановлар бар. Әнә алар минем тиңкәмә тиде. Алар оппозициядә, алар үзләре коммунист булсалар да, партия солдатлары димәс идем мин аларны. Барлык урында ил кушканны, партия кушканны үтәп тору нык җәелгән бер заманда, болар, үзләренчә кыланган булып, райком эшенә аяк чалалар. Урта хәлләрне дә киреләнергә мәҗбүр итәләр.
— Ә нишләргә соң алар белән?
— Әйтеп торам бит: үрнәк өчен, килгән-киткән түрәләргә күрсәтер өчен файдалан син аларны, ләкин азындырма. Азындырсаң, алар синең авторитетыңны җимерәчәкләр.

— Төгәлрәк әйтә алмассыңмы, Баязит Харисович, азындырмас өчен мин нинди чара куллана алам?

— Айтугановларның икесенең берсеннән котылырга кирәк сиңа. Тота-каба түгел, әлбәттә, җаен табып, нигезләп. Соңгы елларда мин ул фикергә килгән идем инде, тик сәламәтлегем какшау аркасында гына ниятемне гамәлгә ашыра алмый калдым. Бер нәрсәне исеңдә тот: табигать Айтугановлардан булдыклылыкны кызганмаган, акыл-ны да капчыгы белән биргән. Болар берсе дә синең файдага түгел. Әгәр алар башка председательләрне үз юлларыннан алып китсәләр, синең эш сүтеләчәк. Син районны җитәкләргә тиеш. Кабат әйтәм: урталарга таян. Алар райком сүзеннән чыкмый, урталар күп, планны алар үти, районны алар алып чыга...

Кеше сүзе кеше үтерә, диләр. Ханзафаровның әйткәннәре Морат Баяновичның миенә шулкадәр дә кадак булып кереп кадалган икән, һич кенә дә хәтереннән чыкмый. Беренче пленумда, Тимергалиевне Таулы Төбәк райкомына беренче секретарь итеп сайлаганнан соң уздырылган беренче пленумда, башка председательләр белән бергә, Айтуганов та чыгып сөйләде. Өлкән Айтуганов. Башкалар сөйләгәндә зал гөжләп утырды, Айтуганов сөйләгәндә, чебен очканы да ишетелә иде.

Тагын берничә мәртәбә сынады Тимергалиев. Элекке секретарь әйткәннәр гел дә менә дөрескә чыга. Айтугановлар район белән җитәкчелек итәргә ирек бирмиләр. Уйламыйчарак бер сүз ычкындырдыңмы — Айтугановлар эләктереп кенә ала, аларга бүтәннәр иярә. Галинур Айтугановны киңәшмәдә урыныннан торгызып бер кимчелеген әйтәсең, ә ул сиңа шундый итеп китереп чәпи, башкалар шаркылдап көлеп җибәрә.

Яшь Айтугановтан котылырга кирәк, бу башкаларга сабак булыр, әтисе дә дан өянәгеннән айный төшәр.

Бәйләним дисәң, сәбәбен табарга була. Кимчелек кемдә юк? Райком өчен утка-суга керергә, чәче белән җир себерергә торган инструкторларга фәрман гына бир — ун кимчелегеңне табып кайтачаклар.

Тимергалиев эшли башлаган беренче елны Галинур барлык йөкләмәләрен дә үтәп җиткерә алмады, ашлыкны әйбәт тапшырды, бәрәңгесе уңмады. Бәйләнергә буламы? Әлбәттә! Ике мәртәбә инструктор җибәрде Тимергалиев — материал җыеп кайттылар. Район газетасы аркылы яшь председательнең кимчелеген исенә төшерделәр. Нервысы талкындымы? Һичшиксез! Икенче елны ул сөтен йөкләмәдәгечә тигез алып бара алмады, дәүләткә сату нормасын тутырды тутыруын, сыер башына сөт арттыру йөкләмәсе үтәлмәде. Монысын да исенә төшерделәр Галинур Айтугановның. Ул хакта район газетасында проблемалы мәкалә чыкты. Дөрес, ул Галинур җитәкләгән колхоз турында гына түгел иде, алган йөкләмәләргә намус белән карау турында иде. Сөт йөкләмәсен үтәмәүчеләр байтак иде, тик аларны бу әллә ни борчымады, председательләрнең алары каешланган иде инде, ә менә Галинурның бик нык хәтере калганын әйттеләр. Аның белән бергә байтак вакыт парторг булып эшләп, райкомга авыл хуҗалыгы эшләрен җитәкләүче булып күчкән Гайниев әйтте моны. «Без аңа артыграк бәйләнәбез түгелме? Галинур бит башкалардан бер баш югары бара»,— диде. Тимергалиевнең уйга калган чагы да булды. Тукта, гел аның нервысында уйнау каныгу булып чыга түгелме? Бу хәл башка председательләр арасында райкомга кире караш тудырмасмы? Төрле ягын уйлап карый Тимергалиев, күңеле Галинур ягына авышкан чаклары була, әмма өченче ел коры туфракка үҗәтләнеп арыш чәчүе, бюрога алып килгәч, Тимергалиевтән ачыктан-ачык көлүе исенә төшсә, каны кайный башлый иде.

Галинур — әзерлекле председатель, инициативалы, белемле, экономист; өстәвенә хатыны — укытучы, гаиләсе тату — өч баласы мәктәптә укый, тәртиплеләр. «Яңа көч»тә бөтенләй төпләнергә дип бура да буратып йөри икән инә — моңарчы колхоз салган йортта яши иде. Әнә шул бура буратып йөри дигәннәре Тимергалиевне кабат ярсындыра. Нығытып торып төпләнсә, тамыр җибәрсә, председательлектән алсаң да, ул Чукмарлыдан китмәс, председатель булмаган хәлдә дә кире йогынтысын ясап ятыр.

Тагын бер мәртәбә уйлап карый Морат Баянович. Галинур Айтуганов райкомга бу ике елда шатлык китердеме? Китермәде. Чәчүен ул райком белән бәхәсләшеп чәчә, уракка да бәхәсләшмичә чыкмый, ашлыгын тапшырып бетерә, тик районны алгы сафта алып барырга тырышмый, ашлык тапшыруны гел соңарта, азаккылардан булып үти. Шул хакта киңәшмәдә, келәмгә бастырып, җавап ала башласаң, җавабы әзер:

— Сез бит, Морат Баянович, белеп торасыз: безнең эш бер икмәк тапшыру гына түгел бит. Киләсе ел уңышы өчен коры вакытта симәнә салып куярга кирәк. Фуражны да кайгыртмый булмый. Задание икмәген без аны тапшырып бетерербез, райкомга кызыллык китермәбез.

Әтисе Фәһим Айтугановта булган тыныч-сабырлык, дәрәҗәсен белеп сөйләшергә тырышу үрти Морат Баяновичны. Үрти, каһәр! Чөнки ул башкалар алдында райкомның авторитеты белән санашмау булып чыга. Фәһим Сабирҗанович санашмаса, ул әле бер хәл иде, яшь Айтугановның санашмавы начар. Начарлыгы тагын шунда, әгәр ул колхозны күрәләтә җимерсә, булдыксыз булса, алыр идең дә ташлар идең. Ил алдындагы бурычын соңарып булса да үти, колхозчылары аңардан зарланмыйлар. Әмма ул гына аз, 800 йортлы бер авылга, бары тик бер авылга урнашкан «Яңа көч» колхозының Тимергалиев уенча, әллә нәрсәләр эшләргә кулыннан килә. Булсын иде ул менә үрнәк, нык үрнәк, һәр яктан камил колхоз. Менә, дияр иде Морат Баянович, нинди яшь, нинди тырыш, уңган, дияр иде. Аның үрнәгендә башка яшь председательләрне тәрбияләү эшенә керешер иде райком. Узган елны, яңгырлар үзәк бәгъренә үткән елны, ашлыкны төп-төгәл киптереп тапшырам, киптергән өчен, ичмаса, колхозчылар акча алыр дип, икмәк сату заданиесен әтисе белән икәүләп артка сөйрәделәр.

Бу хәлләр исенә төшкәч, Тимергалиев авыр сулый. Бәлки, алар хаклы да булганнардыр, чөнки әнә элеваторга тапшырылган район икмәгенең барысын да киптереп, җиңләтеп өлгерә алмадылар, бер мең тоннадан артыгы җирдә өелеп калды. Ул исән чыгамы әле язга, чыкмыймы? Чыкмаса, әйтәчәкләр, ник киптерми тапшырдыгыз, әнә Айтугановлар киптереп тапшырды бит, диячәкләр. Әгәр барлык колхозлар да киптермәгән килеш тапшырган булсалар, Айтугановлар, аларга ияреп, тагын өч колхоз бүселеп чыкмасалар, бармак төртеп күрсәтер кеше булмас, барсы да тигез җавап бирерләр иде — өлкәдәгеләр дә, райондагылар да, колхозлар да. Юк бит, болар аерыла, болар райком әйткәннең киресен эшли. Боларга гына үзгә кирәк.

Кайсыдыр бер колхозны иң югары күрсәткечләргә ирештерергә, тышкы ягыннан да иң матур, иң төзек авыл итеп күрсәтергә хыяллана Тимергалиев. Районның даны булган «Сабанчы» кирәкми аңа, нәкъ менә «Яңа көч» кирәк. Дөрес, теләсәң кайсы колхозны күтәрергә, бөтен көчне аңарга тупларга булыр иде, тик «Яңа көч»тән башка бер генә колхоз да Морат Баяновичның күңеленә ятмый. Йә ул ун-унбиш чакрымга сибелгән бишәр-алтышар авыллы колхоз була, йә аның урыны чокырда, юллары, күперләре рәтле түгел. Ә «Яңа көч» сигез йөз йортлы бер авылдан гыйбарәт. Менә нәрсәдә хикмәт! Хуҗалыкның бары тик бер генә авылда булуы, кибетлә-

ренең дә, мәктәбенең дә, клубының да бер авылга тупланып, шуңа гына хезмәт күрсәтүе Морат Баяновичны ифрат дәрәҗәдә мавыктыра. Ул анда бөтен республикада дан тотарлык культура сарае, иң көчле урта мәктәп, иң зур терлекчелек комплексы булдырырга хыяллана. Стадион, ипподром, чабыш атлары, механизаторлар мәктәбе, тагын әллә нәрсәләр булдыруны күз алдында тота. Тиз арада. Үзе җитәкчелек иткән чорда.

Чәчүлек җире генә дә ун мең гектардан артык булган гигант колхозда, бер авылга урнашкан колхозда, бары тик анда гына җәеп җибәрә ала Тимергалиев колачын. Анда ул үзен күрсәтми икән, форсатны кулдан ычкындыра икән, аның өлкәгә күчү, өлкә күләмендәге җитәкче булу өмете җимерелә. Гомер уза, чәчләргә кырау төшә, күрми дә каласың — картлык капка шакый. Аннары син кемгә кирәк? Чакырырлар обкомга, әйтерләр: лаеклы ялга әзерлән, хөрмәтле Морат Баянович, диярләр.

Гомер кешегә бер генә бирелә, акыл адәм баласына соң килә. Өлгергән акылыңны үз вакытында файдалана белмисең икән, азактан терсәкне тешләргә туры килмәгәе...

## 2

Районнардагы иң авыр тармак — терлекчелек. Өлкә җитәкчеләре синнән сөт таләп итәләр, тугайларың бармы дип сорамыйлар. Тимергалиевнең райком ишегалдында терлек фермасы юк, ул үз нәүбәтендә таләпне колхоз рәисләренә куя. Менә шундый таләп куюларның берсендә Галинур Айтугановны сынап карарга булды секретарь. Ләкин беренче кеше итеп аңа ташланмады. Башта тәҗрибәлерәк бер председательнең кылын тартып карады. «Менә син бу кварталда сөтне сыер башына биш йөз граммга киметкәнсең. Ничек уйлыйсың, син аны үз инициативаң белән арттырасыңмы, әллә райком булышканны көтәсеңме?» Үз инициативасы белән арттырырга вәгъдә итә «келәмгә баскан» председатель. Чөнки ул белә: райкомның булышуы — урыныңны бушату дигән сүз.

Шул ук сорауны Галинур Айтугановка бирә Тимергалиев.

Торып баса яшь Айтуганов. Коеп куйган атлет: арка-җилкә куна чаклы. Табигать чибәрлектән дә мәхрүм итмәгән — кара бөдрә чәч, иркенәеп үскән калын кара кашлар астыннан томыраеп карый торган зур кара күзләр, матур итеп назлап үстергән кара мыек. Күзен дә йоммый, мыегын да селкетми әйтә бу: «Юк, Морат Баянович, бигайбә, буш вәгъдәләр чәчә алмыйм. Колхоздагы мең ярым баш сыерның сөтен тулаем яртышар килограммга арттыру өчен бик күп нәрсә кирәк бит. Иң әүвәл савымчы җиңгиләрнең, киленнәрнең, кызларның, янә дә килеп, населле бозау үстерүчеләрнең эшләү һәм яшәү шартларын тамырыннан үзгәртергә кирәк. Токым яхшыртуны фәнни нигезгә салырга кирәк. Кыскасы, дүрт-биш елсыз да ирешеп була торган нәрсә түгел бу». Демагог. Чатнап чыккан демагог! Токым яхшырту кирәклеген, әйтерсең, райком белми, ул гына белә. Башкалар аны хөрмәт итеп сөйләшә. Ә бу — табылган акыл иясе! Әнә бит яшьрәкләр аңа таба борыла, үзара пышылдаша: күрдең, янәсе, нинди кыю сөйләшә. Секретарьның күзенә карап турысын ярды да салды! Безгә дә, янәсе, үз акылыбыз белән яшәргә вакыт. Райком кубызына биеп йөрү җитәр!

Председательләрнең шыбырдавын өнәми Тимергалиев. Әгәр алга таба да шулай барса, районда минбеләмлек чире таралачак. Юк, моңа юл куярга ярамый. Котылырга кирәк яшь Айтугановтан. Бу эш никадәрле тизрәк эшләнсә, шулкадәрле яхшырак.

Ул чагында Тимергалиев эшлисе эшенең, уйлаган ниятенең ба-

рып чыгачагына шикләнми, чөнки бу эшнең инде бер өлгесе бар. Таулы Төбәккә килеп эшли башлаган беренче елында ук ул «Көрәш» колхозы председателе Җиһангировны бернинди мәшәкатьсез алып ташлады, аның урынына авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, байтак еллар шушы ук колхозда агроном булып эшләгән кешене куйдыртты. Эшен дә белә агроном, райком белән дә низагка керми.

Тимергалиев бер нәрсәне онытып җибәргән: «Көрәш» колхозында килеп туган хәл белән «Яңа көч» колхозындагы хәл бер үк түгел иде шул.

Колхозчылар Җиһангировтан туйганнар. Авылны культуралы итәм дип буш хыяллар белән йөргән Җиһангиров үзешчәннәр белән мәш килүдән башканы белми: клубта җырлыйлар, кыр станнарында бииләр, умарталыкта гармун кычкырталар, ә ферма каралтылары иске, терлекләр ябык, язын чәчәр өчен сортлы орлык әзерләнмәгән, тармак җитәкчеләрен бик кирәк чакта да табып булмый. Эленке-салынкылык, тәртипсезлек, төпле бер хуҗа булмау колхозны эчтән җимереп, таркатып килә.

Җиһангировны председательлектән алу турында сүз кузгалу булды — бөтен колхоз, яше-карты, дәррәү кузгалып, секретарьны яклады. Ә колхозның агрономы чагында әллә ни эш күрсәтә алмаган Курамшин, председательлеккә күчкәч, нык куллы хуҗа булып чыкты. Фермага коммунистлардан дежур тору оештырды. Мал-туарны кешечә карый, кешечә тәрбияли башладылар. Ә заманында узынган, берничек тә ипкә килми торганнарны ул идарәдә тикшереп тормады, яңа оешкан үзешчән коллективның яшь шагыйренә бурыч йөкләде:

— Ялкауларга, хөрәсәннәргә шундый итеп такмак чыгар, энем, мин аны тиешле җиренә үзем урнаштырырмын.

«Сатирик Мәтәлли» кушаматы алган өйрәнчек шагыйрь такмакларны бик тиз өлгертте, алар башта стена газетасында, аннары район газетасында басылып чыктылар:

Су буенда бакалар  
Баталар да калкалар,  
Чуеншәех егетләре  
Бот күтәреп яталар.

Кызлары да кызлары,  
Алсу алма йөзләре,  
Ялкауларга яр булгач,  
Акаядыр күзләре.

— Менә безнең үзешчәннәр шундый булачак,— диде Курамшин райком секретарена. «Олы юлның тузаны» белән «Галиябану»лар заманы узды. Утлы ракеталарны күккә чөйгән заман бу! Иманын чукыйм әле мин ул Чуеншәех хөрәсәннәренең!

Район газетасы битләрендә басылып чыккан такмакларның астына: «Мондый мактау сүзе бер Субаев Сөнгатькә, Бикмиев Шәйхенурга гына карамый, мондый «кыңгыраулы» егетләрне «Көрәш» колхозыннан тагын да табарга була әле, калганнарын газетаның киләсе санында бастырып чыгарырбыз»,— дип язылган иде.

Тимергалиев, такмакларны укыгач, рәхәтләнеп бер көлде. Курамшинга махсус шалтыратты.

— Карале, Хафиз, Чуеншәехтә бу такмакларны көйгә салучы юкмы?— диде. Исәбе — Курамшинның үтемле чарасын районның барлык колхозларына тарату иде.

Көйгә салдылар такмакларны. Чуеншәехләрдән башланган эш бик тиз башка авылларга да барып җитте. Тимергалиев сайлаттырган яңа председательнең исеме районга таралды.

Ләкин такмаклар никадәрле ачы булмасын, ярты елдан аларның тәэсире бетте. Чөнки теләсә нәрсәгә күнегергә була. Әйтик, үшән ат, чыгымчы ат, сыртын каеш чыбыркы белән ярсаң да, адымын

арттырмый, артыграк тырыша башласаң, чыгымчылап бөтенләй туктап кала.

Чуеншәехләр дә такмакка күнектеләр. Такмак өчен эштән алмыйлар, штраф та салмыйлар, бүтән эшләре юк икән җырчы чикерткәләрнең, тамак ерта бирсеннәр. Алар мунча сыерчыгы төсле чыр-чыр килеп йөргән арада, әллә нәрсәләр кыдырып ташларга була. Чуеншәехләрнең өстенә аварга торган урман бар, кулда куәтле «КамАЗ»лар бар — тик ятармы эчендә җаны булган адәм?! Тотынды Чуеншәехнекеләр урман урларга!

Халыкны сискәндерерлек бер гамәл кирәк иде.

Киңәшкә Тимергалиев янына барды Хафиз Курамшин.

— Әйтегез, Морат Баянович, нишлик, халыкны тәмам аздырып, караклыкка өйрәтеп киткән икән Җиһангиров,— диде ул.

Заманында район прокурорының ярдәмчесе булган Тимергалиев аңа әйтте:

— Чуеншәех халкында сүз йөри, минемчә, ул буш булмаска тиеш: Җиһангировның йорт астында бетонга катырган бик зур подвал бар икән. Ул анда Казан аркылы, Таулы Төбәк райпотребсоюзы аркылы дефицит товар ташып куйган, имеш. Минем белүемчә, ул Казанга йортын күчереп салырга йөри. Мин әйткәннәрне беркемгә дә чишмә, үзең генә бел, ярыймы? Җиһангиров Чуеншәехкә кайткалап йөри дип беләм, әнә шул дефицит товарларын Казанга ташып бетергәнче, аны шаһитлар алдында яктыга чыгарырга кирәк. Бу араларда өйдә тор, беркая да китмә. Прокурордан санкция алып, мин милиция җибәрермен. Тентү үткәрерләр. Тик кара аны, тентү вакытында авыл советы председателе, партком секретаре, син үзең, күршеләреннән өч пүнәтәй анда булыгыз. Төшендеңме?

— Төшендем, Морат Баянович. Ә чыкмаса?

— Чыкмаса, гафу үтенерләр.

Подвалдан бер йөздән артык машина шины, «Волга»ның запчастьлары чыгуын хәбәр иттеләр. Җиһангиров судка бирелде. Дөрес, аны утыртмадылар, ул судан коры чыкты: «Болар колхозныкы, мин югында урлап бетермәсеннәр, яңа председательгә үз кулым белән тапшырырмын дип өемдә сакладым»,— диде.

Секретарьның максаты Җиһангиров Әбүзәрне төрмәдә черетү түгел, Чуеншәехләргә аяусыз көрәш башлаганны төшендерү иде.

Галинур белән дә эшләр шулай җайлы барып чыгар дип уйлаган иде Тимергалиев. Кая ул! Чукмарлы халкы Айтугановны аяк терәп яклады.

— Персидәтелләрне аз күрмәдек без, әммә дәген берсеннән бер җылы сүз ишетмәдек. Галинур безгә кеше итеп карады, кеше итеп дәште, хәлебезгә керде,— абзарларыбызны печәнле, йортларыбызны утынлы итте. Рәхмәт аңа, мең рәхмәт. Бирмибез Айтугановны, бирмибез Галинурыбызны!— дип кычкырдылар.

Бик тә ышанып җибәргән агропром башлыгы Сәүбанов колхоздан беренче көнне буш кул белән әйләнеп кайтты.

Диңгезгә бер кергәнсең икән, йөзәргә кирәк.

Йөзмәсәң — батып үләсең.

Икенче көнне Тимергалиев Чукмарлыга Сәүбановны түгел, райкомның икенче секретаре Гайниевне җибәрде — Чукмарлы халкын белгән кешене, заманында Галинур белән бергә колхозда парторг булып эшләгән кешене. Гайниев, әлбәттә, тешен кысып кына риза булды һәм, билгеле инде, эшне бозып кайтты.

Өченче мәртәбәсендә, ниһаять, Тимергалиев үзе барды. Ике мәртәбә җимерелгәннән соң ул саграк эш йөртергә кирәген аңлады. Әгәр үз дигәнен итмәсә, җиңелеп кайтса, район алдында аның бәясе төшәчәк иде.

Ике мәртәбә тырышып та үзең теләгәнне башкарып чыга алма-

ганнан соң, шундый авыр хәлдә, председательне сайлау-сайламау хакында «Яңа көч» колхозчыларыннан кул күтәртү үзеңне упкынга ташлау белән бер булыр иде. Шуңа күрә ул гомуми җыелышны шундук җыйдыртмады, җыелыш алдыннан «Яңа көч»нең идарә членнарын һәм партия активын чакыртып, Галинур Айтугановның үзен анда кертмичә, киңәшеп алуны кирәк тапты. Менә монда ул үзенә ышана, чөнки монда коммунистлар, Таулы Төбәк райкомында учетта торган кешеләр иде. Алар мине екмаслар, алар мине аңларлар дип, килеп туган хәлне иплән кенә аңлатты Морат Баянович. Идарәне яңарту, председательгә яңа иптәшне сайлау халык файдасына булачагын кат-кат аңлатты. Искергән алымнар белән эшләп булмаячагын, үзгәртеп кору чоры башланганлыгын төшендерергә тырышты, үзеннән соң колхозның парторгы чыгар, парторгтан соң шушы авылда, шушы ук колхозда биш ел буе парторг булып эшләгән Гайниев авылны үз ягына аудара алыр дип көтте.

Алар икесе дә дәшмәделәр.

Бер күзен фронтта калдырып кайткан Вәдүт Ибраһимов, мәктәп директоры, сүз алды.

— Морат Баянович, менә мин сезне игътибар белән тыңладым. Аңларга бик тырыштым, ләкин гафу итегез, аңлап җиткерә алмадым. Председательне алмаштырудан безгә нинди файда киләчәк? Яки сораулы башкачарак итеп куйыйк: алмаштырмаудан нинди зыян күрәбез? Сезгә докладывать иткәннәрдер инде, ике көн буена, унар сәгать утырдык культура сараенда, Галинур Фәһимович Айтугановны җибәрергә теләми бит халык. Теләми, нишләтәсең аларны, камчы белән суктырасыңмыни?! Димәк ки, Галинур Айтуганов буш чикләвек түгел. Рухи зурлыкмы, зирәклекме, әллә халыкка карата ягымлылыкмы — ниндидер сөйкемле сөяге бар аның. Ә без моның белән санашмый булдыра алабызмы? Мин беләм, сез, Морат Баянович, Чукмарлыга начар ният белән килмәгәнсез. «Көрәш» колхозының бик тиз күтәрелүе кирәк сезгә, республикада дан алуы. Туктагыз, уйлашып карыйк, илле өченче елның сентябрь Пленумыннан башлап текә күтәрелеш турында сөйлибез, Үзәк Комитет ике пленумның берсен авыл хуҗалыгын күтәрүгә багышлый — күтәреләбезме? Күтәрелми авыл, кемне генә куйсагыз да күтәрелмәячәк. Ә Галинурда әтисенең каны, әтисенең акылы бар, колхозны ул ашыкмый гына, иплән кенә күтәрелешкә алып барырга тели. Нәкъ шулай. Әтисе бит иң авыр елларда, өстән акырып-бакырып торган чакта да зиһенен җуймады, үзенчә эшләүдән туктамады, бәлки, безнең Галинурыбыз да безне тыныч-сабырлыгы белән, алдын-артын уйлап эшләве белән олы юлга алып чыгар. Мин аны бездә эшли башлаганнан бирле, сигез ел буе күзәтеп киләм. Тимик без аңа. Калдырыйк бер юлга, эшләсен. Алга таба күз күрер, тарта алмый икән, алыштырырбыз. Үзебез ук яклашырбыз сезне, Морат Баянович.

Киңәшмәдәгеләргә ошады директорның сүзе. Моны сизде Тимергалиев,— тик ул аларның перспектива белән яшәмәүләрен, бер көнлек кенә рәхәткә бирелүләрен, үз мәнфәгатьләре өчен генә тырышуларын әйтте.

— Ә райком? Сезнеңчә, райкомның авторитеты бер тиенгә дә тормыймыни?— диде ул, кискен итеп.

— Мәсьәләне болай кую дөрес булмас, иптәш Тимергалиев,— дип, Вәдүт Ибраһимов кискенрәк тонга күчте:— Партия исеменнән сөйләүчеләрне күргән бар безнең. Үзенең шәхси мөнәсәбәтен яки бәясен партия бәясе дип җиткерергә теләгәннәрне дә, шөкер, күрмәдек түгел, күрдек. Андый чор узды. Гафу итегез мине, карт коммунистны, фронтовикны, Морат Баянович, әгәр дә мәсьәләне сез шулай административ төстә куясыз икән, без гомумән дә җыелышны үткәрүдән баш тартабыз. Җыелышны үткәрсен ул чагында обком вәкиле.

Аның соңгы сүзләре Тимергалиевкә бик авыр кагылдылар.

— Мин моны көтмәгән идем сездән, көтмәгән идем, фронтовик иптәш. Сез бит алгы сызыкта, ут эчендә булган кеше. Сезнең өчен бер кешенең интересы райком хәтле райком интересыннан өстенрәк булып чыгар дип уйламаган идем. Болай булгач, мин мәсьәләне райком бюросына куярга мәҗбүрмен.

— Бу нинди куркыту?— диде кемдер.— Райком белән куркыту заманы узмадымыни әле? Без үзгәртеп кору заманында яшәмибезмени?

Вәдүт Ибраһимов ярсынучыны җиңелчә кул хәрәкәте белән туктатты. Идарә бүлмәсендә гадәттән тыш тынлык урнашты. Тимергалиев чигә турысында кайсыдыр бер тамырның сулкылдавын тоеп, кешеләргә күз салды. Барысы да тын утыралар. Авызларына су капканнар. Ник дәшмиләр?

Идарә йортындагы тынлык җанын баса башлагач, секретарь түзмәде, Ибраһимовка үзе мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булды:

— Нишләп тынып калдыгыз, фронтовик иптәш? Әллә райком бюросы алдына басудан курыктыгызмы?— диде.

Ибраһимовның теле бу юлы усаллык белән ачылды:

— Без, Морат Баянович, большевикларча сөйләшмибез, минемчә, Сталин һәм аның ялчылары аркага мылтык терәп сөйләшкәнчә сөйләшәбез. Аңлату, ышандыру юлын сайлагыз, дип әйтә түгелме соң бүген безгә яңа заман? Әгәр инде сез, шул хакыйкатьне инкарь итеп, колхоз коммунистларының и шулай ук колхоз җыелышының, бер мәртәбә генә түгел, ике көн рәттән уздырылган җыелышның ихтыярын санга сукмыйча, безгә үз ихтыярыгызны көчләп тагарга телисез икән, әйтегез туп-туры, ул чагында безнең юллар аерым.

Мондый атмосферада колхоз җыелышын җыю мәгънәсезлек икәнен аңлады Тимергалиев, җанында җиңелү хурлыгы алып, райүзәккә кайтты. «Нүжәли Чукмарлы халкын җиңәрлек көч юк миндә?» — дип сыкранып уйланды.

## 3

Бер атнадан Сәүбанов аның төзәлеп килә торган ярасына тоз сипте:

— «Сабанчы» белән «Яңа көч» тирәләрен әйләнеп кайттым, Морат Баянович. Халык гел сезнең хакта сөйли.

— Нәрсә дип сөйли?

— Тимергалиев хаклы түгел иде, шуңа җиңелде, диләр.

Йотты бу хәбәрне Тимергалиев. Нервысына кисәк китереп сукса да йотты. Халыкның авызын бүрек белән томалап куеп булмый — хәбәрдарлык заманы. Әллә Галинурның үзен чакырып сөйләшергәме? Аңа җайлы урынны Таулы Төбәктән дә табып була бит. Чукмарлыга ябышып, катып калса, ул бит акыллы булмый. Таулы Төбәктән бит ул Казанга тизрәк үрмәли ала...

Болай турыдан-туры әмер белән чакыру килешмәс, сүз тагын да куера төшәр. Сөт тапшыру буенча Тимергалиев председательләрне кабат җыйдыртты. Киңәшмәне үзе түгел, Сәүбанов алып барырга тиеш дип тапты. Менә кайтып әйттеңме ямьсез сүзне, әйттең, үзең алып барып кара әле. Ныклыгыңны күрсәт әле бер!

Башка чакта Морат Баянович «тор-утыр» алымыннан канәгать булып кала, эшләрнең алга китәчәген «келәмгә басучылар»ның күзләреннән күрә иде. Бу юлы ул күңелендә нәрсәнеңдер чатнаганын, җанында икеләнү тойгысы уянганын сизде. Моның сәбәбен тонык кына булса да сизенә иде ул. Келәмдәге геройга шелтә биргәнне шыгаеп тыңламады председательләр, чөнки Галинурны алып ташларга теләп тә булдыра алмавы секретарьның абруена бик нык суккан,

Галинур Айтуганов аның бавырына кара таш булып утырган иде. Ә председательләр нигә сансызланалар? Киңәшмәдә көн батыры утыра — Галинур Айтуганов. Шунда ук аның әтисе, өлкән Айтуганов та бар. Алар үзләрен бик иркен тоталар, алардан бәйсезлек рухы бәрелеп тора. Әнә шул бәйсезлек рухы башка председательләргә дә йокмый дисеңме? Аларның күңелендә бер уй: «Әнә бит Галинурны урыныннан алырга Тимергалиев үзе барган, пычагымны да кыра алмаган. Безгә дә берни дә булмаячак. Узды ул председательне райком кубызына биеткән чаклар!..»

Маңгаен угалап, маңгай өстенә сибелгән тыңлаусыз чәчләрен әледән-әле кулы белән артка сыпыргалап, өстәл янында утырды Тимергалиев. Зур бәдәнле гәүдәсе белән ара-тирә торып та баскалады, өстәл тирәли йөренеп тә алды. Тавышын күтәреп, сөйләп тә алды, тик күңеленнән һаман бер уй китми азаплады: аны тыңламыйлар, аңа игътибар итмиләр, аны санга сукмыйлар...

Айтугановларны алып калып, аерым-аерым сөйләшергә кирәк булыр. Фәһим Сабирҗанович ни уйлый? Галинур «Яңа көч»тә үткәргән җыелышлардан соң яңа бер фикергә килмәгәнме? Башта кайсысы белән сөйләшергә: әтисе беләнме, улы беләнме? Мөгаен, әтисе белән кирәктер.

Өлкән Айтуганов белән сөйләшүе аңа гел уңайсыз була. Фәһим Сабирҗановичта аксөяк нәселләрдән килә торган бер затлылык бар. Үзе югында ул аның хакында шактый ук ямьсез уйласа да, каракаршы утыргач, ихтыярсыздан, үзе дә аңламастан, ул аңа карата ихтирамлы, олылап караумы кебек бер халәт сизә.

— Гафу итегез, Фәһим Сабирҗанович, сезне райкомда эшләргә чакырганнары булмадымы?— дип сорап куйды Тимергалиев.

— Чакырдылар гына түгел, мин анда алты-җиде ай эшләп тә алдым,— диде Айтуганов, елмая биреп.

— Киттегезме аннары?

— Киттем. Ул минем урын түгел.

— Алай икән. Хәлләрегез ничек, Фәһим Сабирҗанович? Бураннар бик комачауламадымы?

— Бураннар дип, аларның нинди комачавы булыр икән? Киресенчә, файдалары булды, Морат Баянович. Кырда кар тоттык. Казан газовиклары, халык өйдә утырудан файдаланып, Балдамар йортларына газ миче чыгардылар.

— Әллә бетердегез дәме ул эшне?

— Юк әле. Өч авылда гына бетердек. Тагын дүрт авыл бар, алары кечерәк авыллар. Ихтимал, быел, исән-сау булсак, җәйгә тәмамлап та куярбыз.

— Мал-туарны кышлату яклары ничек? Сөт артамы? Бүген сезне кузгатып тормадым инде, Фәһим Сабирҗанович. Сезнең дә бит нормага тулмый сөтегез.

— Тулыр дип өметләнәбез. Менә сенажның бер траншеен ачтык. Сутлы азык, бәлки, арттырып та куяр сыерларның сөтен...

— Тутыра күрегез. Яшьләр бит сездән үрнәк ала. Айтуганов булып Айтуганов тутырмагач, безгә нәрсә кала, диләр.

Фәһим абзый әкрен генә көлеп куйды.

— Ул сөт ди-ди менә бу чәчнең соңгы бөртекләре дә коелып бетте инде, Морат Баянович. Бер йөз грамм сөтне арттырту өчен райком пәрәме тиресеннән чыга, ниләр генә кыланмый егетләрегез. Шул саннар астында кеше югала бит, кеше онытыла.

— Беләм,— диде Тимергалиев, аңа туп-туры карап.— Бездән обком, сездән райком таләп итә.

— Булыр ул, Морат Баянович, булыр. Вакыты җиткәч, дип әйтүем. Бүген белән генә торып булмый бит. Бүгенгене перспектива аша карарга кирәктер безгә.

Аны мөмкин кадәр тыныч чырай белән, кулын иягенә таянып тыңлады секретарь. Галинур мәсьәләсенә күчәр вакыт җитте, дип уйлады. Юкса бу тәҗрибәле кешенең түземе чамасыз. Ул үз улы хакында бер мәртәбә, юл уңаенда гына сүз кузгатты. Бүтәнчә авыз ачып сүз әйтмәячәк. Колхоз хәлләрен сөйләр, кешеләрен күккә күтәрер, комбикорма сорар, төзү материаллары, улына кагылмас.

— Әйтегез әле, Фәһим Сабирҗанович, «Яңа көч» колхозында булып узган хәлләрне сез ничек бәялисез?

— Аны бит мин түгел, райком бәяләргә тиеш.

— Шулай да... тәҗрибәле кешенең, ветеранның сүзен ишетәсе килә.

— Мин ул хәлне очраклы килеп чыккан нәрсә дип карамыйм, Морат Баянович. Илдә кискен борылыш бара. Көн дә сөйлибез шул хакта, төн дә сөйлибез. Зәңгәр экраннан да сөйлибез, эфирдан да. Тамырдан үзгәртү, дибез. Әгәр сез бер ел эчендә биш председатель алмаштыруны тамырдан үзгәртү дип карыйсыз икән, ул — сезнең эш. Миңа калса, тамырдан үзгәртү — кешенең ирекен бумау.

— Ул чаклысы аңлашыла. Теоретик яктан караганда, сез әйткәннәр дөрес. Ә конкрет очракта менә... әйтик, сезнең улыгыз, коммунист кеше, райком ихтыярына буйсынырга тиеш идеме?

— Сезнең таләпләрне дөрес дип тапкан сурәттә, әлбәттә, буйсынырга тиеш иде. Мин улымны, Морат Баянович, халыкка таян, халык сүзен аяк астына салма, дип өйрәттем. Белүемчә, аны халык җибәрергә теләмәгән. Ул халык ихтыярына буйсынган. Ә безнең партия Уставында нәрсә диелгән? Коммунистлар партиясе халык мәнфәгатен кайгырта, шуның өчен яши, диелгән бит.

— Сез, димәк, улыгызга хәзер кит дип тә, китмә дип тә әйтергә теләмисез?

— Юк, теләмим. Аның үз акылы бар. Унбиш ел инде ул партия сафында, сигез ел хуҗалык эшендә. Әгәр мин аңа нидер әйтеп, аны гел өйрәтеп торсам, райком эшенә тыгылган булыр идем.

«Бүре бу. Азау тешен ярган бүре!» — дип нәтиҗә ясады Тимергалиев. Әмма уйлаганын телдән әйтмәде:

— Яхшы. Сезнең бу мәсьәләгә карашыгыз хәзер ачык миңа. Рәхмәт җитди уйлавыгыз, уегызны әйтеп биргәнегез өчен. Рәхмәт. Улыгыз Галинур белән тагын бер мәртәбә, бу юлы икәүдән-икәү генә сөйләшеп карасам, сез каршы килмәссезме?

— Ю-ук, булмаганны! Нишләп каршы килим ди. Ул бит сездә учетта тора. Аның белән сөйләшү өчен әтисенең рөхсәтен сорау кирәкмидер...— Айтуганов ягымлы итеп елмайды, аннары йөзенә борчылу галәмәте чыкты, маңгаена тирән-тирән ике сызык ятты.— Дәүләт эшен сөйләштек, Морат Баянович, дөнья хәлләрен дә белик инде. Улыгызның хәбәре бармы?

— Кайсы улымның?

— Әфганстандагы.

Тимергалиевнең караңгы тонык чыраен әллә ниткән бер нур сызып алды. Аның гел дә җитди-кырыс булуына күнеккән Айтугановка хәтта бер генә мәлгә сәер дә булып китте.

— Рәхмәт игътибарыгызга, Фәһим абзый. Артурыбыз исән, кичә хаты килде. Тауларда йөрибез, күңел тыныч түгел, Әфган мөҗәһитләре бик мәкерле, дигән. Менә шунысы күңелне тырнап тора. Әнә бит тимер табутлар безнең районга да кайткалады...

— Бала һәркемгә дә газиз, Морат Баянович,— диде Айтуганов, аннары кирәгеннән артыграк утырганын абайлап:— Ярар, мин китим, иптәш секретарь, Галинурны чакырыйммы? Кирәкме ул сезгә?— диде.

— Чакырыгыз,— диде Тимергалиев, әүвәлге җитди чыраена кайтып.

Тимергалиев яшь председатель белән әллә ни тәкәллефләнеп тормады: колхоз хәлләрен дә сорашмады, аңа хәтта утырырга урын да күрсәтмәде.

— Йә, Галинур Фәһимович, ничек? Биш көн вакыт узды, синең күңелгә яңарак берәр уй килмәдеме?

— Юк,— диде Галинур тыныч, әмма нык тавыш белән.— Халык минем китмәвемне сорады. Мин аның ышанычын аяк астына салып таптый алмыйм.

— Ярый, алай булгач, бүтән йомышым юк,— диде Тимергалиев дәрәҗәсен саклап. Ә үзе күңеленнән: «Китсә ни булган? Барыбер сындырам бит. Келәмгә сырты белән салам. Вакыт кына кирәк»,— дип уйлады.



4

Данияр Дәминев «Яңа көч» колхозына эшләрнең бик кайнар вакытында килеп төште. Баш бухгалтер ярдәмчесе Асия Харисова агу эчкән һәм аны Таулы Төбәк больницасына озатканнар.

Шул уңайдан колхозга халык тикшерүчесе килгән. Райком секретаре Тимергалиев белән агропром башлыгы Сәүбанов та биредә икән.

Галинур Айтуганов, бәлки, шуңадыр, Даниярны иркенләп каршылый алмады, җәелеп сөйләшергә вакыты булмады, ул аны колхозның кунак йортына илтеп урнаштырды да, гафу үтенеп, китеп барды.

Даниярга, әлбәттә, иң әүвәл председатель белән сөйләшү кулай булыр иде. Ни хәл итмәк кирәк, председатель бик авыр хәлдә торып калган, аның өчен хәзер корреспондент белән әңгәмәләшү түгел, килеп туган хәлне, авылдагы көтелмәгән киеренкелекне бетерү мөһимрәктер. Өлкән Айтуганов бит Даниярга әйтте, Галинур эшләгән колхозда тоташ киеренкелек тудырып торуны райком үзенә максат итеп куйган.

Данияр, беренче эше итеп, киеренкелек зонасыннан райком секретарен аерып алу, шуның белән аз гына булса да, Галинурны кичке сөйләшүгә әзерләүне үзенә бурыч итеп куйды.

Тимергалиевне ул идарә йортыннан эзләп тапты. Райком секретаре, Сәүбанов белән бергә, идарә урнашкан кабинетта Галинур Айтуганов белән бик кызу бәхәс алып бара иде.

Шакымый-нитми керде Дәминев кабинетка, ә анда утыручылар рөхсәтсез бирегә кем бәреп кергәнен аңлап җиткергәнче, райком секретаре янына килеп басты да:

— Мин сезне райүзәктән эзлим, иптәш Тимергалиев. Ә сез менә кайда качып ятасыз икән...— дип сүз башлады.

— Кем сез?— диде секретарь, ачуы килеп.

— Мин Дәминев булам. Корреспондент. «Советская Россия»дән.

Секретарь йомшый төште:

— Ни йомыш?

— Сезнең өстән жалоба бар, иптәш секретарь.

— Нинди жалоба?— дип, Тимергалиев председатель ягына күз сирпеп алды: таптың, янәсе, жалоба хакында сүз куертыр урын...

— Мин гостиницага урнаштым. Әгәр бүген кич вакыт тапсагыз, без мәсьәләне уртага салып сөйләшер идек.

— Безнең вакыт юк. Бүген кич без Таулы Төбәккә кайтабыз,— дип, арага килеп кысылды Сәүбанов.— Сез әллә ул хакта онытып җибәрдегезме, Морат Баянович?

— Онытмадым,— диде Тимергалиев.— Без бүген, әлбәттә, райүзәктә булырга тиешбез. Әйдәгез, иптәш Дәминев, Таулы Төбәктә очрашыйк.

— Кайчан?

— Иртәгә.

— Булмый. Мин иртәгә көне буе Чукмарлыда булам. Сөйләшәсе кешеләрем бар.

— Ә берсекөнгә?

— Берсекөнгә иртүк Казанга китәм, аннан Мәскәүгә. Редакция миннән җавап көтә.

— Ярар, кичкә чаклы вакыт бар,— диде инде хәл җыеп өлгергән Тимергалиев.— Кем белә, бәлки, кичен очрашып та куярбыз.

— Ихтыярыгыз. Очрашу минем өчен булудан бигрәк сезнең өчен кирәк,— дип дәрәҗәсен саклап әйтте Дәминев һәм, кабинеттагылар зиһеннәрен җыеп өлгергәнче, чыгып та китте.

Ул көннең көн буе кунак йортында утырды: колхоз председателе сигез ел эшләү дәверендә ел саен ясаган отчетларны укыды, кирәкле документларны, канцеляриягә шалтыратып, соратып алды. Редакциягә хат язган кешеләрне берәм-берәм үз янына чакырып сөйләшкәнче, колхозның нинди сулыш белән яшәгәнен тою, килеп туган хәлне акылы аша үткәрү мөһим иде аңа.

Кунак йортының ялгыз бүлмәсендә үз уйларын уйлап, тәмәке төтененә күмелеп утыра иде, ишектән кубанкалы, киез итекле утыз яшьләрендәге берәү килеп керде.

— Гафу итегез, корреспондент Дәминев биредә дигәннәр иде. Сез аның кайсы бүлмәдә яшәгәнен әйтә алмассызмы?

— Әйтә алам. Ләкин сез кем буласыз? Башта без шуны белик.

— Мин Рамай Мансуров булам. Минем максат... Туктагыз әле, мин кем белән сөйләшәм соң?

— Азапланмагыз. Корреспондент мин. Узыгыз, утырыгыз. Ник килдегез?

Керүче бермәлгә каушабрак калды.

— Мин шушы колхозның парторгы...— диде ул, ишек төбендә таптанып.

— Алайса, өстегезне салыгыз. Мин әле сезнең янга үзем керергә тора идем, килеп яхшы иткәнсез.

Керүче киез итектән идәнне ерып уза алмый, ә итекне ул чолгау чорнап кигән, аягыннан салса, яланаяк калачак иде.

Дәминев аңа өйдә кия торган йомшак киез башмаклар китереп биргәч, ул шулай да аягыннан салды, чолгауларын итек эченә тыгып куйды, өй башмакларын аягына эләктереп, өстәл янына килеп утырды, күп булып чәчелеп яткан кәгазьләргә күз ташлады.

Дәминев кухня ягыннан ике стакан кайнар чәй алып чыкты.

— Әйдәгез, чәй эчә-эчә сөйләшик, минем бүтән нәрсә юк,— дип көлеп куйды ул.

Такыр башлы, киңчә битле парторг, суыктан кызарган көрәк чаклы куллары белән кайнар стаканны учлап утырды.

«Үтә чыккан беркатлы адәмгә охшап тора бит әле бу, чүчинкәсен дә оекбашсыз гына киеп килгән, куллары да бияләйсез-нисез кызарып чыккан, моның белән минем борчак пешәр микән?»— дип уйлады Данияр. Әмма күңелендә оешып җиткән уйларын ул Рамай Мансуровка әйтергә ашыкмады, сүз башлап җибәрер өчен:

— Сезнең тулы исемегез Рамаймы, Рамазанмы?— дип сорады.

— Кенәгәгә язганы Рамазан инде аның, үскән чакта малайлар Рамай дип йөрттеләр дә Рамай булып калдым инде мин,— дип эре таза тешләрен күрсәтеп елмаеп куйды Мансуров.— Ә нигә?

— Юк, болай гына. Язасы-нитәсе булса дип соравым. Исемемне бозганнар дип үпкәләп йөрергә калмасын.

Данияр шул сүзе белән килгән кунакның күңелен күтәреп, тартынып-нитеп тормаслык хәлгә китерде.

Чәй эчә-эчә сөйләшеп киттеләр.

Данияр беренче эше итеп парторгка аларның колхозыннан газетага җибәрелгән хатны күрсәтте.

— Сезнең эшме? Таныйсызмы?— диде.— Мөнә бу сезнең имзамы?

— Безнең эш. Минем имза. Җавап ник юк икән дип борчыла ук башлаган идек инде. Югыйсә райком быел артыгын кылана, перәме кыса безне. Барлык колхозларга да комбикорма өләшеп чыктылар, безгә — юк. Төзү материаллары да быел безгә тәтеми. Семинарларга барганда райкомның беренче секретаре миңа гел кырын карый. Бер үк эшне эшләп, бер үк йөкне бергәләп тартып та, сине үги бала сыман гел кагып торсалар, авыр була икән ул. Эшкә кул бармый. Кәеф кырыла. Гаделлекнең кайчан да булса өскә чыгарына ышанмый башлыйсың. Әгәр дә тоташ шулай бара торган булса, без, «Яңа көч» колхозы коммунистлары, Таулы Төбәк райкомына ышанмавыбыз хакында партия Үзәк Комитетына коллектив хат язарга мәҗбүр булачакбыз.

Корреспондент Дәминев — каршысында утырган зур куллы, киңчә битле Мансуровка, үтә дә беркатлы булып күренгән авыл кешесенә, төбәлебрәк карарга мәҗбүр булды. Ул аның чыраенда, коңгырт күзләренең кысыла төшүендә, чәйле стаканны бушатканнан соң өстәлгә терсәге белән таянган уң кулының йомарлануында тәвәккәллек күрде. Юк, бу беренче карашка гына примитив булып күренгән икән. Хезмәт кешеләренә хас ныклык, үз дигәнен эшләми калмый торган үҗәтлек, яхшы мәгънәсендәге үҗәтлек Данияр күңелендә аңа карата теләктәшлек уятты. Моның белән барлык мәсьәләне уртага салып, ачыктан-ачык сөйләшергә була түгелме?

— Иптәш Мансуров, сез миңа әйтегез әле: Галинур Айтуганов сездә ничә ел эшли?

— Мин моны күзне йомып та әйтеп бирә алам. Төп-төгәл сигез ел да дүрт ай. Ни өчен шулкадәр кистереп әйтәм? Чөнки нәкъ сигез ел да дүрт ай элек минем улым, төпчек балам, туган иде. Галинур, председатель булып сайланган көнне үк мине, хатынымны котлап, безнең өйгә килде. Үзе белән идарә члennарын да алып килгән иде. Мин ул чакта парторг түгел идем әле, бездә парторг булып ул елны Гайниев эшли иде, райкомның хәзерге икенче секретаре. Хәтерлим, Гайниев тә килгән иде безгә. Бик хөрти генә өйдә яши идек әле, тузган иде эти сугыш алдыннан салып кергән йорт. Сүзне барысы исеменнән Гайниев әйтте, ул безне икенче улыбыз туу белән котлады һәм «Яңа көч» колхозының механизаторына председательнең дә әйтер сүзе бар, диде.

— Син минем кордаш буласың икән, Рамай Мансуров,— диде яшь председатель. Барлык кешедән дип әйтсәм, арттыру булыр, һәрхәлдә, идарә члennарының барысыннан да сорашып чыктым, сине намуслы кеше, диделәр. Шуңа күрә без идарәдә хәл кылдык, быел сиңа колхоз хисабына йорт салып бирергә! Ә хәзергә эти кеше белән әни кешене икенче улыгыз туу белән котлыйбыз, таза булып, игелекле булып үссен балаларыгыз!— диде.

Валлаһи дип әйтәм, мин Галинурга кадәр безнең авылда председатель белән парторгның кешеләрне бала туу белән котлаганнарын хәтерләмим. Чукмарлы халкы — каты бәгырьле халык, берәүгә дә, шөкер, баш биреп яшәмәде, әмма Галинур килгәч, үзгәрде кешеләр, ничектер ягымлырак булып киттеләр дип әйтимме?

— Әгәр мин дөрес аңлаган булсам, Галинур Айтуганов халыкны кешелекле булуы белән үзенә тарткан?

— Нәкъ өстенә бастың, корреспондент иптәш, кем әле, Дәминев.

— Яхшы. Шулай дип язып куябыз: «Яңа көч» колхозының председателе җир кешеләрен, игенчеләрне ихтирам итә. Монысы — әйбәт. Ә сүзендә тора беләме? Әллә ул дәрәҗәсен күтәрер өчен генә йорт салам дип вәгъдә бирдеме?

— Вәгъдәсендә торды: бер ел эчендә без йортка кереп утырдык.

— Молодец! Тагын бер сорау: аның этисе белән нинди уртак сыйфатлары бар?

— Уртак сыйфатларын әйтә алмыйм. Алар, миңа калса, икесе ике кеше. Фәһим Айтугановта — крестьян үҗәтлеге, хәйләкәрлек бар, ул җиде кат үлчәми торып бер кат та кисми. Ул теләсә кемнең теләсә нинди сүзенә мөкиббән китми. Галинур ышанучан. Өстәвенә — фантазер. Аның күңелендә бер тәүлек эчендә әллә ниткән хыяллар туа, ул хыялларын теләсә кем белән уртаклаша. Ул нәкъ менә кирәкле урынында Тукайны, Такташны, Туфанны яттан әйтеп бирә ала. «Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадерен белү?» кем шигыре? Тукайныкы. Сора син шуны берәр райком секретареннан — әйтә алмаячак. Минемчә, партия эшендә эшләгән кеше яз килгәнне беренче башлап тоярга, авылда ата каз каңгылдаганны беренче булып ишетергә тиеш. Авылда яңа туган бала тавышы аңа музыка булып тоелырга тиеш. Әгәр партия работнигы сандугач сайраганга сөенә алмый икән, кырларны тутырып шаулаган игеннәрне җаны белән тоймый икән, аны партия эшендә эшләтмәскә кирәк. Ә чынында партия эшендә кемнәр эшли — карьеристлар, үз тормышларын башкаларныкына караганда матур итеп күрергә теләүчеләр.

— Ә Тимергалиев?

— Нәрсә Тимергалиев?

— Ул да карьеристмы?

— Мин хәзер үк аңа тулы характеристика бирә алмыйм. Әмма безнең колхозга булган мөнәсәбәтендә ул үзен гадел җитәкче итеп таныта алмады.

— Стоп! Моны рәнҗегән як сөйли. Ә, бәлкем, Айтугановны ул көчлерәк кеше белән алыштырырга теләгәндер? Бәлкем, аның шундый кандидатурасы бардыр?

— Юк аның андый кандидатурасы. И була да алмый. Председательләр күктән төшми. Аларны еллар буена тәрбияләргә кирәк. Мин сезнең «Сабанчы»дан килгәнегезне беләм. Андагы отчетларны карамый калмагансыздыр. Без ел саен Галинур белән икәүләшеп аның этисе Фәһим абзый ирешкәннәрне үзебезнең уңышлар белән чагыштырып карыйбыз. Галинур Айтуганов этисе кырык ел эчендә ирешкәннәрне сигез елда яулап алды.

— Ә нишләп, алай булгач, аның исеме шауламый, этисенең исеме шаулый?

— Чөнки әле аның миллион сумнарга төшереп салдырган терлекчелек комплексы юк, автомат җайланмаларга корылган ындыр табагы юк, картлар йорты, аптекасы, больницасы юк.

— Ә ни өчен юк?

— Чөнки Галинур беренче дүрт ел эчендә үзенә кадәр эшләгән председательнең бурычын — ике миллион сумны дәүләткә түләде. Тагын дүрт елдан ике миллион саф табыш җыйды. Без аңа ышанабыз. Барлык колхозчылар ышана. Райкомда Галинурга сыер башына ярты литр сөтне арттырмаганы өчен кырын карыйлар. Юк, күз буяуга бармаячак Айтуганов Галинур, бармаячак, муенына бау салсалар да... Чөнки ул Фәһим малае, фронтовик малае, чөнки ул ялганны белми. Былтыр безне райкомнан кыстылар, ашлыкны тулы кондициягә китереп тапшыру мәҗбүри түгел, ул эшне заготзерно үзе башкарыр, диделәр. Өлкән Айтуганов та, кече Айтуганов та ул эшкә бармады. Райкомның, әлбәттә, ачуы килде, чөнки ике Айтуганов, алардан күрмәкче тагын башка колхозлар икмәкне киптереп тапшыру аркасында районның дәүләткә икмәк сату заданиесен өзделәр, Таулы Төбәк шул сәбәпле алга сикереп чыга алмады. Тимергалиев безгә куеныннан йодрык төйнәп калды. Ул, әлбәттә, өлкән Айтугановка түгел, яшь Айтугановка ташлана, чөнки өлкән Айтуганов — каты чикләвек, ул депутат, аны республика гына түгел, ил белә. Ә яшь Айту-

ганов әле көч җыйнап кына килә, ул әле зур бер сикерешне ясарга җыена гына. Инде менә аны урыныннан алып ташларга ашкына Тимергалиев, без Галинурны бирмәгәнгә тешләрен шыгырдата. Мин шул Чукмарлы халкын җиңмәсәмме, ди. Җиңмәячәк! Утны кәгазьгә төреп асрап булмаган кебек, гаделлекне дә яшереп асрап булмый...

— Яхшы, Рамай, әйт әле миңа: ашлыкны киптереп бирү белән сез нәрсә оттыгыз былтыр? Рас аны заготзерно үзе киптерергә алынган икән, әшли бит инде ул аны, ә сез райкомга юри каршы килүчеләр булып чыгасыз түгелме соң?

— Юк, корреспондент иптәш, дөрес сүз сөйләмисең. Моңарчы сүздә бер нәрсә әйтелде, гамәлдә икенче нәрсә эшләнде. Без аның шулай икәнен ун мәртәбә, йөз мәртәбә, мең мәртәбә күргән. Киптермәячәкләр, дидек без, игенне. Алдан күреп әйттек. Тәки шулай булып чыкты да...

— Ничек, киптерелмәгән килеш калдымыни икмәк?

— Калды гына түгел, тонна-тонна икмәк элеваторда юеш килеш калып янды, пычкы чүбенә әйләнде.

— Сез моны каян белеп әйтәсез? Кем җиткерде сезгә бу хәбәрне?

— И аллам, райком секретаре белән Сәубанов ашыгыч рәвештә Таулы Төбәккә китеп бардылар. Үзәк комитеттан халык контроле килеп төшкән, черегән, кара янган бодайны нишләтергә икәнен хәл итәләр бит анда бүген...

— Ә Галинур?

— Аны да алып киттеләр.

Бу хәбәр Дәминевкә яшен суккандай тәэсир итте. Менә ни өчен райком секретаре аның белән сөйләшергә теләмәгән икән...

— Ә нигә Галинурны алып киттеләр анда? Сез бит икмәкне киптереп тапшырган кешеләр...— диде Данияр.

— Бөтен хикмәт тә шунда шул: әгәр барысы беравыздан, райком әйткәнгә кушылып, ләббәйкә дип торсалар, дәгъвасы да чыкмас иде аның. Нәкъ менә Айтугановлар чи килеш тапшыруга каршы чыкты. Халык контроле, күрәсең, ул хакта хәбәр иткәннәр. Айтугановларны халык контроле шаһит итеп чакырган.

— Алай булгач, Тимергалиев сезнең колхозны... әгәр ул үзе бу бәладән исән-сау котылса, иң явыз дошманы, аны егарга тырышучы дип таныячак.

— Һичшиксез! Менә шуннан соң хикмәтләр башлана инде,— диде парторг Мансуров.— Шуннан соң яшәү көрәше түгел, үлем уены башланачак.

## 5

Дәминев икенче көн җиткәнне көтте. Галинур Таулы Төбәктән кайтыр, хәлләрне аңлатып бирер дип көтте. Аңа Галинурны күрү бик кирәк, икәүдән-икәү генә әңгәмә кору аның өчен бик мөһим иде.

Юк кайтмады Галинур. Икенче көнне иртән дә, хәтта кичен дә кайтмады. Димәк, аны җибәрмәгәннәр.

Данияр көнне тоташ кәгазь актарып кына үткәрә алмый, хатка кул куйган тагын берничә кешене күреп сөйләшү кирәк иде аңа. Бригадир белән, сыер савучы кызлар белән сөйләшү парторг Мансуров сөйләгәннәрне тулысынча раслады — алар председатель Айтугановның халык кайгысын кайгыртуын бик тә үз итеп, яратып сөйләделәр, әгәр райком, элекке еллардагы сыман, Галинурга каныгып, аны урыныннан алсалар, Чукмарлыга мәгънәсез һәм мәнсез бер бушбугаз килсә, эшләр тагын кыенга китәр, эш кешесенә тагын көн бетәр инде, дип борчылдылар.

Дәминев Чукмарлы халкының Айтугановны тулаем яклавына

күңеленнән тәмам ышанып җиткән иде инде, әмма, көне буе өйдә утырудан арып, урамда һава алырга чыккач, аны кибет яныннан узган чагында каеры тунлы бер абзый туктатты.

— Син, иптәш, Мәскәүдән килгән гәҗитче түгелме?

— Нәкъ үзе. Йомыш бар мәллә?

— Йомыш бар гына түгел, йомыш зур, гәҗитче иптәш.

— Тыңлыйм мин сезне, абзый. Сез кем буласыз?

— Мин шушы авылның пенсионер бер карты. Мин ишеттем, безнекеләр Айтуганов Галинурны яклап хат язганнар дип...

— Әйе. Әллә сез риза түгелме?

— Мин берничек тә риза түгел, мин хәттәки каршы.

— Ягъни мәсәлән, сез ни өчен каршы?

— Хисмәтуллага, исереп аягын яндырган тракторчыга, законсыз пенсия биргәнгә каршы мин.

— Законсыз дигәне нәрсә инде аның? Аңлатыбрак сөйләгез әле, абзый.

— Сөйлим, гәҗитче иптәш, сөйлим. Миңа менә теге чакта, моннан алты ел элек, исереп күземне чыгарганга, үзе гаепле дип, кырык сум пинсә бирделәр. Әчеп аяксыз калган Хисмәтуллага бер йөз тәңкәдән артык пинсә чыгарганнар. Нинди киртәгә сыя торган эш бу, панимайыш. Берәүгә бер төрле, икенче берәүгә бөтенләй башка төрле. Мин моңа кәтигәрически каршы. Пинсиәнир белән пинсиәнирне аралау гүбчи дә килешә торган эш түгел, панимайыш.

— Сезне кем дип белик, абзый?

— Пинсиәнир карт Җаппар дип белерсең. Теләсә кая чакырсалар да мин бер үк сүзне күзгә карап әйтеп торачак...

Бу хәл Даниярның күңеленә вәсвәсә салды. Әнә, тикшерә башлагач, андый яклары да бар икән тормышның. Пенсия билгеләү мәсьәләсен Галинурның үзе белән сөйләшәсе булыр. Әгәр законсыз пенсия куйдырткан икән, бу аны бизи торган нәрсә түгел.

Галинур Таулы Төбәктән өченче көнне төштән соң гына кайтты. Кайту белән идарәне җыйды. Утырышка Дәминевның да керүен үтенде.

— Иптәшләр, кем дә кем таныш түгел, танышыгыз: бу — «Советская Россия» газетасының корреспонденты Данияр Дәминев була. Ул безнең колхозга сез язып җибәргән хат буенча килде. Безнең хуҗалыкның экономикасын, халыкның тормышын өйрәнде. Инде менә мин аны сезнең янга алып чыктым.

Идарә бүлмәсендә, гөр килеп, уйларын уртаклаштылар.

Галинур тавышлар тынганны көтеп алды.

— Ни өчен әле, тора торгач торҗагун дигәндәй, кич җиткәндә, артык әллә ни эш тә юк чагында чакырып, алҗытып йөри бу безне, дип үпкәләмәгез. Мин сезне бирегә авыр бер хәбәр әйтергә чакырдым. Бүген безнең кайгылы көнебез. Таулы Төбәк заготзерносына тапшырылган былтыргы бодайның бер мең тоннасын элеватордан ун чакрым ары Бүре чокырына илтеп күмдек.

Бүлмәдә хәвефле сүз ишетелде:

— Без тапшырган бодай түгелдер бит?

Аңар кемдер шундук җавап бирде:

— Акылыңа кил — нишләп безнеке булсын?! Без бит бодайны да, арышны да җиренә җиткереп, коры итеп тапшырдык.

— Черегән бодай безнеке түгел,— диде Галинур.— Ул үзе, кара исәп белән исәпләгәндә, әллә ни күп тә түгел: Таулы Төбәк быел дәүләткә саткан йөз мең тонна ашлыкның нибары бер проценты гына. Ә шулай да жәл — мең тонна, алтмыш мең пот бит ул. Колхозчыларның күпме маңгай тире, күпме өмете янып көл булды дигән сүз.

— Тимергалиевкә нәрсә диделәр?

— Үзәк Комитеттан килгән халык контроле үз нәтиҗәсен үзе

чыгарыр, йә каты шелтә бирерләр, йә кисәтү ясарлар. Бер Тимергалиев кенә гаепле түгел монда. Ил белән шул хәл бит. Без шалкан күк бәрәңге үстереп бирәбез, подвалларда аның яртысын черетеп әрәм итәләр. Грузиннар әнә гәрәбә төсле йөзем китерә Мәскәүгә, вагоннардан бушатканчы аның яртысы юкка чыга. Азмы илдә җилгә очканнар, череп җир каны булганнар. Революциягә кадәр Россия бодайны үзе саткан чит илгә, ә хәзер ел саен валютага, алтын бәрабәренә Канададан бодай алабыз. Ник? Әнә шул без үстергән икмәкне кемнәрнеңдер әрәм итүе аркасында. Әнә бу мең тонна бодайны колхозлар киптереп тапшырсалар, черемәгән булыр иде ул. Канададан аласы бодайның мең тоннасы кимрәк булыр иде. Юкса нәрсә килеп чыга? Мәскәү — обкомны, обком райкомны ашыктыра, райком безне, менә башлана бозык эшләр...

«Айтугановлар җитәкләгән колхозларда болай да начар яшәмиләр: тамаклары тук, өсләре бөтен. Картлык көнебездә урамда калабыз дип тә курка торган түгел. Димәк, аларның җанына тигән нәрсә бер генә — илдә тәртип булмавы...»— дип уйлады Дәминев.

Шуны уйлап бетерүе генә булды, стена буена тезелеп утыручылардан берәү, түгәрәк чал сакаллы, җитмеш яшьләрендәге кеше, урыныннан торды.

— Син, энем Галинур, безгә Мәскәү гәҗитеннән кеше килгән, дидең. Без бит авылыбыз белән дигәндәй, һәммәкиебез кул куеп, райкумның безгә тынгылык бирмәве хакында хат язып җибәргәниек. Мәскәүдән килгән иптәш, үз ирегебелән, синең сүзне тыңлапмы, безнең идарәгә кергән икән, әйтсен инде үзенең сабраҗиниясен, без хаклымы, әллә райкум — Тимергалиев хаклымы? Югыйсә нәрсә килеп чыга? Үзебез уйлаган срукта чәчү чәчү — гаеп, кырдан җыеп алган ашлыкны иливатырга киптереп бирү — гаеп, бар нәрсә гаеп. Кем яхшырак белә басуда ниләр эшләргә кирәген — көннәр буе кәгазь буяп утырган райкуммы, әллә гомер буе чәчү чәчеп, урак урып, ындыр сугып тешләре коелып беткән Габделгәрәй абзагызмы?

— Кем бу?— дип сорады Данияр, председательгә таба иелеп.
— Сыйфат комиссиясе председателе,— диде Галинур.
— Йә, ничек, миңа фикеремне әйтергә ярыймы?— дип иплән кенә сорады Данияр.— Әллә тыңлап кына утырыйммы?
— Әйтмәсәгез, халык риза булмас бит.
— Ярый, алайса, белдерегез халыкка, әйтәм.
— Иптәшләр, сөйләшүне туктатыйк. Безнең колхозның сыйфат комиссиясе башлыгы Габделгәрәй абзыйның бик озын итеп әйткән соравына җавапны корреспондент Данияр Дәминев бирә.

Данияр торды. Шундук идарәдәге кешеләрнең барысы берьюлы үзенә төбәлүен сизде. Кызыксыну гаять зур, менә шушы минутта идарә кешеләре үз колхозларының язмышы хәл итела дип беләләр иде.

— Иптәшләр, мин «Яңа көч» колхозының эш кәгазьләрен дә, ел саен колхоз рәисе ясаган хисап докладларын да укып чыктым. Керем-чыгымнарның ничегрәк эшләнүен дә бухгалтер кызлар аңлатып бирде миңа. Кайбер иптәшләр белән әңгәмә дә үткәрдем.
— Соң, шуннан, шуннан?..— дип түземсезләнде берсе.
— Шуннан шул, минем фикер ачык: хат язган иптәшләр хаклы. Мин бу хакта үзебезнең газетада махсус язып чыгарга исәплим.
— Ай рәхмәт!
— Гаделлек бетмәгән икән әле.
— Фаш итегез ала канатларны!— дигән сүзләр ишетелде.
Председатель халыкны кул күтәреп тынычландырды.
— Иптәшләр, шауламыйк, корреспондент Дәминевка сөйләп бетерергә ирек бирик.

— Сез минем төп фикеремне аңладыгыз,— дип дәвам итте Данияр.— Инде мин сезнең кайбер нәрсәләргә ачыклык кертүегезне үтенәм. Колхозның бухгалтер ярдәмчесе Асия Харисова, гомерен өзәргә уйлап, агу эчкән. Ник эчкән ул агуны? Райком сезгә халык тикшерүчесе китергән. Халык тикшерүчесе әйтә, председатель Айтуганов Харисовага басым ясап, керем-чыгымнардагы кайбер махинацияләрен яшереп калдырырга уйламадымы икән?— ди. Сез моңа ничек карыйсыз?

Стена буендагы эскәмиядән ашыгып кына яшь бер хатын күтәрелде, урынында гына калырга теләмичә, өстәл янына ук килде, алдан ала бик югары, күтәренке тавыш белән башлап җибәрде сүзен:

— Бу — яла! Кычкырып торган яла бу Айтугановка. Ревизия комиссиясе бездә ел саен, председатель отчет ясар алдыннан ревизия үткәрә. Без үз колагыбыз белән ишетәбез. Безнең председательнең кулы чиста, намусы саф. Менә бөтен идарәдән сорагыз, колхозның барлык кешесен җыелышка җыеп сорагыз, алар бертавыштан әйтер: без Галинур Фәһимович Айтугановка үзебезгә ышанганнан да күбрәк ышанабыз. Дөресме, иптәшләр?

— Дөрес!— дип кычкырдылар.

— Яхшы! Бу хәтлесе аңлашылды. Алайса, нигә Харисова агу эчкән?— диде корреспондент.

Бик кычкырып, ярсынып сөйләгән яшь хатын кинәт уңайсызланып, тынып калды. Аннары халыкка карап түгел, Дәминев белән Айтугановка карап сөйли башлады.

— Асия — минем дустым иде. Аның үз-үзенә кул салуында председатель Айтугановның бернинди дә катнашы юк. Клубта сәнгать җитәкчесе булып эшләгән Хәмзәне өзелеп яратты ул. Хәмзә Асияны Казан каласына китәргә чакырды, Асия авылдан китәргә риза булмады, ә Хәмзәсе аны ташлап китте дә калада инде өйләнгән...

— Сез моны халык тикшерүчесенә әйттегезме?— диде Данияр.

— Әйттем. Ул һаман черәшеп каткан: бухгалтерия документларына ревизия ясатам,— ди.

Габделгәрәй абзый урыныннан тормыйча гына:

— Менә күрдегезме инде гаделсезлекне? Болар барысы райкум эше! Тимергалиев безне теге килүендә җиңә алмагач, бу килүендә җиңәргә азаплана. Галинур басым ясамый, райкум басым ясый,— диде.— Аңлашылдымы, хәбәрче иптәш.

— Бу хәтлесе аңлашылды. Минем үзем өчен ачыклап җиткерәсе тагын бер нәрсә бар. Кайбер иптәшләр белән сөйләшкән чакта, әйттеләр, Галинур Айтуганов идарә членнарын законсыз эшләр эшләүгә этәрә икән.

— Мәсәлән?— диделәр идарәдәгеләр.

— Мәсәлән, сезнең колхозның механизаторы Шәрәфиев Хисмәтуллага пенсия түләүне идарә законсыз юл белән хәл иткән, ә идарәне ул юлга иптәш Айтуганов этәргән. Ничек булды ул хәл? Шуны төгәлрәк әйтеп бирә алмассызмы?

— Юк, җәмәгать, болай ярамый. Законсыз дип кем әйтте, исемен әйтеп сөйлә, кем, хәбәрче иптәш? Без белик аны! Путный сүз сөйли торган кешеме ул, әллә корыны бушка әйләндереп йөрүче бер йолкышмы?— диде сыйфат комиссиясе рәисе.

— Сүз иясе белән йөрми. Мин хәзергә әйтми торам аны,— диде Дәминев.

— Ярар. Рамай, син сөйлисеңме?— диде Галинур парторгка.

— Була, сөйлим,— дип, Даниярга таныш парторг урыныннан торды.— Эш болай, иптәш корреспондент.— Безнең авылда утыз ел буена гаять дәрәҗәдә намуслы эшләп килгән механизатор Хисмәтулла абый бар. Унҗиде яшеннән ул тракторга утырды, язларын сука

сукалады, чәчү чәчте, җәйләрен комбайнга күчеп, урак урды, елның елында район күләмендә беренчелекне бирмәде. Менә быел, көтмәгәндә, бәхетсезлеккә очрады Хисмәтулла Шәрәфиев. Язгы чәчүне тәмамлап, янә дә беренчелекне алган көнне алар өч тракторчы берәр шешә аракы эчкәннәр. Каяндыр тагын тапканнар. Хисмәтулла абзый өенә исереп кайткан. Гомердә дә булган хәл түгел. Хатыны Фәүзияттәй бик борчылып, балалар күрә күрмәсен дип, ирен келәткә җибәргән. Йокласын, айнысын дигәндер инде. Хисмәтулла абзый келәткә керәсе урынга, мунчага барып кергән. Мунчага яккан булган икән Фәүзияттәй — ирен кырдан кайткач юындырырга дип, менә шул. Хисмәтулла абый мунча идәненә ятып йоклаган. Йоклаган килеш, белештермичә, аягын янып торган мичкә тыккан. Больницада моның аягын кистеләр.

Идарәдә пенсия билгеләргә кирәк булгач, без бик кыен хәлгә калдык: нишләргә? Көнкүрештәге травма дисәк, бик аз тия акча, эш өстендә дисәк, дөрес түгел. Ярты көн бәхәсләшкәч, эштәге травма итеп билгеләдек пенсияне.

— Димәк, сөйләүче хаклы,— диде Дәминев.— Пенсия законы бозылган. Күрәләтә. Әйеме?

— Формаль яктан караганда, әлбәттә: бозылган. Әмма Хисмәтулла Шәрәфиевнең утыз ел буена ике-өч кеше урнына эшләп, колхозга никадәр файда китерүен исәпләп карасак, ягъни әхлак нормаларыннан килсәк, бозылмаган. Мин үзем, мәсәлән, идарә дөрес хәл итте, дип исәплим.

— Ә логика?

— Логикасы гади: Хисмәтулла абый, протез аягы белән тагын тракторга утырды: тагын колхозның алдынгысы булып эшләп килә. Ә без формаль килсәк, законның хәрефенә ябышсак, нәрсә булыр иде? Җанында ни калыр иде механизатор Шәрәфиевнең? Авыл кешесенә ихтирам булмау китерде түгелме соң инде кибетләрдәге буш кишәләргә?

## 6

— Иптәшләр, әгәр сез рөхсәт итсәгез, мин менә шушында рәисегез Айтуганов белән икәүдән-икәү генә кайбер мәсьәләне ачыкларга теләр идем,— диде Дәминев.

Идарәгә җыелганнар шаулап таралгач, ул әйтте:

— Галинур, мин иң әүвәл күңелемдә йөрткән бер сорауны ачыкларга телим: сез колхозда үз теләгегез белән калдыгызмы, әллә әтиегез Фәһим абзый сезнең председатель булуыгызны теләдеме?

Галинур мыек астыннан гына елмаеп куйды:

— Кем белгән инде аны...

— Шулай да?

— Барлык үсмер малайлар кебек, минем дә укуга бер дә исем китмәде. Әти исә минем, әлбәттә, бик яхшы укуымны тели, ләкин ул мине тикшереп бара алмый, үзебезнең Балдамардан ун чакрымдагы авылда бетердем мин урта мәктәпне. Интернатта яшәп. Тугызынчыда укыганда, кырга китеп, эскерт төбенә җыелабыз да өч-дүрт малай тәмәке тартабыз. Укудан кайтып килгән кызлардан бүген нәрсәләр булганны, өйгә нинди эш бирелгәнне сорашабыз да әтиәниләргә, Балдамарга кайткан чакта, шуны сөйлибез. Ял көннәрендә.

Бер көнне әти, әллә шиге төшеп, әллә юлы төшеп дигәндәй, мин укыган Шомыртлы мәктәбенә барып сораша! Журналда: «булмады», «булмады» дип куелган. Әти без яшәгән торакка килде, нинди дәресләр кергәнне, нәрсәләр узганны сорады. Мин ялганлап сөйләргә ке-

решкән идем, чәчтән умырып тотып, башны стенага бәрде. Икенче тапкыр да бәрмәкче иде, мин башны тартып алып өлгердем, ә ул стенага кулын китереп бәрде.

— Ярар, нәгаләт, үзеңчә яшә. Теләсәң нишлә. Кара аны, миңа җылап киләсе булма!— диде, кулын стенага бәргәнгә бик нык ачуы килде.

Мин укырга тотындым. Ләкин — соң! Артта калынган.

Менә шул башны давайга салып, шагыйрьләнеп йөрүләр кыйбатка төште миңа. Авыл хуҗалыгы институтының механика факультетына керергә талпынып карадым. Юк — кая ул! Белем коелып беткән. Шап минем зачеткага — «ике»лене! Өйгә кайтасы, әтинең күзенә күренәсе килми. «Үзеңчә яшә!»— дигәнен искә төшерә башласа, дип уйлыйм, хурлыгыңнан кая керер тишек тапмассың. Киттем Оргсинтез заводына — бер ел чирәштем, кирәкле дәресләрне тотындым штудировать итәргә — акыл керде малайга! Ярый әле, баш бар үземдә,— дип мыек астыннан гына көлеп куйды Галинур.— Авыл хуҗалыгыннан хәзер минем гайрәт чикте, Химия-технология институтына керергә булдым. Әзерлек курсларына язылдым, бик тәртипле рәвештә йөрим, әгәр, дип фикер йөртәм, әзерлек курсларын яхшы узсам, институтка кердем дип исәпләргә мөмкин. Уздым бит тәки, үҗәтлегем дә җитәрлек булгандыр инде, әтинең башны стенага бәрүе дә истән чыкмагандыр, тырышып-тырмашып, үчлекләнеп имтихан бирәм, тик Химия-технология институтына түгел, әлеге дә баягы — һаман да авыл хуҗалыгына сөйри аяк. Бу юлы механикага түгел, экономикага. Уздым. Шуннан соң шалт — әтигә телеграмма! Так-то, так-то, чабата да лапта, хөрмәтле Фәһим Сабирҗанович, синең юлдан язар улың студент булды. Әти хат-мазар да язып тормады, телеграмм да сукмады, ялт итеп Казан каласына килеп төште. Яңа костюм алып бирде, пальто. Бераз акча. Үпкәләр хәлем юк, әти безне азындырды дип,— акчаның бармак арасыннан тамганын гына бирә иде. Ул чакта кәеф китә торган иде, кызлар янына да барасы килә, имтиханнарны тапшыргач, аз-маз күңел дә, ачасы. Хәзер сөенәм, кем белә, бәлкем, тагын, үсмер чактагы кебек, тәмәкечеләр компаниясенә ияреп китәр идем...

— Институтны ничек тәмамладыгыз?— диде Данияр.

— Алып мактарлык, салып таптарлык түгел. Бер генә фәннән «өч»лем бар иде.

— Нәрсәдән?

— Капиталистик экономикадан.

— Ничек ул алай?— дип елмайды Данияр.

— Менә шулай. Безгә бит гомер буе социализм капитализмнан прогрессиврак дип өйрәттеләр. Уйладым-уйладым да, капиталистик экономиканы «өч»легә бирергә булдым, социалистик экономикадан югарырак булмасын дидем, тегесен «дүрт»легә тапшырган идем.

Кайттым Каңгырашка. Ул әле «Сабанчы»га кушылмаган иде. Авылда әтиләр белән торам, Каңгырашка барып эшләп йөрим.

Безнең авылда башлангыч мәктәптә укытучы булып эшләп йөрүче Нәзифә бар иде, педучилище тәмамлаган. Таныштык. Күңел төште шуңар, ә мине, үч иткән кебек, армиягә алалар. Кыз белән бик әйбәтләп сүз куештык, өйләнеп китмәкче булдым мин моңа. Әтигә хәбәр иттем, әнигә. Әни болай риза да кебек, тик әтидән шикләнә. Әти әйтте: «Кайткач өйләнерсең. Синең катыныңның намусын саклап ятасы бар икән тагын!»— ди. Армиядән кайткач өйләндем. Көткән мине Нәзифәм, хат алышып торган идек.

Тагын нәрсә әйтим: Утызга җитәрәк «Яңа көч» колхозына председатель итеп сайладылар. Беренче елларны гел әти белән киңәшеп тордым. Сигез ел булды инде эшли башлаганга.

— Эшләгән нинди әйбәт эшләрең бар? Чын дөресе?— диде Дәминев, аның кара бөдрә чәченә, кара мыегына, җемелдәп торган нурлы күзләренә төбәлеп карады.

— Колхозның ике миллион сум ссудасын түләдем. Терлек абзарлары салдым. Дөрес, мин хыялда йөрткән каралты түгел, шулай да файдасы тия. Хыялда эти салдыртకан төсле гигант комплекс булдыру, нәселле сыерлар белән тутыру иде аны — тик менә Морат Баянович... адым саен каныга да тора.

— Ә бит сезне колхозчылар яклаганнар. Менә гаделлек таләп итеп хат та язганнар. Китми торгансыздыр бит? Тимергалиев бит сезне, күпме генә тырышса да, урыныгыздан кузгата алмаган.

— Анысы дөрес,— дип моңсу гына елмаеп куйды Галинур.— Колхозчылар белән борчак пешә минем. Райком мине урынымнан алырга дип үткәргән җыелыштан соң авыл халкы тагын да тырышыбрак эшли башлады.

— Соң, шулай булгач?

— Район җитәкчелеге белән үзеңне һәрдаим конфликт хәлендә сизеп яшәве бик авыр. Кулны тота, хыялларны сүндерә, эштән гайрәт чигә. Нигә мин шулай булгач, үземне аңлы рәвештә авыруга сабыштырыйм? Минем бит өч балам бар, аларны карап-багып үстерү минем өстә бит.

— Китсәгез, кая таба юл тотасыз инде?

— Башка районга. Чөнки Таулы Төбәктә калсам, Морат Баянович миңа барыбер көн күрсәтмәячәк.

— Бәлки, калырга кирәктер? Халык бит сезгә ышанган.

— Калудан мәгънә юк, Данияр. Ярамый калырга, һич! Озакка сузган саен Тимергалиев миңа ныграк каныгачак, райком каныгу — бик начар фал ул. Көчемдә чакта, мин үземә лаеклы урын эзләргә тиеш.

— Болар барысы дөрес. Көн кебек ачык. Тик сезнең киту Таулы Төбәк файдасына түгел ич.

— Ник алай дисез, Данияр?

— Сезнең киту башкаларны да кузгатачак. Председательләр корпусы тулаем кузгалачак. Ә бу райком секретареның абруена китерер сугачак.

— Ә мин, мәсәлән, шул көнне көтәм, төшләремдә күрәм инде. Тимергалиевнең урыны колхозда түгел, прокуратурада. Анда да әле ул элекке алымнар белән эшли алыр микән?

Данияр урыныннан торды, арлы-бирле йөренеп алды, блокнотын чыгарып, ашыгып-ашыгып нидер язды, аннары Галинурның каршысына ук килеп, аның җилкәсенә дусларча кулын салды:

— Гафу ит, никтер «сез» дип түгел, «син» дип дәшәсе килә башлады. Кайчан китәргә инде синең ният?

— Язгы чәчүләрне тәмамлагач, печән өстендә булыр, мөгаен.

— Нигә нәкъ менә печән өстендә?

— Эти язгы чәчүне тәгәлләп китәргә куша. Ә печән өстендә, яңа председатель китерсәләр дә, әле уракка әзерләнергә вакыт кала. Аннары бит мин, Тимергалиевкә үч итәм дип, колхозның эшләренә кул селтәмим. Урак өстенә техниканы тулы әзерлек белән калдырып китәрмен. Сабантуйларын уздырып, халыкка печән өләшеп, тыныч күңел белән китәргә исәп.

— Фәһим абзыйга да, Галинур, сиңа да рәхмәт. Мин эшемне тәгәлләдем шикелле. Рөхсәт итсәң, мин кузгалыйм инде,— диде Дәминев.

— Юк, китмисең. Кунып китәсең үземдә!— дип каршы төште Галинур.

— Мин бит инде Чукмарлыда өч кич кундым.

— Анысы мин барында түгел.

— Кыстама, Галинур. Мин кунак йортына кайтыйм, башымда минем мең төрле уй — кәгазьгә бүген үк төшермәсәм, алар коелып бетәчәк. Баш тишек капчык ул, берсен җыя, икенчесен коя.

— Алайса, без рәсми телдә сөйләшик, иптәш корреспондент. Сезне минем әти көтә, Фәһим Айтуганов. Ул бит бала-чага түгел, күрешми киткәнгә үпкәләр.

— Нигә, без Балдамарга барабызмыни?

— Балдамарга бару-бармау сезнең эш. Әти бездә, Таулы Төбәктән ул миңа кайтты. Сезне көтеп утыра.

— Шулаймыни?! Ник башта ук әйтмисең аны? Без бит монда вакыт үткәрмәгән булыр идек, сезгә кайтып сөйләшер идек,— диде Данияр.

— Монда сөйләшә торганы монда сөйләшенде, өйдә сөйләшә торганы, кем белә, бәлки, башкачарак булыр,— диде Галинур, өстәл яныннан күтәрелеп.— Киттек, Данияр абый. Дөрес әйтәмме, сез миңа абый тиешледер бит?

— Абый, әлбәттә. Сиңа ничә яшь әле?

— Утыз җиде.

— Миңа бит инде кырык биш.

— Сәмәй егет чагыгыз икән! Киттек, Данияр абый. Әти көтеп зарыккандыр инде безне.

## 7

Урамнан җәяү кайттылар. Сөйләшмәделәр. Буран кузгалган, юеш ябалак карны биткә китереп сылый, яка эчләренә тула иде. Икесе дә тун якаларын күтәреп, буранга каршы атладылар.

Галинур идарә йортыннан ерак тора икән, Данияр битен кулы белән каплап бара-бара арып бетте. Урам буенда ике-өч урынга өеп куйган бураны күргәч кенә җылы керде. Шәт, шушыдыр, яшь председатель үзенә яңа йорт салдыра, дигәннәр иде.

Электр уты белән яктыртылган ишегалдына кергәч, Даниярны сәер бер тойгы биләп алды. Канәгатьсезлек дип әйтергә микән аны, өметләр акланмау дипме — ни булса да булды, аның күңелендә шундый бер тойгы уянып өлгерде. Ишегалды зур булса да, анда каралтыкура күренми, урыс капка буендагы мунча гына күзгә ташлана иде.

Балдамарда чакта ул ике көн эчендә дә авылның урамнарын аркылыга-буйга йөреп чыкты. Андагы, алты почмаклы биек йортлар, рәшәткәле итеп коелган биек коймалар, ихата эчендәге каралтыкура, тимер капкалы гараж, ярты күккә тикле менеп җиткән антенна колгалары белән чагыштырганда Галинур Айтуганов яши торган йорт гадәттән тыш гади түгелме?

Өйнең ишегалдына караган өч тәрәзәсендә ут күренә, шул ут яктысында кар күбәләкләре бөтерелә, биредә аулак булганлыктан, буран барлыгы сизелми, җил улавы гына ишетелә иде.

Такта чолан аша уздылар. Бүрәнә өйгә кергәч, биткә өй җылысы бәрелде. Тәмле аш исе борынны кытыклап алды. Өс-башны салып, чөйгә элгән арада, эчкәрге бүлмәдән Фәһим абзый килеп чыкты.

— Кайтып җиттегез тәки. Бик хәтәр буран кузгалды бит әле,— дип, ягымлы итеп каршылады ул Галинур белән Даниярны.

— Буран бар, буран әйбәт,— дип көлеп куйды Данияр.— Кайтуын кайттык та менә, гостиницага ничек кире кайтырмын, дип кайгыра башладым әле.

— Алдагысын алла кайгыртсын. Күз күрер,— дип, Фәһим абзый Даниярны алгы бүлмәгә алып керде.

Монда кергәч, Даниярның күңелендәге канәгатьсезлек бетеп киткәндәй булды. Бүлмә бик иркен. Идән тутырып бик зур келәм җәелгән, стена буенда стенд тора, анда савыт-саба, китаплар тезеп куелган, бу бүлмәдә стендтан башка мебель юк, тәрәзә буендагы өстәлнең өсте газеталар белән каплап куелган иде.

Тыштан караганда бәләкәй булып күренгән өйнең эче шундый иркен булуына Данияр гаҗәпләнергә дә өлгермәде, кухнядан поднос белән ризык күтәреп, сылу бер яшь хатын килеп чыкты: матур чигү үрнәкләре төшерелгән зәңгәрсу халат, сары косынка астыннан сузылган ике толым кара чәч, балкып торган алсу йөз!

— Менә бу безнең олы киленебез Нәзифә була инде. Өч бала анасы. Укытучы. Кулинар,— диде Фәһим Айтуганов.— Ә менә бу егет — корреспондент Данияр Дәминев.

— Балалар кайда соң?— диде Данияр, баш иеп исәнләшкәч.

— Балалар йоклый инде,— дип оялчан елмаеп әйтте Нәзифә.

Табын инде әзерләп куелган икән, газета кәгазьләрен алгач, өстәлдә винегрет, салат, балык, тавык ите куелганы күренде. Аның янына бер табак кайнар бәрәңге куйды Нәзифә.

Аннары ул, игътибарны үзенә тартып, кухня ягыннан шаулап кайнап чыккан ак самавыр күтәреп керде.

Фәһим абзый сүзне кыска тотты:

— Утырыштык, балалар.

Данияр бер нәрсәгә игътибар итте: Фәһим абзыйның улы Галинур әтисеннән узып, берни дә эшләмәде. Әтисе әйткәч кенә, стендның ябык бер бүлемтегеннән алып, табынга өч рюмка һәм бер шешә аракы китереп куйды.

Шешәне ашыкмый-нитми, җаен китереп, Фәһим абзый ачты, рюмкаларга салып чыкты.

— Минем нәселдә хәзер, Данияр, игътибар итсәң, дүрт буын яши. Әни — сиксән алтыда, беренче буын; хатыным Сөембикә белән мин — алтмыштагылар, икенче буын; Галинур белән Нәзифә — утыз биштәгеләр, өченче буын; оныклар — дүртенче буын. Моны мин шулай булырга тиешле нормаль хәл дип саныйм, шулай булмаган сурәттә авылда, крестьян йортында буыннар алмашу, бер-берсеннән күреп үсү булмаячак. Авыл хуҗалыгын үстерергә дип өсләренә бурыч алган галимнәр моны белергә тиеш. Чөнки традицияләр бетәме — авыл бетә, игенчеләр династиясе тарала.

— Бик кызыклы хакыйкать, минем бу хакта уйлаганым юк иде, Фәһим Сабирҗанович,— диде Данияр.

— Бу кызыклы гына түгел, гыйбрәтле хакыйкать,— диде өлкән Айтуганов.— Дүрт буынның бер чылбыры да өзелми икән, ул гаиләдә өмет бар. Буыннар буыннарны кайгырта, ялгышсалар — буыннар буыннарны гафу итә, кичерә, ярлыкый. Синең, Данияр, ишеткәнең бардыр, Рузвельт үзенең бер сенаторы хакында: «Бу, әлбәттә, дуңгыз, әмма үзебезнең дуңгыз,»— дигән.

Данияр башын артка ташлап рәхәтләнеп көлде. Фәһим абзый әйткән бу мәзәктә мәгънә тапты Данияр. Бер авыл кешеләре, ничәмәничә буын бергә үсәләр икән, димәк, алар бер-берсен кыерсытырга ирек куймаячаклар. Әнә нәрсәгә ымлый өлкән Айтуганов.

Фәһим абзый, гүя аның ниләр уйлаганын белгәндәй:

— Мин бу тостны авылда династияләр бетмәсен өчен тәкъдим итәм,— диде.

Өчесе берьюлы йотып куйдылар.

Нәзифә килен чыгарган итле кайнар ашны ашадылар.

— Фәһим Сабирҗанович, минем күңелгә көтмәгәндә сәер бер сорау килде: әйтегез әле, зинһар, сез менә райком секретаре Тимергалиев белән колхоз председателе Айтуганов арасында берәр аерма күрәсезме?— диде Дәминев.

— Күрәм,— диде Айтуганов.
— Нинди, мәсәлән?
— Тирес өеме алдында мин эшләпәмне салам. Ә менә Тимергалиев салырмы эшләпәсен?
— Салмастыр.
— Ник дип сора. Чөнки аның «менә бу минеке!» — дигән басуыры юк. Тирес өемен ул әйләнеп узар, туфлиен буяудан куркыр. Райком секретаре белән минем арадагы аерма менә шунда, Данияр Күреп торам, син гел уйланасың, шулай булгач, Тимергалиевнең Галинурга ник канызгуын аңлагансыңдыр. Аны — мин барлык райком секретарьларын истә тотып әйтәм — еллар буе, дистә еллар буе командага буйсынырга өйрәттеләр. Менә шул гадәтне ташлый алмый райком. Алмаячак та! Бу — аның фаҗигасы.
— Ә син, Галинур, ничек уйлыйсың?
— Берничек тә уйламыйм. Минем өчен партия уйлый бит.
— Бу житди җавап түгел,— Дәминев өстәл яныннан торып басты.— Мин менә үзәк газетаның заданиесе белән килдем. Вазифамны бик ансат кына да башкарып чыга алган булыр идем. Килдем ди, әйтик, «Яңа көч» колхозына, сорашып чыктым ди, хатка кул куйган кешеләрдән, ревкомиссия белән сөйләштем ди, Морат Баяновичка, әдәп өчен, янына кереп, бер-ике сорау ташладым ди, ул миңа, әлбәттә, партиянең, бу очракта райкомның абруен саклау хакында күптән билгеле дежур сүзләрне әйтеп бирде ди, мин шуларны хатка теркәп, «Советская Россия»га җибәрдем ди. Нәрсә, мин бурычымны үтәгән буламмы? Намуслы журналист буламмы мин ул чакта?
— Намус төшенчәсен кай яктан килеп бәялисең бит...— диде Галинур.

Фәһим абзый да аяк өсте баскан иде инде, ул дәшмәде, Галинурның тәҗрибәле, дөньяга аек күз белән карый торган журналист алдында ничек имтихан тотуын гына күзәтеп торды.
— Безнең халыкта, татарларда «егетлек» дигән төшенчә бар,— дип ике кулын берьюлы йодрыклап сүз башлады Дәминев.— Егетлек, минемчә, җитәкчене җитәкче итә торган иң беренче сыйфат. Егет була белгән кеше мактаганнан да азынмый, хурлаганнан да изелеп төшми. Бик авыр ситуацияләрдә дә ул егет булып кала. Менә, Галинур, син бик кыен ситуациядә калдың. Колхозчылар гаделлекне синең якта дип саныйлар, сине урыныңнан алдыртмас өчен җан талашалар. Тимергалиев үзен хаклы саный һәм сине урыныңнан алып ташлау өчен барлык властен кулланырга тырыша. Син шушы ситуациягә ничек карыйсың?
— Бер генә җөмлә белән җавап биримме?
— Юк. Мине бер генә җөмлә канәгатьләндермәстер. Ник дигән? Хатны мин кат-кат укыдым. Колхозчыларның дәлилен беләм. Сезнең колхозның парторгы Рамай Мансуров белән бик озак сөйләштем мин, син ясаган отчет докладларын бик җентекләп, әнәсеннән җебенә хәтле укып чыктым, язучылар теле белән әйткәндә, синең отчетларыңнан нинди холык карап торганын аңладым...

— Нинди холык соң?— диде Фәһим абзый кызыксынып.
— Әйтимме?
— Әйтеп кара.
— Шагыйрь карап тора Галинурның отчетларыннан.
Бу юлы Галинур кычкырып көлде.
— Шәррән яра мактау булса да, мин бу билгеләмә белән килешәм,— диде Галинур.— Чын язучы беркайчан да узган этап була алмый. Ул гел заманча. Чөнки аның иҗаты киләчәккә юнәлгән. Бу — минем фикер, үз башым белән килеп җиткән нәтиҗә. Колхоз председателе дә узган этап була алмый, әгәр ул... киләчәккә карап яшәсә...

— Шагыйрьлеге нәкъ менә шунда Галинур Айтугановның, миңа калса, мин аның бер генә докладында да аяк астына карап сөйләгәнен күрмәдем. Киләчәккә күз төби яшь Айтуганов. Килер көн белән яши. Шуннан соң инде минем беләсем килә, бу сыйфат Галинурда ничек туган? Фәһим абзый, син эти кеше, рөхсәт ит, бер нәрсәне дә яшерми сөйләп бирсен Галинур.
— Соң сөйләсен. Син кирәк дип табасың икән инде, сөйли бирсен. Мин бит чыгып та тора алам.
— Ю-у-ук, үзеннән генә, япа-ялгызыннан гына сөйләтәсем килсә, мин аның үзенә генә биргән булыр идем ул сорауны. Миңа аның этисе барында сөйләве мөһимрәк. Ул чагында мин ике буынны чагыштырып карый алам, үзем өчен ачык булмаганнарны ачыклап бетерә алам.
— Ярый, алайса, әйтәм. Һәр гаиләнең аеруча атаклы бер бәйрәме була торгандыр. Безнең өйдә иң зур бәйрәм — минем эти үткәрә торган бөек Җиңү бәйрәме. Ул көнне эти барлык туганнарны чакыра. Энесе Фатыйхны, мине, Фаягөлне — барыбыз да җәмагатебез, бала-чагаларыбыз белән киләбез. Өйдә бит әле безнең Таһир белән Сания, аларның ике кызы. Алсу белән Айгөл бар. Дәү әниебез Гөлйөзем әби бар. Өй тула кеше белән. Бик күп ризык әзерләнә, без дә үзебез белән күчтәнәч алып киләбез. Бу бәйрәм хикмәтле — эти безгә нәселебезнең исән икәнен аңлата, үз тормышыннан гыйбрәтләр сөйли. Әнә шул гыйбрәтләрнең берсе минем хәтеремә бигрәк тә сеңеп калган.
— Кайсысы икән ул, улым?— диде Фәһим абзый.
— Сугыштан ничек исән калу турындагысы.
— Кызык, сөйлә әле шуны, Галинур.
— Юк, эти үзе сөйләсен, мин аның кебек килештереп сөйли белмим.
— Сөйлисезме, Фәһим Сабирҗанович?
— Ярар, алайса сөйлим. Мин, Данияр, унсигез яшемнән ут эченә кердем. Көз көне иде, юеш иде, утыз биш чакрымлык поход узганнан соң безгә окоп казырга куштылар. Коточкыч арыган идек. Безнең, яшь солдатларның, һәркайсы янына карт солдат Бондаренко килеп йөрде. «Казыгыз, балакайларым, арыган булсагыз да казыгыз»,— диде. Олылар сүзен тыңлау — безнең татарларда закон. Казыдым мин. Азапланып, хәлдән таеп казыдым. Бондаренко карт ничек өйрәтте, шулай казыдым, басып торырлык итеп. Озакламый фашистлар безгә һөҗүм итте. Минем яшьтәгеләрнең күбесе окопларын тиешенчә казымаганнар икән,— һәлак булдылар. Мин казып кергән булгач исән калдым. Карт солдат Бондаренкога гомерем буе рәхмәтлемен, чөнки мин аңа дөньяда яшәвем белән бурычлы!
Тын гына утырдылар.
Аннары Галинур әйтте:
— Алгы көнгә карап яшәргә кирәк икәнен мин, Данияр абый, әнә шулай беренче мәртәбә эти сөйләгәннән күңелемә беркетеп куйдым...

## 8

Хәбәрне Сәүбанов алып керде.
— Яңалык, Морат Баянович: безгә делегация килә!
— Нинди делегация?
— Советлар Союзы делегациясе.
— Кемнәр?— дип бик җитди итеп сорады Тимергалиев.
— Райком секретарьлары, агропромчылар, колхоз председательләре, төзүчеләр.
— Сәбәбе?

— Тәҗрибә уртаклашу.
— Уртаклашырлык нинди тәҗрибәбез бар безнең?
— Айтугановның терлекчелек комплексын карарга килəлəр.
Тимергалиев чак кына сүгенеп ташламады:
— Нинди бетмәгән Айтуганов бу?! Кая карама — Айтуганов. Айтугановлар, Айтугановлар... Кем җиткерде бу хәбәрне?
— Обком секретаре Дулатов шалтыратты. «Сабанчы»ның үзәк усадьбасын, Тимергалиев белән икәүләп карап чыгыгыз. Балдамарны делегациягә күрсәтерлек итеп әзерләгез, диде.
— Нәрсәсен әзерлисең аның? Балдамар болай да төзек авыл: йортлары яңа, урамнары туры.
— Хикмәт урамнарда гына түгел, Морат Баянович. Рәтлисе нәрсәләр бар «Сабанчы»да. Батырлар һәйкәле примитив, пожар каланчасы да иске. Идарә йорты каршысындагы күрсәткеч такталары да ташкулчим! Кибетләрнең вывескалары уңып беткән. Шуларның барысын миллионер колхозга лаек итеп эшләтергә кирәк. Зәвыксыз нәрсәләр делегациянең күзенә шундук ташланачак. Комплекска килеп җиткәнче авылның культурасы турында кире фикер туып өлгерәчәк. Делегация председательне түгел, безне гаепләячәк, райкомны. Зәвык тәрбияли белмиләр, дип әйтәчәк. Ихтимал, делегацияне обкомның беренче секретаре үзе озата килер. Мин әйткәннәрне делегация Беренченең үзе алдында ук әйтеп бирсә, нишләрбез? Хурлыкка калмабызмы?
— Син хаклы. «Сабанчы»ны әзерләү кирәк. Кайчан килә делегация?
— Бер айдан,— диде Сәүбанов.
— Аңарчы син әйткәннәрне эшләп өлгертербезме?
— Председатель булышса, өлгертәбез,— диде Сәүбанов.— Беләсезме, Морат Баянович, Казаннан архитектор чакыртырга кирәк, минемчә. Без бит сәнгать мәсьәләсендә профаннар.
— Сөйләшеп куй, алайса. Кемне чакыру әйбәт булыр дип уйлыйсың, Даут Кодрәтович?
— Иң яхшысы — Хәйдәров. Аны республикада да, илдә дә беләләр. Тик ул өйдәме икән?
— Алайса, сөйләш, белеш, кайчанга килә ала архитектор, өчәү барырбыз «Сабанчы»га.
Бәхетләре — Хәйдәров өйдә булып чыкты, колхозга, бигрәк тә миллионер колхозга барырга ул бик теләп риза булды. Авылларның тышкы кыяфәтен культуралы итү, кайчандыр, сугыштан соң юкбар материалдан гына әмәлләп куелган һәйкәлләрне алыштыру аның күптәнге хыялы икән, моны ул Сәүбановка яшермичә әйтте.
Һәм алар өчәүләп «Сабанчы» колхозына китеп бардылар.
«Бәхетнең аяк астында ятуы мөмкин бит әле. Бәлки, бу бару Галинур мәсьәләсен хәл итәргә дә булышыр. Игътибарны кем яратмый. «Сабанчы»ның тышкы кыяфәтен үзгәртеп, күз явыңны алырдай итеп матурлап куйсак, Фәһим Айтуганов та безнең тегермәнгә су коя башламас микән?»— дип фикер йөртте Тимергалиев, февраль кояшы астында балкып яткан карлы басуларга карап барган чакта. Күгәргән бодайны бүре чокырына күмү, Галинурны яклап, үзәк газетага колхозчылар язган хат аларның нервысын шактый ук талкыган иде.
«Сабанчы» рәисе кунакларны, бик артык балкымыйча, рәсми рәвештә генә каршылады.
Иң әүвәл ул аларның кунак йортында тамакларын туйдырды, шуннан соң гына нинди йомыш белән йөрүләрен белеште.
Уй-планнарны Тимергалиев әйтеп бирде.
— Ярый, хуп. Архитектор авылны карасын, һәммә нәрсәне үз күзе белән күрсен, шуннан соң мәсьәләне уртага салып сөйләшербез,—

диде Айтуганов. Архитекторның кулына кыйммәтле аппарат тотып чыгуы да, сөйләшкән чакта әңгәмәдәшен аңларга теләп ихлас тыңлавы да Фәһим абзыйга ошады, шуңа күрә ул аның белән үзен дустанә тотты, урамнан урамга йөргән чакта колхоз хәлләрен бик теләп сөйләде. Тимергалиев белән Сәүбанов, сүзгә кушылмыйча, ишеткәннәрен мыекка чорнап кына бардылар.

Бик иркен һәм төзек бер урамга килеп чыккач:

— Менә, бу, Хәйдәров иптәш, Яшьләр урамы дип атала. Тарихы зур түгел, моннан ун ел элек кенә төзелә башлады әле. Эшендә яхшы эшләгән, матур итеп гаилә корган егет-кызларга урынны шушыннан бирәбез. Йортларны колхоз сала — хуҗалары, шәһәрдәге кебек, йорт хакын фатир хакы итеп түләп баралар. Биш ел эшләү дәверендә бер генә кисәтү-шелтә дә алмасалар, йортның бәясен яртылаш киметәбез.

— Казанда да булсын иде андый хәлләр,— дип куйды Хәйдәров, председательнең сүзен хуплап.

Нарат бүрәнәдән биек итеп салынган, кайберләре такта белән дә тышланган йортларның һәркайсы янында туктап, озаклап карады Хәйдәров, челтәрле биек коймаларны, яшелгә, зәңгәргә, акка буялган тәрәзә йөзлекләрен рәсемгә төшереп алды.

Аның бар нәрсәне җентекләп каравы, председательдән өзлексез сорашуы райком секретаре Тимергалиев белән агропром башлыгы Сәүбановның күңеленә хуш килде. Архитектор хәтле архитекторны канәгатьләндерә ала икән бу йортлар, димәк, киләчәк делегациянең дә күңеленә ятышлы булуы ихтимал. Һәрбер йорт алдындагы биек урыс капка, капкалардагы кояш орнаменты, кәрнизләргә агачтан юнып эшләнгән челтәрләр күңелгә ятышлы иде. Коймаларга тоташтырып ак мунча, гараж салынган, эчкәрге якта иркен лапаслар, бурабзарлар тезелеп китә — җыеп кына әйткәндә, муллык, көрлек күзгә бәрелә, утызынчы елларда булса, мондый йортта яшәгән авыл агаен, ихтимал, кулакка санап, сөргенгә олактырган булырлар иде.

Бара-бара Хәйдәрев сүзсез калды. Сорашмый хәзер. Йортлар янына килә, капкалар янына, тәрәзәләр каршысындагы челтәр рәшәткәләрне озаклап карый, рәсемгә төшерә һәм авыр гына көрсенә...

Урамның аргы башына килеп чыккач, ул түзмәде, күңеленә аеруча ошаган бер йортны сайлап, Фәһим Айтугановны, район җитәкчеләре белән бергә, шул йорт фонында киң телескоплы япон аппараты белән рәсемгә төшереп алды һәм, ниһаять, тагын телгә килеп:

— Колхоз авылын менә шундый итеп күрергә мин күптән хыяллана идем, — диде.

Сәүбановның түбәсе күккә тигән иде, Морат Баяновичка күз кысып алды: архитекторны алып килүебез юкка түгел, янәсе.

Тимергалиев архитекторга болай диде:

— Йәгез, Сәфәр Хәйдәрович, сезнең фантизияне эшкә җигеп карыйк: тагын нәрсә өстәргә була бу урамга? Сезнеңчә, монда нәрсә җитми?

— Мондамы? Монда, иптәш секретарь, абсолютно берни дә кирәкми. Моны сакларга, моны ВДНХга, Мәскәү күргәзмәсенә җибәрергә кирәк. Төсле фотолары белән, әлбәттә! Кышкы күренешне һәм җәйгесен. Күрсеннәр, өйрәнсеннәр халык архитектурасын.

Райком секретаренең йөзе башта балкыды, аннары тоныкланды. Нәрсә, аның Казан хәтле Казаннан архитектор китертүе юкка булып чыгамыни? Берни дә эшләмәячәкмени ул «Сабанчы»га?

— Бәлки, бүгенгә җитеп торыр, Сәфәр Хәйдәрович, — диде ул архитекторны арыган дип уйлап. — Бәлки, калганнарын ял итеп алгач карарбыз. Вакыт бар бит әле.

Эшне сузарга яратмый торган Айтуганов каршы төште:

— Юк, җәмәгать, бер тотынгач, карап бетерик инде, калган эшкә кар ява. Мине иртәгә Мәскәүгә, депутатлык эше белән бюджет комиссиясенә чакыралар...

Кунаклар бәхәсләшеп тормадылар. Терлекчелек комплексын карарга киттеләр.

Тау башында, коры һәм җиләс урында, тимер-бетоннан салып куелган гигант корылмалар. Комплекс һәр ягыннан яшел буяулы рәшәткә белән әйләндереп алынган. Рәшәткәнең тышкы ягында наратлар, каеннар, өрәңгеләр үсә — ап-ак кар җирлегендә наратларның яшеллеге, зәбәрҗәт төсле аерылып, күзгә ташланып тора, комплексны тирес оясы итеп түгел, ниндидер курорт-санаторий каласы итеп күрсәтә иде.

— Агачлар ник койманың эчке ягында түгел? — дип сорады архитектор Хәйдәров.

Проект буенча алар эчтә булырга тиеш иде. Без, колхоз җитәкчеләре, киңәштек тә агач аллеясен койманың тышына чыгарырга булдык. Беләсезме, комплекс озак төзелде, проект белән исәпләшсәң, агачларны корылма үзе төзелеп беткәч кенә утыртырга туры килә, алдан утыртсаң, алар тапталып, сынып, изелеп бетәчәк иде. Шуңа күрә без аларны койма артына утырттык, комплекс төзелә башлаганчы ук. Инде менә күзгә күренерлек урман булдылар.

«Бүре бу. Эшли дә белә, эшен күрсәтә дә белә. Төлке бу, хәйләкәр төлке!» — дип уйлады райком секретаре.

— Яхшы, — диде архитектор. — Мөстәкыйль эшләү яхшы. Ләкин, ялгышмасам, төзелеш банкылары типовой проекттан тайпылырга, аңа төзәтмә кертергә рөхсәт итмиләр шикелле. Сез ул ягын ничек көйли алдыгыз соң? Анда бит акчаны тиенләп санаучылар утыра.

— Ә без алны-артны карамадык. Үзебезгә ничек җайлы, шулай эшләдек. Комплекста бетон юллар каралмаган иде, дамба тәбәнәк иде. Ә без дамбаны ярты метрга күтәрдек, ун километр озынлыгындагы бетон юллар белән урадык комплексны. Проектта терлекчеләрнең ял йорты юк иде, кибетләр дә каралмаган иде. Анда бәләкәй генә будка каралган, терлекчеләр анда черем итеп алырга тиешләр, шуның янәшәсендә, газета-журналлар укыр өчен, бер бүлмә булырга тиеш иде. Без ветврачларга, комплекс мөдиренә аерым кабинетлар эшләдек, йокы бүлмәсен, душларны, аптеканы өстәдек, махсус мунча салдык, савымчы җиңгиләрнең сәламәтлеген махсус тикшереп тору өчен врач кабинеты булдырдык, азык хәзерләү цехларын, сөт үткәргечтән килгән сөтне җыеп бару пунктын, савымчыларга, бозау үстерүчеләргә нинди уңайлыклар кирәк — барысын да исәпкә алдык, терлекчеләрне бер мәртәбә бушлай ашата торган ашханә дә булдырдык.

— Проектны күпмегә боздыгыз булып чыга инде? — диде Хәйдәров, ирен чите белән елмаеп.

— Биш йөз меңнән артыграк өстәмә чыгым тотарга туры килде.

— Һәм банкта сезнең башыгыздан сыйпадылармы?

— Сыйпарлар, сыйпамаган кая! Штраф артыннан штраф тондырдылар. Миңа да, шәхсән, колхозга да. Мин үземә төшкәнен барып түләргә дә риза идем, идарә члennары риза булмады. Гомуми җыелышка чыгардык. Җыелыш карарын банкка илттем.

Управляющий кычкыра миңа: «Дәүләт кулланышка керткән типовой проектны бозарга сезнең ни хакыгыз бар?!» — ди.

Мин дә кычкыра башласам, дәгъва, әлбәттә, зурга китәчәк иде. Мин председатель булып кына түгел, депутат та булып аңлатырга тотындым моңа. Мин әйтәм, проектны шәһәрдә яшәгән, колхоз авылын, терлекчеләрнең тормышын сыңар күзе белән дә күрмәгән ар-

хитекторлар ясаган. Ни өчен әле без мәгънәсез бер чиновникның күрсәтмәләрен үтәр өчен генә проектның кимчелекләренә күз йомарга тиеш? Колхозчылар әйтте, үлсәк үләбез, әмма терлекчеләргә уңайлы булган комплекс салып куярбыз, диделәр.

— Кем сезгә ярты миллионнан артык дәүләт акчасын, ссуда акчасын җилгә очырырга рөхсәт итте? — ди бу миңа.

Управляющий бик усал — дөмеккән, кискән-кыркыган нәмәстәкәй. Иренне кысып куйган, каш астыннан карап тора миңа, күзенең карасы эчкә кереп беткән, агы гына торып калган.

— Ни өчен сез, председательләр, дәүләт кесәсенә керүдән туктамыйсыз? Көннән-көн, елдан-ел нахаллаша барасыз? Кем рөхсәте белән сез ярты миллион акчаны артык тоттыгыз? Кем сезгә типовой проектны бозарга, башбаштакланырга рөхсәт итте? Әйтегез, ссуданың күпмесен алырга өлгердегез әле?

— Безнең ссуда алган юк.

Управляющийның тагын да ныграк каны кызды.

— Кемгә сөйләп утырасыз сез моны? Кемне ышандырмакчы буласыз? Комплексыгыз бит өч миллион ярымга төшкән. Хәзергесе моментта ул хәтле акчаның кайсы колхозда булганы бар? Нигә сез депутат башыгыз белән алдашып утырасыз?

— Әйе, — дидем, — комплекс безнең, чыннан да, өч миллион ярымга төште, безнең дәүләттән бер тиен дә бурычка алганыбыз юк.

Управляющий бу юлы русчалатып кычкырып җибәрде:

— Не может быть!

Моңарчы миңа татарчалатып акырып утырган кешенең кинәт русчага күчүен аңладым мин, башкалар да ишетсен, башкалар да аңласын, башкалар да үзен якласын өчен русчалатып кычкырды.

Шундук бөтен банкны аякка бастырды.

— Документы! Живо!

Сәгате-минуты белән безнең счетны, алган акчаларны табып китерделәр.

Чыннан да, безнең ссуда алмаганны, төзү эшләренең һәммәсен инде менә утыз ел буена үз акчабызга гына башкарганны белгәч, аңа хәтта күңелсез булып китте. Минем белән дуамал сөйләшә башлавын аклар өчен:

— Да-аа. Чыннан да — үз акчагызга. Бу факт хәлне үзгәртә, — дип үз алдына сөйләнде. Аннары миңа тагын бер мәртәбә усал гына карап алгач әйтте: — Барыбер проектны бозарга хакыгыз юк. Ул бит институтлар тарафыннан төзелеп, совмин аша гамәлгә кертелгән. Штрафны без колхозга түгел, банк рөхсәтеннән башка финанс системасын бозганыгыз өчен, үзегезгә салабыз. Рәхим итеп биш йөз сумны банкка түләгез, аннары счетыгыздагы арестны алырбыз, — диде.

Аның үз дигәнен итәр өчен генә күрәләтә явызлык эшләве минем кәефемне алды һәм мин дә аңа каршы закон капчыгын ачып җибәрдем:

— Гафу итегез, управляющий иптәш, колхозчының үзе тапкан, бөртекләп, тиенләп җыйган акчасын үзе белгәнчә, үзенә җайлы булганча тотарга хакы юк дип кем әйтте сезгә? Мин, Югары Совет депутаты буларак, ул законнарны кабул иткән чакта, үзем кул күтәрдем, сезнең «Сабанчы»га да, миңа да штраф салуыгыз — законсыз күренеш, әгәр шуның белән килешергә теләмисез икән, безнең счеттан арестны алмыйча, колхозчыларны акчасыз калдырасыз икән, мин хәзер үк Югары Советка телеграмма сугам, — дидем. Кычкырмыйча, тавышны күтәрмичә, үземнең хаклы икәнемне күрсәтер өчен тыенкы итеп әйттем.

Управляющийның яңак сеңерләре бүртеп чыкты.

— Алыгыз счетыннан арестны! — диде янында торучыларга, ә

миңа бер сүз дә әйтмичә, хәтта ки саубуллашмыйча да кабинетына кереп бикләнде.

— Әйтмәс шул. Берәүнең дә җиңеләсе килми, — диде Тимергалиев һәм архитекторга күз кысып алды: менә кем янына алып килдем мин сине, янәсе.

Әмма Хәйдәревнең аңа һич кенә дә игътибар итмәстән, Айтугановка карап, аны бик тә бирелеп тыңлавын күргәч:

— Фәһим Сабирҗанович, без тагын рәссам халкы алдында күп сөйләп, мактанчыклар исемен күтәреп калмыйк, күрсәтегез терлекчеләргә җайлы булсын дип ясаткан өстәмәләрегезне. Уңайлы кабинетлар, җылы ашханәләр бар икәнен хөрмәтле кунагыбыз үз күзе белән күрсен, — диде.

— Әйе, әйе, кытайлар әнә, йөз тапкыр ишеткәнче бер тапкыр күргәнең яхшырак, диләр. — Бу сүзләрне, райком секретарен яклау өчен, Сәүбанов әйтте.

— Ашыкмыйк, җәмәгать. Без башта сөт үткәргечкә, аннары диспетчер пунктына, аннары сөтнең куелыгын колхозда ук билгели торган лабораториягә сугылырбыз. Алары да артык чыгым булып саналды банкта. Әмма без сөт үткәргеч кую белән савымчыларны көненә бишәр центнер сөтне кул белән күтәреп ташудан коткардык, ә лаборатория безне алдаучылардан аралап алды...

Бүлмәләрне, кабинетларны, цехларны, сыер араннарын, автомат җайланмаларны караган саен, андагы яңалыкларны күргән саен Казан кунагы уйчанлана барды. Айтугановның күңеленә ошады аның үз-үзен тотышы. Димәк, ул буш кеше түгел, димәк, колхоз авылы проблемалары аны битараф калдырмый. Әйе, калдырмый торгандыр, юкса ул кино-мазар күрсәтер өчен, телевидение тапшыруларын карар өчен дип махсус ясалган залны да, кибетләрне дә озаклап карамас, терлекчеләргә дип пешерелгән аштан авыз итәргә теләмәс иде.

Төшке аштан соң алар төп эшкә керештеләр. Райком секретаре белән агропромчы Сәүбанов күптәннән кыҗрап торган эшкә. Авылның тышкы кыяфәтен тагын ничегрәк затлы итәргә була?

Хәйдәрев хикмәтле кеше булып чыкты. Идарә алдына, урамга тезеп куелган икешәр метр биеклегендәге унбер стендны ул озаклап, җентекләп карады.

— Моны сез худфондта эшләттегезме, Фәһим агай? — диде.

— Юк. Моны безнең ветеринария врачы Каюмов Максуд эшләде.

— Нәрсә, сез аны художество училищесында укыттыгызмыни?

— Укытмадык. Үзлегеннән өйрәнгән. Ул үскән чакта безнең Балдамар мәктәбендә художественныйны тәмамлаган бер рәссам бар иде. Рәсем җене Максудка әнә шул укытучыдан йогып калды. Каюмов чеканканы да белә, агач тамырларыннан җанварлар ясый, кайберләрен музейга да куйдык.

— Музеегыз да бармыни?

— Бар. Акчуртанда. Моннан уникe чакырым. Иске мәчетне ремонтлап, туган якны өйрәнү музее ачтык. Ул үзе бер тарих. Вакыт булса, үзегезгә генә аерым сөйләрмен әле. Музейны фәнни нигезләүче егетебез Казанда яши. Гарәп-фарсыны су кебек эчә, үзе рәссам да. Төп мәсьәләгә кайтыйк: менә сез, архитектор кеше, бу стендларны ничек дип табасыз? Ярыймы болар, әллә яңаларны эшләтергә кирәкме? Сез әйтмешли, худфонд аркылы...

— Бу стендларның бәйләнерлеге юк, Фәһим агай. Хәрефләре дөрес, ерактан ук күренеп тора, плакат таләпләренә җавап бирер дәрәҗәдә язылган болар. Рәсемнәре дә канәгатьләндерә мине. Тик боларның... урыны монда түгел. Алар бит сезнең идарә йортыгызны каплыйлар. Идарә бинасы матур — ак кирпечтән, өстәвенә колонна-

лы, килгән бер кеше күрә алсын иде аны, соклана алсын. Кыскасы, стендларны моннан алырга кирәк.

Морат Баяновичка, ниһаять, җан керде.

— Кайдарак куйсак дөрес булыр икән, Сәфәр Хәйдәрович?

— Минемчә, аларны менә шушы керү юлының уң ягына, коймага тезеп чыгарга була. Килгән-киткән кеше идарәгә шушы юлдан керә бит. Шулай итсәгез, идарә йорты да капланмас, стендлар да юри тезеп чыккан төсле булмас. Карыйсы килгән кешенең стендка күзе болай да төшәчәк.

— Рәхмәт, Сәфәр Хәйдәрович! — дип ашыгып хуплады аны райком секретаре, тик архитектор көтмәгәндә аның күңеленә тиеп алды:

— Ашыкмыйк, иптәш секретарь, хуҗаның сүзен ишетмәдек бит әле. Килешәсезме минем белән, Фәһим агай?

— Килешәм. Акыллы фикер, — диде Айтуганов.

Аннары алар идарә йорты каршысындагы бәләкәй бакчага куелган Батырлар һәйкәле янына килделәр.

Архитектор Хәйдәров һәйкәлне — биек пирамиданы барлык ягыннан карап чыкты.

Бөтенләй якын ук килеп, күгәрми торган калайны каккан кадакларның тутыккан күгәрекләре юл-юл булып калай өстенә агып төшкән урыннарын күзлек киеп карады. Артка чигенә-чигенә, кулын каш өстенә куеп та карады. Урам якка чыгып, ике-өч йортны узып китеп тә карап торды. Пирамиданың бер кырыена ярым түгәрәк ясап, цементтан коеп эшләнгән тәбәнәк стенага язылган исемнәрне укыды. Анда 580 кешенең исеме теркәп куелган иде. Сугыш кырыннан кайта алмый калганнар...

Ул, парланып киткән күзлеген салып, аны ап-ак кулъяулыгы белән озаклап сөртте. Айтуганов аның һәйкәлдән канәгать түгеллеген аңлады.

— Пожалуй, менә монысын алыштырырга кирәктер, — диде Хәйдәрев.

Тимергалиевкә шул җитә калды.

— Алыштырырбыз. Колхоз көчле! Фикерегезне төгәлрәк итеп әйтсәгез иде, Сәфәр Хәйдәрович. Нindiрәк итеп күрергә телисез сез миллионер колхоздагы Батырлар һәйкәлен?

Бер читтәрәк хәзергә дәшми-нитми басып торган председатель Айтугановка һәм агропромчы Сәүбановка карап алгач, архитектор Хәйдәров әйтте:

— Гомумән, һәйкәлләрнең монументаль булганы яхшы. Минем уемча, һәйкәлдә кеше сыны — сугышчымы, баласын күтәргән анамы булырга тиеш. Аны заводта койдырып алу кирәк. Әйтик, бронзадан. Аннары менә бу цемент стена ошамый миңа. Аны мәрмәрдән куярга, исем-фамилияләрне чокып язарга кирәк булыр. Ә халык йөри торган урыннарга, кимендә бер гектар чамасы бетон плиталар җәеп чыккан-да әйбәт булыр иде. Ә шул мәйданны, диңгез портларындагы шикелле, калын кара чылбыр белән әйләндереп алу мәслихәт, минемчә. Мондый һәйкәл миллионер колхозның ныклыгын, куәтен күрсәтеп тора алыр иде. Менә бу җитди, бик җитди эш булыр иде.

— Күпмегәрәк төшә инде андый һәйкәл? — диде Тимергалиев.

— Нинди материалдан коясың бит? Фигурасы нинди биеклектә була — шуңа карап. Чама белән — алтмыш меңнән бер йөз меңгә чаклы.

Эшләрнең кая барганын Айтуганов архитекторның беренче сүзләреннән үк аңлап алган иде инде. Кинәт аның зиһене томаланды. Әлегә пирамиданы үз урынында түгел дип уйлау белән йөрәге катыкаты кага башлады. Күз алдына кырык еллар элек булган күренеш килеп басты.

1946 елның җәе. Балдамарның, Югары һәм Түбән Камышлының фронттан исән кайткан утызлап кешесе, кулларына көрәк тотып, җир казый. Чүкеч белән калай суга. Юан нарат бүрәнәне пирамида итеп юна. Берсе китә, икенчеләре көрәккә, балтага, чүкечкә тотына. Маңгайларыннан тир ага, солдат гимнастеркалары аркаларына ябышкан.

Кулына көрәк тота алмаганнары, сыңар аяклы яки сыңар куллылары бар. Алары чирәм өстенә утырып, тәмәке тарталар. Үзләре белгәнчә киңәш бирәләр. Исәннәре эшли, Балдамарга, Камышлыларга кайта алмаганнарга, чит-ят җирләрдә үлеп калганнарга һәйкәл әзерли...

Эштән соң вакытларда, иртәләрен һәм кичләрен тырыша торгач, һәйкәл әзер була. Казыган чокырга пирамиданың төбен турылап, төрле сүс арканнар белән тарттырып, чокырга төшерәләр — иң авыр, иң җаваплы эшне башкарып чыгалар.

Чокырны кыр ташы белән тутыралар — ни дисәң дә унбер метры җир өстендә утырып калды бит, җил-давыллардан авып китмәгәе. Кыр ташы өстенә сыек цемент агызалар, цемент шакыраеп ката — пирамида бернинди давылларга да бирешмәслек хәлгә килә. Аннары һәйкәл тирәли тупыл кисентеләре утыртып чыктылар. Алар язын шаулап яфрак ярды һәм елдан-ел биегрәк үрләде. Фронттан исән кайткан укытучы Кәрами сугышта үлеп калганнарның исем-фамилияләрен йорт саен йөреп җыйды, азактан үзе ясап өлгерткән цемент стенага майлы буяу белән ун көн буена язды.

Еллар узды, җилләр исте, елгалар саекты, әмма бу урын шул еллардан бирле «Сабанчы» авылларының иң изге, иң газиз урыны булып санала. Идарәгә килгән бер кеше шушы һәйкәл янында уза. Күккә ашкан өянкеләр, яфракларын талгын җилдә шаулатып, исәннәргә сәлам бирәләр, яу кырыннан кайталмый калганнарның истәлеген сөйлиләр. Инде шул өянкеләрне кисеп ташларгамы? Инде шул пирамиданы аударып, ниндидер яңасын, күрер күзгә мәһабәтрәк булганын куяргамы? Ветераннар ни дияр моңа, үпкәләмәсләрме соң?

— Син нишләп бер сүз дә дәшмисең, Фәһим Сабирҗанович? — диде райком секретаре. — Архитектор иптәш безгә бик тә яхшы проект тәкъдим итә ич.

— Ишетеп торам...

— Соң, шулай булгач?

— Беләсезме, Хәйдәрев иптәш, — дип Айтуганов Казан кунагына таба борылды. — Мин сезнең тәкъдим белән килешәм. Әмма дә ләкин без, сугыш ветераннары, яу кырыннан исән кайтканнар, бу һәйкәлне 1946 елны үз кулыбыз белән куйган идек. Хәтер дигән нәрсә бар бит әле...

— Аңладым... — диде архитектор, гафу үтенгән сыман, кулын күкрәгенә куйды.

— Нәрсә, һәйкәлнең яңасын куймаска булдыкмыни? — диде Тимергалиев, кәефе китеп. Ай бу Айтугановларны, киресен эшләмәсәләр, күңелләре булмый...

— Гафу итегез, Морат Баянович, булмый. Кул күтәрелми бу һәйкәлне ватарга...

— Зерә... — диде Сәүбанов. — Зерә каршы киләсез, Фәһим Сабирҗанович. — Без сезгә ярдәм итәргә теләгән идек.

— Китик без, — диде Тимергалиев. — Калганын райкомда сөйләшербез. Ә сезгә, иптәш Айтуганов, бер айдан делегация килә, барлык илдән. Ике йөздән артык кеше. Шул уңайдан килгән идек без. Алар авылларыгызны, кешеләрнең яшәү рәвешен караячак. Обком заданиесе бу — ике йөз кешене бер көн буе туйдырырлык урын әзерләгез.

— Ә ник, безгә атап киләләрмени алар?
— Әйе, комплексны карарга. Мәскәү киночылары төшергән фильм кешеләрдә кызыксыну уяткан. Әзерлек барышын хәбәр итеп торырсыз дип беләм. Монысы үтенеч түгел, монысы — райкомның әмере.
— Кулдан килгән кадәрле тырышырбыз.
Тимергалиев белән Сәүбанов, кичке ашны да көтеп тормастан, үзләре алып килгән архитекторны машиналарына утыртып кайтып киттеләр.
Айтуганов аларны терлекчеләр каласы урнашкан үргә хәтле озатып куйды.
«Менә хикмәт, тагын бер мәшәкать артты. Эшсез килсә, эш калдыра», — дип уйлады Фәһим абзый, отыры ераклашкан райком машинасыннан күзен алмый карап торды...

## 9

Ул көнне бик сәер төш күрде Фәһим абзый.
Кич, имеш. Фәһим — яшь-яшь егет, салам түбәле бер йортның капка төбендә утыра, имеш. Өй каршысындагы карт шомырт ап-ак чәчәктә. Әнә шул шомырт эчендә, Фәһимгә күренмичә, сандугач сайрый: «Фәһ-һим, Фәһ-һим, фуйть-фуйть», — ди. Менә сиңа тамаша. Фәһимнең исемен каян белде сандугач?
Ул да түгел, шомырт чәчәкләре арасына башын тыккан бер сыер карап тора: «Фәһ-һим-мүүү, Фәһ-һим-мүүү», — дип мөгри сыер. Нәрсә әйтмәкче була икән ул? Ә-ә, аңлады Фәһим, әлеге сыер аңардан: «Әллә син, Фәһ-һим-мүүү, Сөембикәне эзләп килдеңмү?» — дип сорамакчы була. Аптырый Фәһим, карале, әкәмәт, сандугач та белә аның исемен, сыер да белә. Сыер хәтта аның сөйгән кызының да исемен белә!
Фәһим сыердан ояла, аны куып җибәрмәкче була. Ләкин сыер китми, аның янына башка сыерлар килә. Сыерлар ишәя. Көтүләре белән Фәһим өстенә киләләр. «Син безнең Сөембикәне урлап китмәкче буласыңмы?» Сыерларның мөгезе ыргак төсле, күзләре зур, акайган, алар аны сөзмәкче булып, башларын бөгеп киләләр. Ярсып киләләр алар, җирне дөпелдәтеп, җыйнаулашып киләләр.
Фәһим йөгермәкче була, йөгерә алмый, сыерлар Дәүрән болыннары ягына китеп баралар. Фәһим таллар арасына кереп егыла да... уянып китә. Караса — Фазылбану корткаларның шомырт төбендә йоклап ята икән ич. Ул бит, туктале, ник килде соң әле монда? Исенә төште, Дәүрән болыннарындагы печәннең өлгергәнме-юкмы икәнлеген белешергә дип килгән иде бит, карап йөреп арыганнан соң Камышлыдан Балдамарга килеп чыккан иде. Сөембикәсен күрәсе килеп, аларның капка төбенә килеп утырган иде. Сөембикәсе, менә-менә мәктәптән, балаларны укытудан кайтып җитәр, ул аны сагынды, күрәсе килә, сөйләшәсе килә. Көтеп-көтеп тә Сөембикәсе кайтмагач, ул Фазылбану корткаларның шомырт агачы төбенә ятып тормакчы, ял итеп алмакчы булган иде. Бакчы, йоклап та киткәнмени? Чү, каяндыр быргы тавышы ишетелә. Көтүче Җаппар ич бу. Нәрсә, көтү дә куалармыни инде? Шулай озак йоклады микәнни ул? Фәһим тормакчы була, гәүдәсе авырайган — тора алмый, аякларына гер такканнармыни, атлап китүе кыен. Юк, ул әле йокылы-уяулы гына ята. Күзләре йомыла, йомыла. Ул тагын төш күрә башлый. Каяндыр ат көтүе килә. Ялларын тузгытып, койрык чәнчеп чаба атлар. Юк, чапмый алар, һавадан очып бара. Фәһимнең малай чагы. Әтисе Сабирҗан ишеп биргән каеш чыбыркыны тотып, атлар артыннан китә.

Атлар очып барган җирләреннән Дәүрән болынына төшәләр, су эчәргә дип инеш буена җыелалар. Фәһим аларның инештән су эчкәннәрен карап тора, әтисе кебек, сызгырып эчермәкче була атларны, тик сызгырган тавышы чыкмый. Ул да түгел, атлар, төтен кебек эреп, юкка чыгалар. Инештә алардан соң болганчык су гына агып кала. Су уртасында бер таш ята, әллә түмгәкме? Алай дисәң, нигә соң ул селкенә? Карале, таш түгел икән бит ул, түмгәк тә түгел, су уртасында ятып калган ат икән. Ул тора алмый. Бытбылдык Сәмигулла җигеп йөргән сары кашка бит бу. И мескенем, атлар белән бергә чыккан. Ул бит күтәрәмгә калган ат, нигә аны кәнүшнидән чыгардылар икән? Баягы ат көтүе төтен эченнән килеп чыга, атларны Сөләйман абзый җитәкләп килә. Атлар кешегә әвереләләр. Кулларында — бау-аркан. Ә алар бит Бытбылдык Сәмигулланың сары кашкасын су эченнән чыгарырга килгәннәр. Сары кашканы бау белән уратып алып, судан чыгармакчы булып тарталар. И авыр да соң ул күтәрәмгә калган атны торгызулары! Башкалар белән бергә Фәһим дә тарта бауны, тырышып-тырышып тарта, тарта торгач егылып китә һәм... күзләрен ача. Күзенә кояш бәрә, Дәүрән болыннары ягыннан көтүче Җаппарның быргы кычкыртканы ишетелә. Куркып, торып утыра Фәһим. Караса — каршысында ук басып тора көтүче Җаппар, сап-сары тешләрен ыржайтып көлә: «Персидәтел энекәш, Фәһимулла, син нишләп йөрисең монда? Кәҗәң югалдымы әллә? Шул йолкыш кәҗәңне эзләп килдең мәллә?» — Фәһим хурлана, ояла. Көтүче Җаппар аның бирегә ник килгәнен белә, әлбәттә. — «Өй артына җегет килгән, кертик микән, әнкәем? Җегете бигрәк уңган икән, шомырт төбенә җатып җоклаган», — ди Җаппар, сап-сары тешләрен ыржайтып көлә...

Фәһим тагын төш күрә башлый.

...Дәүрән болынынннан бер кыз атлый. Аягында сап-сары чабата, аппак йон оекбаш. Бала итәкле ал күлмәген, чигүле ак яулык астыннан ике толым кара чәче атынгалап бара, толым очындагы чулпылары чылтыр-чылтыр килә. Ул да түгел, алар Фәһим белән бергә, янәшә атлый башлыйлар. Фәһим кызның кулыннан кысып тоткан. Тузанлы юлда алар артыннан ике янәшә эз сузылып кала. Карале, ул кызый Сөембикә икән ич. Фәһимнең сөйгәне икән бит ул. Бара-бара да туктый Сөембикә, сап-сары булып, кояштай балкып торган чабаталарына карап әйтә: «Менә аягыма чабата киеп алдым әле. Җиңел булсын дидем. Синең белән барасы юл озын, бик-бик ерак әле икәү бергә барасы», — ди. Фәһим аны үзенә таба тартып китерә, кочакламакчы, үпмәкче була. Инде үбәм дигәндә генә, Сөембикәсе аны этеп җибәрә: «Кит, мәхәббәтсез, әллә көпә-көндез, оялмыйча, үбешеп торырыеңмы?» — ди. Фәһимнең аңа гел дә менә ягымлы сүзләр әйтәсе килә, тик авызыннан сүзе чыкмый. Төштә гел шулай инде ул, сүз чыкмый авыздан. Сөембикәне кулына күтәрә Фәһим, алар болын өстеннән очып баралар. Карале, адәм баласы күккә күтәрелә алмый, аның өчен кошлардагы төсле пар канатлар булырга тиеш, диләр, дөрес түгел икән бит ул сүзләр, адәм баласы күккә күтәрелә, кошлар кебек очып та бара ала, тик аның өчен янында өзелеп-өзелеп сөйгәнең генә булу кирәк икән...

...Алар инде очмыйлар, арыш басуы уртасыннан баралар. Сөембикә җилкәсенә аллы-артлы сумкалар аскан. Туй буласы, имеш, Сөембикә туйга дип Таулы Төбәктән ризыклар алып кайта, имеш. И-ии галәмәт, төшкә дә шундый чын нәрсәләр керер икән? Чыннан да, Сөембикә илле чакрымны җәяү атлап, аларның туена ризыклар алып кайткан иде бит. Бик арыган булса да, бик шат иде ул чакта аның сөйгәне. Бүген моңсу, күзләрендә күләгә. Әллә үпмәгәнгә үпкәли микән? Күктән кояш карап торганда, юлның ике ягында сап-сары арыш басулары чайкалганда, ничек инде оялмыйча үбәсең? И җүләркәем, кил инде, алайса, күңелең булсын, үбим инде бер...

...Сөембикә юкка чыга, арыш басулары да югала. Фәһим япа-ялгызы, берүзе генә Таулы Төбәк урамнары буйлап атлый. Шыксыз Таулы Төбәкнең урамнары, агачсыз. Ташлы дамбадан дагалы ат бара. Арбага яшьләр утырган, бер-берсенең иңнәренә кулларын салганнар. Сугышка китүчеләр микәнни? Алай дисәң — ник гармуннары юк? Ат арбасы яныннан биек фуражка кигән, кулына мылтык тоткан милиционер бара. Бакчы, арбада яшьләр түгел. Арбада амбарчы Гөләндәм, бухгалтер Мәдхия. Өс-башлары тузган, битләре канга баткан. Милиция аларга мылтык түтәсе белән суга. Фәһим милиционер янына килә. «Ник сугасың аларга?» — дип кычкырмакчы була, кычкыра алмый, тавышы юк, ыңгыраша гына...

— Фәһим, Фәһим, дим, әтисе, тор әле, — дип иңбашыннан каты гына селеккәнгә ул күзләрен ачты. Каршысында — Сөембикә.

— Әтисе, саташтың ахрысы, төш күрдең бугай, бик каты ыңгыраштың...

— Әкәмәт сәер төш күрдем. Әллә кайчан булган хәлләрне күреп бетердем. Синең белән һаваларда очып йөрдем, өегезнең шомырт төбендә йокладым, Таулы Төбәктән сумкалар күтәреп кайтканыңа хәтле кердe, сары чабаталарыңа хәтле. И гомерләр, шул чаклар мидә сакланып калган диген, ә?

— Ник ыңгыраштың соң? Болар бит куркыныч төш түгел...

— Әле сине күрү белән генә бетмәде. Бер милиционер безнең авыл кешеләрен арбага төяп, төрмәгә алып китеп бара икән, дим. Амбарчы Гөләндәмнәрне. Вәйт хикмәт, кырык ел элек баштан узганнар төшкә керә.

— Ярар, тынычлан, әтисе. Көннәрең бигрәк борчулы булды шул: Галинурыбыз өчен жаның гасабиланды, — диде Сөембикә ханым жанны тынычландыра торган ягымлы тавышы белән. — Әйдә, тор инде, юын, киен. Син яраткан бәрәңге күзикмәге пешердем.

Көне буе исеннән чыкмады күргән төше. Керсә дә керер икән чын төш. Сөембикәне әйт — нинди дә үзе булып, яшьлеге булып керде төшкә. Йоклап киткән иде шул бер көнне аларның шомырт бакчасында.

Ә милиция белән булган хәлнең гомердә дә онытыласы юк.

Фәһим председатель булып эшли башлаган гына иде әле. Заманаларның бик авыр, законның бик каты чагы иде. Бөтенесе фронт өчен дип эшләнелә. Ачмы син, тукмы — беркемнең бер эше юк. Жыеп алынган ашлыкның унөч проценты орлыкка калдырыла, унбиш проценты фуражга һәм колхозчыларга. Бер гектардан жиде центнер уңыш алына. Барлык жыйнап алганы — дүрт-биш центнер. Идарә атларының һәм ерак урманга баручы атларның аз булса да азыклары булсын дип, йөз пот солыны аерып куйганнар иде. Балдамарга район милиция начальнигының урынбасары килеп төште. Кашавай чанага киерелеп утырган, чырай тук, караш — бөркетнеке! Шулай булмыйча соң — фронтны кайгырта бит. Тылдагы фронт солдаты! Колхозларда бер төрле дә башбаштаклык булмаска, бер генә тиен акча да, бер генә грамм ашлык та читкә китмәскә тиеш. Сталин шулай кушкан, Сталин әйткән — закон, ә милиция — закон сакчысы. Балдамарга ул килеп төшкән мәлдә — гонаһ шомлыгы — урман кисүчеләргә башлык булып барасы Шаһгали карт аркасына бер пот солы күтәреп кайтып бара икән. Мөбәракшин аны күрә, туктата: капчыгында нәрсә? Солы. Солы ник синең капчыкта? Каян килгән солы? Менә шулай, шулай, ерак урманга барабыз, утын кисәргә. Амбардан солы алдым, атыма.

Кашавайлы чана амбар ягына борыла, амбарчы Гөләндәмгә усал карап әйтә:

— Кемнәргә солы бирдең? Алар хәзер кайда? Немедленно, бер-

сен-бер калдырмый, табып алыгыз, солыларын кире китерсеннәр. Бу ниткән башбаштаклык? Фронтка кирәкле солыны разбазаривать итеп ятасың, понимаешь?

Мөбәракшин амбарга пломба салдырта, Гөләндәм елап Фәһим Айтуганов янына йөгерә.

Авыл советы председателе Нәҗми абзый, колхоз председателе Айтуганов — законга каршы бара алмыйлар бит инде — ерак урманга китәсе печән йөген сүттерделәр, чана астына ук салып куйган ике капчык солыны идарә йортына алып кайттылар.

Ә Шаһгали карт белән үсмерләр, сүгенә-сүгенә, олауны яңадан төйи калдылар.

Мөбәракшин амбарчы Гөләндәм ападан, әвен бригадиры Шәйхелисламнан, бухгалтер Җамалиева Мәдхиядән сорау алып, куркытып һәм янап, барысын бер олау белән Таулы Төбәккә озаттырды. Аларның һәркайсының өйләренә кереп, берәм-берәм тентү ясап чыктылар. Ул заманда ындыр сугу кыш урталарына хәтле сузыла торган иде. Әвен бригадиры Шәйхелислам, — күрәчәгенә күрәдер инде, — кесәсенә салып бодай алып кайткан, шуны калай чүмеч белән пешерергә куйганнар. Биш баласы бар иде Шәйхелислам абзыйның. Озак тормый, Шәйхелислам абзыйның бер җамаяк бодай боткасы да идарә өстәленә килеп утырды.

Милиция начальнигының урынбасары, җамаякка таба озын ак бармагы белән төртеп күрсәтеп, председательгә ябырылды:

— Бу ниткән безобразие, Айтуганов?! Дәүләттән яшереп, солы урлап калуың гына җитмәгән, фронтка озатыласы бодайны уңгасулга таратасың! Безнең солдатлар анда кан коя, ил иректе булсын дип башларын сала, понимаешь, ә монда фронт бодаен ашап, симереп яталар. Шуннан соң син кем буласың инде, ә, Айтуганов? Гитлер тегерменәнә су коючы син, безнең җиңелүебезне, фашистларга кол булып калуыбызны теләүче корткыч! Менә кем син!!!

Ул төнне Фәһимнең күзенә йокы кермәде. Иртәгесен мине дә алырлар, райүзәккә конвой белән алып китәрләр, дип көтте. Аны алып китмәделәр китүен, әмма иртүк авылга килеп төшкән район ревкомиссиясе, тикшерү материалларын җыеп алып, Таулы Төбәккә китеп барды. Өскә килгән бәланең ни белән бетәсен көтеп, кул кушырып утыру мөмкин түгел иде, өстәвенә әнисе Гөлйөзем ах-вах килә, аның елап шешенгән күзләрен күреп тору чамасыз авыр иде.

Ни булса ул дип, Фәһим Айтуганов Таулы Төбәккә үзе китте.

Милиция идарәсенә барды — ишегалдына да кертмиләр. Анда керә алса, ичмасам, кулга алынганнарның берсен генә күреп булса да, тәрәзә аша сөйләшер иде. Озак йөргәннән соң, биек болдыр аша идарә йортының эченә керде. Авыр имән ишекләрне бер ачып, бер ябып йөри торгач, кирәкле кешесен, ниһаять, тапты. Кулга алынганнарның хәлен белергә рөхсәт иттеләр. Ишегалды уртасындагы агач йортка — КПЗ дигән урынга япканнар икән «сабанчы»ларны. Милиция атларын караучы Хәмзә карт кайсы тәрәзә янына барырга икәнен өйрәтеп җибәрде. Беренче булып аны тәрәзәдән Гөләндәм апасы күреп алды. «Фәһим энем, без монда»,— дип елап җибәрде. Ат караучы карт моны күрде, рәшәткәле тәрәзә артындагы хатынның елаганын ишетте, гозерләнеп сорагач, Фәһимне тоткын белән сөйләштерде, үзе капка буена барып, милиция кешеләреннән берәрсе кермиме дип саклап торды. КПЗ дигәннәре — камера предварительного заключения дигән сүз икән, ягъни суд хөкеменә кадәрле ябып тоту урыны. Әнә шул камераның түбәнге катына әвен бригадиры бөкре Шәйхелислам абзый, бер бүлмәсенә колхоз бухгалтеры Мәдхия ябылган булып чыкты. Шәйхелислам картны Фәһим ишегалдына чыккан килеш очратты, ул, милиция озатуында, параша түгәргә чыккан иде. Карт

еламый, әмма ул бик суырылган, ябыккан, сакал-мыегы үскән. Ул үзе өчен кайгырмый, мин Себердән кайта алмасам, балаларым ятим кала инде, дип кайгыра иде. Балдамар кешеләре ул чагында төрмәгә эләккән бер кешене Себер җибәрәләр, шахталарда күмер чаптыралар, урман аударталар дип беләләр иде. Аларның Себер хәтле Себердән әйләнеп кайтачакларына берничек тә ышанмыйлар, төрмәгә эләккән һәркем, алар уенча, туган җирләреннән еракта, газиз кешеләрен күрергә тилмереп үлеп калачаклар инде...

Шәйхелислам картның кайта алмам дигәне Фәһим өчен бик табигый иде, чөнки ул сәламәт түгел, авылда ул үләннәр белән, яңа сауган сыер сөте белән генә дәваланып тернәкләнгән иде. Бөкре булганнан бигрәк, аның бавырымы, бөереме сызлый иде. Себердә аңа кем әзерләсен ди үләннәр белән сөтне! Аның белән Фәһим бер-ике авыз сүз алышты, дөньядагы бик күп бәхетсезләрне, «өтермән»гә ябылганнарны саклаган карт милиционер, үзе читкәрәк китеп, аларга хәләхвәл белешергә рөхсәт итте.

Бәлагә тарыганнарның хәлен белгәннән соң Фәһим милиция начальнигының урынбасары Мөбәрәкшин янына керде. Өнәмичә каршы алды аны Мөбәрәкшин, иренен кысып, аска карап сөйләште. Юк, моны сөйләшү дип әйтергә дә мөмкин түгелдер.

— Юкка йөрисең, председатель, үзеңне утыртып куймаганга сөенәсе урында, башкаларны кайгыртып маташасың. Эшләрен тикшереп, допрос алып бетергәч тә мин синең корткычларыңны суд хөкеменә тапшырам,— диде.

Район башкарма комитетына кереп чыкты Фәһим — ревизия комиссиясенең тикшерү нәтиҗәләрен белеште. Колхоз буенча аларның ялгыш эшләре юк, барысы да тәртиптә икәнен белде. Анысы Айтугановның җанына җылы өрде. Инде алай булгач, мәсьәләне ахыргача хәл итәр өчен, райкомга барырга кирәк. Менә анысы куркыта. Иң азаккы, иң кыен сүз яки җанга җиңеллек китерә ала торган җылы сүз анда әйтеләчәк. Беренче секретарьның кабул итү бүлмәсе янына ике тапкыр килеп, ике тапкыр кире китте. Өченче мәртәбәсендә техник секретарьдан, суык бүлмәдә башына ак йон шәл ябынып утырган яшь кенә кыздан, Заһир абзый янына керергә мөмкин булмас микән, дип сорады. Йомышын әйтеп күрсәтте. Секретарь кыз, Фәһимгә,— колакчын бүреген култык астына кыстырган ак чырайлы чандыр егеткә,— мөлдерәп карап торды да, ярар, сорап карыйм, кабул итсә, керерсең, диде.

Күңеләндә нинди миһербанлыклар булгандыр, кабул итте секретарь Фәһимне. Заһир абый дигәннәре — кыска итеп алдырган коңгырт чәчле, сакал-мыексыз, утыз биш яшьләр тирәсендәге бер кеше иде. Күз төпләренә капчыклар асылынган, күзләре кызарыбрак тора иде. Язу язган җиреннән бер генә мәртәбә күтәрелеп карап, каршысындагы егетне күздән үткәргәч, ул ни актан, ни күктән дигәндәй, бер сүз дә әйтмәде, килүченең гозерен тыңлап кына утырды. Чырае өметле түгел, чырае кырыс, үтә дә кырыс иде. Бер мәртәбә дә ачылмады, яктырмады. Тыңлап бетергәч, Фәһимгә чыгып торырга, коридорда көтәргә кушты. Фәһим үтә дә борчылып, коридорда әрлебирле йөренгән чагында, Мөбәрәкшин һәм аның белән бергә милиция киемендәге тагын ике кеше, кулларына папкалар тотып, райком секретаре кабинетына кереп киттеләр. Мөбәрәкшин Фәһимне күрде, каш астыннан аңа шундый усал итеп карады, Айтугановның күңеленә тагын шом төште,— болай булгач, каныгыр инде, юкны бар итеп, барны тагын да күпертебрәк сөйләр, бер чирәшеп катса, кире чигенмәс, үз туксанын туксан иткәнче тырышыр...

Фәһимне күңелсез уйлар басты.

Бик озак булды Мөбәрәкшиннар кабинетта. Коридордагы стена

сәгате дыңгырдатып берне сукты, икене сукты — тегеләр һаман кабинетта.

Ниһаять, чыктылар. Фәһимгә күтәрелеп тә карамыйча китеп бардылар. Секретарь кыз, ишектән ак шәлле башын тыгып:

— Айтуганов! Заһир Шакирович янына керегез,— диде.

Секретарьның йөзе бу юлы да ачылмаган, гадәттәгечә, кырыс иде. Айтугановны ул өстәл янына, үзенең каршысына утыртып, «Сабанчы»дагы хәлләрне озаклап сорашты. Тик соңыннан гына, күзен күтәреп, Фәһимгә карады. Күзләре һаман кызыл, тик күз карашы кырыс түгел, ягымлы иде.

— Сезнең кешеләрнең гаебе юк, энем. Милиция аларны чыгарыр. Ат белән килдеңме? Бик яхшы. Алмага бар үзләрен, утыртып алып кайтырсың...— диде.

...Бик күп еллар узган иде инде бу хәлләргә. Бик күп җилләр искән, бик күп сулар аккан, амбарчы Гөләндәм апа да, әвен бригадиры Шәйхелислам карт та күптән гүр ияләре. Бухгалтер Җамалиева Мәдхия генә кайдадыр, Алабугадамы, Чаллыдамы, кызларында яши, инде бик олыгайган, дип сөйлиләр. Кырык ел буена ул көннәрнең хатирәсе күңелдән китми саклана, хәтта төшләргә керә. Фәһим дигән яшь егетнең күңелендә менә шул чагында райкомга карата ниндидер олы бер ихтирам уянып калган иде. Заһир Шакирович дигән кеше аның өчен әтисе Сабирҗан белән янәшә куярлык кеше иде, гаделлекнең үрнәге иде. Әгәр ул Фәһимне тыңламаса, явыз Мөбәрәкшинны гына тыңлаган булса, Фәһимнең авылдашлары әллә кайларда, ерак Себер тайгаларында үлеп калган булырлар иде. Шуннан соң ул үзе дә колхозны тартып алып бара алырлык җитәкче булып үсеп җитәр идеме икән әле? Белмим, икеле. Аның иманы какшаган булыр иде, күңеле төшәр, канаты сынар иде. Сынык канат белән очып булмый. Тау белән тау гына очрашмый, адәм балалары очраша.

Айтугановны СССР Югары Советы депутаты итеп сайлагач, персональ пенсионер, көмеш чәчле Заһир Шакирович, «Сабанчы»га килеп чыкты. Инде бик олыгайган, сиксәнгә килеп җитә язган бу кешенең чырае әле дә бик якты түгел, холкы-фигыле шундыйдыр инде, әмма күңеле бик якты иде. Балдамарга ул Фәһим Айтугановны үзе эзләп килгән, кайчандыр фронттан кайткан яралы егетне инде менә хәзер күкрәп торган миллионер колхозның җитәкчесе, дәүләт эшлеклесе булуы белән бик горурлана икән.

Үткәннәрне искә төшереп, Айтугановларның умарта йортында икәүдән-икәү генә төн үткәрделәр. Сүз иярә сүз чыгып, милиция башлыгының урынбасары Мөбәрәкшинны да искә алдылар.

— Исәнме икән әле ул, юкмы? Әгәр исән булса, бер күреп сөйләшәсе иде, элекке кансызлыклары өчен аз гына булса да үкенә микән ул?— диде Айтуганов.

— Таулы Төбәктән ул Казанга күчкән иде. Артык тырышканы хакына аны зур урынга күчергәннәр иде. Казанда янды ул. Илле тугызынчымы, алтмышынчымы елны аны ришвәт алганы өчен ун елга төрмәгә яптылар. Төрмәдән кайта алмаган ул, төрмә больницасында беткән,— диде Заһир абзый.

— Язмыш агач башыннан йөрми, кеше башыннан йөри ул,— дип, Фәһим Айтуганов үзенчә нәтиҗә ясады.

Тавышы йомшак, тавышында һәлакәткә очраган кешене кызгану сизелә иде.

## Бишенче бүлек

### 1

Яз бик иртә килде.

Көттермичә килде.

Казаннан, партия-хуҗалык активы җыелышыннан кайткан чакта, Морат Баянович, үз күзенә үзе ышанмыйча, «Волга» машинасының тәрәзәсен төшерде, райүзәкнең тау битенә күз ташлады, анда кар беткән, малайлар тау битендәге былтыргы үләннәрне яндырып чыкканнар, тау бите үзенең каралыгы һәм шәрәлеге белән күңелгә ниндидер шом сала иде.

Әле бит апрельнең уннары гына. Ә инде кар юк, инде елгалар ташып бетеп, ярларына кайтып төшкән. Дым башка елларны басукырларга акрынлап кына, иплəп кенә сеңә, чөнки яз үз җае белән килү сәбәпле, кар акрын эри, җирнең туңы белән бергә эри, эрегән кар сулары елгаларга таба йөгерми, җиргә сеңә бара иде. Быелгы яз бер атна эчендә карны да ялмап алды, суларны да ерак дәрьяларга агызып җибәрде.

Әгәр яңгыр яумаса?

Кояш шушы рәвештә кыздыруын дәвам итсә?

Морат Баяновичны күңелсез уйлар биләп алды. Обком менә ни өчен актив җыелышын үткәргән, менә ни өчен киңәшмәгә райком секретаре белән райбашкарма председательләрен һәм агропром башлыкларын гына түгел, республиканың сигез йөзгә якын хуҗалыгыннан барлык колхоз рәисләрен һәм совхоз директорларын да чакырган икән.

Үз гомерендә күп төрле киңәшмәләрдә булып, ул киңәшмәләрнең әллә ни файдасын күрмәгән Морат Баянович, Таулы Төбәктән Казанга барырга чыкканда, бу юлы да партия-хуҗалык активы җыелышына зур өмет багламады. Авыл хуҗалыгы буенча секретарь Дулатов ясарга тиешле докладның исеме үк күңелдә ризасызлык тудыра иде.

— Сәүбанов, докладның исемен укыдыңмы?— диде ул агропром башлыгына, машинада бергә барган чагында.

— Укыдым,— диде Сәүбанов.

— Ошадымы?

— Мин ул хакта уйламадым.

— Зерә,— диде Тимергалиев, кесәсеннән киңәшмәнең көн тәртибен язган кәгазьне чыгарды.— Менә без тыңлыйсы докладның исеме: «КПСС Үзәк Комитетының «Авыл хуҗалыгында оештыруның һәм хуҗалык исәбенең рациональ формаларын кертү нигезендә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча кичектергесез чаралар турында»гы карарын үтәүдә республика, партия, совет һәм хуҗалык органнарының бурычлары».

Сәүбанов бик уңайсыз хәлдә калды. Әгәр ул докладның исеме буталчык һәм чамасыз озын дисә, обкомны яманлаган була, әгәр докладның исеме бик яхшы дисә, райком секретаре Тимергалиевкә каршы төшкән була. Менә алтын урталыкны табып кара син шунда!

Ул дәшмәде.

— Йә, ничек?— диде Тимергалиев.

— Озынрак бу, Морат Баянович.

— Моны ничек итеп кыскарак әйтергә була?

— Белмим.

— Беләсең, Даут Кодрәтович, беләсең. Обкомга каршы килү булыр дип кенә әйтмисең. «Авыл хуҗалыгын үстерүнең кичектергесез

чаралары турында» дип аталырга тиеш доклад.

— Бәлкем, бәлкем...— диде Сәубанов.

Алар башка сөйләшмәделәр. Әмма шушы кыска гына гәптән дә Морат Баянович үзе белән янәшә эшләгән агропром башлыгының бигүк таянып булмый торган кеше икәнен чамалады.

Киңәшмәгә бер көн алдан чакырганнар иде. Казанның культура учакларын, кайбер районнарның алдынгы колхозларын күрсәттеләр. Бу чараларның язгы чәчү алдыннан председательләрнең күңелен күтәрү, язгы чәчүгә дәртләндерү өчен эшләнгәнлеген төшенде Тимергалиев. Чамасы чамага килде аның — обкомның беренче секретаре, бөдрә чәчле башын иеп, зур зал белән исәнләшкәч әйтте:

— Кәефегез шәп икәне күренә. Яхшы районнарда, әйбәт колхозларда булдыгыз. Башыгыз да авыртадыр, йөрәк тә?

Залдан реплика:

— Баш авыртмый.

Беренче көлеп куйды:

— Сүз андый авырту турында бармый. Ул авырту күптән юк инде. Февраль уртасында Балтачта унбер килограмм сөт савалар, Кукмара да шуңа якынлаша. Ә башка районнар биш-алты килограмм белән утыралар. Менә шул хакта уйларга кирәк. Баш әнә шуны уйлаудан авыртырга тиеш.

Зал тынып калды.

Әңгәмәне бик озын кереш сүз белән түгел, төп-төгәл саннар һәм фактлар белән башлап, зал белән киңәшүгә коргач, Тимергалиевнең күңелендә докладчыга карата ихтирам хисе уянды.

Колхоз һәм совхозларның саф кереме узган елны бер йөз миллион сумга арткан. Шулай барса, колхозлар дәүләткә булган бурычларын дүрт-биш елда түләп чыгачаклар икән. Узган елны ун район сыер башына өч мең килограммнан артык сөт сауган. Тагын 25 район шуңа ирешсә, тиз арада сикереш күтәргә була.

Планны үтәмәгән районнарның, бурычка баткан колхозларның исеме әйтелә башлагач, Тимергалиев чигәсендә бер тамырның сулкылдап-сулкылдап тибә башлавын сизде. Кара-каршы сөйләшкән чакта тәнкыйтьләнү — бер хәл, мең ярым кеше җыелган театр залыннан тәнкыйтьләнү — икенче. Уф! Давыл узды, докладчы бу юлы Таулы Төбәккә кагылмады.

Ләкин иртәрәк тынычланган икән Морат Баянович. Республика агропромының кәгазь чүмәләләре өеменә, районнарга бер ел эчендә 1200 мәртәбә күрсәтмә җибәрелүгә тукталган чакта Таулы Төбәк тә өскә калыкты. Таулы Төбәкнең РАПОсы үз карамагындагы колхозларга — һәркайсысына!— бер ел эчендә генә дә утыздан артык телефонограмма җибәргән, райком секретаре иптәш Тимергалиев шушыларның һәммәсенә күз йомган.

Дулатов әлеге саннарны үтергеч бер җөмлә белән тәмамлады: «РАПОлар элекке авыл хуҗалыгы идарәләре кебек начар эшлиләр».

Залда кул чаптылар.

Беренче секретарь, кул чабулар тынгач, реплика ташлады:

— Ишеттегезме, Морат Баянович, әнә кул чабалар? Иптәш Тимергалиев, сез биредәме?

Морат Баянович торып басарга, меңләгән күз карашына түзеп, биредә, дип әйтергә мәҗбүр булды. Шул минуттан башлап ул доклад сүзләрен ишетми башлады. Миендә рәнҗү кайнады. Кемгә? Дулатовка, обкомның беренче секретарена, әмма барыннан да бигрәк — Сәубановка. Шушындый зур җыелышта басып торырга, аталы-уллы Айтугановларның авыр күз карашын күтәрергә мәҗбүр булды ул. Сәубанов аркасында. Аның кәгазь волокитасы оештыруы аркасында. Әнә Айтугановлар канат кагадыр, йөз грамм сөтне киметкән өчен безне

келәмгә бастыра идең, «тор-утыр» командасы белән физкультура уйната идең, рәхәтме басып торулары?— дип сөенәләрдер...

...Морат Баянович, киңәшмәдә утыруын онытып, күңеле белән Таулы Төбәккә кайтып киткән иде инде: басуларда, терлек каралтылары арасында йөри, алда торган язгы чәчүне уйлый иде. Кул чабулар аны тагын театр залына кайтарды.

Дулатов индивидуаль сектор турында сөйли икән. Аның киракләгән, шәхси хуҗалыкларның сыерсыз калуларын ачынып телгә ала икән. Аның әйтүенә караганда, шәхси хуҗалыклардагы мал-туар республиканың бер миллионнан артык кешесен туйдыра ала, ләкин моңа җитди карамаган районнар да бар икән. Буада, Чүпрәледә, Балык Бистәсендә, Таулы Төбәктә бер ел эчендә генә дә шәхси хуҗалыкларда өчәр-дүртәр йөз баш сыер кимегән. Бу ни хәл бу? Шәһәрдә берәүнең йолкыш бер эте югалса, шундук республика прокурорына мөрәҗәгать итәләр. Ә биредә сыер кадәр сыер югала, берәмләп түгел, йөзәрләп!

Беренче секретарь докладчыны бүлдереп әйтте:

— Таулы Төбәктә дә шәхси хуҗалыкларда сыер саны кимегән диелде. Мин кызыксындым, «Сабанчы» колхозының председателе иптәш Айтуганов бер ел эчендә генә түгел, ун ел эчендә шәхси сектордагы сыер малының бер генә башын да киметмәгән, киресенчә, арттыруга ирешкән. Яшь механизаторлар да анда хәзер сыер-сарык асрый. Фәһим Сабирҗанович, сез биредәме?

Айтуганов торып басты.

— Биредә, иптәш секретарь.

— Сез шәхси хуҗалыклардагы сыерларны ничек саклап кала алдыгыз?

— Колхозчыларга без печәнен дә, саламын да җитәрлек дәрәҗәдә бирәбез. Әгәр берәр гаилә үз теләге белән дәүләткә ит яки сөт тапшырса, без аңа ашлык та сатып бирәбез. Икешәр мең литр сөт тапшырып, унар центнер бодай алган колхозчылар бар бездә...

Шаулатып кул чаптылар. Тимергалиев күрде, беренче секретарь да елмая-елмая кул чабып утыра.

Фикер алышулар башлангач, өченче итеп сүзне «Сабанчы» председателенә бирделәр. Морат Баянович моңа сөенергә тиеш иде, хупларга тиеш иде ул моны югыйсә, ул җитәкләгән район кешесе бит, киңәшмәне алып баручы аның СССР Югары Советы депутаты икәнлеген, дүрт дистә ел буена колхозны үрнәк төстә җитәкләвен барлык кешенең аңына сеңдерерлек итеп, басым ясап әйтте, ветеран, диде, ә Морат Баянович сөенмәде, аның уенча, Айтуганов бүген үзенең чыгыш ясарга тиешлеген аңа әйтергә, сөйлисе сүзен аның белән килешергә тиеш иде. Ә ул киңәшми, ул башбаштаклана. Мөстәкыйль була, янәсе. Тыңлап карыйк, ул әле, бәлки, чүп өстенә чүмәлә, дип, райкомга тагын да нәрсәләрдер ягарга, обком каршысында дан казанырга тырышыр...

Үз уйларын ул Айтуганов уйларына ялгап җибәрде.

— Киңәшмәгә җыелган чакларда колхоз-совхоз җитәкчеләренә бик матур сүзләр ишетергә туры килә: «председательләр корпусы», «директорлар отряды», «безнең алтын фонд» һәм башкалар, һәм башкалар. Ә менә көндәлек тормышта безне эт итеп сүгәләр, өркетәләр, дөньяда торырлыгыңны калдырмыйлар. Докладтан без стабильлек хакында ишеттек. Председательләргә караш бар җирдә дә бер төсле, ягъни стабиль булсын иде. Бу — минем беренче таләбем. Икенче таләбем шул: колхоз Уставын бозмыйк. Уставта бит акка кара белән: колхозчыларга түләүне рентабельлелеккә карап башкарырга, дип язылган. Соңгы вакытта колхозларда адәм баласының эшләгәне өчен түгел, авылда яшәгәне өчен түләү модага керде. Эшләгәне өчен түлик,

җәмәгать, эшләмәгәне өчен түләмик. 100 сумлык табышы бармы, 40 сумын түлә колхозчыга. Ә бит артта барган колхозларда 40 сумын түгел, 60 сумын түлиләр. Шулай итеп, мул иген үстергән, мул сөтле терлекләр асраган колхозчы хезмәт хакын артта сөйрәлгән колхозның хөрәсән ялкауларына караганда кимрәк ала, начаррак яши булып чыга. Кайчан бетәр бу гаделсезлек? Кеше җилкәсендә симереп ятулар кайчан бетәр?

Аннары. Бездә еш кына шулай килеп чыга: төзелеш материалы булмау сәбәпле, председательләргә көне-төне Казанга, Мәскәүгә, обкомга, совминга, агропромга, самына, замына, помына чабарга, кулны сузып теләнергә туры килә. Күпме нефть газын без фәрештәләр патшалыгына озаттык алтмышынчы елларны. Хәзер Уренгой-Помары магистраленнән алабыз. Миңа «Сабанчы»га газ китерү өчен кырык чакрым озынлыгындагы торба кирәк иде. Ун ел буе шуның артыннан йөрергә, утыз хуҗага теләнергә, утыз мең чакрым юл узарга, Кама аша чыгар өчен паром төпләрендә унар сәгать яңгыр астында күшегергә, бәләкәй генә бер күпергә материал алыр өчен икешәр мең чакрым казылмалы юллардан чабарга туры килде. Чыдыйм икән — авылым кешеләренең колхоз тормышыннан гайрәтләре чикмәсен, дип чыдыйм. Алдымда кечкенә генә бер яктылык күреп, шуны күздән югалтмыйча, барам да барам. Перестройка дигән үзгәртеп кору үзәктә бар, бездә юк. Булыр дип ышанмыйм да. Безне һаман басалар, безне һаман изәләр, мыскыл итәләр, эт көненә калдыралар. Миллионер колхозның ихтирамлы хуҗасы буларак, мин боларны сөйләмәс идем, сөйләми хәлем юк, ник дигәндә, минем белән янәшәдә дә, миннән еракта да авыллар юкка чыга, талана, кешеләр, бәхет эзләп, кала юлларында йөриләр.

Юллар. Күпме нефть чыгардык без республикада. Ике миллиард ярым тонна нефтьне Европа дәүләтләренә шалкан бәясенә сатып җибәрдек. Без шул акчага Татарстанда юллар сала алмый идекмени? Без шул акчага Культура сарайлары, больницалар сала алмый идекмени? Сала ала идек. Куркаклыгыбыз, үзәккә ярашырга маташуыбыз, коллык психологиябез безне хәерче хәленә, теләнче хәленә калдырды.

Без республика күләмендә нинди генә киңәшмәләр үткәрмик, нинди генә күз яшьләре коймыйк, күпме генә зарланмыйк, берберебезне күпме генә тиргәмик, берни дә барып чыкмаячак. Юк! Мин моңа ышанган. Төптән-тамырдан актарып ала торган үзгәрешләр кирәк. Үзәктәге пленумнарда әйтәләр, кара туфраклы булмаган өлкәләргә миллиардларны салдык, тик авыл һаман үсми, һаман тауга күтәрелми, һаман авыллар бушый бара, йортларның тәрәзәләренә аркылы такталар кагыла, диләр. Салган миллиардларны җир йота, диләр. Булдымы соң ул миллиардлар? Булмады, юк! Аларны министрлыклар, агропромнар йотты. Аз гына вакыт эчендә авыл хуҗалыгы машиналарына, техникага бәяне өч мәртәбәдән артыкка күтәрделәр. Киңәшмә саен әйтә торган миллиардларны әнә шул техника йотты. Минем бүген дәүләт банкысында ике миллионнан артык саф табышым бар икән, техниканы саклап тоту аркасында гына була алган табыш ул. Утыз ел буена хезмәт итә торган йөк машиналары бар безнең, егермешәр ел сакланган тракторларыбыз бар. Бик тә камил, бик тә куәтле булганга сакламыйбыз без аларны, башка барыр җиребез булмаганга саклыйбыз.

Нинди дә булса бер мода килеп керәме — без алны-артны карамыйча, аның файдалымы-юкмы икәнен исәпләп тормастан, шуңа ташланабыз. Аренда модасы чыкты. Гаилә подряды дигәнен китереп өстәделәр. Таулы Төбәк райкомы, райбашкармасы, агропромы мине көн дә әгъвали, төн дә әгъвали, арендаsuccessfully үзләштерергә, шуны башка-

ларга үрнәк булырлык итеп үзләштерергә куша. Ә мин аны теләмим. Колхоз системасы мине канәгатьләндерә. Берәү үзенең тракторын ел буе ватылмаслык итеп ремонтлый, йокысын-ялын онытып, җайланмалар куя, кыш буена мастерскойдан кайтып керми, ә икенчесенеке бер атнага да җитми. Алар ничек бер подрядта, бер арендада эшли алсыннар? Ярсып торган чабыш аты белән ишәкне бер арбага җигеп куйган төсле була түгелме соң бу? Колхозларны тарату турында, индивидуаль эшләү турында сүз чыгара акыллы баш галимнәр, тик алар бер нәрсәне уйлап җиткерә алмыйлар: телиме авыл агае күмәк хуҗалыктан китәргә? Әле дә хәтеремдә, сугышка кадәрле ашлык сугу машинасын, тегермән куласасын әйләндерә торган атлар бар иде. Җәй буе әйләнеп тора иде алар. Эшләреннән бушатып, болынга җибәргәннән соң да ул атлар гел әйләнеп йөри торганнар иде... Моннан бер генә нәтиҗә чыгарып була: бер ише кеше коллективта эшли алмый, бер ише кеше ялгыз эшли алмый. Булсын хезмәтнең төрлесе — арендасы, подряды, әмма колхозларны таратырга ашыкмыйк. Минем белән бу хакта бәхәсләшүче, мине аңларга теләмәүче дөнья тулы, сүзләрен дөрескә чыгару өчен алар Америка, Канада фермерларын мисал итеп китерәләр. И аллакай гынаем, ул нинди дәлил була ала инде, ә? Америкада фермерлык бер йөз дә илле ел яши, алар үз эшләренең остасына әйләнгәннәр, ун тапкыр үлеп, ун тапкыр терелгәннәр. Гыйбрәтләр аласы бар алардан, гыйбрәтләр...

...Морат Баянович үз районы председателенең сүзләрен гаҗәпләнеп тыңлады. Ул аның бер генә мәртәбә дә район күләменә төшеп зарланмавын, райкомга бәла якмавын, улы белән килеп чыккан конфликтка кагылмавын хуплады, ул аның үзе белән киңәшмичә чыгыш ясарга җөрьәт итүен дә онытты, баштарак, Айтуганов сөйли башлаган чакта күңеленә килгән үпкәсен онытты. «Сабанчы» колхозының ни өчен өч дистә ел буена дәүләттән ссуда алмыйча яшәвен ул менә хәзер, бары тик хәзер генә төшенде бугай. Фәһим Сабирҗанович бит ул уйлаганнан ике баш югарырак булып чыкты. Моның шулай икәнен ул обкомның беренче секретареның аңа булган мөнәсәбәтеннән дә күрде. Айтуганов сөйләп бетерүгә, беренче секретарь аяк өсте торып басты:

— Иптәш Айтуганов, обкомга сезнең нинди үтенечегез бар?

— Техниканы озак саклау турындагы ишарәмнән аңлагансыздыр. Машиналар бик искерде. Безгә бүген бер «КамАЗ» бирсәгез иде.

Беренче секретарь:

— Бу чыгышыгыз өчен генә дә бер «КамАЗ» бирергә була. Бирикме, иптәшләр?

Халык кул чапты.

«Хәйләкәр төлке бу. Төлке генә түгел, акыллы бүре бу!» — дип инде ничәнче тапкыр дулкынланып уйлады Тимергалиев.

## 2

Казаннан кайткан чакта Таулы Төбәкнең тау битендәге шәрәлек, узган елгы үләннәре малайлар тарафыннан яндырылганнан соң калган каралык, обкомдагы киңәшмә тәэсирләре белән бергә кушылып, шом салды Тимергалиев күңеленә.

Айтугановның үзе инанганны эшләвен, принципиаль бер ныклык белән гамәлгә ашыруын ул инде күргән иде, әмма сөйләгән чакта болай ук әзерлекле, болай ук логикалы һәм үткен телледер дип башына китерми иде. Чөнки ул район киңәшмәләрендә күбесенчә авызына су кабып утыра, ачыктан-ачык бәхәсләргә, дәгъваларга бирелеп китми, ярар, карарбыз, дип кенә куя да азактан гел үзенчә эшләп

йөри. Инде менә ул ачылды: моның белән көрәшү авыр, хәтта ки мәгънәсезлек икән...

Бу хакта Морат Баянович агропром җитәкчесе белән фикер алышырга да ниятләгән иде, ләкин Сәүбанов киңәшмә бетү белән каядыр юкка чыкты. Моны Тимергалиев начарга юрады. Теге чакта ул Айтугановларга каршы җү-җү килде, райком бюросына алар өстеннән ни дә булса тамызып торды, Морат Баянович килгән елны нинди бирелгәнлек белән аңар йорт салдыртты, инде койрык тайдыруы микәнни?

Казаннан кайтып төшкән көннең иртәгесен ул үз кабинетына Сәүбановны чакыртты. Бик артык җәелеп китмичә, кырысрак чырай һәм рәсмилек белән:

— Иптәш Сәүбанов, район буенча барлык колхозларның язгы чәчүгә хәзерлеген тикшереп чыгыгыз. Кичен, сәгать бишләр тирәсендә, төп-төгәл миңа хәбәр итәрсез,— диде.

Сәүбанов аның тавышындагы корылыкны да, рәсмилекне дә сизми калмады. Тик ул, Тимергалиев уйлаганча ук, үзен буш кул белән тоттыра торган кеше түгел иде.

Күз өстенә төшеп торган калын аксыл кашларын күтәреп, гаҗәпләнеп, ике арада берникди салкынлык та булмаган сыман, гадәти итеп әйтте Сәүбанов:

— Мин, Морат Баянович, Казанда чакта ук белешкән идем инде аларны. Колхозларның әле берсе дә дип әйтерлек чәчүгә чыкмаган. Райкомның командасын көтәләр.

— Команда бирү чоры узганын белмиләрмени?— диде Тимергалиев.

— Беләләр дә...

— Соң, белгәч?

— Председательләр барысы да киңәшмәдә иде бит. Алардан башка бригадирлары хәл итмәгән.

— Ә Айтугановлар?

— Алар инде чәчүнең яртысын бетергәннәр. Дым да каплатканнар, арыш уҗымнары да күкрәп утыра...

— Аңлашылды,— диде Тимергалиев, тузгыган чәчләрен ике куллап артка сыпыра-сыпыра.— Аңлашылды. Сез миңа өзлексез әйтеп тордыгыз: Айтугановлар фәлән, Айтугановлар төгән. Ә мин сезгә, шушы районда Айтугановлар белән бергә, янәшә эшләгән кешегә ышандым. Ә нәрсә килеп чыкты?

— Нәрсә?— диде Сәүбанов, кашын җыерып.

— Безнең начар дигән, райком тәгәрмәченә таяк тыга дигән Айтугановыбызга обком секретаре машина бирә. Без бирмибез! Без аны кайгыртмыйбыз. Без корыны бушка әйләндереп йөрүчеләр булып калабыз түгелме?

— Беләсезме, Морат Баянович, безгә, район җитәкчеләренә, җаныбызны талап, урт чәйнәп утыру килешми. Безгә әнә шул Айтугановларның өлкәненнән үрнәк алырга, аны үз арбабызга җигеп куярга, ә яшен, демагогын, тизрәк куарга да, «Яңа көч» колхозында үзебез теләгән үрнәк хуҗалыкны оештыра башларга кирәк.

Сәүбанов, сүзен әйтеп бетергәч, Тимергалиевкә сынаулы караш ташлады: ничек кабул итте, янәсе, ул аның сүзен.

— Чәчүе ничек бара Галинурның?— диде Тимергалиев, өстәл өстенә караган килеш.

— Чәчүе аның, гадәттәгечә, яхшы бара. Көйле. «Сабанчы»дан калышмый аның колхозы.

Тимергалиев, иренен тешләп, ачу белән Сәүбановка карады:

— Галинур да бит киңәшмәдә булды. Ничек соң аның егетләре аңардан башка чәчүгә чыгарга җөрьәт иткәннәр?

— Беренчедән, аларның парторглары Рамазан Мансуров — үзбаш

уйлый ала торган җитди кеше, агроном, икенчедән, «Яңа көч»тә тармак җитәкчеләре, әйтик, бригадирлар,— тәҗрибә туплаган егетләр, өченчедән, Галинур, күрәсең, киңәшмәгә китәр алдыннан аларның барысын җыеп, сөйләшеп алган.

— Шулай булгач, синең әле генә әйткән сүзләреңдә нинди логика кала?

— Кайсы сүзләремдә?

— Галинурны тизрәк урыныннан алырга дигән котkы сүзләреңдә.

— Морат Баянович, безгә Галинур Айтуганов мәнфәгате кадерлеме, райком мәнфәгатеме?

Тимергалиев озак кына башын учлап тын утырды.

— Нишлибез?— диде Сәүбанов, аның җавабын көтеп бетерә алмыйча.

— Кем белә нишләргә икәнен? Башлар катып бетте инде. Элек рәхәт иде ул, ичмасам. Обком нинди директива җибәрә,— шуны үтисең дә җаның тыныч. Райком кушканны председательләр үтәми карасын — партбилетларыннан колак кагарга да озак түгел иде. Хәзер эте дә өйрәтә сине, бете дә... Үләрсең, валлаһи, муеныңа бау салырсың...

Сәүбановка секретарьның чыгырдан чыгуы ошый, ул аның үз алдына куйган максатына туры килә иде. Әшен әтисе урнәгендә ашыкмый гына алып бара торган Галинурга каныкса, аны урыныннан алдыруга ирешсә, Тимергалиевнең абруе халык алдында да, коммунистлар алдында да төшәчәк, ул чагында инде аны киләчәк сайлауларда тотмаячаклар. Ул бирелдән, Таулы Төбәктән китеп, Казанда берәр тынычрак урынга урнашачак, ә Сәүбанов барлык тырышлыгын салып, көчен кызганмыйча эшләткән җитмеш мең сумлык йорт, Таулы Төбәктәге иң зиннәтле һәм иң зур йорт аңа торып калачак.

Секретарьның ачуын тагын да ныграк кабартыр өчен, Сәүбанов янә дә бер мәртәбә кабатлауны кирәк тапты:

— Йә, нишлибез, Морат Баянович?

— Иртәгә иртә баштан ук Шәрифулла Гайниев белән икәүләп басуларны әйләнеп кайтыгыз. Мөмкин чаклы тизрәк ерып чыгарга кирәк язгы чәчүне! Казанда мин синоптиклардан белештем, май коры килер, диләр. Язгы чәчүне бик тиз, туфракта дым беткәнче ерып чыксак кына отабыз. Шуны истән чыгармагыз, председательләрнең дә башларына төеп кертегез,— диде секретарь.— Кичен миңа хәбәр итәрсез. Аңлашылдымы?

Кыр эшләрен ничаклы гына тиз башкарып чыгарга юнәлеш тотмасын Морат Баянович, тәки сузылды. Уникe көнгә барып җитте җәмгысы. Ул чагында инде басулардан дым очып беткән, чәчкечләр артыннан өермәсе белән тузан күтәрелә иде.

Тагын бер атнадан басуларның хәлен белергә, бер уңайдан башка йомышларын да йомышларга дип Таулы Төбәккә өлкә комитеты секретаре Дулатов шалтыратты. Бер дә теләмәгән иде әле Тимергалиев аның килүен. Ул, менә-менә яңгырлар явып китәр, менә-менә сабан ашлык ямь-яшел булып тишелеп чыгар дип көтә иде. Киләм дигән икән инде, килмәгез дип ничек әйтәсең...

Биш көннән килергә вәгъдә иткән иде Дулатов. Биш көн дә узды, атна да узды — юк секретаребыз. «Ник килмисез?»— дип шалтыратырга уңайсызлана Тимергалиев, ә үзе көн саен көтә, көн саен гасабилана. «Киләм дип кунагың килмәсә, авырып хатының үлмәсә, аңардан да кыен хәл юк дөньяда»,— ди торган иде Моратның әтисе. Шул хәлгә калып бара бит әле Баян абзыйның улы.

Юк, шул хәлгә генә түгел, коточкыч хәлгә калып бара Морат Баянович. Дулатовны көткән арада «Советская Россия» газетасында журналист Данияр Дәминевнең «Династияләр җимерелгәндә» исемле

мәкаләсе басылып чыкты. Таулы Төбәк шуңа ташланды. Газетаның бер битен тутырып басылган ул мәкаләне укыган чакта Тимергалиевне йөрәге тота язды. Анда Айтугановларның колхоз белән җитәкчелек итүләре иң югары дәрәҗәгә күтәреп макталган, ә Таулы Төбәк райкомының эш стиле бер тиенгә торгысыз итеп юкка чыгарылган иде. Анысына гына да түзәр иде әле Морат Баянович (үзгәртеп кору чорында кемне генә тәнкыйть утында көйдермиләр!), мәкалә авторы Айтугановларны кысрыклауны, бигрәк тә яшь Айтугановка көн күрсәтмәүне кайчандыр, Брежневлар идарә иткән заманда алдынгы методлар кулланган Иван Никифорович Худенко белән, аның төрмәдәге һәлакәтле язмышы белән янәшә куйган иде.

Үзен бюро членнары кызганып юатып йөрмәсен өчен, Морат Баянович шундук өенә кайтып китте. Бүген ул беркем белән дә очрашмаска, беркемнең дә сүзен тыңламаска, берүзе, япа-ялгызы өендә генә ятарга тиеш...

## 3

Температурасы күтәрелде аның, тамагына кабасы килмәде. Хатыны, врач Әминә ханым, ике көн буена аның яныннан китмичә, гел саклап утырды. Беренче көнне Морат Баянович хатыныннан бик тә риза, ул аның кулын тотып, кысып-кысып та куйгалый, аратирә ыңгырашып та ала, ул хатын дигән затның иң кыен чакларда кирәк булуын аңлаган иде.

Икенче көнне аңа хатыны да ят булып, кирәкмәгән кеше булып тоела башлады. Чөнки ул иренә:

— Карале, Морат, ни булыр икән инде сиңа?— дип әйтеп куя.

— Тыныч кына утыр, бер нәрсә дә булмас,— ди Мораты, бүтән дәшми, очсыз-кырыйсыз уйларына күмелә. Болытлар килә күз алдына, өермәләр килә, тора торгач, болытлар тарала, күкрәге киңәеп, сулышы иркенләп киткәндәй була, күз алдында күкнең зәңгәр кыйпылчыклары калка, нәкъ әнә шул чагында хатыны:

— Карале, Морат, сине секретарьлыктан төшерсәләр, без нишләрбез? Бу йортны бездән алырлар бит,— дип җанына тия.

— Бар әле, ичмасам, чыгып тор әле, ник каныгасың әле син миңа?— ди Морат Баянович, хатыны чыгып киткәч, тагын үз уйларына күмелә...

Инде тынычланып җитәм дигәндә генә хатыны аңа транзистор кертеп бирә. Ил хәбәрләрен тыңла, янәсе.

Казанны тотыштырган иде Тимергалиев, ник тоташтырганына үкенеп бетә алмады. Гәзитләргә күзәтү тапшыралар. Дәминевнең мәкаләсен «Советская Татария» һәм «Социалистик Татарстан»га күчереп басканнар, диктор шул мәкаләдән өзекне укый.

Морат Баянович транзисторны җан ачуы белән идәнгә тондырды. Дөбердәгән тавышка хатыны килеп керде:

— Тагын ни булды инде? Нигә транзистордан аласың соң үчеңне?

— Күп сөйләнеп торма, Сәүбановны чакыр, транзисторны син миңа юри керткәнсең, дөмексен бу дип...

— И аллам, бар икән күрәселәрем!..

Морат Баянович райком хәлләрен белергә, халыкның мәкаләгә ничегрәк караганын ишетергә дип чакырган иде Сәүбановны. Аз гына булса да кызганырлар, корреспондент акны кара дип язган, күперткән дип әйтерләр дип көткән иде ул.

Сәүбанов керә-керешли үк аның канына тоз сала торган хәбәр китерде:

— Мәкаләне обкомда укыганнар. Райкомның эшен обком бю-

росы тикшерәчәк икән,— диде Сәүбанов. Ул моны күзен дә йоммыйча, шундый бер миһербансызлык белән әйтте ки, Морат Баянович хәтта торып утырды.

— Кем әйтте моны сиңа? Каян белдең?— диде ул ашыгып.

— Дулатов килде. Ул әйтте.

— Кайчан?

— Кичә. Авылларга чыкты — Шәрифулла Гайниев белән.

— Соң? Сөйлә инде, нәрсә авызыңа су каптың?

— Авыллардан Дулатов күңелсезләнеп кайтты. Сабан ашлык күп урында тишелмәгән, тишелгәннәре дә бик кәй, диде.

Тимергалиев хәлсезләнеп урынына ауды. Беркавым сүзсез ятканнан соң сорады:

— Айтугановны күргәннәрме?

— Кайсысын?

— Мине өлкән Айтуганов кызыксындырмый. Галинурны күргәннәрме? Ул ничек караган мәкаләгә? Канат какканмы?

— Әйтә алмыйм.

— Нишләп?

— Галинур бит юк. Галинур колхоздан китте.

Морат Баянович янә дә урыннан торып утырды:

— Ничек китте? Нишләп китте? Кайчан китте?

— Зерә дә әкәмәт сәер кеше сез, Морат Баянович, сез бит инде аның китүен генә түгел, урыныннан дөбердәтеп алынуын тели идегез. Нигә гаҗәпләнәсез аның китүенә?

— Син, Сәүбанов, боргаланма,— дип, ниһаять, бугазга басып сорау бирде Тимергалиев.— Син миңа әйт, кайчан китте, ни рәвешле китте Галинур Айтуганов?

— Белмим. Безгә кермәде. Китүе турында гаризасын обкомга илтеп биргән.

— Ә нишләп обкомга? Ул мәсьәләне бит обком хәл итми, без хәл итәбез.

— «Яңа көч»тә эшләү мөмкин түгел. Райком белән көнө-төнө конфликтта торуыңны уйлап утыру бик авыр. Күңел үсми, кулдан эш төшә. Китәргә, башка районда эшләргә рөхсәт итегез миңа, дигән. Райкомның мине тоташ мыскыл итеп торганын белгәнгә күрә, гаризаны райкомга түгел, обкомга яздым»,— дигән...

Морат Баянович бүтән сорашмады. Сорашырга теләге дә юк, хәле дә киткән иде.

Ике ел буена диярлек ул Айтугановлар белән көрәште. Алар эшләгән эшне күрмәмешкә салышты, аларны башкаларга үрнәк итеп куймаска тырышты. Ул Галинур Айтугановны урыныннан алдырыр өчен Сәүбановны Чукмарлыга җибәрде, Шәрифулла Гайниевне җибәрде, үзе барды. Булмады, барып чыкмады, куенына салып куйды моны Морат Баянович, салып куйды — чөнки баш бирми торган, райкомга буйсынмый торган кеше аңа кирәк түгел иде.

Быел ул аның белән соңгы тапкыр көрәшкә чыкмак булды. Ул аны җиңәренә ышанды, ул бу эшкә янә дә Сәүбановны тартты. Тукта, ул тарттымы Сәүбановны бу эшкә, әллә Сәүбанов үзе аны тарттымы?

Мие кайнарланган, уйлары өермә булып ташыган чакта абайлап алды Морат Баянович: башлап бит Айтугановларга ул ташланмады, Сәүбанов ташланды, Сәүбанов аның, Морат Баяновичның да, күңеленә гел коткы салып торды...

Инде менә Галинур киткән. Таулы Төбәктән үк чыгып киткән. Кая китте икән? Кайсы районга? Анда аны ничек кабул итәрләр? Хатыны Нәзифә, укытучы, үзенә эш табармы? Өч баласы бар иде бит Галинурның, алар яңа урынга ничек ияләнерләр? Бура буратып

куйган иде, бик зур итеп, бик хәтәр олыдан кубып хуҗалык булдырмакчы иде. Сәүбанов әйтте: әгәр ул ныклы бер нигез корып җибәрсә, аны бу колхоздан бульдозер белән дә куптарып алып булмас, бурасын бураганчы, яңа йортын җиткезгәнче без аның үзен куптарыйк, диде.

Галинур киткән. Арыш басуларын, бодай басуларын калдырып киткән. Әгәр быел аның басуларында иген тишелмәсә, кырларында тузан тузып утырса, халыкның ул киткәнгә исе дә китмәс, эшли алмады, булдыксыз иде, китүе хәерле, дияр иде. Күкрәп утырган басуларын ташлап киткән егетне кызганачаклар, райком исеменә каргыш яудырачаклар. Бу хәерлегә түгел...

Морат Баянович кинәт үзен шушы эшләр өчен гаепле итеп сизде. Җанында ниндидер үкенү хисе, кылган гамәлләреннән риза булмау хисе тойды.

Бер-ике мәртәбә аның бүлмәсенә хатыны Әминә ханым кереп чыкты, дару эчмисеңме, дип сүз катып карады, Морат Баянович стенага таба борылып ятты да аның бер генә соравына да, үтенеченә дә җавап кайтармады, аның берәү белән дә сөйләшәсе килми, ул хәтта үзен-үзе күрәлмас дәрәҗәгә җиткән иде.

Күз алдына кара бөдрә чәчле, киң җилкәле, кара мыеклы Галинурның сабыр гына елмаеп торуын китергәч, ул хәтта үкенүдән ыңгырашып куйды. Нинди кешене районнан биздерде бит ул, нинди кешене!

Иртәгесен ул авырлык белән генә торды, башы сызлый, чигәләре сулкылдый, йөрәк турысында нәрсәдер чәнчештереп тора иде. Ләкин аның бүтән ятарга исәбе юк иде инде. Ваннага кайнар су агызып юынды, киенде, сакал-мыегын кырды — райкомга керергә кирәк иде.

Аның тормышында яңалык, үзгәлек башланган, ахрысы. Моңарчы гадәти булып, табигый булып күренгән кешеләр аңа ничектер төбәлебрәк, сөзебрәк карыйлар, сүз белән әйтмәсәләр дә, ул аларның күз карашларында, үз-үзләрен тотышларында сәерлек, башка төрлелек сизә, мөнәсәбәтләренең үзгәрүен тоя. Әнә шул хәл аның моңарчы эшләп килгән эшен гадәттәгечә алып баруын авырайта иде.

Күңеле белән ул бик тиз килеп җитәчәк үзгәрешләрне көтеп яши башлады.

## 4

Озакламый Таулы Төбәк райкомының пленумы җыелачагы, анда оештыру мәсьәләләре каралачагы мәгълүм булды.

Бу хәбәр Морат Баяновичны никтер кайгыга салмады. Аны ул партия Үзәк Комитетының халык контроле килгән, бер мең тонна черегән бодайны Бүре чокырына илтеп күмгән көннән үк көтә, аны тик бер генә нәрсә юатып асрый, черегән һәм чокырга күмелгән бодайда бер аның гына гаебе түгел, обкомның да, аннан югарырак оешмаларның да гаебе бар, андый ямьсез гамәлләрнең тамыры бюрократик команда алымнарында иде.

Бәлки шуңадыр, бодайны чокырга салып, өстенә кызыл ярдан бульдозер белән балчык ишеп төшерә башлагач, аталы-уллы Айтугановлар «аһ» итеп куйгач, Мәскәүдән килгән халык контроле вәкиле, тыныч-җитди чырайлы Серафимов: «Моннан авыррак хәлләрне дә күрдек, иптәшләр. Чернобыль фаҗигасе түгел әле бу»,— дип, шунда басып торучыларны «юаткан» иде.

Оештыру мәсьәләсен караганда аңа доклад-мазар ясап торырга туры килмәде. Өлкә комитеты секретаре Дулатов көн тәртибен әйтеп, фикер алышырга чакыргач, аны чамадан тыш гаҗәпләндергән ике

кеше булды. Берсе — Сәүбанов, икенчесе — Айтуганов. Сәүбанов ярсый-ярсый, калай самавыр кебек кайный-кайный, Тимергалиевнең кимчелекләрен фаш итте. Моңа Тимергалиев үзе генә түгел, хәтта пленум членнары да гаҗәпләнделәр. Ә бит элек Морат Баяновичның сүзен Сәүбановтан да ныграк яклаган, башка фикер белән чыккан кешеләргә карчыга сыман ташланган кеше юк иде. Айтуганов, киресенчә, ифрат дәрәҗәдә сабыр, моңарчы булганнан да сабыррак чырай белән, хәтта ки, моңсу-сагышлы чырай белән залдагыларга үкенечле сүзләрен әйтеп торды. Утырып яуган, сагынылган яңгыр кебек, әллә ничек шифалы, ягымлы булып ишетелделәр Морат Баяновичка аның сүзләре. Ул райком секретарен гаепләми, аның өстенә тәнкыйть утын сипми, ветеран буларак, зур гомер юлы узган кеше буларак, килеп туган хәлнең авырлыгын, җитдилеген, гыйбрәтлелеген ача, райком җитәкчесенең мондый аяныч хәлдә калуына аның үзеннән бигрәк югарырак җитәкчеләрне, системаны гаепли иде. Әнә шул моңсу-үкенечле кыяфәте белән торып калды ул Морат Баяновичның яралы күңелендә.

Пленум узганнан соң дөньяга ничектер битараф карый торган булып китте Морат Баянович. Яңа сайланган райком секретаре Гайниев аңа берничә мәртәбә шалтыратып, хәлен сорады.

— Рәхмәт, Шәрифулла, әкрен генә, бер көе генә яшибез әле. Син, бәлки, квартирны бушат, дип әйтмәкче буласыңдыр. Улыбыз Артурдан бер хәбәр дә юк, шуңа борчылып торабыз. Берәр атнага сабыр ит инде,— диде.

— Юк, Морат Баянович, мин сезне башка мәсьәлә буенча борчыйм әле. Тиздән бит Таулы Төбәкнең район сабан туйларын үткәрәсе бар. Сабан туе комиссиясенә керергә риза булмассыз микән?— диде кешеләргә карата ягымлы Шәрифулла. Ул эшеннән бушатылган секретарьның моңа риза булмаячагын белә, тик ул аны алдан, аз гына булса да кайгылы хәбәргә әзерләмәкче була, Тимергалиевнең Әфганстанда хезмәт иткән улы Артур һәлак булган, аны шушы көннәрдә тимер табут белән Таулы Төбәккә кайтарырга тиешләр иде.

Кайгылы хәбәрне мәрхүмнең әти-әнисенә җиткерү Таулы Төбәкнең хәрби комиссары майор Бәһрамовка йөкләнде. Майор хәбәрне ничек җиткерү хакында яңа секретарь Гайниев белән киңәште.

— Башта Әминә ханымга — Артурның әнисенә әйтергә кирәк, ул врач кеше, ул иренә караганда ныграк, ышанычлырак булыр, әтисе, әле генә эш урыныннан алынган кеше, бу хәбәрне, кинәт әйтелсә, күтәрә алырмы икән?— диде Гайниев.— Әминә ханым Морат Баяновичны әкренләп әзерләр...

Райком бүлмәсенә Шәрифулла Гайниев үзе, райбашкарма рәисе Мөнир Әсфәндияров, майор Гали Бәһрамов, район больницасының врач-терапевты Зөләйха ханым җыелдылар.

Көтә башладылар.

Төсе качкан, күзләре бик борчылган Әминә ханым килеп кергәч, кабинетта тынлык урнашты.

Майор Бәһрамов, аяк өсте басып, хәрбиләрчә ныклык белән хәбәрне әйтеп бирде, Тимергалиевләрнең кайгысын уртаклашты.

Әминә ханым чайкалып китте, ачыргаланып кычкырып җибәрде:

— Балам! Балакаем, Артурым минем! Нишләттеләр сине? Кайларга илтеп газиз башкайларыңны ашадылар?!

Аңа тынычландыру даруы бирергә теләделәр, ятырга, сабыр булырга кирәклеген әйтергә теләделәр. Әминә ханым аларның берсен дә ишетми, тыңламый, ачыргаланып, улына дәшә, улын чакыра, гасабилана иде.

Врач-терапевт Зөләйха ханым аны, хәрби комиссар белән бергәләп, өйләренә кадәр озатып куйды.

Икенче көнне табутны алып кайттылар. Моңарчы Таулы Төбәккә кайткан башка табутлар кебек, ул кечкенә, кеше буе түгел, табутның капкачы белән аскы ягы эретепме, ничектер ябыштырылган, аны ачып каравы да мөмкин түгел иде.

Шушы хәлне белгәч, Әминә ханым һушыннан язды, аны «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртып, уколлар кадап аңына китерделәр.

Табут бер төнне Тимергалиевләр өендә кунды. Әминә ханым кич буе, төне буе күз яше койды, эти кеше кычкырып еламады, тешен кысып чыдады, еласа, хатыны Әминә ханымга тагын да авыррак булыр дип курыкты.

Кайгы, таш булып, аның бәгыренә урнашты.

Ул күңеленнән әрнеп, уфтанып, ыңгырашып куйды. Кем булып чыга инде ул? Улының үлемен әзерләүче булып чыга ич. Гомумән дә Әфганстанга яшьләрне илтеп тыгарга кирәк идеме икән? Галимнәр телендә «генофонд» дип йөртелгән яшьләрне, илнең каймагын ут эченә илтеп салырга кирәк идеме? Ә бәлкем, югарыдагы түрәләр, Брежневлар, Сусловлар уйлый белгән кешеләрне, аларның бушлыгын фаш итә алырдай белемле, нык буынны кырдырып бетерергә теләгәннәрдер? Әгәр шулай була калса, Сталин тиранлыгыннан аларның кай төшләре артык та, ни өчен андый кешеләр башкаланың Кремль стеналары буенда, иң хөрмәтле урында ятарга тиешләр?

Морат Баянович төне буе йокламый чыкты. Берсеннән-берсе авыр, катлаулы, ерып чыга алмаслык сораулар аның миен бораулап тордылар. Ул гомер юлын күз алдыннан үткәрде. Авылда үскәнен, яшел чирәмнәрне, аннары укыганын — мәктәбен, университетның юридик факультетын, прокурор булган елларын, Таулы Төбәктә үткәргән ике елын. Алар аңа барысы да мәгънәсез булып, кирәксез булып тоелдылар. Ул үзенең кем икәненә аяусыз рәвештә бәя бирде: ул партия йомышларын үтәп йөргән п и ч ә т л ә н г ә н с т а н д а р т икән ич. Стандарт! Менә ни өчен гомерләрен зур эшкә, мәгънәле эшкә багышлаган Айтугановлар белән конфликты килеп чыккан икән аның. Менә ни өчен Чукмарлы кешеләре аның үзен дә, ул җибәргән кешеләрне дә тыңларга теләмәгән, аңар каршы бөтен авылы белән күтәрелгән икән...

...Артурны икенче көнне төш вакытында Таулы Төбәкнең яңа зиратына күмделәр. Табутны каберга сөлге белән әтисе һәм тагын бер фронтовик төшерергә тиеш иде. Морат Баянович сөлгене кулына чорнап тотканнан соң фронтовикны белергә теләп, күтәрелеп карады, танығач, тетрәнеп китте — аның каршысында Фәһим Айтуганов иде...

Морат Баяновичның күзләрен яшь пәрдәсе каплады, зиратка килгән йөзләгән кеше, Таулы Төбәк кешеләре, яшь пәрдәсе аша аңа тоташ бер түмгәкләр, урман түмгәкләре булып күренделәр.

Матәм маршы уйнап җибәрделәр,— быргылар, тәлинкәгә тәлинкә бәргән тавышлар үлемнең чынлыгын расләды: кабергә балчык коела башлаганны ул су эченнән килгән шикелле генә ишетте.

Кемнәрдер аны тотып тора, кемнәрдер:

— Балчык сал, Морат, балчык сал,— дип дәшәләр иде.

Зираттан чыкканын, машинага утырып киткәнен ул төштә күргән кебек кенә хәтерләп калды. Үзләре йортының капка төбенә җиткәч кенә аңына килде. Анда да аны гармун тавышы аңына китерде. Кайчандыр шушы урында тәбәнәк бер йортта, җимерек үз йортында яшәгән сукыр карт капка төбенә килеп утырган да гармун уйный, үзе гармунга кушылып җырлый иде:

Агыйделләр каты акса да,
Комнары кала икән.
Кайгы-хәсрәтләр китсә дә,
Моңнары кала икән...

*1985—1989*

**Мөхәммәт Мәһдиев**

# АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

**ИСТӘЛЕКЛӘР**

## Гагра

*«Гагра — Кавказ яр буеның энҗе ташы».*

Э. Шеварднадзе.

### 1



Язучыларның Гаградагы иҗат йортына беренче тапкыр 1966 елның октябрендә килдем. Үз гомеремдә беренче тапкыр ялгыз бүлмәдә калып иҗат эше белән шөгыльләнергә тиеш идем. Нәрсә язарга? Мин әле моны белми идем. Юлга чыгарга бер көн кала, Матбугат йортына барып, әдәби журналда шушы көннәрдә генә чыккан зур мәкаләм өчен («Солтан Рахманколыйның иҗат портреты») зур гына гонорар алдым. Сиксән сумнар тирәсе дип хәтердә калган. Ул вакыт өчен зур акча иде. Әмма шунда ук кәефне җибәрерлек күренешкә очрадым: вестибюльдә Гали Хуҗиның мәете салынган табут тора иде. Шулай төшенке күңел белән кайтып киттем. Салкын, яңгырлы көн.

Иртәгесен калын драп пальто, калын эшләпә киеп аэропортка килдем. Рафаэль Мостафин да гаиләсе белән шунда бара икән. Мәкаләләрем «Казан утлары»нда чыккалап килсә дә, аның белән танышлыгым юк иде. Бер-беребез белән «сез» дип сөйләшеп самолет салонына уздык. Артык сөйләшмәдек, Рафаэльнең ул чорда татар халкы алдында дәрәҗәсе бик тә зур иде — журналның эчтәлеген, исемен яңартты, Твардовскийның «Новый мир»да ясаган революциясен татар әдәби журналында ул ясады. Ул чорда журналда бик кыю-кыю мәкаләләр басылып алды — Рафаэль милли геройга әйләнеп китте. Язучылар җыелышларында кыю-кыю чыгышлары белән күренгән саен аның абруе арта барды. Мин аңа сокланып, читтән карап, матур көнләшү белән көнләшеп яши идем.

Адлерның җылы һавасы биткә самолет трабында ук бәрде. Кинәт кенә драп пальто да, калын эшләпә дә артык булып тоелды: аэропорт тирәсендә кыска җиңле күлмәк кигән, ялан аякка табан-тапки гына эләктергән кара янган ирләр, ханымнар мәж киләләр иде.

Хуш... Бер үземә бер бүлмә, зур гына язу өстәле, тынлык. Ашханә — аста гына, ул елларда иҗат йортларында ашау-эчү бик затлыдан һәм мулдан була иде — хәзер кайсы гына иҗат йортына барсаң да бер үк хәл: теге елларның өстәл өсләрен сагынасың. Нәрсәдер язып карыйсы килә, ләкин бит мин моңарчы гел мәкаләләр генә язып килдем. Аларны язу өчен кул астында төрле фәнни материал, чыганаклар,

---

Ахыры. Башы журналның 1 санында.

белешмәлекләр кирәк. Ә минем өстәлдә ап-ак кәгазь битләре генә.

Шулай, ул кәгазьләр шактый хәрәкәтсез ятты. Пляжда кызынабыз, көймәдә йөзәбез, бадминтон уйныйбыз — Рафаэль белән күптән инде «син»гә күчтек. Ул — шәһәр тәрбиясе алган егет, авылны белми. Мин исә авыл мужигы тормышын, абзар-курасын, читәнен, гореф-гадәтләрен, авыз иҗатын беләм. Кыскасы, ул шәһәр тормышыннан, мин авыл тормышыннан бер-беребезгә төрле хәлләр сөйлибез. Рафаэль тыңлый белә һәм вакытында рәхәтләнеп көлә белә. Минем өчен менә дигән аудитория булды бу. Көннәрдән бер көнне Рафаэль миңа әйтеп үк куйды бит:

— Карале, ник син бу эпизодларны аерым хикәяләр итеп язмыйсың?

— Ә?

— Хикәя итеп, дим.

Шул җөмлә мине кешелектән чыгарды.

Шул төнне мин йокламадым. Өстәлгә бер кап «Трезор» куйдым да, яза башладым. Уйлавымча, чын язучы әсәр иҗат иткәндә вакыт-вакыт тәмәке тартып алырга тиеш; янәсе, ул башны яхшы эшләтер өчен кирәк. Таң атканда беренче хикәям әзер иде: «Галиябану». Кульъязмамны мин төш алдыннан пляжга алып чыктым да, Рафаэльгә укыдым. Ул тавышын тәгәрәтә-тәгәрәтә көлде, рәхәт чикте. Бер-ике җиренә төзәтмә дә кертте.

Шуннан минем өчен газаплы да, шатлыклы да көннәр, төннәр башланды. Путевка көне беткәнче мин Рафаэльгә «Ахири», «Алла бармы?», «Тормыш дулкыннары» дигән, төн утырып язган кыска хикәяләремне укыдым.

— Кайтуга машинкада суктырып ал да (Рафаэль инде татарча шактый ук катлаулы сүзләр кулланып сөйләшергә өйрәнеп килә иде), журналга китер, бастырам,— диде.

Һәм сүзендә торды. 1967 елның маенда журналның бишенче санында, агай-эне һич тә көтмәгәндә, бу хикәяләр басылып чыкты. Минем запас шуның белән бетте, бүтән язар әйберем юк иде. Ләкин... Тегермән ташын бер тапкыр ялаган күсе аңа кабат килми калмый, диләр тәҗрибәле тегерменчеләр.

Награда алган шул куәт белән мин, күп тә үтмичә, «Без — кырык беренче ел балалары» дигән повесть язып «ташладым». Әйе, ташладым, чөнки мин аны бер атна эчендә яздым. Рафаэль аны рецензиягә Ибраһим Газига биргән. Үтерде, суйды инде мине дип йөрсәм, И. Гази урамда мине очратып, кульъязмамны кайтарып бирде дә, бер искәрмәсе барлыгын әйтте.

— Менә бу урында синең төп героең — рус теле укытучың — телен шартлатып куйсын,— диде.

Рафаэль бу повестьны да тиз тотты, анысы да май санында басылып, 1968 елның матур җәй башында укучылар кулына килеп керде.

Минем проза өлкәсенә керүемә Рафаэльдән башка берәү дә шатланмады. Бигрәк тә өлкәннәр гвардиясе каршы торды. Ни гаҗәп, Габдрахман Минский белән Атилла Расих кына миңа җылы сүз әйттеләр.

Габдрахман ага мине очратып:

— Сездә О'Генри чалымнары бар,— диде. Мин көлдем, әлбәттә, мактауны кабул итмәдем: О'Генри иҗатын яхшы белгәнемә күрә генә түгел, утызынчы еллар матбугатында Гадел Кутуйның бер мәкаләсенең эчтәлеген дә яхшы белгәнгә. Г. Минскийның беренче әсәрләре дөньяга чыккач Г. Кутуй болай дип язган:

— Безнең татар әдәбиятында да Толстойлар туа башлады...

Атилла Расих та шулай каты «тондырды»:

— Сездә Кави абый стиле сизелә, экспрессив стиль,— диде.

Мин монысын да йөрәк трансформаторым аша — өч йөз сиксән

вольтны йөз егерме биш вольтка төшереп кабул иттем, шулай да аларга бик рәхмәтлемен. Мин әле ул вакытта каян белим Габдрахман аганың, Язучылар союзында партоешма секретаре булып эшли башлагач, «Фронтовиклар»ым «Казан утлары»нда басыла башлагач, журналны күтәреп обкомга барасын?

— Менә бит нинди көнгә калдык,— дигән ул,— яшь язучының бер герое тальян күтәреп Ленин укыган университетка килеп керә һәм шаулатып татарча җырлый.

Ул елларда әлеге зур йортта әдәби әсәрнең һәр җөмләсен тикшереп, ничек язарга өйрәтеп утыручы бер иптәш, чыннан да, бар иде. Бу хәбәр инде аңа шәп азык булгандыр. «Фронтовиклар» журналда тере килеш туналып басылды.

Ләкин ни генә әйтмәсеннәр, соң иде инде. Рафаэль Мостафин мине мәшәкатьле авыр юлга кертеп җибәргән иде.

Гагра шәһәре шулай минем тормышымда зур борылыш ясады. Әйе, ул елны мин анда бик киеренке эшләдем. Төнлә утырып язам, төштән соң Рафаэльгә укыйм. Кичке якта ял итәм. Рафаэль кичке якта эшли.

Кичке ялым да үземчә: килеп ике көн үтүгә, пляжда утырганда янибызга өлкән яшьтәге бер абзый килеп татарча эндәште:

— Сез Казаннан бит, әйеме? Сезне Мостафин булыр дип уйлыйм, Рафаэль Мостафин. Ә менә бу егетне бөтенләй белмим.

Баксаң, шушы йортта ук ял итүче, гомере буе типография тирәсендә эшләгән Зариф абзый икән. Пенсиягә чыгуына, аңа Гаграга путевка биргәннәр.

Һәр кичне Зариф абзый нидер сөйли. Ул НЭП елларында ук яшь көенчә Казанга килеп урнашкан, дөньяның ачысын-төчесен күргән, утызынчы елларда ук аның «хуҗасы», эшендә күтәрергә вәгъдә итеп, аңа үзенең кызын «сылаган». Яратышмыйча гына гомер кичергәннәр, шулай да ике кыз үстереп, икесен дә юньле генә урнаштырганнар, инде оныклары бар.

— Мин яшьтән үк мут булдым, кулымнан гармун төшмәде, мәҗлес түрендә мин булдым,— дип сөйли ул.— Без яшь чактагы Кабан күле өсләрен күрсәң син. Андагы көймәләр, тальян белән шау итеп көймәдә йөргән егетләр-кызлар. Ул суның чисталыгы. Җәен анда коенулар. Шул Кабан исән булганда миңа еракка барып йөрү нәрсәгә? Һи, ул күңеллелекләр, хөрлекләр инде. Ул хөрлекнең соңгысы егерме сигезенче ел булды. Аннан дөньяны кара болыт баса башлады. Кешенең башы аска иелде. Мин типографиядә эшли идем, метранпаж булып. Берәздән укып та йөрдем.

Әйбәт тыңлаучы икәнемне белгәч, ул үзенең бик эчкәреге серләрен дә сөйли башлады. «Пилзень» сырасы көн саен булып тора, бәрхет сезоны, Гагра бай, күләч, мул, тыныч. Гел генә дә рәхәт күрәсе килеп тора.

— Менә мин олайгач бер яшь хатынга гашыйк булдым, энекәш,— дип сөйләп китте ул, кичләрнең берсендә.— Ике җиткән кызым, икесе дә кияүдә. Ә мин — гашыйк. Яшь тол хатын, ире алкоголик булып киткән, аерылышканнар, кечкенә малае белән яши. Гастрономда, бүлек мөдире. Миңа илледән артык — оялам да, ну яратам гына бит. Аның эш кабинетында телефон бар, минем — өйдә. Ул эшләгән кибет безнең икенче каттан күренеп кенә тора. Мин бит Тукай урамында иске агач йортта, элеккеге бай йортында торам. Баштарак тегенең өендә очрашкаладык, ул гел һинд чәе тота, шуны эчәбез, рәхәтләнәм дә инде. Ну, бәйрәм алларыннан тегенди-мондыен да тоткалыйбыз. Заһидә апаң берни белми, иртүк торуга оныклары янына чыгып чаба. Мин дә йә беренче, йә икенче сменада эшлим. Берничә ел рәхәт күрдем шулай, ләкин бит тегенең малай үсеп килә. Калынаеп, тазарып. Мин тегендә йөрергә шикләнә башладым хәзер. Куркам. Ә карт мәхәббәт дөрли генә.

Карт гыйшыкка сиксән чиләк
Су сипсәң дә сүрелмәс,—

дигән җырны беләсеңме? Очраша алмау газабына чыдый алмыйча, гастрономга кенәнә икешәр тапкыр керәм, шул бүлеккә килеп басам. Ул да шул тирәдә. Алан-йолан басып торабыз. Мин йә горчица, йә бер дә кирәкмәсә дә, лавр яфрагы алган булып, кайтып китәм. Холкым үзгәрде. Элек тә яратмаган хатыным бөтенләй пәри булып күренә башлады. Картайды инде, факт, битләре тартылды, песи җамыгы хәтле генә калды. Миңа шикләнебрәк карый бу. Сизәм — минем белән ширлекләнеп үк сөйләшә башлады бу. Күрәм — кызлары, кияүләре белән дә әкеш-мәкеш килеп йөрешүне туктатты бу. Нишләргә?

Шулай ярты ел газап чиктек. Менә көннәрдән бер көнне — минем отгул — Заһидә апаң мунчага барырга җыена. Инде мин уйлыйм, икеөч сәгатьлек тәгаен генә аулагөй бу, тегеңә хәбәр итим. Хатын кухняда вакытта тегеңә телефоннан каушый-каушый хәбәр итәм, бер ярты сәгатьтән, йәме, дим, квартирыбыз икенче катта, подъездда үзем каршы алырмын. Чирек кенә сәгать булса да сөйләшеп утырырбыз, ыхымыхы...

Ул арада Заһидә апаң, рәхмәт төшкере, сумкасына мунчаласын, сабынын, миллеген төяп Плэтән мунчасына чыгып та китә. Минем йөрәк дөп-дөп тибә, тәрәзәдән күзне алмыйм. Диван артында җыеп куйган бер «Рислинг»ым бар иде, тиз генә шуны өстәлгә куйдым, ике фужер алдым. Ул арада күрәм — ап-ак халаты өстенә затлы тунын болай гына салган да, безгә таба җаныкашым йөгерә. Йә ходай, трамвай гына таптамаса иде үзен, дим. Керде, урамнан кышның салкын исләрен, конфет исләрен алып керде, җаныкаем. Тунын чөйгә алып элүем булды, муеныма сарылып елый ук башлады:

— Зариф абый, нишлик, мин болай яши алмыйм,— ди. Мин бернәрсә дә әйтә алмадым, оныкларың бар көе «хатынны аерам» дип вәгъдә биреп булмый бит инде. Диванга утырдык, кочагыма алдым, ә ул һаман үкси. Мин тыныч утырам инде, ишек эчке йозагына бикле, безнең бит, әйткәнемчә, байлар өе, ишекләр биек, ике якка ачылмалы, астан бусагага келәләр белән эләктереп куйган. Ап-ак буяулы, җиз тоткалы, затлы ишекләр.

Шулай чирек сәгатьләр утыргандыздыр. Ул да тынычлана төште. Инде теге «Рислинг»ны эчәргә вакыт дип урынымнан кузгалырга уйлап бетермәдем, бикле ишегем ике якка «дырк» итеп ачылды да...

Зариф агай шунда сырадан авыз итте, миннән сигарет сорап алды, ут бирдем, ул тирән итеп йотты.

— Шуннан соң, энем җаным... ни күзем белән күрим? Кулына балта тоткан Заһидә апаң. Ие. Безнең — утын миче, балта кухняда гына.

— Ах, б... тәреләр, икегезне дә чабып үтерәм бит! — дип, бу безнең өскә ташланды да.

— Һай! — дип җан ачысы белән кычкырды минем асылкошым, мин балтаны эләктереп алганда.— Һай!

Һәм, сикереп торып, тунын эләктереп чыгып та йөгерде. Балтаны каерып алу шактый авыр эш булып чыкты, идәндә мунчала, сабын, сөлге таралып ята иде, Заһидә апаңның ике кулыннан кысып креслога утырттым да тынычлану өчен берничә секунд бирдем. Үзем баш ватам: теге ак ишек ничек ачылды? Эчке йозакка бик һәйбәтләп ике тапкыр борып бикләгән идем бит... Һәм... кинәт аңладым. Заһидә апаң кухнядан торып минем телефоннан сөйләшкәнне тыңлаган. Мунчага киткән булып, мин күрмәгәндә генә, ишекләрнең тупсадагы келәләрен ычкындырып куйган. Ике яклы ишек менә шулай, ике башлы таяк ул, энем. Шуннан нишлибез? Хатын елады, елады да,

телефоннан ике кызын, ике киявен чакырды. Кияүләрнең берсе министр ярдәмчесе, икенчесе АТХда, чибәр, таза егетләр. Алардан оялам. Кичкә җыелдылар бит болар. Алар җыелгач, апаң тагын кызып китте, тагын теге балтаны алып керде, килә бит мине чабарга дип. Кызлар арага керә:

— Әни, җаным, башларың төрмәдә черер, түз, сабыр бул,— диләр. Кызлар акыллы минем. Ә кияүләр теге «Рислинг»ны малга да санамыйча, үзләре кыстырып килгән «Столичная»ны хәл итеп утыралар. Катышмыйлар. Кияүләр акыллы минем. Хуш, алар киттеләр. Сөймәгән хатын белән икәү генә калдык. Кич җитте, өйдә ут алындыручы юк, мичкә ягучы юк. Салкынайды. Чишенмәгән көе бераз яттым да, торып, киенеп, урамга чыгарга җыендым.

— Мин бераз йөреп керәм,— дидем. Хатын бозлы тавыш белән:

— Әйдә, бар, җәһәннәмеңә кит, теге б...ң янына барасыңдыр инде,— дип калды.

Ләкин миндә икенче, русча әйткәндә «более зрелый план» бар иде инде. Бездән ерак түгел, Сафьян урамында элеккеге карт интеллигент Шәриф абзый яши. Ялгызы. Сиксәннәрдә булыр. Ул — безнең гаиләнең дусты. Утыз еллар буе аралашабыз. Заһидә апаң өчпочмак пешерсә — аны чакырмый калу юк. Тавык тутырса — аны Шәриф абзыйсыз ашау юк. Хатынымны ул бик ихтирам итә, аңа «килен» дип кенә дәшә, сигезенче-тугызынчы мартта дигәндәй, чәчәген кертмичә калмый. Киттем мин шуңа, сөйләдем барысын да. Ул тыңлап бетерде, бүлдермәде.

— Иртәгә шимбәме? — дип кенә сорап куйды.

— Әйе, шимбә, Шәриф абзый,— дидем мин ниндидер җиңеллек өмет итеп.

— Иртәгә иртәнге уннарда икегез дә өйдә булыгыз әле,— диде ул бик уйчан кыяфәттә.— Килен дә оныклары янына китмәскә тиеш.

...Иртән апаң белән аерым утырып ашадык. Сөйләшү юк. Калган аш, каткан ипи, салкын чәй. Мичкә үзем яктым. Апаң әле белми, мин исә Шәриф абзыйны көтәм. Менә нәкъ ун. Ишектә кыңгырау. Юри бармыйм. Заһидә апаң барып ача. Бүреген сала-сала, карын селкеп ишектән Шәриф абзый керә, сөйләшә-сөйләшә керә.

— Нихәлләрегез бар, балалар, бу арада бер дә хәбәр-хәтерегез юк, авырыйсыз мәллә?

Дәшү юк, мин карт песи булып, йомшак кына атлап, Шәриф абзый тирәсендә йөрим. Ә ул апаңа текәлеп караган:

— Нәрсә, килен, авырып киттеңме әллә? Күзләрең шешенгән сыман. Берәр борчу-фәлән юктыр бит?

Ярты минут түзде апаң, бер минут түзде, ләкин һәр түзүнең чиге була бит. Кинәт кычкырып куйды:

— Әнә бу карт приституттан сора безнең хәлне,— дип миңа күрсәтте дә, Шәриф абзыйның ябык күкрәгенә башын салып шашынып елый башлады. Факт — аңа бушанырга кирәк иде. Шуннан... шуннан Шәриф абзый өстәл янына утырды да кырыс итеп тамагын кырып болай диде:

— Балалар, ник миннән яшерәсез? Ни булды? Сиксән яшьлек бабагыздан ни яшерәсез? Ә?

Һәм Заһидә апаң төкми-чәчми бәйнә-бәйнә барысын да сөйләп бирде. Мине соңгы елда ничек күзәткәнен, кичә телефоннан сөйләшкәнне ничек тыңлаганын, ак ишекләрнең аскы келәләрен ничек ычкындырганын, ничек итеп кулына балта алганын... Мин, караклыкта тотылган малай кебек, түбән карап дәшмичә утырдым. Иллә дә Заһидә апаң бушанды да инде. Шуннан, күрәм, Шәриф абзый урыныннан торды, пальтосы янына китте, кашнесын алып муенына салды, бүреген киде. Аннан, миңа борылып, җирәнеп кенә караш ташлады да,

болай сөйләп китте:

— Менә нәрсә, Зариф. Энем дип әйтергә телем бармый. Шундый кабахәт кеше булып чыктың син, синең белән гомер буе аралашып синең шундый дуңгыз икәнеңне белмәгән мин юләр. Ю-у-ук, булмый болай Заһидә сеңлем, куып чыгар син бу этне урамга. Бу — синең кискән тырнагыңа да тормый. Моннан соң минем өемә аяк басасы булма, сабаке. Шундый хатынның да кадерен белмәгәч. Алма кебек кызлар үстереп бирде бит ул сиңа, оятсыз!

Шәриф абзыйның сугышка кадәр Минзәлә колхоз-совхоз театрында бер-ике ел уйнап йөргәнен белә идем, тәмам рольгә керде бит бу!

— Ташла, ку син бу этне урамга,— диде ул апаңа карап,— типкәләп чыгарып ат син бу кабахәтне. Һи-и-и... Шушындый хатынның кадерен белмәгәч. Ялганчы! Ничә тапкыр бергә Морквашида ял иттек, Крутушкада. Шунда гел Заһидәмне сагындым, хатыннан башка ялның бер кызыгы юк,— дип үзәкләремә үтә идең бит син. Ялганчы! Киттем мин, бу йортка аяк басучы түгел...

Күрәм, җиңгәндә шунда зур үзгәреш булды. Күз яшьләрен сөртеп:

— Шәриф абый, чәем әзер, берәр генә чынаяк эчәрсең бәлки? — диде.

— Юк, юк,— диде тәмам рольгә кереп беткән карт,— юк. Бу җирбит янында ничек утырыйм мин.— Үзе инде кашнесын, бүреген кире элеп маташа иде.— Кухняда булса гына...

Һәм алар икәүләп кухняга уздылар. Аннан чынаяк, чәйнек тавышлары ишетелде. Мыдыр-мыдыр сөйләшәләр иде. Мин колак салдым. Җиңгәң әле һаман мышык-мышык килә, ләкин инде йомшак. Шәриф абзый сөйли:

— Инде, килен, син дә исәпләп кара: олайгач, ир кеше бер тапкыр азынып ала. Табигать законы ул. Кара син аны, ә? Юньсез! Миңа бит гомер буе тукып торды: шушы Заһидәм булмаса, мин дөньяда яшәүнең бер ямен тапмас идем, дип сөйли бит. Ул инде ял йортындагы киосклар янына килсә: Шәриф абый, хатынга берәр бүләк аласы иде бит! Заһидәмне сагындым бит! — гомер буе шулай.

Ишетәм-сизәм, җиңгәң мышкылдаудан туктады. Тагын бер үзгәреш булды, күрәсең. Сөйләшәләр.

— Шәриф абзый, ясыйм тагын берне?

— Йә, ясарсың, булыр. Ни бит килен, менә болай бит. Дүрт аяклы ат та абына. Әллә минәйтәм, балалар хакына килешәсезме? Кызларын бик ярата бит теге эт җан... Чык әле монда, эттән туган нәрсә! — дип кычкырды карт шунда бүлмәгә таба.— Чык әле, кая юкмы, берәр нәрсәң, тәмам нервымны эштән чыгардың бит, билләһи...

Мин, шатланып, теге бәхетсез «Рислинг»ны эләктереп, кухняга ашыктым. Чыксам — күрәм, җиңгәң бөтенләй икенче кеше булган. Шәриф абзыйның «Рислинг»кына түгел, аннан көчләрәген дә бер-ике рюмка тотканын беләбез. Шунда җиңгәң әйтә куйды:

— Шәриф абзый, кияүләр килсә дип алып куйган бер коньягым бар, алып килимме? — ди.

Карт тиз генә сынмый.

— Бу адәм актыгы белән коньяк эрәм итәсе түгел иде дә бит, нишлисең, әйдә китер, килен... Һай-һай-һай... Сине бик каты яратканын белмәсәм, хәзер үк аерылышыгыз дип әйтер идем дә, гөнаһтан куркам.

Шәриф абзый төш узгач кына, мичләр томаланып пилмәннәр ашагач кына китеп барды.

— Карагыз аны, балалар. Моннан соң мине борчыйсы булмагыз, ә син килен, бу шалманны ныграк тот, ләкин дә кулыңнан ычкынды-

расы булма, мондый егетне теләсә нинди тол хатын биш куллап үзенә кабул итәчәк,— дип сөйләнә-сөйләнә чыгып китте.

— Шәриф абзый, атна уртасында тагын кил,— дип чылдыраган тавыш белән җиңгәң аны озатып калды. Мин дә шыпырт кына балтаны утын сараена чыгарып куйдым.

Өйдә мамыклы җылы, мәче дә җылынган, ашатылган, рәхәтләктән паласка тәгәрәгән, борынгы зур сәгатьнең тек-тек итеп гомер санаганы гына ишетелә. Шул көннән соң икенче тормыш башланды. Мин аңладым: язмышыңа күнәргә кирәк. Бер кул белән ими дә, бөти дә тотып булмый шул. Ну инде, энем, менә ризык белән ант итәм, чын яратуның нәрсә икәнен белеп калдым мин. Минем алтмыш еллык гомерем ул кайнар ярату көннәренең бер аена да тормый, белдеңме? Мин бәхетне татып карадым. Мин язмышымнан канәгать...

Төнлә мин йоклый алмадым, бу абзыйның язмышы турында уйлап яттым. Шуның өстенә таңга таба коточкыч давыл башланды. Гагра урамындагы эвкалиптларның ыңгырашуы ишетелеп торды. Иртәнге якта гына йоклап киткәнмен.

Иртәгесен төшкә кадәр пляжда Рафаэльгә мин Зариф абзый хикәясен сөйләп утырдым.

— Бик һәйбәт хикәя чыга бит, язып карыйммы? — дидем.

— Юк, маташма,— диде Рафаэль. Ул әдәбият теориясен яхшы белә, минем шикелле гомерен «Кыскача курска» әрәм итмәгән.— Ни өчен шулай? — дим.

— Беренчедән,— ди ул.— Син инде моны миңа сөйләдең. Кешегә сөйләгән әйбердән хикәя чыкмый. Икенчедән, моны сиңа сөйләгәннәр, ә үз эмоцияләрең, үз кичерешләрең юк. Өченчедән, бу — бик интим тема. Хәзер заман башка, зуррак, социаль мәсьәләләр күтәрергә кирәк. Тема бик очлы булырга тиеш. Шунсыз син язучы булып китә алмыйсың...

Рәхмәт аңа! Тик мин төшке ашка кадәр «очлы тема» турында уйлап йөрдем, нәрсә ул, җавабын тапмадым. Ләкин ашханәгә кереп аның өстәле янында аз гына утырып алган идем, төшендем. Рафаэль кашыгын куеп, аш тәлинкәсен бер читкә этте дә, елмаеп әйтте:

— Борщ бик очлы, ашап булмый,— диде. «Острый» дигәнне тәрҗемә итеп безнеңчә сөйләшүе икән. Хәер, нигә гаҗәпләнергә? Юлга чыгарга бер-ике көн кала мин Казан телевидениесеннән бер әңгәмә тыңлаган идем. Югары белемле ветврач сөйли, бер совхоздан тапшыру бара. Ул әйтә:

— Бу кварталда без барлык ата сыерларны иткә озатып бетерергә тиешбез,— ди. Ә нәрсә? Ялган сүз сөйләми бит, бәйләнеп кара!

Кичен, иләнгән сәгатьтә, диңгез буендагы кафеда ике шешә сыра алып мине Зариф абзый көтә иде. Мин әшне тиз тоттым:

— Теге ханым белән тагын күрештегезме? — дидем.

Зариф абзый хикәясенең дәвамын сөйләргә әзерләнеп килгән.

— Ул, бичара, икенче көнне үк эшеннән киткән. Мин кибетләргә йөри-йөри аны эзләдем. Гафу үтенәсем килде, аны кыен хәлгә куйган кеше мин бит. Өйдә тыныч-тынычын, ләкин мин бит ялгызым хәсрәттә. Шулай ярты еллар бөтен гастрономнарны әйләнеп чыктым. Инде өметсез йөргәндә бер көн бәхет кояшы балкыды: Горький урамындагы гастрономда очраттым мин моны. Гади сатучы булып эшли икән, җанашым. Чыкты залга, бераз сөйләшеп тордык. Эш сәгате беткәндә килеп тордым да, караңгыдан файдаланып, байтак юл озата бардым. И, серләштек тә инде: теге вакыйгадан соң тагын бер тәтәрәп алган: алкоголик ире кайтып тора башлаган. Алар ике ир туган икән, икесенең дә рәте юк, ди. Монысы әчә, ә кечерәге өйләнми, карт әнисе, укытучы-пенсионерка янында эшләмичә әрәмтамак булып яши икән. Бар шөгыле — киосктан бөтен булган газета-журналны

алып кереп, диванга ятып шуны уку һәм конфет-варенье, печенье ашау, ди. Алкоголик кияү белән берәр ай яшәгәч, бичара хатын моны җитәкләп әнисенә илтеп тапшырган. Энекәше печеньены вареньега манып ашап утыра, идән тулы газета-журнал икән. Шуннан минеке (!) әйткән:

— И, әнкәй,— дигән,— боларны имезгәндә бер күкрәгеңнән аракы, икенчесеннән бал актымы әллә?

Әнисенең алкоголик улын бик тә кире биреп җибәрәсе килгән:

— Килен,— дим,— тыңла сүземне, ирнең үгие юк аның,— дип үгетләп караган. Ләкин минеке (!) бирешмәгән, бүтән килмәскә кушып чыгып киткән. Дөрес инде: шундый чибәр, булган хатынга дуга белән печән чабып йөрүче җилкуар ни пычагыма! Хәзер бит ирләр азынды. Хатыннары туйдыра, ә аларның эш рәхәт, дандарага җон тетеп йөриләр шунда. Менә шулай, гафу үтендем, җиңел булып китте. Тагын эш телефонын алдым. Ул телефонны күңелдән бикләдем дә, кайткач алфавит кенәгәсенә теркәдем. Билгеле инде, ирләр фамилиясенә әйләндереп. Шулай кирәк ул — аны бит үзең аңлыйсың. Сафин Хәлим дип язгансың икән, димәк — Сафина Хәлимә; Вафин Сәлим дип язгансың икән, димәк — Вафина Сәлимә. Андый эштә сак булырга кирәк.

Менә бер вакыт миңа бәхет кояшы тагын бер елмаеп алды. Кайда гына күрешик икән, дип янып-көеп йөри башлаганда урамда Шәриф абзыйны очратам.

— Больницага тикшерелергә керәм, гөлләремә су сибеп, мәчемне ашаткалап чыкмассыңмы? — ди. Аннан ди, бер ял көнне килеп китапханәмне рәткә сала алмассыңмы? Рәте бетте,— ди. Һәм, мин риза булгач, шундук бер пар ачкычын бөҗрадан салдырып ук бирде. Шул ук көнне кич больницадан өйгә чылтыратты да. Бер унбиш көн ятарга туры килер, дигәннәр врачлар.

Мин күкләргә аштым. Нинди ул сипмәгән, нинди ул ашатмаган? Ялга каршы үземә тиз генә бер командировка уйлап таптым. Зәһидә апаң да шатланып риза булды, оныклары янына дачага барырга дип канатланып йөри иде. Кечкенә чемоданга сабын, сөлге, теш порошогы кебек нәрсәләр салды, элегрәк шулай йөри идем. Чистаймы, Арчамы, Норлатмы. Типография эше белән. Мин урам телефоныннан йәлт кенә хәбәр ит яшь апаңа.

— Фәлән сәгатькә, фәлән урам, фәлән йорт,— дим.

Бардым, кердем, таныш гөлләргә су сиптем, таныш карт мәчегә сөт җылытып бирдем. Бераздан яшь апаң да килеп җитте, үзе шат, үзе дер-дер килә. Һәм без шундый рәхәт әңгәмәгә чумдык, безне күзәтеп торган карт мәчегә хәтле барысын да аңлап, караңгы төшәрәк үз эше белән биләмгә чыгып китте. Шәп утырдык без. Серләштек, хәтта елашып алдык. Чәй куеп җибәрдем — бәхет. Тик Шәриф абзыйның шкафын, өстәл тартмаларын күпме генә актарсак та, бөртек тә чәй тапмадык. Булка да юк икән. Мин шунда егетлек күрсәттем. Ишек янындагы хуҗалык сумкасын алдым да, кибеткә чыгып киттем. Өстеннән бикләп. Йәлт кенә Тукай урамына чыктым, чәй юнәлттем, кызу-кызу атлап «Булочная» дигән кибеткә бара идем, галстук, пиджәк тегендә, мин изүләрне чишкән, яланбаш, кулда теге сумка — килә идем... килә идем, энем җаным... Шунда ни күрим? Тротуардан каршыма сумка тотып килә... Зәһидә апаң. Беттем, катып калдым. Туп-туры каршыга килә бу, танк булып килә. Күз алларым караңгыланды. Хәзер борылып китсә дә тотылам, каршына барсам да. Тотылам, нишләргә? Чибәр апаң бит читлектә — ачкыч миндә. Тир бәрде, йөрәк туктады. Аны сөйләве генә озын. Ара бит ике-өч метр гына калды. Шуннан... Тукай урамындагы фотоматериаллар кибетен белә-

сеңме? Кинәт кенә шуның стенасына сыланып бастым да, этүтән[1] шикелле кулларымны «по швам» төшереп, күзләремне йомып каттым да калдым. Йөрәк әле дә эшләми, тын ала алмыйм. Шул секунд эчендә ерактагы балачагым искә төште. Авыл урамында урыс капкага сөялеп тезелеп баса идек тә, берәү чираттан күкрәккә төртеп саный иде — һәр күкрәккә бер сүз.

Абзый, сиңа
Падишадан
Хәбәр килгән:
«Ә» димәскә,
«Мә» димәскә,
Уйнамаска,
Еламаска,
Көлмәскә.

Соңгы сүз кемгә эләксә, шул кеше күзен йомып торырга тиеш, кем генә китереп төртсә дә, тавыш чыгарасы түгел. Менә шул вакытта нәрсәләр искә төшеп тора диген. Шулай берничә секунд узды. Бераздан акрын гына күзләремне ачам, карыйм — Заһидә апаң мине күрмичә узып киткән, җай гына атлап Плэтәнгә таба бара иде. Йә, хода! Менә шуннан соң алла юк дип кара инде син... Урланган бәхет менә шулай хәтәр була ул, энем.

Гаграда кич бик кинәт килә, караңгы бик кинәт төшә. Тагын нисләр сөйләгән булыр иде Зариф абзый, белмим, әмма, сәгатенә карап алды да, кузгалды:

— Әйдә, энем, якты күздә кузгалыйк,— диде.— Ярый, сиңа әңгәмәдәш булганың өчен рәхмәт, бүген төнлә Сухуми — Мәскәү поезды белән мин китеп барам, путевкамның срогы тулды,— диде.

Аерылышыр алдыннан нык итеп кулны кысты, читкә карап авыр сулады.

— Һи-и, энем... Дөньяда иң эшәке әйбер — картлык. Карт булмасам, шундый чибәр яшь хатын яныннан, аулактан, үз теләгем белән чәй, булка эзләп чыгып киткән булыр идеммени? Ититтиомайть... Нәрсәгә ул булка? Нәрсәгә ул чәй? Һи-и-и... Яшь булсаң, дим.

Икенче көнне мин теге, без сөйләшеп утырган кафега бармадым. Анда барудан ни кызык бар соң хәзер? Ни ямь бар анда?

## Казан. Университет

### Зәгъфран иленә сәяхәт

*«Монда, бу бинага атлап кергәндә, яшьләр бер фикере дә булмаган буш сүзләр ишетмәсләр».*

(Н. И. Лобачевскийның 1804 елда Казан университетында сөйләгән нотыгыннан)

1

Бу бүлектә сүз мәшһүр университетның алтмышынчы еллары турында барачак. Табигый ки, мин сиксәненче елларга әлегә тукталмыйм, ул елларга бәя бирергә әле иртәрәк. Исән булсам, алар ха-

[1] Адьютант сүзеннән алынган булса кирәк. Казан арты сөйләше.

кында да язачакмын. Хәер, язылачак ул китапның өлгеләре минем өстәлемдә инде, тик гомер кирәк, гомер, шайтан алгыры... Әнә шул иң кирәкле әйбер бик исәпле бит бу фани дөньяда.

Университет... Монда кереп уку минем мәңгелек хыялым иде. Ләкин керә алмаячагымны да белә идем. 1947 елның июлендә, аттестатымны газиткә төреп тотып, шул бинаның колонналары янында басып тордым. Күзгә яшь бөялде. Чалгыдан, сәнәктән, «уфалла» арбасыннан кичә генә аерылган яшүсмер ничек итеп шундый мәшһүр уку йортына укырга керә алсын инде? Һәм мин авыл халкы өчен бераз якынрак булган Болак буе педагогия институтына киттем. Анда керә алдым тагы...

Ә теге хыял мине әзәрлекләде. Шул хыял миңа тынгылык бирмәде. Университет значогы таккан яшьләрдән гомер буе көнләштем.

Һәм 1960 елның сентябрендә, имтихан биреп, татар әдәбияты кафедрасына аспирантурага кердем. Керүем бик кызык булды: немец теленнән имтихан биргәндә, әзерлегем бик түбән икәнлеге беленгәч, имтихан алучы Евдокия Алексеевна Кирпичникова чәченә ябышты:

— Сез нәрсә уйлыйсыз, ничек кандидатский минимумны бирерсез? — диде. Мин, батырлыгымны җыеп:

— Әгәр миңа уңай билге куеп чыгарсагыз, ант итәм: минимумны мин яхшы билгесенә тапшырачакмын. Ант итәм. Антыма ышанмасагыз, хәзер үк икеле куегыз, ләкин мине газапламагыз,— дидем. Ул ыңгырашып миңа «удовлетворительно» куйды. Алдан ук шуны әйтеп китим: мине икенче бер юньле хатын — Марианна Николаевна Пахомова укытты һәм мин зур дәүләт комиссиясе алдында чак-чак кына «биш»ле алмадым. Комиссия әгъзалары, киңәшеп, «дүрт»ле куйганда Марианна Николаевна болай диде:

— Ах, бөтен аспирантларым да шундый үҗәт, шундый максатчан булсалар иде, бу иптәш бит нольдән башлады. Мондагы тырышлык!

Анысы бардыр, анысы сугыш вакытында ач көе тезләнеп «уфалла» арбасы тартканда ясалгандыр.

Татар әдәбиятын тапшырганда комиссиядә Х. Госман, Я. Агишев, З. Мәҗитов иде. Тегеләрен танысам да, З. Мәҗитовны белми идем: бу нинди малай-шалай миңа сорау биреп бәйләнеп утыра соң, дип ачудан тешләремне кысып җавап бирдем. Зәет шундый яшь иде әле!

Ахырдан сөйләде: мине чыгарып җибәргәч, билге турында киңәшкәндә Якуп ага әйткән:

— Хәтыйп, бу егеттә өмет бар бит, бишле куйыйк,— дигән. Шулай бишле куйганнар. КПСС тарихыннан биргәндә ниндидер төгәл булмаган фраза ычкындырып харап була яздым: имтихан алучы Р. И. Нафиков нәгъръәләр орды инде, сүкте, дулады. Югары белемем буенча тарихчы икәнемне белгәч, үз итеп, «коллега» итеп, ихтирам белән сүкте. Аннан, елмаеп, кулны кысты. Бераздан приказ чыкты.

Аспирантлар өчен булган тулай торакка ордер алып барып урнаштым да, «кәҗүнни» караватка сузылып яттым. Тормышымда яңа этап башлана иде. Фәнни җитәкче Х. Госман, икенче көнне үк кафедрага чакыртып, әдәбият исемлеге бирде. Минем чаманы тартып карагач, туп-туры китапханәгә юл күрсәтте. Аның әйтүе буенча Казан император университеты каршындагы Тарих, Этнография, Археология җәмгыятенең гыйльми язмаларын өйрәнергә керештем. Алар барлыгы калын-калын утыз дүрт том иде. Бу хәзинә минем күземне байтак ачты. Китапханәгә, ачылышына килеп, кичен соңгы булып чыгып китә идем. Гыйлемгә ачлык!

Аспирантлар кызык халык: шкафта — сабын, мунчала, юылмаган кер; коньки, эспандер, гер, гантель — идәндә аунап ята. Һәрберсе кабатланмас бер шәхес. Физик Гаял — таза, йонлы күкрәкле, фран-

цуз телен өйрәнеп көннәр буе бүлмәдә ята. Иртәрәк кайтсаң, ишек бикле, шакыйсың — эчтән башын гына тыга да:

— Ыцлуцай, бер ун-унбиш минут йөреп кермицеңме, двоеродная цецтра килгән, цәй генә эцик инде,— ди. Шулай, көненә әлләничә «туганы» килеп китә моның. Бу өлкәдә шактый тәҗрибәле, әмма кеше буларак юньле, тәртипле егет. Бер ярты «Волжская» дигән портвейн алса, бер айга җитә.

— Кызлар алдында авыздан аз гына хуш иц килеп торца — артыгы нигә аның? — ди.

Гаял — армиядә булган егет, тәҗрибәле, үзенчәлекле. Шунда вакытта Мәскәү радиокомитетына хат язган: нишләп гел «рус каены» дип җырлыйсыз? Каен бит ул Татарстанда да үсә, агачның милләте булмый бит, дигән.

Бераздан аны контрразведка бүлегенә чакыртканнар да, болай дигәннәр:

— Бәхетең инде, Хрущев заманы, югыйсә, кабереӊ өстендә шул рус каены үсеп утырыр иде...

Икенчесе математик, керәшен малае Коля, гел бишкә укыган да, кафедрада калдырганнар. Сак, пөхтә, тәртипле. Аракы эчми. Бервакыт, шкаф өстендәге чемоданын алып, шуның төбеннән затлы венгерский коньяк чыгарып күрсәтте:

— Узган ел Мәскәүдә алган идем,— диде. Шаккаттым. Коляның бер кимчелеге бар — үз гомерендә кызлар кулы тотып караганы юк. Шуны белгән тәҗрибәле Гаял кичен йокыга яткач тәмләп әңгәмә башлый.

— Ыцлуцай, Коля. Цин бик күп нәрцә югалтацың. Ыцту цин! Кызлардан башка дөнья — дөньямыни ул? Ул, малай, танцыга алып керәцең, йомшак кына итеп биленнән тотацың, иягеңне тегенең йомшак җилкәценә куяцың да, тегенең хуш ицле чәчләренә битеңне кытыклатып биеп китәцең. Кыз бала гел йомшак кына була бит ул...

Кызып китеп Гаял әлләниләр сөйләп ташлый, йокыга киткәндә Коля ыңгыраша, саташа, әйләнгәләп матрацын изә. Дүртенчебез геолог Сеня, икенче курс аспиранты, аның кандидатлык минимумнары биреп бетерелгән, ул диссертация яза. Кайвакыт атналар буе бүлмәдән чыкмый — Гаялгә бик комачау итә — бер сумка «бомба» алып кайта да, шуларны караваг астына тезеп куя һәм көннәр буе шуны чөмерә. Аның мәхәббәт өлкәсендә нинди дер драмасы булган, искиткеч юньле малай, аны бөтен кеше ярата. Ул, караватына утырып, кичен мин кайтканны көтә. Мин кайткач шатланып китә һәм, бераз «өстәп» куйгач, һәр көнне бер генә сүз әйтә:

— Эх, Мухаммет... Дилетанты мы, дилетанты...

Берәр атнадан соң ул эшенә чума, сөйләшмәс була... Аны бик башлы егет, әйбәт яшь галим диләр.

Аспирант халкы атнага бер-ике тапкыр кафедрага килеп чыга, анда төрле мәшәкать — йә кафедра утырышы, йә партҗыелыш, йә диплом яклау. Менә диплом яклау комиссиясенең утырышы. Тукта, тукта, кем бу шул кадәр җайлы итеп сөйли?

— Хөрмәтле иптәшләр, хөрмәтле комиссия әгъзалары. Сезнең алдыгызга куелган диплом эше безнең әдәбиятыбызның моңарчы аз өйрәнелгән аерым бер мәсьәләсенә багышланган. Диплом авторы моны эшләү өчен бик күп көч куйган, бу диплом бик әтрафлы итеп башкарылган. Әлбәттә, әлбәт-тә, бу эш буенча шактый бәхәс кузгатырга мөмкин, моның кайбер дәлилләре белән бәхәскә дә керергә мөмкин, ләкин бу утырышта андый бәхәс кузгатуны мин кирәк түгел һәм максатка ярашлы түгел дип исәплим, шуңа күрә, теге яки бу якларына кермичә генә, мин моны югары бәягә лаек дип исәплим.

Бу — студентларның рухи атисе — Якуп ага Агишев.

Аның мондый йомшак, җайлы чыгышларын берничә утырышта шулай тыңлагач, мин моның «кухня»сын ачтым. Кафедрада бишенче курс студентларына гадәттән тыш җиңел тема бирәләр икән. Мәсәлән, «К. Нәҗми иҗатында кояш образы», «Һ. Такташның «Сыркыды авылы» әсәрендә нэпманнарны фаш итү», «Г. Ильясиның «Бичара кыз» драмасында Җанбай белән Җантимер образлары» һ. б. И алла! Университет кадәр университет тәмамлаганда шулар булдымы тема? Мин, элеккеге тарихчы буларак, К. Маркcның университет тәмамлагандагы фәнни эшен күз алдына китердем; Н. Г. Чернышевскийның студентлык елларында язган гыйльми хезмәтен күз алдына китердем; яки Газиз Гобәйдуллин дигән Казан егетенең 1916 елда император университетын тәмамлагандагы темасы: «Марко Поло турында тәҗрибә». Г. Газиз — совет чорында мәшһүр тарихчы, профессор.

Якуп ага диплом эшләрен, оппонент буларак, ахырысы, бөтенләй укып тормый. Чөнки, темасына карап, кемнең нәрсә әйтә алачагын алдан белә бит инде ул! Шуңа күрә һәр эшкә ул әнә шулай «әтрафлы», «бәхәсле» кебек сүзләр белән уңай бәя биреп утыра. Якуп ага, кабатлап әйтәм, студентларның, аспирантларның иң яраткан кешесе иде. Аның аспирантлары да җитәкчеләренә карата шулкадәр игътибарлы булдылар, мин боларга кызыгып карый идем. Юк, миннән алай булмады. А. Яхин, мәсәлән, Якуп аганың аспиранты, җитәкчесенең соңгы сулышына кадәр аңа игътибар, ярдәм күрсәтте. Алар арасындагы эчкерсез дуслыкка мин көнләшеп карый идем.

Якуп аганы элегрәк елларда зур бер начальникка кандидатлык язып биргән дип сөйлиләр иде. Булгандыр, чөнки алтмышынчы еллар башында «кандидатлык» бик нык модага кереп китте, бик күп райком секретарьлары, райисполком председательләре, горком, обком кешеләре кандидат булып беттеләр. Ул елларда шундый хәбәр дә йөри иде: фәлән профессорга фәлән райком секретаре соискатель булып беркетелгән, тиздән яклаячак икән. Шулайдыр, чөнки карыйсың, профессор көннәрдән бер көнне өр яңа шәп квартирага күчеп маташа.

— Ә-ә,— диләр моны белгәч,— димәк, теге яклаган.

Ул елларда кандидатлык темалары бигрәк тә экономика, авыл хуҗалыгы, медицина, тарих, философия өлкәсендә күп иде. Кеше генә җиткер. Мисаллар: «1928—30 елларда кулакларны ликвидацияләүдә комсомолның уңай роле», «Малайларны сөннәткә утыртуның сәламәтлек өчен зарары», «Мурманск өлкәсендә кукуруза үстерү мәсьәләләренә карата», «Ислам диненең әдәбият-сәнгатькә зарары», «Хосусый һәм шәхси милеккә каршы көрәш — экономикабызның төп юнәлеше» һ. б.

Булгандыр, Якуп ага да язып биргәндер. Минем моңа сыек кына бер дәлилем дә бар. 1961 елның май аенда опера театрында ниндидер бер әдәби кичә булды. Берәр юбилей иде бугай. Якуп агайны теге буфетка да алып барып килделәр, монысына да. Буфетларда ул вакытта коньяк, коры шәраблар өзелми һәм исерекләр дә булмый иде. Әмма Якуп агай кыза калган. Кичәнең ахырында плащларны алырга дип гардеробка чиратка бастык. Тирләгән калаемны тотып, Якуп ага белән Х. Ярми уртасында мин дә тора идем. Шунда, бичәсен култыклап, Якуп агайның теге начальнигы килеп чыкты.

— Һо-о, Якуп Хәлилович, сәлам,— диде ул киң елмаеп.— Ни хәлләр?

Шунда Якуп агай тегеңә борылып бераз күзен алартып торды да, кисәк бәрде:

— ...(исемен әйтте). Дурак! Надан! Дөнья наданы бит син! Бар, күземнән югал!

— Һе-һе,— диде уңайсыз калган начальник,— күрәм, артыграк

төшереп алгансыз...— һәм юк та булды.

Якуп ага кафедрада эшлисе иде әле, ләкин аны алтмышы тулган көндә пенсиягә китәргә мәҗбүр иттеләр. Ул, эшне аңлагач, карусыз гына гариза язды, китеп барды һәм... коллективтан аерылгач, озак үтми җир куенына кереп тә ятты.

Ә монда, монда, туксан өченче аудиториядә нинди җыелыш тагын? Нык мускуллы, сабыр характерлы профессор, дөнья бәясе кеше Николай Александрович Гуляев гыйльми советны алып бара, авылдан чыккан бер егет олы юлга басарга — кандидат булырга җыена икән. Ян өстәл кырында — ак нейлон күлмәгенең җиңнәренә янтарь запонкалар эләктергән шома битле яшь оппонент, икенче бер оппонент инде сөйли үк башлаган. Бүген пәнҗешәмбе көн икән бит, ә ул елларда һәр ике пәнҗешәмбенең берсендә конвейердан икешәр кандидат чыкты да торды. Бер пәнҗешәмбедә мин дә чыктым ул конвейердан. Теге оппонент нәрсә сөйли?

— Туарчество таких поетов как Маякауский, Исакауский, Туардауский очень сильно влияли на развитие многонасиональной литиратури, в том числе и на татарской...

Ә, таныдым, бу — филология фәннәре докторы Мөхәммәт Гайнуллин, галимнәрнең үзенчәлеклесе: Мөхәммәт ага, башка гуманитар галимнәрдән аермалы буларак, үз гомерендә беркемгә дә аяк чалмады, киресенчә, татар яшьләре арасыннан гыйльми хезмәткәрләрнең бөтен бер плеядасы үсеп чыгарга ярдәм итте. Күз алдына китерегез әле: әгәр татарлар арасында шул елларда М. Гайнуллин урынына икенче бер кеше доктор булган булса? Әйтик... Әйтик... һәм... Нәрсә булган булыр иде? Бүгенге көндә татар филологиясе мәрхүм Мөхәммәт Гайнуллин башы кебек тап-такыр булыр иде. Ул үтенеч белән килгән бер генә яшь галимгә дә оппонент булудан баш тартмады, вакланмады, кешене җәберләмәде. Әнә шуңа күрә болай дип сүзен тәмамлый ул:

— Яуа работа нисомнинны заслуживает присуаения яму искомой эстипени кандидата филалагических науык.

Молодец, рәхмәт, Мөхәммәт ага. Синең русчаңнан ятып кына көләләр, Рәсүл Гамзатовларны андый акцент бизи генә әле...

Шундый яхшы күңелле булганы өчен Мөхәммәт аганың бер сыйфатын гафу да итәләр иде: профессор, ике дә уйлап тормыйча, үз тирәсендәге яшь галимнәрнең табышларын үзләштергәли дип сөйлиләр иде.

Арткы рәтләрнең берсендә ялт та йолт килеп зур галим Әнвәр Ахунҗанов утыра — монысы факультетта киенү моделе. Аның өстендә иң затлы костюм — йә Польшаныкы, йә Югославиянеке. Ул безнең шикелле Казанның 4 нче фабрикасыныкын беркайчан да кимәс. Аның костюмына карата галстугы, галстугына карата күкрәк кесәсеннән күренеп торган бер кисәк материя булыр. Штиблетларын буямас өчен ул трамвайга кермәс, гел такси белән генә йөрер. Баскычтан-баскычка. Очраганда — көненә ничә тапкыр очрашсаң да — өр яңадан кул биреп күрешер һәм әйтер:

— Мәһди, бу галстугың килешми. Иртәгә мин сиңа икенче галстук алып киләм.

Ләкин икенче көнне син аны күрә алмыйсың: Әнвәр абый ул көнне, һичшиксез, комиссионкада була, югославский костюмын шунда тапшырып, япон материалыннан яңа костюм тектерергә ательега йөгергән була. Факультетта мода ягыннан ул бер генә ирне дә үзеннән уздырмады, без мокытларга һәрвакыт үрнәк булып торды.

Гыйльми совет тәнәфес игълан итә, галим-голямә коридорга агыла, аяк басарлык урын калмый. Ләкин шул тыгыз халыкны як-якка сибеп, урталай ярып берәү килә — мәһабәт гәүдәле, карчыга күзле, кара бөдрә чәчле — бер кулында бүреге, икенче кулында папка һәм

зур тартма белән конфет, «шалевый» якалы пальтосын җилгә җибәргән, ә күзләре яна! Кызу-кызу килә, туксан бишенче аудиториягә ашыга, үзе бераз гына көйли. Ә күзләре... яна! Бу — Мостафа Ногман, фарсы теле укытучысы. Күп җырлар авторы, студентлар арасында король. Ул әле диссертация якламаган, ассистент акчасы фәлән сум гына, шуның өстенә... алимент. Мәһабәт гәүдәле чибәр ир университет кассасының амбразурасына иелми генә ведомостька кул куя, кассир хатыннан ояла, чөнки бер алганда кулына утыз өч сум, икенче алганда — аннан да азрак. Шулай да аның кәеф шәп, университет ДОСААФында мотоинструктор булып акча эшләүче мишәр егете, бишенче курс студенты Фалистан әҗәткә акча юнәткән дә, шул акчага бер тартма конфет алып, дәресенә керә. Бер ярты сәгать «зәбан-е фарси», «фәрһәң» «миһман» фәлән-төгән дип күнегүләр эшләтер дә ул, аннан үз җырын хор белән җырлатыр.

Карлыгандай кара күзләреңә
Карыйм әле күзем талганчы...

Шулай җырлатыр, конфетын өләшер һәм, звонок булгач, шул хисләр дулкынында коридорга чыгар, урта бер җирдән бронемашина булып узар. Күзләр әле һаман шулай. Андый-мондый юлына очрасаң, саллы гәүдәсе белән сине чигендерә-чигендерә стенаның бер почмагына китереп терәр дә, чыгар хутың беткәнлегенә ышангач, мышный-мышный болай дияр:

— Карале, ыслушай. Кичә без Рөстәм Яхин белән бер романс иҗат иттек. Ну малай, класс инде! Билләһи. Менә тыңла:

Бөдрә таллар, зифа таллар
Ефәктән киенгәннәр...

Менә гыйльми совет утырышы тәмам. Бәхетле диссертантларны урап алганнар, кул кысу, чәчәк бирү. Күбесе, хым-хым килеп, мәгънәле ымнар белән рәхәтләнеп, банкетка җыена, ә менә затлы мехлы пальто, затлы мехлы, өсте плюш түгәрәк бүрек кигән Шаляпин сыман эре бер ир акрын гына аска төшеп бара. Кем бу, чыннан да Шаляпин үзе терелеп кайтканмы әллә? Юк, бу — галимнәрнең галиме, бөек шәхес Латыйф Җәләй. Шаляпин түгел ул, чөнки Федор Ивановичның муены туры булган, ә Латыйф агайның муены кәкрәеп, башын бер якка борган да куйган. Ул синең белән күкрәгеп каршыңа куеп сөйләшер, йөзе читкә борылган булыр. Бичара, авыру аны бик нык каһәрләгән иде, мин авторефератымны күтәреп өенә барганда аның бер аягына ампутация ясаганнар иде инде.

...Мин каушап кына кердем аларның коридорына, хуҗа апа чишенергә кушты, каушавымнан озаграк чишендем ахрысы, түр бүлмәдән көр ирләр тавышы дөбердәп ишетелде:

— Раушана! Кем ул анда, керсен тизрәк!

Кердем, исәнләштем. Ап-ак җәймә җәйгән, ап-ак мендәрләр. Шуларга сөялеп ап-ак күлмәк, ап-ак кальсон, башына чуар түбәтәй кигән мәһабәт ир утыра. Кулында гарәп графикалы калын бер иске китап. Өстәл өсте тулы кәгазьләр. «Галим кеше шушылай була икән инде»,— дип уйлап куйдым. Ул минем авторефератны актарып чыкты, башта уңайга, аннан кирегә. Аннан кайсыдыр битенә тукталды. Мин аңа мөлдерәтеп карап хөкем көттем. Ниһаять, ул миңа күтәрелеп карады.

— Менә болай, энем. Бу эшкә уңай бәя бирермен мин. Бюллетеньне конвертка салып кеше йөгертерсез. Профессор Гуляев андыйның рәтен белә. Аннан инде ни... Мин бит банкетларга йөри алмыйм. Яшь галимнәр белән сөйләшеп утырасым килә. Яклаган көннең иртәгесен шыпырт кына килеп китәрсең әле. Тик, ишек яныннан узган-

да, Раушана апаң янында озак тукталып торма. Аның мине саклыйсы килә. Ә мин — бу дөньяда бер ялгызым. Әсирлектә мин.

Профессор бик тә, бик тә кызганыч иде.

Яклаудан соң икенче көнне, әлбәттә, мин анда бардым: «Таможенный досмотр»ны уңышлы гына уздым. Хәтерлим, «контрабанда» белән үткән товарым бик затлы иде: «Ром румынский». Эчкәч, авызыңнан гел әфлисун исе килеп тора инде. Раушана апа бәрәңге кыздырып йөри иде, безнең бу гөнаһны сизми калды. Ләкин бераздан сизде. Чөнки ак урын-җир өстендә ак күлмәк-кальсонлы, бер аякка калган мәһабәт ир елый иде:

— Шәкертләрем күп минем. Кайберләре килеп хәлемне белә. Ә минә Мирфатих онытты. Кафедра мөдире булганнан бирле онытты.

...Мин аның яныннан киткәндә ишектә тагын бер шәкерт очрады.

— Командировкага барам, Латыйф аганың фатихасын алырга килдем,— диде ул. Раушана апаның сынаулы тикшерүе астында. Шәкертнең кулында папка гына иде, «таможня»ны ансат узды.

Бичаралар... Нинди юньле кешеләр булып хәтеремә кереп калдылар. Мәрхүмнәр инде алар, күптән мәрхүмнәр. Бар иде ул елларда шундый эчкерсез галимнәр. Бар иде. Әйтик, яңа ачылып килгән журналистика кафедрасында Гази ага Кашшаф бар иде. Таягына таянып, шыгыр-шыгыр азапланып, химкорпусның дүртенче катына менеп килә. Көтеп аласың, чөнки ул сиңа бик кирәк. Сиңа матбугатта басылу кирәк, ә мәкаләңне журнал редакциясе борып кайтара: берәр өлкән галимнән рекомендация кирәк, ди.

— Исәнмесез, Гази абый, сездә йомышым бар иде...

Тирләгән, бүреген салган. Кайнар кулын биреп күрешә.

— Тыңлыйм, пожалуйста.

— Гази абый, ни бит. Менә бер мәкалә язган идем журналга, берәр өлкән галимнән рецензия кирәк, диделәр.

— Ярый, бик яхшы, мин уңай рецензия язып бирермен.

Син телсез каласың: темасын, кайсы журнал икәнен сорамады — уңайны язам, ди.

— Ну бит, Гази абый, сез әле...

— Ә, син язгач, яхшы мәкалә булачагына шигем юк минем. Сал минем портфельгә, кайчанга кирәк...

...Аспирант тормышының иң кызык чоры — май, июнь айлары. Компания булып урманнарга баруны, Идел яры буенда учак ягып, фәнни җитәкчеләрең белән бергә таң аттыруны — барысы да була. Ул заманда әле курыкмыйча шәһәр читендә төн кунып, таң атканчы фән турында сөйләшеп урамнарда, паркларда йөреп була иде, ул чакларда милиция хезмәткәрләре сугыш, үтереш статистикасын җыеп кабинетларда кандидатлык диссертациясе язып утырмыйлар, ә турыдан-туры урамда тәртип саклыйлар иде. Ул чакларда әле «запросто» гына кичен ял паркына кереп йөреп була иде.

Әнә, кичә төнлә — июнь төне — физик Гаял математик Коляга кызлар турында озак сөйләп ятты да, керәшен малае төне буе уфылдап чыкты, йоклый алмады. Иртәгесен кайнар су белән «колбасный хлеб» ашап утырганда Гаял миңа әйтте: «Бу малайга шефлык итмиңә булмаңтыр. Бүген киң паркка алып барам да мин аны, шунда берәрцен мунцаклап тоттырам да, үзем кайтам да китәм».

Коля, беркатлы егет, «свидание»гә ярты көн әзерләнде. Үтүкләүме кирәк, ялтыратумы. Кичке җидедә алар, зур бер операциягә баргандай, дәү кубып чыгып киттеләр. Мин иркенләп картотекамны актарырга булдым. Сеняның тагын «теге» атнасы җиткән иде, ул боларның киткәненә артык игътибар бирмичә, артларыннан әйтеп калды:

— Дилетанты они оба, Мухаммет. И мы с тобой — дилетанты.

Шулай диде дә, карават астына үрелде.

Нәкъ ун минуттан Гаял кайтып керде.

— Вце,— диде ул,— паркка кереп тә тормадык. Шундук бер мәткәне тотып алып таныштым да, Николайны шуңа беркетеп китеп тә бардым.

Нәкъ ике минуттан, борынын салындырып, Коля кайтып керде. Бүлмәдә авыр тынлык урнашты, Гаял да герләрен куйды. Коля, чишенеп, сөлгесен алып юыныrга чыгып киткәч, Гаял әйтеп куйды:

— Һи-и, малай. Берәр җайцыз цүз әйткәндер теге мәткәгә. Бик чибәр иде. Мут иде.

Һәм ул, геометрик күзлегеннән чыгып, теге чибәрнең силуэтын — керенке, чыгынкы урыннарын бушлыкта ике кулы белән сызымлап күрсәтте. Шундый оста итеп — тегенең үзен күргәндәй булдык.— Юк инде, малай, точно: цөйләцә белмәгән. Керәшеннең акылы инде аның билгеле: керәле дә чыгале.

— А мы все дилетанты,— диде Сеня простынясе астына чумып.— Да, буквально все.

Аспирантураның икенче курсында мин математиклар бүлмәсенә туры килдем. Өчесе дә мәшһүр профессор Борис Михайлович Гагаев шәкертләре иде. Гагаев — зур галим, математика буенча зур хезмәтләре дөньяга билгеле кеше. Ул Себер һәм Урал югары уку йортлары өчен кадрлар әзерли. Әйтүләренә караганда, ул сиксәннән артык кандидат һәм егермегә якын доктор әзерләгән. Чын галим шундый булырга тиештер, шәт. Чөнки моның фани дөнья белән алыш биреше юк. Дөнья кууның нәрсә икәнен ул белми. Нәкъ Коръән хәдисендәгечә: әддөнья — җифәтен, вә талибыһа кәльбен, ягъни, бу дөнья — үләксәдер, аны куучылар — эттер.

Математиклар белән бер бүлмәдә яшәвемә мин бик шат булдым. Шулар дөньясына, шулар коллективына кереп киттем. Болар — бөтенләй башка дөнья, боларда бөтенләй башкача мөнәсәбәтләр. Әйтик, боларда фәнни җитәкче — алла. Фәнни җитәкче өчен аспирант — ясле баласы. Гагаев үз аспирантларының туган көнен, баласының, хатынының туган көнен белә, ул көнне аспирантка берәр бүләк китермичә калмый. Хәер, боларның «исәбе», диспетчерлык хезмәте — аның хатынында. Бәләкәй генә бу карчыкны кайчандыр бик чибәр балерина булган дип сөйлиләр. Аларның балалары юк, өйләрендәге тормыш та бик гаҗәп диләр: тәрәзә пәрдәләре урынына кнопка белән беркетелгән газеталар, урам ягыннан караганда болар сап-сары материал булып күренә, ә эчке ягын караган икән бер аспирант — «Красная Татария», ди, 1936 елгы саны, ди. Бәләкәй әби профессорны култыклап университетка алып килә, кафедрасына алып кереп чишендерә һәм тиешле аудиториягә кертеп җибәрә дә, үзе коридорда нәкъ сиксән минут басып тора. Шул вакыт аның янына аспирантлар килеп китә, әби аларга консультация урынын, көнен, сәгатен билгели, шул арада «Хатыныңнан хат киләме? Әниең терелдеме әле?»— дип сорап куя. Звонок булуга, аудитория ишеген ачып профессорга күренә, чөнки белә, үзе күренмәсә, карт шунсыз чыкмаячак. Әбине күргәч, тегесе исә ишеккә таба юнәлә, әмма танырлык та түгел: (аның чәчләре һәм берәр атналык сакалы ап-ак инде), ә монда бөтен пиджагы, чалбары да ап-ак. Чөнки профессор бер кулы белән тактага формула язса, икенче җиңе белән шуңа ышкылып, лекция беткәндә тегермәнчегә әйләнә дә бетә. Гагаев лекциягә конспектсыз керә, студент тыңлыймы аны, юкмы, килгәнме группа, әллә килмәгәнме — профессорның анда эше юк, рас аны әби аудиториягә кертеп җибәргәч, ул белем бирергә тиеш, калганында аның эше юк.

Бабайның киенү рәвеше дә бик кызык: хәлле аспирантлар, яшь доцентлар, урта яшьтәге профессорлар поляк, фин костюмнары, куртка-пальтолары белән шифыртланып йөргәндә, Борис Михайловичның өстендә төймә ялаулары (петля) ашалып, киңәеп, тузып беткән

бик нык «тотылган» драп пальто, башында сукно тышлы мутон бүрек. Егерме-утыз еллык. Ләкин ул бүрекне дә профессор үзенчә кия. Колакчыннарын өскә күтәргән, әмма бәйләмәгән. Шуңа күрә йөргәндә ул колакчыннар шактый нык тирбәлеп баралар. Ярый, монысы булды да ди инде, Ибраһим Гази да шулай кия бүрекне. Әмма Борис Михайлович бүреген... кашкасын янга куеп кия һәм колакчынның берсе маңгайда, икенчесе баш артында тирбәлә. Кайвакытта әби белән икәүләп алар китапханәнең «гыйльми хезмәткәрләр өчен» дигән уку залына килеп керәләр дә бабай китапханәче белән шау килеп сөйләшә башлый: залда утырган бөтен кеше гаҗәпләнеп күтәрелеп карый, монда бит кычкырып түгел, шыпырт сөйләшергә дә ярамый. Ә профессор үзенең югалган аспирантын эзли. Чөнки бер атна инде күренгәне юк. Табылса, ну әбидән эләгә инде аңа. Табалар: баксаң, аспирантның ерак өендә (Чиләбе, Новосибирск) хатыны авырып киткән, әлеге аспирантка күчтәнәчләр алып анда кайтып килергә кирәк, ә йөз сумлык стипендия белән әллә кая бара алмыйсың, бичара аспирант төннәрен вагон, баржа бушатырга йөри икән. Моны белгәч бетте инде: кичке якта тулай торак бүлмәсенә әби белән бабай килеп керә, аспирантны «эт итеп» сүгәләр һәм йөз, ике йөз сум акча калдырып чыгып китәләр. Әби:

— Смотри, Ванюша, бу әҗәт түгел, кайтарып бирү турында уйлама да,— ди.

Бичаралар... Алар нәкъ тә инде Гогольнең «Борынгы алпавытлар» әсәрендәге Пульхерия Ивановна белән Афанасий Иванович иде.

Борис Михайловичны университет ректоры Михаил Тихонович Нужин бик ихтирам итә иде. Соңрак миңа өч ел буе ректорат әгъзасы һәм Зур гыйльми совет әгъзасы булып «Югары эшелон» эшләрендә катнашырга туры килде. Шунда күрә идем: бик тә житди булган ректорат утырышы барганда берни белән дә исәпләшмичә бәреп кереп үз йомышын хәл итеп чыгып китүче бөтен университетына бер Гагаев кына иде. Андый вакытта Михаил Тихонович:

— Ни эшләмәк кирәк? Бик зур галим бит,— дип кенә куя иде.

Борис Михайлович үлгәч, әби ялгыз калды. Ләкин университетка йөрүен туктатмады. Карты лекция укыган аудиторияләр янында сәгатьләр буе басып тора, звонок булуга аудитория ишеген ачып, карты чыкмасмы дип көтә иде. Шулай бер-ике ел йөрде. Математик хатын-кызлар, лаборанткалар аның ишек янында басып торганын күреп күзләрен сөртеп алалар иде.

И бу дөнья! Соңгы тапкыр әбине мин Ленин урамында күрдем: җәйнең эссе көне. Әби бик иске җәйге пальто кигән, башында хан заманыннан калган чепчик. Аякларында иске ботинка, калын оеклар. Ләкин... бер оегы тубыгына кадәр сыдырылып төшкән. Ул ирен, бердәнберен эзләп университетка таба бара иде. Шунда Гоголь сүзләре искә төште:

— Скучно на этом свете, господа!

## II

*Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,*
*Шунда әүвәл Коръән аятен укыган,*
*Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәдне,*
*Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.*

Г. Тукай

Ул елларда университетта үз эшенә фанатикларча бирелгән «иске тип» профессорлар байтак иде. 1966-1969 елларда университетның берләштерелгән профкомы председателе булып эшләгәндә

мин болар белән шактый аралашу бәхетенә ирештем. Болар — математиклар Б. Л. Лаптев, А. П. Норден, биолог В. М. Марков, Н. А. Ливанов, юрист А. Т. Бажанов һ. б. Әлбәттә инде аралашу фән өлкәсендә түгел, минем белән алар арасында мондый мөнәсәбәт мөмкин дә түгел. Ләкин мин боларның сәламәтлеген кайгыртырга тиеш, санаторий путевкалары, һәрхәлдә, минем имзасыз бирәүгә дә бирелми. М. Т. Нужин миңа әдәп белән генә гел искә төшереп тора: анда фәлән-фәләнич кермәдеме әле сезгә, аңа «Васильево» кирәк икән, ди. Белеп торам инде, теге карт гвардия, бөтенләй таныш булмаган бер татар егете янына кергәнче, башта ректор янында булып чыга. Трускавец, Кисловодск-фәлән кирәк булганда турыдан-туры облсовпрофка элемтәгә чыгабыз, конкрет фәлән кеше өчен дип сорыйбыз. Болар гаҗәп әдәпле, культуралы кешеләр. Борис Лукич Лаптевка телефоннан хәбәр итсәң: шундый-шундый путевка бар, дип. Ул әйтә: хатыным белән киңәшим, врачым белән сөйләшим, бер тәүлек вакыт бирегез, ди. Икенче көнне телефоннан әйтсә дә була инде, юк бит, профкомга килә:

— Сезгә игътибарыгыз өчен зур рәхмәт. Мин бара алмыйм,— ди.

Николай Александрович Ливанов кышкы суыкта гел кепкадан йөри. Профессорның кышкы пальто кигәнен күргән кеше юк. Яше байтак — сиксәннең аръягы. Аңа бик кырын карыйлар: ул дөньяга мәшһүр ботаник, университет галимнәре арасында Октябрь революциясенә кадәр үк профессор исемен алган бердәнбер кеше. Кырын карауның сәбәбе: 1919 елда, большевиклар фәнне харап итәләр, дип Америка галимнәренә күмәк язылган хатка ул имза куйган, имеш, андыйны онытмыйлар.

Профессор Александр Петрович Норден — үзе бер дөнья. Зур гыйльми совет бара (төп бинада, амфитеатрлы мәһабәт залда, биофак залы). Түрдә химия, биология аудиторияләрендә генә була торган бик озын, киң өстәл. Совет барганда ул өстәлнең артында ректор, ике проректор гына утыра. Менә фикер алышулар вакытында профессор Норден сүз ала. Тора, папиросын каба, кабыза, ике кулын артка, биленә куеп бераз бөкрәя төшә дә шул өстәл алдында аркылыга йөри-йөри сөйли башлый. Ни президиумга карау юк, ни аудиториягә. Шулай йөри-йөри теге өстәлнең артына да кереп китә, арттан да берике буй буйлый, йөри торгач ачык ишектән чыгып ук китә, үзе әле һаман сөйли — төпчеген ташларга чыгып киткән икән — керешли дә сөйли.

Михаил Тихонович мондый галимнәргә искиткеч зур ихтирам саклый һәм һәрвакыт аларның кадерен белергә чакыра иде. Дөрес, университетта яшәп килгән мондый академик атмосферага югарыдагы бюрократия аяк чала. Бюрократиягә слетлар, комсомол конференцияләре, профсоюз активы җыелышлары, ә күбрәге — отчет-кәгазьләре кирәк. М. Т. Нужин торгынлык бюрократиясеннән аеруча җафа чикте, өлкә комитетыннан кайткач, гел дару эчә, авырып егыла иде. Бер-ике көн авыргач, иртән ректорат җыя, рәсми өлеш алдыннан дөнья хәлләрен сөйләшеп алалар. Мин яшь, тыңлап кына утырам. Ректоратта М. Т. Нужиннан кала иң зур дәрәҗәле кеше — татарлардан астрономия буенча беренче профессор Шәүкәт Хәбибуллин, фән эшләре буенча проректор. Ул — буйлы, чибәр, һәр кичне диярләк физика факультеты студентлары белән спортзалда баскетбол, волейбол уйный, ә М. Т. Нужин авырудан иза чигә.

...1964 елның җәендә, ял вакытында мине, ничектер инде, телефоннан эзләп таптылар.

— Никита Сергеевичны каршы алучылар исемлегенә кертелдегез, факультеттан нибары уникe кеше, инструктажга килегез,— диделәр.

Барсам — гаҗәпкә калдым. Инде бер атна элек үзәктән кешеләр килеп университет ишек алдындагы чардакларны, бөтен подвалларны,

күрше йортларның чормаларын тикшергәннәр, бөтен әйләнә-тирәне күзәтү астына алганнар икән. Университетның арткы ишеге бикләнгән, алгы ягына өстәмә сак куелган, аларның кулында исемлек, анда бу бинага керергә хокукы булган кешеләрне әллә ничә инстанциядә тикшереп раслаганнар (һәр чиновникка нинди дә булса эш кирәк бит! Ипи ашаганны акларга кирәк бит!) икән.

Мин үземнең (әле «несчастный» ассистент) бу зур дәрәҗәгә ничек ирешкәнемне тиз аңладым: ял вакыты, кешене каян табасың, ә мин тулай торакта яшим, вахтер аша табып була. Шулай, мин норма тутырыштым.

Иртәгесен университетка җыелдык. Шәһәр урамнары себерелгән, халык тротуарга тезелгән, предприятиеләр эшләми. Казан шәһәренә ничә миллионга төшкәндер ул көн, белмим, халык сөйләде: иске аэропорт белән шәһәр һәм Матюшино арасында ГАИ һәр төнне репетиция уздыра икән. Иртән пропусклар белән, исемлеккә билге куйдырып, университет эченә тулдык. Котчыккыч киеренкелек, курку катыш каушау хөкем сөрә иде. Көн эссе булуга карамастан, бөтен ирләр костюм, галстуктан. Миңа үзебезнең факультетның партоешма секретаре кисәтү ясады: мин, җиңен сызганып Кытай күлмәге «Дружба» гына кигән идем. Колонналар янындагы ишек ике якка да киң итеп ачылган һәм андагы өстәл өстендә аэропорт белән туры элемтә аппараты куелган иде. Вестибюльдә агитаторлар кат-кат әйтеп йөрделәр: Актлар залында очрашу вакытында сораулар бирмәскә, Никита Сергеевичка якын килмәскә, букет бирмәскә. Һәм инде, алла сакласын... букет ыргытмаска (эчендә нәрсә булмас?). Язу бирмәскә. Сөйләгәнен тыңларга һәм кул чабарга! Төш вакыты җитте. Комсомол комитеты секретаре Владимир Николаевич Одринский телефоннан алынган хәбәрне ректорга әйтергә йөгереп кереп китте: хөкүмәт самолеты инде — һавада, һәм берничә минуттан Казан аэропортына төшәчәк. Ниһаять, тагын Одринский йөгерә: машина аэропорттан чыккан да, безгә таба юнәлгән. Бөтен җитәкчелек колонналар янына чыгып басты. Без дә ачык ишекләр аркылы урамга карап торабыз. Менә, менә... Тыннар кысылды, йөрәк типкәннән колонналар селкенә сыман. Менә котчыккыч гөрелдәү тавышы, колонналар яныннан метеор булып бер машина уза, ике, өч, һәм... ачык зур машинада күреп калабыз: ак костюм кигән, зур таза битле, төп шикелле нык Хрущев кул белән университетны сәламләп выжылдап узып та китте. Халык «аһ» итте, бик зур гәпләр — фаразлардан соң гына таралдык. Иртәгесен һәм атналар буе истәлекләр, имеш-мимешләр сөйләү китте. Менә кайберләре: М. Т. Нужин әлеге хәлдән үзенчә нәтиҗә чыгарган. Өлкә комитетында идеология бүлегендә аны яратмыйлар. Әнә шул яратмауны конкрет белдерү өчен, Ленин укыган бердәнбер университетка үзен «ленинчы тип җитәкче» дип игълан иткән Хрущевны алып кермиләр. Бу — очраклы хәл түгел. Ректор иртәгесен больницага кереп яткан, имеш.

Н. С. Хрущев университет колонналары яныннан выжылдап узып киткәндә аны каршы алуны университетта атна буе оештырып арган, аяксыз калган егет җан ачысы белән бер сүз әйткән:

— И-и-х, ... ь! — дигән.

Аны шундук җиңеннән тотып билгесез ике егет бер читкә алып киткәннәр һәм инде ул элеккеге эшендә эшләми имеш.

Хәтерлим, Казан шәһәре икенче көнне дә юньләп эшләмәде. Олы кунакны озатасы бар иде. Аэропортка узганын очраклы рәвештә Әбҗәлилов тукталышында күреп калдым. Миңа ул кәефсез күренде. Казанның матди хәле бик авыр, иң гадәти әйберләр — булка, сөт кебек ризыклар кысылган, сөткә чиратны иртә таңнан аласы, сәгатьләр буе чират торасы иде. Шәһәрдә төрле хәбәрләр йөрде: имеш, университет каршындагы Володя Ульянов һәйкәле төбендә бер язу тапканнар: «Володя, проснись, Никитой займись». Булырга мөмкин, чөнки газета-

ларда, бигрәк тә «Известия»да беренче биттә инде Хрущевның үзен генә түгел, оныкларын да төшерә башлаганнар иде. Газеталарда ул вакытта өч кенә төрле рәсем була иде: Никита Сергеевич; кукуруза; дуңгыз баласын кочаклап, йә сыпырып, йә үбеп төшкән хатын-кыз.

Сентябрь ахырлары иде, мине факультет буенча Октябрь бәйрәме комиссиясе рәисе итеп билгеләделәр. Бәйрәм демонстрациясе уздыру ул заманнарда җәмәгатьчелекнең төп энергиясен суыра торган эш иде. Әйтик, райком, горкомның идеология бүлеге бер-ике ай буе бары тик шуңа хәзерлек эше белән генә шөгыльләнә. Бу юлы да шулай булды. Университет комиссиясе председателе, хәрби кафедра полковнигы факультетка килде дә портретлар, транспарантлар әзерлеген тикшерде. Шулар саклана торган склад-бүлмәгә кердек. Полковник блокнотын чыгарып тикшерә, билге куя башлады:

— Никита Сергеевич Хрущев? Есть. Галочка. Алексей Николаевич Косыгин? Есть. Анастас Иванович Микоян? Есть. Леонид Ильич Брежнев. Есть...

Шулай портретларны барлап чыкты да, тагын бер килермен дип, кайбер күрсәтмәләр биреп, пуф-пуф килеп чыгып китте.

Шәһәр бәйрәмгә әзерләнә, әмма гастрономнар күсе аягын сындырырлык дәрәҗәдә буш иде. Халык ачуын эчкә йотты, бөтен кеше газетаның яңа санын кулына алган саен Хрущевны, кукурузаны сүкте. Кибеттән булка ала алмыйча бала янына кайткач (без инде студентлар тулай торагының бер бүлмәсен алып яши идек) ачу белән хатынга әйттем:

— Шушы Хрущевны алып ташласалар, нәзер итеп әйтәм, сиңа йон кофта алып бирәм,— дидем. Никита Сергеевичның төрмәләрне ачканын, канибал Берияне юк иткәнен, нахакка һәлак ителгән этиемнең намуслы исемен кайтарганын оныттым. Димәк, миндә әле тормышның ачы тәҗрибәсе юк. Иртән хатын уята:

— Тор әле, тиз бул, соңгы хәбәрләр тапшырдылар, Хрущевны алып ташлаганнар,— диде.

Йокыдан шактый авырлык белән торучы мин — шундук сикереп аякка бастым.

— Чынмы?

— Әнә инде, әнә ЦКның пленумы булган...

Хатын шул атнада ук теге «нәзер» мәсьәләсендә мине китереп кысты. Нихәл итәсең, авызыңнан кара кан китсә дә сынатмаска өйрәнелгән, илле таңкәне чыгарып бирергә туры килде.

Нәкъ бер көннән соң факультетка бәйрәм комиссиясе председателе, әлеге дә баягы полковник килде. Теге бүлмәгә уздык, полковник блокнотын чыгарып тагын портретларны тикшерә башлады.

— А этого дурака убрали? — диде ул, исемен әйтмичә генә, блокнотындагы «Н. С. Хрущев» дигән сүзгә ручкасы белән төртеп.

Алдык, алып куйдык инде, иптәш полковник. Нигә алмаска? Радио бит инде икенче тәүлек күпме пычрак коя ул бичараның такыр башына. Хрущевның портреты башы аска каратып арт ягы белән тузанлы почмакка сөялгән иде.

Аннан демонстрация булды. Колонналарның башында зур полотнода куе кара кашлы, юмарт игелекле битле, изге чырайлы, Леонид Ильич Брежнев иде — инде дә шәһәр рәссамнары бу айда акчаны көрәпләр алды! Колонналар шуны күтәреп алга, коммунизмга таба, Ирек мәйданы аша атладылар. Ләкин бер «ЧП» булмады түгел: кайсыдыр институтта, КАИ дип хәтердә калган, бәйрәм комиссиясе председателе зирәклек күрсәтмәгәнме, әллә студент халкы шуклык эшләгәнме, Ирек мәйданына җиткәндә генә колонна өстенә Хрущевның портретын күтәрделәр. Бичара. Казан шәһәрендә соңгы күренүе иде аның. Шундук теге колоннага милиция капитаннары, майорлары ташланды, портретны суырып алдылар да, рәхимсез өстерәп, Карл Маркс ура-

мындагы бер йортның ишек алдына алып килеп киттеләр. Ахырдан бу институтның җитәкчеләренә шактый эләккәндер, дип уйлыйм мин.

Демонстрация бетте, халык өенә таралды, университетның профком председателе оркестрларны үз бүлмәсенә чакырды. Барладылар: труба, тромбон, саксофон һ. б. исән-сау тапшырылды.

— Рәхмәт сезгә, орлы, подводить итмәдегез, мәгез, вәгъдә ителгәнне алыгыз.

Һәм, сейфтан ярты литр чиста спиртны алып, студент егетләргә тоттырды. Спиртны өч көн элек, химия факультеты профбюро председателен кысып, кан-яшь елатып алган иде ул.

Тормыш икенче җайга, икенче төрле сөйләшү-аңлашуга, икенче төрле мөнәсәбәтләргә кереп бара иде. Әле беркем дә егерме бер ел үткәч артка әйләнеп карап, Хрущевның кешелеклелеген сагынып искә аласын күз алдына китерми, уйлап та карамый иде. Моны аңлау өчен исә тормышның ачы тәҗрибәсе булу кирәк иде. Без, үзебез белмәгән көе, «торгынлык»ка кереп бара идек.

## III

*«Татарның мәгыйшәтен асылыннан сүтеп төзәтергә кирәк! Безгә аның урынына яңа мәгыйшәт кирәк; әүвәлдәге наданнар урынына галим вә зыялылар, әүвәлдәге мөтәгассыйблар[1] урынына ачык фикерле вә яңа хәрәкәтләрне алып баручылар, әүвәлдәге үз кулларында булган нәрсәләрне дә ычкындыручылар урынына һөнәр вә сәнагатьле, мәгыйшәт сугышында мәгълүб булмаслык татарлар кирәк!».*

Ф. ӘМИРХАН

Яңа чор башланды.

Борынгы кабилә аталары сүзләрен йомгаклаганда:

— Мин әйттем,— дип бетерә торган булганнар. Алар өчен бу инде, һичшиксез, «үз сүземә үзем җавап бирәм», дигән мәгънәне аңлаткан. Ләкин без кергән яңа чорда моның без табынырга тиешле «мин әйттем» дигәне генә калды. Без әлегә белмәгән, аңламаган «торгынлык» дип аталачак чор башланды. Яңа диссертацияләр агымы башланды. Хрущевны телгә алган диссертацияләр яклау алдыннан гына яндылар. Булачак кандидатлар, докторлар больницаларга ятты, инфарктлар, инсультлар көндәлек хәбәргә әйләнде. Тарихчылар, политэкономистлар, әдәбиятчылар, философлар пачкасы-пачкасы белән «яндылар». Минем таныш математиклар — Гагаев аспирантлары хәтәр елмаеп йөри башлады.

— Ә, шулаймы? Фән, гыйлем беркайчан да хөкүмәт алмашынуга карап үсәргә тиеш түгел. Фәннең үз законнары бар һәм әгәр ул сәяси партиягә буйсынса — үлә, бетә. Борис Михайлович безне шулай тәрбияләде.

Чыннан да, сәясәткә, тарихка, бигрәк тә, Ватан сугышы тарихына, критерийлар үзгәрде, тарихчылар, әдәбиятчылар, язучы-журналистлар буталып беттеләр, ә Ньютон биномы, Ом законы, Ландау теориясе, Эйнштейн ачышы шул көенчә калды.

Тарих, филология өлкәсендә, идеологиядә корбаннар китте. Моны өлкә комитетының идеология бүлеге башында торучылар үзләренә бер геройлык санап алга таба өстерәделәр, яңа корбаннар сорадылар.

КПСС тарихы буенча эшләүче галим Әдгас Борһанов тарихта яңа критерий белән чыкмакчы булган иде, өлкә комитетыннан башына

---

[1] Мөтәгассыйб — иске фикерле, катып калган фикерле. Сәнагать — промышленность, мәгълүб — җиңелгән.

суктылар. Докторлык диссертациясе янды. Университетның чираттагы партия конференциясендә ул үзен яндыруда катнашкан М. Вәлиев белән трибунада бәреште.

— Сез минем идеологик дошманым,— диде Әдгас аңа мөрәҗәгать итеп.— Сез — минем докторская диссертациямне харап итүчеләрдән берсе.

Каты әйтте, теге иптәшнең өлкә комитеты алдында дәрәҗәсе төшәрлек итеп әйтте. Йә, кайткач, тегендә, бюрода, нәрсә дип информация ясарсың? Ә-ә, әле син университетка барып, рядовой бер коммунист белән сөйләшеп тә, партия принципларын яклый алмадыңмы? Алайса, без сине бу эштән азат итик...

Иптәш күз алдына китерә: иртәгә ул махсус складтан, шәхси транспорттан, махсус ашханәдән, поликлиникадан, гомумән, оҗмахта яшәүдән мәхрүм ителә. Юк, болай ярамый. Һәм Борһановка әйтә:

— Сезнең мине дошманым дип санавыгыз белән, өлкә комитеты секретаре буларак, мин горурланачакмын...

Ә тарих болай: диссертациясендә ул Октябрь революциясендә эсерлар да актив катнаштылар дип язган. Өлкә комитетындагы бер иптәш (үзе дә кандидатлык яклаган) М. Т. Нужин, Ш. Т. Хәбибуллин, Р. И. Нәфиков һәм партком секретарен чакырып «мунча» оештырган.

— Сез анда эсерларны яклап ятасызмы? — дигән.

Нужин әйткән:

— Бу сезнең фикерме, әллә Үзәк Комитетныкымы?

Аппаратчик әйткән:

— Бу — минем фикер.

Нужин аңа болай дигән:

— Ах син, юньсез! Син кем белән сөйләшәсең...

Шундый заманнар килде. (Мин боларны язганда Борһанов инде күптән профессор, Мәскәүдә яши, АПНда. «Московские новости» газетасында Борһанов — «үз кеше». Талантлы кеше, әгәр аны физик яктан үтермәсәләр, берничек тә әрәм булмый, югалмый).

Без әле аңлап бетермибез, идеология өлкәсендә яңадан Сталин чорына кайта башлаганбыз. Һаман әле «Идегәй эпосыннан, Гаяз Исхакый исеменнән дер калтырап куркып, университетның татар бүлегендә «дебил»лар хәзерлибез. Идеология өлкәсендә рухи юлбашчыбыз — Салих Батыев. Ул — татар филологиясе буенча, тарих буенча — доктор, академик. Ул — корифей.

— Иптәш Батыев болай дип әйтте...

— Менә мин кичә генә Салих Гыйлемханович янында булдым...

Аның янында булып кайткан кеше ул көнне берәр җыелыш җыймый калмый инде. Ә ул әйткән: безнең дошман — Гаяз Исхакый, дигән. Йосыф Акчура, төрек полковнигы погоннары тагып, 1942 елда безнең чикләрне үтәргә маташты, дигән. Безнең дошманыбыз — Али Акыш, ул безгә каршы китаплар яза, дигән. Безгә, дигән, интернациональ гаиләләр төзергә кирәк, әнә, дигән, татарның фәлән композиторы, рус хатынына өйләнгән, балалары тугач аңа «Иван» дип исем кушканнар. Бу бит — безнең илдә генә булырга мөмкин! Моңа ничек шатланмаска!

Тарих, әдәбият фәнендә халык тарихын сату, спекуляция башланды. Әдәбият — тел кафедраларының эшчәнлегенә КГБ килеп керде һәм актив рәвештә катнашты. Кафедра җитәкчеләре моңа тез чүгеп риза булдылар. Дессертацияләр яклау, доктор булу өчен гыйлемнән ерак булган ярыш, көрәш башланды.

Тулай торакка яшь шагыйрьләр белән очрашырга Роберт Батуллин килгән икән. Очрашу тәмамлангач, бер студент аны бүлмәсенә чакырган. Шешәсез булмагандыр, анысына гарантия бирүе кыен, ләкин бит бүлмәне эчтән биклəп сөйләшеп утырганнар. Нәрсә турында? Лео-

нид Ильич турында тәнкыйть сүзе әйтмәгәннәрме? Социализмның экономикасы, үсеше турында сүз булмаганмы? Китте тикшерү, китте «идеологик диверсия» эзләү. Кафедрада шул, партгруппа җыелышында — шул. Зуррак җыелышларга да китте бу мәсьәлә.

Торгынлык чорында Сталин исе килә башлады.

Ул арада торгынлык чоры КГБсыннан миңа карата ике-өч «дәшү» булды.

Беренчесе болай. Хәер, нигә әле миңа? Нигә бүтән кешегә түгел? Бөтен хикмәт шунда ки, мин 1968 елгы әдәбият-сәнгать-тарих мәсьәләләре конференциясендә бераз яңачарак чыгыш ясап «сталинист»ларга тәнкыйть фикере әйткән идем. Мин әле белми идем: сталинизм яңадан баш калкытып ята икән бит! Шул конференциядәге чыгышымнан соң, мин инде аңладым, югары оешмалар алдында «кара исемлек»кә кердем. Ике диверсия ясадылар: көннәрнең берендә химкорпусның 97-нче бүлмәсендә (ул безнең кафедра иде) миңа адресланган хат табыла. Почта белән килгән, кем язганын күрсәтмәгәннәр. Адрес гадәттән тыш төгәл. Түгел «химкорпус» дип кую гына, ничәнче кат, кайсы бүлмә икәнен, исем-фамилияне дә гадәттән тыш төгәллек белән күрсәткәннәр. Конвертны кулга алам — карт кеше язуы. Төгәллек, хәрефләрдә бераз гына искелек, аз гына калтыравык кул. Ачам. Гарәп графикасында язылган озын хат. Татар милләтенең аянычлы язмышы һәм моннан чыгу юллары турында. Ул елларда «милләт» сүзе — котчыккыч бомба! Ул — Хиросима, Чернобыль! Хат авторының конкрет тәкъдиме бар: «Алдагы пәнҗешәмбедә сәгать 15-16 арасында, сез эшли торган үзәк урамдагы «Ял» кафесына кергәч, сулдан икенче өстәл янында йөзем шәрабы эчеп утыручылар сезне милләт мәсьәләсен хәл итү өчен сөйләшүгә чакыралар». Бу — провокация иде һәм мин, әлеге хатны тотып, КГБ офицерына килдем. Ул әлеге хатны укырга да теләмәде. Кара-каршы утырганда ул хатны никадәр генә аңа таба борсам да, ул әлеге хатка күз дә ташламады. Әлеге офицерның гарәп графикасында укый-яза алганын белә идем. Шунда мин әйттем:

— Иптәш подполковник, моның срогы бит иртәгә, барыйм әле, күрим әле шул кешеләрне. Теләсәгез, сез мине күзәтү астында тота аласыз бит...

Ләкин подполковник әйтте:

— Слушай, без сезне татар әдәбияты өчен бик кирәкле кеше дип беләбез. Дөресен әйтим, сезнең бөтен поведениегез безгә мәгълүм (мин дерелдәп алдым). Сез — яшь кешесе. Неужели сез, вакытыгызны әрәм итеп, шушы бездельник, маразматиклар янына барып йөрисез?

Мин аңладым, мин «кара исемлектә» һәм күзәтү астында идем. Бераздан минем Гали Рәхим турындагы мәкаләм кергән университет җыентыгын сүтеп ташлыйлар; аннары, «Иж-Буби» мәдрәсәсенә багышланган мәкаләм басылып чыккач, гомумән, «ышанычсыз»лар рәтендә йөри башлыйм.

Кафедрада миңа «марксизм-ленинизм буенча әзерлеге юк» дигән кара тамга тагыла. Үземнең философиядән кандидатлык минимум биргәнне яхшы хәтерлим. Комиссия председателе — Л. Л. Тузов, әгъзаларның берсе — трагик язмышлы Д. М. Пронин иде. Миңа «Материализм һәм эмпириокритицизм» әсәре эләкте. Бөтен тирәнлеге белән үк аңлап бетермәсәм дә, бу әсәрнең язылу тарихын, Богданов, Бернштейннарны, Ленинның концепциясен мин әйбәт белә идем. Кызып китеп сөйләгәндә Пронин акыллы күзләрен Л. Л. Тузовка юнәлтеп:

— Леонид Леонидович, бик әйбәт сөйли бит, нигә вакыт әрәм итәбез? — диде. Миңа философиядән «бишле» куйдылар. Ә бераздан бәхетсез Пронин авырып китте. Сталин, лагерьларын күрсәң, әзсез калмаган. Дмитрий Михайлович һәм аның хатыны икесе дә репрессиягә эләгәләр. Бердәнбер малайларын «ЧСР» дип билгеләп (член семьи

репрессированного) балалар йортына озаталар. XX съездан соң ПронинНар Казанга кайта. Сталинга, партия җитәкчелегенә бик нык рәнҗегән марксист Пронин партиягә яңадан керү, торгызылу турында кайгыртмый. Аны университетка эшкә алмыйлар; ул, Зеленодольск ягына китеп, китапханәче булып эшли, бераздан университет китапханәсенә хезмәткә керә. Балалар йортыннан малайны эзләп алып кайталар. Егетнең бөтен тәне татуировкадан гына тора. Проникнар шәһәрнең Некрасов тыкрыгында котчыккыч авыр шартларда яшиләр: түшәмнән су ага, кышларын өйдә җылылык сигез градус. Малайның ике аягы бозылып, аңа, ампутация ясыйлар, бераздан ул үлә.

Гомеренең соңгы елларында гына Дмитрий Михайловичка квартира бирәләр, кафедрага эшкә алалар, ләкин — соң инде...

Ни гаҗәп: 1979 елда чыгарылган «Казанский университет» дигән альбомда Дмитрий Михайлович Пронинның фамилиясе юк.

Милләт сатканнар — бар.

Минем үз гомеремдә алган бик күп «билге»ләрем арасында иң кадерлесе — философиядән Пронин куйган «бишле».

Андый галимнәр, минем аңлавымча, университетта бетеп баралар иде инде. Һәрхәлдә, теге иске, академик мәктәп кими, саега бара.

Инде мин, күпмедер еллар узгач, «Марксизм-ленинизм теориясендә надан» дигән сүзне күтәреп яшәргә мәҗбүр булдым. Мин ялгыз калдым. Сабакташ дусларым юк (мин монда читтән килгән) югары оешмаларда ни баҗай, ни авылдаш юк. Ялгыз — вәссәлам! Борынгы шәрыкъ шагыйре Бәделнең сүзләре миңа бик тә туры килә иде. Аллага дәшеп ул болай дигән:

«Бер тактага гына утыртып дүрт диңгезнең арасына агызып җибәргәнсең дә, «итәгеңне юешләтә күрмә, һушъяр бул» дип әйтәсең».

Менә сиңа мә, «һушъярлык»!

Торгынлык еллары башланды. Бу еллар һәркемгә үзе булдыра алганча ачылырга мөмкинлек бирде. Торгынлык еллары, лакмус кәгазе кебек, кешеләрне ачты. Бу еллар катализатор булды. Кешеләр бик нык үзгәрде. Тарих, филология, философия өлкәсендә татар галимнәре берсен-берсе батыра, сата, әләк яза, яклау процессларына комачау итә башладылар. Надан «галимнәр» барлыкка килде. Милләт, халык мәнфәгатьләрен сатып карьера эшләү гадәткә керде. «Язгы җылылык» елларында байтак игелекле эш эшләгән язучылар, журналистлар, галимнәр элеккеге идеалларыннан баш тарттылар.

Безнең кафедрада исә алдагы егерме биш елга перспектив план төзелде. Ул план буенча безнең фәнни кадрлар, аспирантлар бездә түгел, ә Лейпцигта, Берлинда, Таһранда әзерлек алырга, Һейне, Шиллер иҗатын турыдан-туры укып татар поэзиясенә мөнәсәбәтле тикшерергә, Иран университеты кафедраларында аспирантура узып Гомәр Хәйям, Сәгъди, Рудаки иҗатларын фарсыча укып, татар әдәбиятына килеп чыгарга тиешләр иде. Кыскасы, үзебезнең китапханәдәге төплэм-төплэм элеккеге газета-журналларны, архив материалларын өйрәнмичә, зәгъфран үсә торган илгә гыйльми сәяхәтләр ясау күздә тотыла иде. Зәгъфран иле! Изге җирләр! Мин сезне шулкадәр яратам!

Беренче тапкыр зәгъфран иле белән мин 1953 елда таныштым. Үзенә барып түгел, ә бөек шагыйрь Сергей Есенин иҗаты аша. Хәтерлим: Сталин үлүгә, бер ай уздымы икән, хәрби корабльләрдә аврал вакытында Лидия Русланова җырлары яңгырый башлады. Корабльдә шулай — аврал вакытында «җанга тәэсирле» җыр тапшырылырга тиеш, аврал дигән авыр, юеш, шактый пычрак бер эштә музыка тавышы сиңа ярдәм итәргә тиеш. Лидия Русланова белән берлектә корабль малайлары арасына Сергей Есенин дигән бер шагыйрь килеп керде. Сталин чорында мәктәптә шулай иде: Маяковскийны мактыйсың-мактыйсың да, Есенинны, укымаган көе гене, сүгәсең. Дәреслекләрдә гел

шулай иде: нормаль генә хәрефләр белән бара да текст, кинәт вакка күчә: «Есенин мәктәбен» сүгәсе. Ул еллардагы дәреслек авторлары, әгәр алар бүген дә исән булсалар, һәм акылларында булсалар, оятларыннан үз-үзләрен үтерергә тиеш дип исәплим мин.

Әйе, Есенин. 1953 елда машинкада басылган кәгазь белән кинәт килеп керде ул безнең арага. Бәреп. Снаряд булып. Без ул шигырьләрне күңелдән ятладык. Хәтердә иң нык уелып калганнары — «Иран көйләре» («Персидские мотивы») иде. Анда зәгъфран иленең зәңгәр кичләре, сихри лалә чәчәкләре, җылы җилләр, исерткеч шәрыкъ мәхәббәте турында сүз бара иде.

Менә хәзер кафедрада шул илгә бару турында план корып ятабыз. Зәгъфран иле! Мөмкин булса, иң беренче булып мин китәм сиңа...

Свет вечерний шафранного края,
Тихо розы бегут по полям.
Спой мне песню, моя дорогая,
Ту, которую пел Хаям.
Тихо розы бегут по полям.

Мин «үз университетым» белән саубуллашам. Рәхмәт сиңа гали уку йорты! Син миңа тормыш мәктәбен, яшәү тәҗрибәсен бирдең. Синдә минем фәнни телем ачылды. Чын галим белән синтетик, «заманча» ясалма докторлар, кандидатлар арасындагы аерманы күрергә синдә өйрәндем. Мин синдә яңадан тудым.

Оглянись, как хорошо кругом:
Губы к розам так и тянет, тянет.
Помирись лишь в сердце со врагом —
И тебя блаженством ошафранит.

Хөрмәтле укучы! Менә мин хәзер шушы урында туктап торам. Бу истәлек – повестьның беренче өлеше шушының белән тәмам. Карале, җир йөзендә күпме юньле кешеләр яшәгән бит! Һәм һәрберсе үзенчә, үз яхшылыгы, үз кимчелекләре белән яшәп дөньядан киткән. Дөрес, монда язылган шәхесләрнең бер төркеме әле дә җирдә яши, әле дә Казан асфальтына басып йөри. Ләкин дөнья үзгәртте аларны, бик нык үзгәртте. Бу повестьның икенче яртысында әнә шундый шәхесләр турында сүз булмый калмас әле. Укучы! Алда язылганнар — минем шәхси уйларым, шәхси күзәтүләрем. Шәхес исә бик сирәк очракта гына объектив була ала. Ләкин әдәбият — шәхси уйлардан торырга тиеш. Югыйсә, автор буларак, мин — нигә?

Шулай, үзем яраткан югары уку йортыннан сиксәненче елларда тәмам күңелем кайтып китеп барам мин.

«Карету мне, карету!»

*1987—1989, Абхазия*

## Гарифҗан Мөхәммәтшин

### ТӘРӘЗӘЛӘР ЯЗГА КАРЫЙ

❁

Тәрәзәләр язга карый,
Тәрәзәләр яз көтә.
Тәрәзәләр шуңа якты —
Аларны яз ярсыта,
Тәрәзәләр яз көтә.

Язга баккан тәрәзләрдә
Ал чәчәкле яраннар...
Күңелемдә язын кабат
Уянасы ярам бар...

Ал чәчәкле яраннар.

### Аерылмыйк сөюдән

Төн килде дә гашыйк саен
Берәр йолдыз өләште,
Һәр гашыйк үз йолдызына
«Сөям» диеп эндәште.

Нәрсә булды йолдызларга,
Артты мәллә утлары?
Таралды да юкка чыкты
Төннең кара утлары.

«Сөям» дигән шул изге сүз
Төнне аклыкка төргән...
Һәм изге мәхәббәт хисе —
Җанны яктырта торган.

Күктә яңа йолдыз туа,
Сөеп, «Сөям» диюдән,
Күкләр якты булсын, дисәк,
Аерылмыйк сөюдән,
Аерылмыйк сөюдән!

---

ГАРИФҖАН МӨХӘММӘТШИН *(1941) — шагыйрь, «Килегез, дусларым», «Уеннан уймак» исемле шигырь китаплары, популяр җырлар авторы. Балтачта яши.*

❋

Исеменне уйдың йөрәгемә —
Каен кәүсәләрен телгән кебек.
Ә каеннар шундый шауладылар —
Ни буласын алдан белгән кебек...

Ә каеннар, бәлки, белмәгәндер,
Миңа гына шулай тоелгандыр,
Яфраклары җәрәхәттән түгел,
Күз җиткәнгә генә коелгандыр.

Җәрәхәттән түгел, күз җиткәнгә,
Күзгә җилләр әче булган өчен...
Мин рәхмәтле сиңа — гомер юлым
Яктыртырлык яшен булган өчен.

❋

Күкчәчәкләр үрелеп карый
Арышлар арасыннан,
Таныйлардыр алар мине
Күзләрем карасыннан.

Таныйлардыр, дәшәләрдер:
— Кая китеп барышың?
... Учларымда уып кайттым
Бер башагын арышның.

❋

Басынкыланды күңелем,
Гүя күзгә урман ул —
Уе башка, гаме башка,
Ярсып купмый зурдан ул.

Белә: яшьлектә кизәнгән
Зур эшләре бетмәгән...
Узган гомерем — сослымнарга
Куелмаган көлтәләр.

❋

Син ул чакта киләчәктә идең:
Ак томанлы язгы таңнарда,
Төшләремә минем керә идең,
Былбыл булып кунып талларга,

Ә хәзер син үткәннәрдә инде:
Төшләремә минем кермисең.
Күз алдыма килеп басасың да...
Йокы гына бары бирмисең.

❋

Каен сиртмә, кайры бишек —
Безне шулар үстергән,
Әллә шуңа каеннарны
Күңелем үтә үз күргән.

Җырлый алар моңлы итеп,—
Иртән, көндез, кичкырын —
Кайры бишеккә иелгән
Әнкәйнең бишек җырын.

❋

Мичтә чатнап куак, артыш яна,
Өйгә рәхәт җылы тарала,
Мич алдында әнкәй моңсу гына
Сый әзерли безгә табада...

Шул хатирә гел күңелдә минем,
Юкса хәтер күпне онытткан...
Ул елларда утлар түгел, безне
Әнкәйләрнең күңеле җылыткан.

Жырлый-жырлый урак ура әнкәй,
Көлтә бәйли, куя сослымга,
Карап торсаң, һәрбер хәрәкәте
Гади түгел аның тылсым ла!

Иген кыры аның каршысына
Үзе килә кебек иелеп.
Әнкәй кулы тигән һәр урында
Көлтә-көлтә кала игелек.

Тау битендә кызарып кына
Җиләкләр пешеп килә,
Моңсу гына шул таулардан
Артышлар төшеп килә.

Аларның да арып-талып
Җиләктән кайтышыдыр...
Малай чагым хәтерләтә
Аларның кай төшедер.

Табынмый яшәми кеше,
Һәркемнең алласы бар.
Кем беләндер бүлешергә
Саклаган алмасы бар.

Үз бәхетен таба кеше
Иманын тапламаса,
Шул алмасын ятлар белән
Вакытсыз вакламаса.

Унсигез яшь язым түгел,
Бу яз үзгә, бүтән,
Ник соң әле шулай ярсып

Ләйсән яңгыр көтәм?—
Әйтерсең лә, күңелем минем —
Гөлләр чәчкән түтәл...

## Влтавада су коендым

1986 ел, Прага истәлеге

Влтавада су коендым,
Иделемне юксынып —
Алыштырамыни чит җир
Туган илнең җир-суын?—
Басмый Влтава сулары
Күңелемнең җирсүен.

Влтавада су коендым —
Дулкыннары шундый ук,
Ярларында таллар шаулый —
Тавышы бар, моңы юк.
Тавышы бар, моңы юк,
Күңелемдә тынгы юк.

Влтавада гел аккошлар,
Карасы бар, агы бар,
Влтава киң — Идел түгел —
Сулары киң, яры тар.

Һәркемнең дә үз Иделе,
Туып үскән ягы бар.

Кочак җәеп йөзеп була
Үз Иделеңдә генә,
Башны салып үксеп була
Туган җиреңә генә,
Серләреңне сөйләп була
Идел җиленә генә.

Хушлашканда Влтаваның
Җыйган идем ташларын...
Тик уйладым: ник ташларның
Моңлы итәм башларын?
Алар да читтә минем күк
Сагынып кояр яшьләрен.
Хушыгыз, диеп ташларны
Влтавага ташладым.
Хуш, Влтава!

### Лирон Хәмидуллин

# ОФЫКТАГЫ РӘШӘЛӘР

ЭССЕ



Жылы төннәрдә, караңгы күк йөзендә, якты нур бөркегән балкышлар кабатланып куя. Гүя, бик-бик еракта, офык артында, тавыш-тынсыз гына яшен яшьнәп алган сыман тоела.

Мондый күренеш җәй урталарында, иген өлгерер вакытларда еш кабатлана. Оренбург төбәгенең иркен дала ягы авылларында күк күкрәүсез, ул яшен-елдырымны никтер «рәшә уйнау» дип атыйлар. Имеш, төннәрен балкып-балкып шулай рәшә уйнаса, иген уңышы мул буласы икән... Нәрсәдән чыгып алай юраганнардыр, әйтә алмыйм. Әмма көндезге эсседә кыр-дала өстендә хәтсез тирбәлгән монарлы рәшә дулкыны, шул көннәрдә карбызларның алсуланып пешеп җитүләре бик тә хәтердә әле. Буй-буй тышлы ул җимешне телеп җибәреп, бер-ике кабым авыз итүгә көннең әлсерәткеч эсселегә, һаваның тынга кабарлык бөркүлеге онытыла. Шулчак тәнеңә һәм җаныңа бик тә рәхәт булып киткәнен тоясың, сулышыңның киңәеп, тирә-як мохитның иркенәеп калганлыгын сизәсең.

Бер уйласаң, көндәлек тормышта гына түгел, яшәешебездә дә әнә шундый балкышлы көннәр булгалап тора ич. Төрле кысанлык, тигезсезлекләргә җан әрнеп, күңел сыкранып, авыр кичерешләргә бирелеп йөргән бер вакытларда баш очында сирпелгән рәшә нурларыдай балкыган көннәр туа, шулчак күңел түрләребез яктырып, яшәү өметләребез дәрт алып үсеп киткәндәй була. Төрле тарафлардан кимсетелгән, тиргәлгән һәм каргалган халкыбыз язмышында да мондый халәт-кичерешләр булгалап торган. Һәм шундый бер дәвер — таң шәфәгыдай аның күңелен ымсындырган бер дәвер — инде узып баручы гасырыбызның башлангыч елларына туры килгән. Бу чор, бу дәвернең бар халәт-кичерешләрен, мөгаен, төп-төгәл итеп шул көннәр шагыйре Сәгыйть Рәмиев ачып салгандыр:

---

Лирон ХӘМИДУЛЛИН *(1932) — әдип, тәрҗемәче, «Юлда», «Дала иртәсе» китаплары авторы. Татарстан ССРның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Дөм караңгы бер хәятта
Таңребез тоткын иде,
Анда иркен бер иманга
Юк ирек, ул кол иде...

Халкыбызның моңарчы булган тормыш-көнкүрешен шулай тасвирлый да шагыйрь:

Балкыды «Нур», килде «Вакыт»,
Иcте саф, хәр «Таң» җиле,—

дип, күңелдә өмет чаткылары кабызган көннәр килүен хәбәр итә. Бәхет өметләре уяткан ул көннәрнең исә Петербург күгендә пәйда булган «Нур», Оренбургта калыккан «Вакыт», Казан төбәгендә нур сирпегән «Таң йолдызы» газеталарына бәйле рәвештә туганлыгын белдерә.

Әйе, әлегәчә йомыклыкта яшәгән татар халкы да колониячел Россиянең беренче уңай үзгәрешләре — 1905 елгы революция чорында беркадәр ирек ала, иркенрәк сулый башлый. Беренче татар вакытлы матбугаты баш калкыта.

Таң вакыты... татар йоклый*,
Мин, йокысыз, уянам,
Уянам да, тиле кебек,
Тик бер үзем уйланам,—

дип, халык язмышы өчен борчылучылар, аны йомыкыйлыктан аерып, йокысыннан тизрәк уятырга ашкынучы алдынгы фикер ияләре көрәш мәйданына күтәреләләр. Мәгърифәтле һәм мәдәниятле халыкның гына олы тарих кагылышларында үз-үзен югалтмавын аңлаган ул каһарманнарның иң алгы сафында ялкынлы йөрәкле әдип һәм шагыйрьләребез булалар. Шул елларда милләтебезнең мәдәни һәм рухи күгендә, җәйге рәшә балкышларын хәтерләтеп, Казан төбәгендә Гаяз Исхакый, Галиәсгар Камал, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Рәмиевләр нуры сирпелә башлый. Ә тарихи җирлегебезнең бер почмагында, ерак Оренбург тирәләрендә, Риза Фәхретдин, Фатих Кәрими, Дәрдемәнд, Шәриф Камал, Мирхәйдәр Фәйзи һәм башкалар балкуын тоясың. Әйе, караңгы сәяси һәм мәдәни күгебездә беренчеләрдән булып алар яшене яшьнәде, алар яктысына башкалар тартылды, көрәш мәйданы киңәя барды...

Инде, башкалардан аерылып, фәкать бер шәхескә — Дәрдемәнд шәхесенә тукталасы, игътибарны аңа гына юнәлтәсе, ул узган тормыш юлына күз саласы, гыйбрәт аласы килә. Әйе, Дәрдемәнд-Рәмиев мәдәниятыбызның яңа бер борылышында фәкать үзенчә генә балкыган, үзенә генә хас юл үткән кеше. Хак ич, шагыйрь Дәрдемәнд-Рәмиев, замандашы Сәгыйть Рәмиев шикелле:

Сызла, сызла, сызла, күңлем!
Сызла бер туктамыйча,
Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла төн йокламыйча!—

дип, халкы язмышы турында уйлануларын бик алай турыдан ярып язмаган. Әмма аның да эчтән күңеле сыкраган, бәгыре әрнегән, әлбәттә. Тирән фәлсәфи эчтәлекле «Кораб», «Без», «Бүзләрем мана алмадым» һәм башка шигырьләре, киләчәк өмет һәм яшәеш, язмыш

* С. Рәмиевнең «Таң вакыты» шигыре (өзек).

хакында уйлануларыннан тыш, милләткә хезмәт итү рухы белән сугарылганнар. Әйе, фәлсәфи фикергә бай, әмма сүзгә саран һәм төгәл җөмләләрдән генә коеп куелган әсәрләреннән тыш та ул үз заманы татар дөньясына, татар милләтенә күп хезмәт куйган иң олы шәхесләрнең берсе булыр.

Чыкты җилләр,
Купты дулкын —
Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!

Әйе, ул шулай сөрән салып, замандашларын уяу булырга өндәп кенә калмады, ил-кораб юнәлешен дөрес юлга чыгару, халкын аңбелемле, мәгърифәтле итү юнәлешендә дә җиң сызганып армыйталмый эшләде. Шушы изге максат өчен ике-өч буын тир түгеп тапкан мал-мөлкәтен дә, акчасын да кызганмады. Кайберәүләр бездә аны миллионер шагыйрь, дип гаепләргә тырыштылар. Ә инде ул миллионның үз халкына яхшы җиһазланган басмаханәләр, мәктәп-мәдрәсәләр аша кире кайтарылганлыгын күрмәделәр. Бер уйласаң, революциягә хәтле татар дөньясында иң абруйлы, иң тотрыклы мәгърифәтчелек юнәлешендә дистә ярым ел дәвамында чыгып килгән «Вакыт» газетасы һәм «Шура» исемле әдәби, сәяси һәм гыйльми журнал нәшире булганы өчен генә дә без, ул бай мирасның варислары, «буржуй» шагыйрь Дәрдемәнд-Рәмиевкә мең-мең рәхмәтләр укырга тиешбез.

Әйе, булачак шагыйрь үз милләтенең киләчәге өметле булсын өчен, аны урта гасырлардан ук килүче гамьсез йокысыннан уятыр өчен халыкка иң беренче нәүбәттә аң-белем бирүнең кирәклеген яшьли үк төшенә. Моның шулай икәнлеген Закирның Истанбулда укыганда абыйсы Шакир Рәмиевкә язган хатларыннан ук чамалап була. Мәсәлән, 1881 елда (булачак шагыйрьгә егерме бер яшь чамасы булганда), Шакир абыйсы аңа мондый хат юллый: «Безнең халык өстендә чапан, башында чалмасы булмаган кешенең сүзенә һич игътибар итми... Халыкка һәртөрле әхвәлне аңлата торган китапларны укырга кирәк. Шуңа күрә дә фәһем алырдай китаплар, романнарны күбрәк алып кайта күр... Типография шрифтләре мәсьәләсен ни эшләтәсең, нинди бәягә алырга мөмкин, яз. Бу сәфәрдә алып кайтасыңмы, әллә соңыннан алдыру яхшы булырмы? Ничек тә булса бу турыда тырышырга кирәк».

Җавап хатларының берсендә Закир Рәмиев абыйсына болайрак дип әйтә: без бит Орскиның кара байлары Борнаевлар сыман малга табынып кына яшәргә җыенмыйбыз, төп максатыбыз — халыкка хезмәт итү, ди.

Шушы урында шагыйрьнең замандашы һәм беренче биографы, язучы Фатих Кәрими сүзләрен искә төшерү дә кызыклы булыр. Әдип, бу ике туганны шул заманның кайбер үз тиңнәре белән чагыштырып, болай язган: «Шул ук Орскида Борнаевлар, Казанда Галкәевләр, Мөэминевлар кебек ул вакытларның күп татар сәүдәгәрләре бар иде. Бөтен гомерләре буенча русчаны дөрес сөйләргә өйрәнә алмаганнар, рус телендәге әдәбият вә матбугаттан файдалана алмаганнар. Дөньяга карашлары бик тар рәвештә булып, коры бер дини фанатик булып яшәгәннәр. Әмма Шакир, Закир Рәмиевләр боларга бер дә охшамый торган кешеләр булып чыкканнар. Боларның фикерләре нык ачылган, дөньяга карашлары нык киңәйгән. Моның, әлбәттә, иҗтимагый сәбәпләре булгандыр».

Борадарән Рәмиевләр, алда әйтелгәнчә, газета һәм журнал чы-

гару белән генә чикләнмичә, озакламый китап басу эшенә дә керешәләр. Татарча басма сүз, матбугат тарихын өйрәнгән Исмәгыйль Рәмиев бу хакта мондый мәгълүмат китерә: «1909 елда техникасының җитешлеге, эшенең пөхтәлеге белән танылган «Вакыт» газетасы басмаханәсе ачыла. Галимҗан Ибраһимов белән Шәриф Камал әсәрләренең күбесе шушы нәшрият басмаханәсендә тарала».

Шуңа өстәп, анда бу авторлар гына түгел, заманында дөнья күргән бик күп башка язучыларның да күренекле әсәрләре һәм укучы «фәһемен үстерү»гә булышлык итүче башка бик күп китаплар да Рәмиевләрнең шушы «Вакыт» типографиясендә басылып таратылалар.

Яңача җиһазланган бу басмаханәдә, әлбәттә, «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналы да басыла башлый. Элек аларны «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкәсе» типографиясе чыгарып килә. Ул типографиянең хуҗалары, исем-атамасыннан чамаланганча, Гани бай Хөсәенев белән язучы Фатих Кәрими, ә типография директоры исә Кәриминең кияве Тимерша Соловьев була. Ул дәвердә газета да, журнал да, таушалган хәрефләр белән басылганга күрә, сыйфатсызрак чыгалар. Шуны да истә тотып булса кирәк, Рәмиевләр тиздән үз басмаханәләрен оештыралар.

Нәкъ шул елларда Тимерша Соловьев кул астында эшләгән язучы Зариф Бәшири истәлегенә күз салыйк: «...Рәмиевләр, бигрәк тә Закиры, матбугат һәм әдәбиятка зур мәхәббәт белән караганлыктан, бу эшкә сәүдә-табыш ягыннан килмәделәр. Матбугатның эчтәлеге белән дә, күләме, тышкы күренеше һәм техникасы ягыннан да нәфис, матур, күркәм булуын телиләр иде...

Закир Рәмиев газета белән журналның техника ягыннан матур булып чыгуына шулкадәр нык әһәмият бирә иде, хәтта машинадан өч тапкыр үткән хәрефләрне яңадан керттерми, алар белән әйбер бастырмый иде. Ул шытырдап, ялтырап торган нык кәгазьләр, чем-кара буяулар китертте...

Закир Рәмиев матбугат хезмәтчеләренә ул чорларда татарлар арасында һичбер җирдә күрелмәгәнчә зур жалованье бирә иде. «Вакыт» газетасы редакторы Фатих Кәрими белән «Шура» журналы редакторы Риза казый (Фәхретдинев) аена йөз утыз сум алдылар. Моны күпләр: «Министрлар жалованьесы»,— дип йөртә торганнар иде...»

Әйе, Рәмиевләр бу басмаханәдән дә, үзләре нәшер кылган вакытлы матбугаттан да табыш алу уенда тормыйлар. Аларның төп максаты — үз милләтләренә хезмәт итү, халыкның мәдәни халәтен үстерү, аң-белемен арттыру була. Шул ук заманда матбугат эшен бары тик табыш алу, кәсеп итү өчен генә файдаланган бик күпләрдән аермалы буларак, алар ел саен диярлек, алтын хисабы белән исәпләгәндә, ун мең сумлык зыян күрганнәр. Ә бит «Вакыт» газетасының тиражы табыш күргән башка байтак газеталарныкыннан кимендә ике мәртәбәгә артык була. Чагыштыру өчен бер-ике генә сан китерик. Кайбер истәлек һәм документлардан күренгәнчә, 1910—12 елларда сабан аты егерме биш сум тирәсе, ә савым сыер ун-унике сум торган. Тозтүбә тоз шахталарында эшләүче төп һөнәр ияләренә көненә утыз-кырыгар тиен чамасы хезмәт хакы түләнгән.

Беләбез ки, 1905 елгы үзгәртеп корулар башланганчы патша монархиясенең һәм нигездә карагруһчылар карашында торган шул чор руханиларының вак милләтләргә, бигрәк тә татарларга карата мөнәсәбәтләре бик тискәре була. Моның җирлегендә, әлбәттә, шовинистик фикердәге кешеләрнең дин һәм мәдәният, мәгариф өлкәләрендә хакимлек итүләре сәбәпле, Россиядәге рус булмаган милләтләрнең, бигрәк тә татар халкының борынгы тарихын төрле юл-

лар белән бозып күрсәтүләр ята иде. Әлеге көчләр гасырлар буена безнең ата-бабаларыбызга үз уй-фикерләрен әйтергә ирек бирми килделәр, үз газета-журналларыбызны чыгаруга каршы тордылар. Бу мәсьәләгә кагылган төрле үтенеч, «прошение»ләрне Петербург чиновниклары чүплеккә ташлый бардылар.

Ниһаять, 1905 елгы күтәрелеш башланды. Вульгар әдәбиятта, бигрәк тә дини үзәкләр тарафыннан таратылган китапларда әлек татарларны төрлечә кимсетү, мәсхәрәләү өстенлек иткән булса, борын төртә башлаган үз милли матбугатыбызда моңа каршы көрәш көч ала барды. Аларда бөек Тукайның «Монда сезгә юк ирек, солтан җиренә китегез» димәкче кайбер шовинистларга карата кистереп әйткән: «Китмибез!.. Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл»,— сүзләре торган саен ешрак кабатланды.

Нәкъ шул дәвердә «Әл-ислах», «Фикер», «Йолдыз», «Таң йолдызы» газеталары белән ярыша-ярыша мәйданга эчтәлеге һәм эшләнеше белән пөхтә, матур «Вакыт» газетасы, тарихи һәм гыйльми материалларга, онытылып барган сәяхәтнамәләребезне барлауга күп урын биргән «Шура» журналы пәйда булды. Моның өчен Рәмиевләр күп көч һәм акча сарыф иттеләр.

Кемнәр соң алар — Рәмиевләр? Кайдан килеп чыкканнар? Илгә, халыкка армый-талмый хезмәт итәрлек булып кайда тәрбия алганнар?

## Чабаталы морзалар

Әйе, Дәрдемәнд-Рәмиев Октябрь революциясенә чаклы татар дөньясында күренекле урын биләгән абруйлы, мөхтәрәм бер шәхестер. Шагыйрь дә ул, нәшир дә, Дәүләт думасына сайланган җәмагать хадиме дә, алтын приискалары тоткан бер бай — элегрәк елларда язылганча, буржуй да.

Аның вафатыннан соң классик әдибебез Галимҗан Ибраһимов хаклы рәвештә: «Болар уяну күгендә беренче йолдызлардан иде»,— дип белдерде.

Ул гап-гади бер татар авылыннан, Оренбург төбәгеннән калкып күтәрелгән икән. Тормыш-көнкүрештәге фамилиясе — Рәмиев, китап, матбугат битләренә теркәлгән әдәби исеме — Дәрдемәнд. Үзеннән ике яшькә олы агасы Шакир Рәмиев белән бергә башта үз авылларында, аннары соң казакъ даласы чигендәге Орск каласының бер мәдрәсәсендә белем сукмагына аяк басканнар алар. Һәм гомер чигенәчә бер-берсен үстерешеп, әйдәп янәшә атлаганнар Закир белән Шакир Рәмиевләр.

Әйе, аларның көн күргән, гомер иткән төбәкләре, туган яклары — шул Орск, Оренбург җирләре, элеккеге Оренбург губернасы. Әгәр дә Закирның ике ел Истанбулда яшәп укуын, яисә Шакирның Европа буйлап сәяхәтен исәпкә алмасаң, алар гел бер урында яшәгәннәр.

Шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Дәрдемәнд-Рәмиев 1859 елның көзендә Оренбург губернасының Эстәрлетамак өязе Җиргән авылында дөньяга килгән. Җиргән — Агыйдел суы буенда, Эстәрлетамак шәһәре белән Оренбург шәһәре арасында урнашкан зур гына авыл. Аның урынын Исмәгыйль Рәмиев: «Җиргән авылы Эстәрледән кырык чакрым үрдәрәк, Оренбург юлы өстендә, Агыйдел буена салынган татар авылы»,— дип билгели. 1908 елдан ул Уфа губернасы

биләмәсенә күчерелгән, ә 1919 ел башыннан, Кече Башкортстан төзелгәч, Башкортстан АССР карамагына кертелә.

Җиргән Урал тауларының Оренбург ягы тигезлегенә авышып барган бер итәгендә, әмма табигатьнең бик тә матур бер өлешендә урнашкан. Җиргән авылында шулай ук татар совет әдәбиятының күренекле бер вәкиле, олы әдип Мирсәяф абый Әмиров һәм Октябрь революциясе еллары, гражданнар сугышы чорлары Татарстан республикасы тарихын барлауга зур өлеш керткән мәгълүм тарихчыбыз Мидхәт ага Мөхәррәмов туганлыгын да әйтеп үтәргә кирәктер. Ләкин Рәмиевләр Закир тугач та (мулла кушкан исеме — Мөхәммәтзакир), бу авылда озак яшәмичә, шул ук Оренбург губернасына караган икенче бер урынга күченеп киткәннәр. Бу вакытта әле кеч кенә Закир яңарак кына аякка баса башлаган була.

Атасы Мөхәммәтсадыйк — шушы авылның хәлле генә бер сәүдәгәре. Хәер, аның әле, мөгаен, Эстәрлетамакта һәм якын-тирә авылларда тагын кечерәк кибетләре дә булгандыр. Бу дәвердә Мөхәммәтсадыйк Рәмиев кызыл мал һәм башка авыл кирәк-яраклары белән сәүдә итә. Шул ук Эстәрлетамакта яшәгән аның якын кардәше Габдулланың да (Исмәгыйль Рәмиев атасы) кызыл мал кибетләре була. Өченче кардәшләре — булачак шагыйрь Сәгыйть Рәмиев атасы Лотфулла исә бүрәнә-агач алыш-бирешендә таныла: башта үзе эрерәк сәүдәгәрләргә хезмәт итә — Урал тауның ашкын елгаларыннан сал агызучыларның әйдәүчесе, башлыгы санала. Соңрак, Оренбург төбәгенең урмансыз якларына күченеп, андагы халыкны агач кирәк-яраклары белән тәэмин итүдә үз өлешен кертә.

Рәмиевләр башлыча авылда көн күрсәләр дә, җир сөрү кебек кара эшкә әллә ни күңел бирмәгәннәр. Моның үз сәбәпләре, үз традицияләре бар, әлбәттә. Чөнки гомер-гомергә алар үзләрен малтуар багып, җир сукалап яшәгән күршеләреннән чак кына өстен күргәннәр, борынгы аксөякләр нәселеннән килгәнлекләрен һич кенә дә онытмаска тырышканнар. Бу хәл, әлбәттә, бер Рәмиевләргә генә хас күренеш түгел, үзләрен кайчандыр морза, бәкләр токымыннан дип хис иткән шул ук Дашкин-Дашков, Чанышев, Еникеев һәм башка бик күпләр өчен дә уртак язмыш бу. Ул заман теркәү кенәгәләрендә, документларда гади авыл халкы ясаклы татарлар саналса, боларның күпчелеге «служилый» дип аталып йөртелгән. Ягъни, кайчандыр патша хезмәтендә булганны аңлаткан тамга йөрткәннәр. Патша заманындагы халыкны исәпкә алу кенәгәләрен актарып карасаң, андый «служилый»лар кечерәк авылларда бөтенләй теркәлмәгән диярлек, зурракларында исә андыйлар дүрт-биш гаиләдән дә артмый: авыл сәүдәгәрләре, мулла-мөгаллимнәр, писарь, старшиналар да вәссаләм. (Элекке Оренбург губернасы авылларын күздә тотуым).

Әйе, ул төркемнең күпчелеген халык телендә «чабаталы морзалар» исемен йөртүчеләр тәшкил итә. Димәк ки, кайчандыр морза, бәк токымнарыннан булып та чабаталыга калучылар. Бер уйласаң көлке дә кебек. Безнең көннәрдә дә бер ара түрә булып торып та, соңра «өйрә чөмерүче»гә калучылар, ягъни, түрәлектән төшеп калучылар азмыни соң?

Әмма «чабаталы морзалар»ның хәле, язмышы, нигездә, күпкә катлаулырак һәм фаҗигалерәк. Алар — башлыча борынгы Казан төбәге халыкларының мөстәкыйльлеге бетерелгәннең соңында барлыкка килгән хакимият һәм сәясәт корбаннары. Шулай булгач, үз гаепләре белән генә түрәлектән түбәнгә тәгәрәмәгән, ә бәлки көчләү нәтиҗәсендә, яшәп килгән сәясәт нәтиҗәсендә шундый хәлгә калган, кыерсытылган бер катлам. Идел-Урал буйларында яшәгән ханлык яулап алынып, аның кешеләрен көчләп чукындыруга кере-

шелгәч тә зур җир биләүче морза, бәкләрнең күпчелеге, билгеле, мал-мөлкәтен югалтмас өчен, мондый сәясәткә буйсынганнар. Шундыйлар арасыннан Россиядә мәгълүм алпавытлардан Державин, Карамзин, Аксаков һәм башка күп кенә күренекле токым, династияләр барлыкка килгән.

Әйтик, рус дворяннары арасыннан чыккан беренче революционер һәм язучы, олы фикер иясе Александр Николаевич Радищевка багышлап, 1935-36 елда СССР Фәннәр академиясе тарафыннан туплап бирелгән басмада иманнарын алыштырырга мәҗбүр ителгән шундый морзалар хакында да бик кызыклы мәгълүматлар китерелгән. Христиан динен кабул итмәгән морзаларны җирсез һәм малмөлкәтсез калдырырга дигән патша указларыннан соң (андый соңгы указ Петр I патша заманында чыгарылган), болар ашыгып чукынырга керешкәннәр.

А. Радищев биографлары, әнә шул хәлләрне күздә тотып, андый морзаларның ул чордагы тормышларын болайрак сурәтлиләр. Имеш, алар үзләре диннәреннән ваз кичеп кенә калмыйлар, үз биләмәләрендәге авыл кешеләрен дә бик тырышып чукындырырга тотыналар, авылларда ашыга-пошыга чиркәүләр төзетәләр. Шул чиркәүләрдә, халык алдында, бик бирелеп яңа дин кушканча гыйбадәт кылалар икән. Ә өйләренә кайткач исә, халыктан яшеренеп, үз мөселман диннәрен дә тоталар икән. Ягъни, ике аллага, ике дингә берьюлы табыналар булып чыга. «Яңа чукынган морзалар арасында мондый хәлләр шактый озак дәвам итә»,— дип тасвирлана әлеге академик басмада...

Әйе, «чабаталы морза» диелгәннәр әнә шул көчләп диннән язды ру елларында бу сәясәткә буйсынмыйча, мал-мөлкәтсез, чабатага калган шул аксөяк токымнар санала икән. Бәлки алар зур җирбиләмәләр тоткан эре морзалар булмаганнардыр да, андый байлыктан дин дип кенә ваз кичү, үз иш-тышларыннан аерылып ала каргага әверелү бик сирәк каһарманнар өлешенә генә төшкәндер, мөгаен. Күпчелек исә мондый үзгәрешне сыкрап булса да, кача-поса үз өендә иске динен тотып маташса да, кабул итә. Шулай эшләми мөмкин дә булмагандыр. Ә инде ул морза-бәкләрнең ярлырак кардәшләре, югалтырлык әллә ни мал-мөлкәте һәм биләмәләре булмаганнары үз диннәрендә калган, күпмедер вакытка чаклы әле олы кардәшләре тирәсендә, аларның сиздерер-сиздермәс кенә булышлык итүен тоеп, вак-төяк дәүләт эшләрен үтәп килгәннәр, хәрби хезмәттә булганнар.

Исмәгыйль ага Рәмиев раслаганча, алар токымыннан да патша хезмәтендә булган, патша сараена якын даирәләрдә йөргән шәхесләр бар икән. Азов-Дон тирәләрен биләгән Төркия солтаны белән сугыш башлаган Петр I патшаның тәрҗемәче-тылмачлары арасында Рәмиев фамилиялесе дә бар, дип ул еш кына сөйли торган иде. Үз нәселе башында исәпләнергә тиешле шул Рәмиевкә кагылышлы документларның тулырагын барлау өчен, бик хаста һәм өлкән яшьтә булуына да карамастан, ул Ленинградка барырга хыялланып яшәде.

— Ленинград архивларына барып төртеләсем килә әле, бераз хәл җыйгач,— дип йөрде Исмәгыйль ага.

Хәл җыйгач, дигәне, исәнлек-саулыгы ныгуга гына түгел, күбрәк матди як белән бәйле иде...

Исем-атамалары патша һәм аның якыннары телгә алынган документларда теркәлгән ул Рәмиевнең нәсел-нәсәбәсе кайчан һәм ни рәвешле ерак Оренбург төбәгенә барып олакканнар соң? Моңа әлегәчә төпле җавап юк диярлек. Ул хәлнең бер Рәмиевләр язмышына гына кагылмавын истә тотып, бу мәсьәләгә тукталып китәсе килә.

Мәгълүм ки, Казан, Әстерхан ханлыкларын яулап алганның соңында Россиянең ил чиге Урал елгасына (элекке иселе — Җаек) һәм Урал тауларының көнчыгыш битләвенә кадәр киңәя. Озакламый бу ике ханлык биләмәләре Казан губернасы итеп билгеләнә. Ә инде бу ханлыкларның элеккеге халыклары булган татар, нугай, башкортлар тынычсызланып, бунтлар ясап интектерә башлагач, ул бунтларны бастырулар уңышлырак хәл ителсен дип, губерния икегә бүленә. 1744 елда оешкан Оренбург губернасына дүрт провинция керә: төньяк Уралдан башлап — Исеть, Уфа, Оренбург һәм Ставрополь (соңрак Самара) провинцияләре. Оренбург провинциясенә исә хәзерге Бөгелмә тирәләреннән алып Уральск, Гурьев өлкәләре, соңрак казакъ ягындагы Тургай өлкәләре дә тупланган була.

Бунт, күтәрелешләр вакытында татарлар — нугай һәм башкортлар белән, башкортлар — казакъ һәм нугайлар белән аралашмасын, алардан ярдәм көтмәсен өчен, шушы халыклар тупланып яшәгән төбәкләр төрле «кордон», «хәрби сызык»лар белән өлешләргә бүлгәләнә. Әйтик, хәзерге Татарстан җирлегендә Арча ныгытмалы сызыгы булганлыгы билгеле, кырык чакрым киңлектәге Идел, Кама елгалары буе кордоны мәгълүм.

1652–56 елларда махсус гаскәрләр Кама аръягы сак сызыгына күчереп утыртылалар. Шишмә, Зәй сулары аралыгына күчерелгән ул ярым хәрбиләшкән «казак»лар авылларының оешкан төстә берничә полкка берләшүе мәгълүм.

Соңрак, бунтлар, баш күтәрүләр кимемәгәч, башкортлар тупланган төбәкләрне дә шундый берничә хәрбиләшкән сызык (ягъни, бер сызыкка утыртылган хәрби авыллар) ярдәмендә бүлгәләүләр башлана. Унсигезенче гасыр урталарында Бөгелмә — Бүздәк — Уфа, Бөгелмә — Шарлык — Оренбург һәм беркадәр соңрак оешкан Оренбург — Орск — Троицк — Югары Урал шәһәр-ныгытмаларын берләштергән сызыклар тынгысыз башкортларга күрше тугандаш халыклар белән аралашу юлларын кисәләр. Бу хәрби сызыклар буйлап төрле ныгытмалар, редутлар төзелә, почта юллары салына. Бу сызык авылларына, нигездә, атлы казаклар хокукы бирелгән һәм күчеп килгән руслар, патша хөкүмәтенә турылыклы служилый чуваш, татарлардан торган ярым гаскәри берләшмәләр күчерелә. Элек-электән рус дәүләте чикләрен шундый ярым ирекле яшәгән «казачий» гаскәрләр саклап килгәнлеген һәм ул казакларның төп нигезен әкренләп руслаша барган кыпчак һәм башка төрки халыклар атлылары тәшкил иткәнен исәпкә алсак, бу ярым хәрби авылларга күчерелүчеләрнең дә шундый ук гаскәр икәнлеген күзалларга мөмкин.

Миңа калса, Казан арты авыллары өчен ят исем — Казаклар, шуңа охшаш башка атамаларда әнә шул Чабаксар — Кокшайск — Арча «хәрби сызыгы» эзедер, мөгаен. Соңгы күчешләр дәверендә Урал суы буена: Троицк — Югары Урал шәһәрләре тирәсенә чик сагы хезмәтен үтәргә утырган нагайбәкләр язмышы патша хөкүмәте тарафыннан оештырылган шул ук кордон-сызыкларга бәйле. Унсигезенче гасырда Илэк шәһәреннән алып Урал суы башындагы Югары Уралгача (Верхнеуральск) рус дәүләте белән дала казакълары арасында чик буе гаскәрләре — Оренбург атлы казаклары берләшмәсе оеша. Бу чик буеның киңлеге Урал елгасыннан йөз-йөз егерме чакрым итеп алына, шунда әлеге керәшен нагайбәкләр, Урал төбәге атлы казакларының бер өлеше һәм элек әчке хәрби сызыклар сагында торган башкорт-мишәр-типтәр гаскәренең башлыча татар телле өлеше күчереп утыртыла. Урал суы буена урнашкан байтак кына татар авылларының тарихы шушы заманнан башлана. Кайчандыр бу гаскәри берләшмәләргә беркетелгән бер катламның «без төмәннәр» дип таныту гадәти булган. Бу төшенчә дә шул

авылларның кайчандыр кантон-полкларга бүленү дәвереннән килсә кирәк.

Шул ук нагайбәкләрнең кайчандыр Бакалы (хәзерге Башкортстанның көнбатышындагы район үзәге) тирәсендә яшәгәнлекләре тәгаенләнгән, ачыкланган инде. Элегрәк аларның, Бакалы якларына күчерелгәнче, Арча төбәгендә яшәгәнлекләренә дә истәлекләр байтак. Димәк, патша хөкүмәте, үзенә тугрылыклы андый халык төркемнәрен бер четерекле урыннан икенчесенә күчереп йөрткән, Казан арты татарлары арасында чуалышлар тына төшкәч тә андый гаскәрләрне икенче сызыкка — нагайбәкләр очрагында Яңа Кама аръягы хәрби сызыкка, ә аннары инде, хаҗәте чыккач, ерак дала чигенә үк күчереп йөртү күзгә ташлана. Нагайбәкләр унтугызынчы гасырның соңгы чирегенәчә, ягъни, дала казакълары тәмам Россиягә кушылганчы, чик сакчылары хезмәтен үтиләр.

Шундый ук хәлне, минемчә, 1789 елда оешкан әлеге башкорт-татар гаскәрләре мисалында да күзәтеп була. Бу гаскәрнең дә башкортлардан торган өлеше элекке биләмә чикләрен саклау дәверендә үк туган булса, калган өлеше исә элеккеге Шишмә — Зәй һәм Самара суы буе хәрби ныгытмалары берләшмәләренә кергәндер. Гаскәрнең соңрак шушы ике өлешнең кушылуыннан туганлыгы төсмерләнә.

Максатчан эзләсәң, бу фикерне дәлилләрдәй мисаллар да табылырга тора. Әйтик, Оренбург янәшәсендәге шул ук Сәет бистәсе (Каргалы авылы) тарихын алыйк. Оренбург төбәге ул дәвердә Рус патшалыгының Урта Азия һәм хәзерге Казакъстан биләмәләре ханлык, солтанлыклары белән аралашу һәм сәүдә итү үзәге булып тора иде. Билгеле, шунлыктан бу губернага солдатлар, ярым гаскәриләр генә түгел, сәүдәгәрләр, тылмач-арадашчылар да күпләп тартылалар. Сәет бистәсенә нигез салучы ике йөз гаиләнең дә күпчелеге шундыйлардан саналган. Патша хөкүмәте аларны махсус үзе күчереп утырткан, яисә «патша хөкүмәте рөхсәте» белән күченеп утырганнар, дип фараз ителә.

Ә менә 1773 ел көзендә, Пугачев явы Оренбургны камап алгач, имештер, Сәет бистәсе халкының бер өше: «Без дә элекке гаскәриләр, казачий сословиядән»,— дип белдерәләр, яңа «патша»ны кунакка чакыралар... Каргалы кешеләре арасында андый хәбәр дә, үзләрен «казачий татарлар» дип танучылар да бүген дә яши әле. Пугач «патша»ның рус атлы казаклары станицасы Бердыда «алтын пулат», татар Каргалысында «көмеш пулат» тотканлыгы тарихи документларга да теркәлгән. Татар, башкорт «пулковник»ларын ул, гадәттә, шул «көмеш пулат»та кабул иткән.

Сәет бистәсенең (Каргалы) Чистай төбәгеннән күчерелүе хак; димәк, анда сәүдәгәрләр белән бергә күпмедер гаскәри — патша хезмәтен үтәгән кешеләр дә күчкән була лабаса. Шунысын да онытырга кирәкми, ул гаскәриләргә, күпмедер хезмәт хакы түләүдән тыш, вак-төяк алыш-биреш итү мөмкинлекләре дә бирелгән булган. Шунлыктан алар төркемендә аксөяк «чабаталы морза»ларның ишле булуы да гаҗәп түгел. Аларның күпләп Урал тавы һәм Урал суы буе авылларына сибелүе дә табигый хәл. Андагы түбән-татар, мишәр-татар, типтәр-татар авылларының тарихы да, нигездә, шушы вакыйгаларга бәйле. Кайчандыр ул авыллар хәрби ныгытма, редут булганнар.

Редут димәктән, шагыйрьләр Гобәйдулла Мөэминев-Рәдүди һәм Төхфәт Ченәкәй-Сәмәвиләрнең туган авылы Рәдүт (документларда теркәлгән исем-атамасы — Никитино) Урал суы буендагы шундый ныгытма авылларының берсе. Бу шагыйрьләр «морза» токымнарына ук кермиләр шикелле, кергән булсалар да онытылгандыр, мөгаен. Алар гадәти «татар атлы казаклары» исәбендә йөриләр шикелле.

Андый авыллар элек Урал суы буенда бик ишле иде. Шамил Усмановның «Легион юлы» әсәре башланып киткән тирәләрдә генә дә (атлы казаклар биләмәсенең бер чите) биш-алты шундый авыл бар. Шул төбәктәге Иләк, Мостай ише авыл-станицалар исә аерым полклар туплану урыны булган. Шунлыктан инде анда катнаш халык — татар һәм рус казаклары яшәгәннәр.

Шушында тасвирланганнардан чыгып, Петр патшаның Рәмиев фамилияле тылмачыннан башлап, Зәй елгасы тирәләрендәге редутныгытмалар аша, Оренбург якларына бер караш ташларга мөмкин. Ә инде ул юл-тарихның аерым буыннары әле тәгаен барланмаган. Хәер, татар халкына кагылышлы андый ачыкланмаган, барланмаган буыннар бик тә, бик тә күп шул әлегә...

## Дашкова Хәнифә

Шагыйрь Дәрдемәнд-Рәмиевнең анасы — Дашкова Хәнифә.

Хәнифәнең атасы Дашков Әлмөхәммәт — шул ук Эстәрлетамак өязенең Явыш авылында яшәгән, диелә. Исмәгыйль Рәмиевнең бер искәрмәсендә: «Князь Дашков, Дашкиннар фамилиясе элек-электән рус тәрбиясе күреп килгән»,— дип языла.

Әйе, борынгы бер тамырдан килгән ул Дашков-Дашкиннар шулай ук татар дөньясының бер аксөяк катламы. Мәгълүм рус алпавытлары Дашковларга мөнәсәбәтләре барлыгын да яшермәгәннәр. Тик тегеләре чукынган, ә болары үз мөселман диннәрендә калучылар.

Бу фамилияне йөртүче мөселман морза Дашковлар башлыча хәзерге Башкортстанның көнбатыш өлешендә һәм бер кадәресе Куйбышев өлкәсенең көнчыгышында таралганнар. Тарихи күзлектән карагында, димәк, шул ук Оренбург губернасының көнбатыш чикләре буенда тупланган булганнар.

Мөхтәрәм шагыйрьнең күп мактауларга лаек анасы Хәнифә генә түгел, гомумән, бу нәселдән һәркем диярлек зыялы, укымышлы булуы белән аерылып торган. Билгеле инде, алар да элек күбрәк сәүдә, һөнәрчелек өлкәләрендә танылганнар, төрле-төрле оешма һәм кәнсәләрдә башлыча түбәнрәк катлам чиновниклар, тылмач-арадашчылар булганнар. Авыл җирлегендә тупланган Дашков-Дашкиннарның бер ише, ярыйсы ук ишле өлеше, әлбәттә, мулла-мәзин дә мөгаллим инде.

Укучы күңелендә: нишләп бу татарлар, хәтта морза токымыннан чыкканнары да шул вак сәүдәгәрлек, мулла-мөгаллимлектән ары уза алмаган, тормышта шуннан да артыграк эш күрсәтә алмаган соң, дигән бер ризасызлык хисе туарга мөмкин, билгеле. Ләкин моңа һич кенә дә ерак бабаларыбызны гаепләргә ярамый — заманасының кырыс киртә-таләпләре аларга андый сайлау мөмкинлекләре бирмәгән. Ул вакытта кешене кешедән сәләте түгел, дине, тоткан рухи кыйбласы аерган. Әле «мәдәниятле дәвер» дип дан алган унтугызынчы гасыр азакларында да мөселман динендәге татарларга карата төрле тыюлар яшәп килгән: сәүдә өлкәсендә, мәсәлән, алар чит илләр белән алыш-биреш итүгә катнаша алмаганнар. Хәрби өлкәне әйткән дә юк инде. Төрекләр белән сугыш чорында һәм башка кайбер «зур кампания»ләрдә сугышчан батырлыклары өчен офицер погоны йөртү хокукын яулаган берничә исемнән гайре чинлы-погонлы офицерларыбыз да булмаган. (Ә бит Россиянең ул чор төп зыялылары — офицерлар.) Ә инде егермешәр, егерме бишәр ел гади солдат газабын кичергәннәр — җитәрлек.

Бу җәһәттән Оренбург өлкә архивында тупланган генерал-лейтенант И. В. Чернов истәлекләренә күз салыйк. Иван Васильевич — тумышы белән атлы казак, гомере буена Оренбург атлы казаклары гаскәрендә хезмәт итә. Ә хезмәтен, истәлекләренә караганда, мөстәкыйль башкорт-мишәр-типтәр гаскәрендә башлый. Чөнки, ди ул, бу гаскәрнең баш командиры һәм штаб чиныдагылар фәкать миндәй атлы казаклардан билгеләнә иде, ди. Бу гаскәрнең «идарәсе (штабы) Кәрвансарайда иде. Ул вакытта (1840 ел) аның белән ротмистр Балкашин җитәкчелек итте... Полкларда урядниклар... муллалар — башкорт-татарлар...»

Дөрес, генерал Чернов искә алган чорда инде, алда әйтелгәнчә, бу гаскәрнең бер өлеше мөстәкыйль ханлык булып яшәгән дала казакълары белән башкорт-татарлар арасында йөз чакрымлы кордонкиртә кору өчен Урал суы буена, шундый ук хезмәтләр үтәү өчен Себер төбәкләренә күчерелгән һәм Оренбург казачий гаскәрләре сафына теркәлгән иде. Ә 1812—1813 елларда, бу милли гаскәрдән егерме полк французларга каршы сугышкан чорда, аның белән, билгеле, берничә рус генералы җитәкчелек иткәндер. Ул сугыш айларында исә бу полклар тулаем данлыклы атаман Платов карамагында булалар. Димәк, «данлы Платов казаклары»ның җиңү казанышлары милләттәшләребез өлешенә дә төшә. Тик безнең аларны барлаганыбыз гына юк. Әйе, Европа халыкларының һушын алып, Берлин, Париж урамнарында татар, башкорт атлылары да үз җырларын кычкырып җырлап йөрегәннәр икән ләбаса. Күп корбаннар таләп иткән сугыш, гадәттәгечә, дини чикләүләрне «чикләп» торган.

Шушы бер мисалдан да күренә ки, элек, патша заманында, сугыш афәте чыкса татарлар алда, ут эчендә. Ә көндәлек тормышта исә ул мулла яисә урядниктан да югарырак күтәрелмәскә тиеш саналган. Чит мәмләкәтләр, шул исәптән, Урал суы артында гына яткан солтан-ханлыклар белән элемтәгә керү дә аерым сәүдәгәрләргә генә рөхсәт ителгән.

Ләкин әкренләп бу өлкәдә дә үзгәрешләр туа, билгеле. Болгар дәүләте чорыннан алып сәүдә һәм һөнәрчелек белән көн күргән халкыбыз вәкилләре әкренләп бу өлкәдә буыннарын ныгыта барганнар. Әйе, егерменче гасырга кергәндә, вак һөнәрчелек һәм авыл сәүдәсеннән башлап та, ярыйсы ук биеклекләр яулауга ирешкән «зур бай»ларыбыз һәм «буржуй»ларыбыз да күренгәли, билгеле. Алар арасында Сембер якларыннан Акчурин, Дебердиевише фабрикантлар, сәүдә капиталыннан Чиләбе төбәге кешесе Яушев, Уфа һәм Киевтән фамилиядәш Максудовлар, Оренбург һәм Орск тирәләреннән бертуган Хөсәеневләр, Борнаев һәм бүтәннәр бар иде. Чал Урал тау һәм үрләре киңлекләрендә алтын приискалары ачып җибәргән Ганиев, Рәмиев, Дашкиннар булды.

Бу кешеләрнең барысы да, әлбәттә, ул дәрәҗәгә, ул биеклекләргә фәкать үз көчләренә, үз хезмәтләренә таянып кына күтәрелә алганнар. Әйтик, Урал тауларының төрле төбәкләрендә зур-зур заводлар корган капиталист Демидовлар ул капиталга маяны кайчандыр дегет кайнатып сатудан башлаган булсалар, «бай» Хөсәеневләрнең дә тәүге мал-мөлкәте йомран тотудан һәм шуның тиресен сатудан башлана ич. Рәмиевләр дә зур эшкә тотынганчы әүвәл кызыл мал сәүдәсе белән көн күрәләр, аннары гына утын сараеннан чак кына аерылып торган бер зур мич-казанлы бина алып, үз «сабын завод»ларын булдыралар.

Узган гасырда Байгузин дигән берәү (шулай ук чукынмыш бер бәндә булса кирәк), безнең халыкны мыскыллап: «Татарның төп максаты шәп лакей булуда»,— дип ышандырырга тырышса да, ирек,

мөмкинлекләр туу белән үк безнекеләр дә әнә чын эшкә тотына белгәннәр икән ләбаса!

Булачак шагыйребезнең әнисе Хәнифә дә әнә шундый күтәрелеп килүче татар эшлеклеләре нәселеннән була. Һәм, иш ишен таба, иш кушын таба, дигән кебек, ике эшмәкәр — Әлмөхәммәт белән Мөхәммәтсадыйк та бер-берләрен табышалар. Хәнифә Мөхәммәтсадыйк Рәмиевкә ярәшелә. Хәер, бу хәлгә дә гаҗәпләнәсе түгел. Сөт өстенә күтәрелгән каймак кебек һаман саен өскә калка барган ул катлам элек тә, гап-гади «чабаталы морза» дәверен кичергән караңгырак елларда да, яңа туган-тумачаны, кода-кодагыйны ерак-еракларга йөреп булса да үз тиңе арасыннан эзләгән.

Мондый гаиләләрдә яктыга үрелү, белем эстәүгә омтылу көчле була, балалар күңеленә кече яшьләреннән үк китап укуга, белемгә дәрт салына.

Хәнифә Дашкованы да әнә шундый кече яшьтән үк укуга, белемгә ымсынган кыз бала буларак күзалларга тиешбез. Габделкәрим Рәмиев үз улына аны яучылаганда Хәнифәнең укымышлылык һәм инсафлылык даны инде тирә-юньгә таралган була. Соңыннан аның хакында Дәрдеманд-Рәмиев чордашлары: «Хәнифә Дашкова... байтак укымышлы, эшлекле, акыллы хатын булганын сөйлиләр»,— дип яздылар.

Балаларына белем-тәрбияне дә ул яшьли үзе биргән, аларны үзе укыткан. Агалы-энеле Рәмиевләр белән күп еллар дәвамында бергә булган, бергә гомер кичкән Фатих Кәрими булачак шагыйрьнең рус телен, рус әдәбиятын авыл шартларында үсеп тә бик нык үзләштерә алуына исе китә. «Ул вакытларда рус теле өязләрдә, авылларда хәзерге шикелле нык таралмаган, русча өйрәнүнең юллары да хәзерге шикелле җиңел булмаган... Закир Рәмиев үзлегеннән русча телне сарыф, нәхүләре белән, дөрес язарлык, дөрес сөйләрлек, яхшы укып аңларлык өйрәнеп алган... Тәрекчә, русча телләрдә язылгын әсәрләрне укып торган»,— дип белдерә ул.

Болардан күрәбез ки, Дәрдеманд тә, абыйсы да рус телен һәм әдәбиятын башлап өй шартларында, әниләреннән ныклап үзләштергән булганнар. Дөрес, Хәнифә үзе берәр уку йортында тәрбияләнгәнме, яисә өй шартларында шулай укымышлы булып җитешкәнме, әлегә әйтеп булмый.

Ә менә өй тәрбиясенең бер өлгесен күңелендә саклаган шагыйрь дәфтәрендәге мондый бер шигырь, җем-җем итеп, үзенә тартып тора сыман, булачак шагыйрьне һәм аның анасы Хәнифәне тере иттереп күз алдына китереп бастыра сыман.

« — Әни, әкият сөйләче,
Сөйләмәсәң — йокламыйм!..»
« — Йом күзкәең, бәбкәм, йәче,
Дә тыңла, сөйлим балам:
Борын-борын бар икән, ди,
Хан баласы — яшь солтан.
Менгәне тулпар икән, ди,
Чөйгәне шоңкар булган...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Йокладыңмы, аппагым?..»
« — Шуннан, әни? Әни, шуннан?..»

## Юлык юлы

Закирга өч яшь тулмастан, 1862 елның җәендә, Рәмиевләр Оренбург губернасының икенче бер очындарак урнашкан Юлык авы-

лына бөтенләй күченеп китәләр. Рәсми кәгазьләрдә «Юлык ямы» дип йөртелгән бу кечерәк татар авылы Орск өязенең дә бер читендәрәк була. Авылның ул вакытта торган урынын, тарихын белмәсәң, сәүдә эшен уңышлы гына җәелдерә килгән Мөхәммәтсадыйк Рәмиев, төпләнер өчен аннан затлырак, һич югы зур шәһәрләргә якынрак берәр урын тапмаган икән, дип уйларга да бик мөмкин. Чөнки авыл буларак та, сәүдәгә җайлылык ягыннан да Юлык, әлбәттә, Җиргәннән күпкә калыша.

Җиргән, бердән, телдән һәм җырдан төшмәгән Агыйдел белән Ашкадар ише иң ямьле агымсулар куенында утыра. Урман дисәң урманы, тау дисәң таулары җанга, тәнгә сихәт бирә торган җир, бер күрсәң үзен һич тә генә онытмаячаксың. Икенчедән, Җиргән ике зур шәһәр арасында, олы сәүдә юлында урнашкан. Сәүдә кирәк-ярагына бай Урта Азиядән кайтарылган төрле-төрле ефәк-парчалар, хуш исле чәйләр, татлы җимешләр, арзанлы атлар, куй-сарыклар барысы да әүвәл Рәсәйнең бу төбәктәге сәүдә капкасы булган Оренбург базарлары аша үтәләр, ә ул базарларга исә моннан — Җиргән авылыннан нибарысы берничә көнлек кенә ат юлы ялтырап ята ич...

Рәмиевләрнең капыл гына кузгалуын авыл халкы да төшенми дә, өнәми дә диярлек.

— Ни-нәрсә калган ул җәһәннәм тишегендә Садыйк байга?

— Бик хаталана булыр! — дип аптырашалар алар.

Арадан, билгеле:

— Мөхәммәтсадыйк бай төпле-башлы кеше, берәр җае чыкмаса, кузгалмас ие,— дип юраучылар да табыла.

Әлбәттә инде, туган-үскән җирләрдә туган-тумачаны, кан-кардәштәй якынлашып, килешеп беткән күрше-күләнне калдырып китүгә хатын-кыз һәм бала-чагалар да бик каршы торалар. Елау-сыктаулар да аз булмый. Тик аларның барысын да җиңә, барысын да күндерә Мөхәммәтсадыйк бай. Алда тагын да матуррак тормыш-көнкүреш чамаланганлыгын, киләчәкнең өметле икәнлеген һәркемгә сиздерергә тырыша.

Арбаларга төялешеп атнадан артыкка сузылачак озын сәфәргә чыгып китәләр болар. Башта Агыйдел суы буйлап Ашкадар ягына, Эстәрле тамагына чаклы төшәләр, беренче зур тукталышны Эстәрлетамак каласында оештыралар. Икенче көнне дә аннан төш вакыты якынлашып килгәндә, күрәсе, саубуллашасы кешеләрне күргәч, кала кибетләреннән аласы соңгы әйберләрне сатып алгач кына юлга кузгалалар.

Эстәрлетамактан соң юл тагын да тарая, җайсызлана төшә. Чөнки инде монда тау табигатенә күнеккән, тау тормышына җайлашкан чын башкорт биләмәләре башлана; ургылып аккан тау елгалары аша салынган күперләр урыны-урыны белән язгы ташулардан соң тәмам рәтләнеп тә бетмәгән булалар. Шуңа күрә авыр йөк төялгән олаулар тау арасы юлларыннан бик әкрен баралар. Ә Мөхәммәтсадыйк бай, билгеле инде, яхшы пар атта гаиләсе белән алдан юртаклый да аннары берәр авылга кереп боларны көтеп ала. Шулай итеп, юл өсте авылларындагы татар, башкортның мулла, сәүдәгәрләрендә кунак була-була алар, ниһаять, максатларына ирешәләр.

Ике кечерәк елга кушылган җирдә, буй-сынга зәгыйфьрәк кенә күренгән усак белән каен катнаш урманчык үсеп утырган үрдә, әүвәл озын агач мәчет манарасы очы күренә. Озакламый, шелтер-шелтер итеп аваз биргән дуга кыңгыравы челтерәвен басып, биш яшьлек Шакирның шатланып кычкырганы ишетелә:

— Җиттек! Килеп җиттек!— ди ул. Аннары, хәреф таныганын белгертеп, иҗекли-иҗекли: — «Юл-лук-ский ямъ!» — дип, юл чатындагы багана язуын укырга керешә.

Жайлы-көйле тормыш-көнкүрешләрен тиктомалдан гына ташлап, губернаның төньяк-көнчыгыш тарафына юл тотучылар бу елларда шактый була, билгеле. Колак ишетмәгән, күз күрмәгән ниндидер Орск каласы тирәләрендә җир өстеннән алтынны учлап җыеп алып була икән, дигән хәбәр бөтен Рәсәй буенча тиз арада таралып өлгерә. Кешеләр, бәхет кошын тизрәк эләктереп калырга ниятләп, ашыгып-кабаланып, ил-җир читендәге шул шыксыз кала ягына юнәләләр. Элек тып-тын яткан тау, дала буйлары да, пошмас солдатлар белән көн-төн эчүдән әтәчләнеп йөрүче атлы казаклар гына «срок тутырып» яткан килеш-килбәтсез өяз башкаласы да тиз көндә җанланып китәләр.

Ике чиркәү, бер мәчетле тын шәһәргә затлы юртакларда гына җилдереп чабучы чуар киемле көяз халык килеп тула. Өй-фатир хаклары бермә-бер арта, сәүдә эшләре гөрләп алга китә, көндәлек кирәк-ярак күзгә күренеп кыйммәтләнә. Әйтәвер, монда тиздән мәхшәр көннәре башлана! Берәүләр күз ачып йомган арада дан-шөһрәтле байга әвереләләр. Уңалар. Чама-чутлары чамалыраклар һәм артык түземсез бәндәләр исә, тиз көндә юртак һәм фаэтоннарыннан колак кагып, җәяүлегә калалар.

Менә шулай башлана Орск өязендәге бу мәгълүм «алтын бизгәге».

Безнең сәфәрчеләрне дә әнә шул «бизгәк» шушы тирәләргә әйдәп китерә дә инде. Ул алтын дигәннәре бик алай аяк астында ук ятмаса да, сабыр итсәң, чарасын күрсәң, аның кулга керәчәгенә шик тумый.

Дөрес, бу урында чигенеш ясап әйтим, алтынга бәйле табышалышлар безнең илдә элек-электән сер итеп сакланган. Бүген дә ни Оренбург, ни Уфа шәһәрләре архивларында ул серне ачкан бер генә кәгазь кисәгенең дә кулланышта булмаганлыгын танырга тиешбез. Оренбург губернасында, аның алтын үзәкләре саналган Орск, Троицк, Югары Урал (Верхнеуральск) төбәкләрендә элекке заманнарда күпме прииска тотучы алтынчы исәпләнгән, алар күпме хәзинә алганнар — ачыклавы читен. Әмма мондагы җирләрнең исәпсез-хисапсыз бай булганлыгы һәркемгә мәгълүм.

Россиягә кушылганнан соңгы Урал тарихында, әлбәттә, алтын, көмеш һәм кыйммәтле таш-җәүһәрләргә бәйләнеше булган кәсепчелектән бигрәк, киләчәк промышленность куәте һәм сугыш кирәкләре өчен мөһимрәк саналган крепостной заводлар — бакыр, чуен, корыч коючылык кәсебе өстенлек иткән. Көнбатыш һәм көнчыгыш тарафларда яулап алу сугышларын дәвам иттерү өчен патша хөкүмәтенә Уралда коелган яисә Урал рудасын кулланып Тула ише үзәкләрдә эшләнгән бихисап туплар кирәк булган. Аннары да һаман саен киңәя һәм җәелә барган Россиянең чагыштыргысыз иген-чиген тоташтырган тимер юллар өчен меңәрләгән чакрым рельсларны, ул юлларның корыч атларын — паровоз һәм вагоннарны шулай ук Демидов, Твердышев ишеләрнең Урал заводлары җитештереп торганнар. Узган гасырның күренекле әдибе Глеб Успенский язганча, мескен башкорт ыру-кабиләләренең җирләрен рәхимсез рәвештә сату, талау дәвам иткән. Иксез-чиксез хәзинә-байлыклы ул җирләр ыру-кабилә би-бәкләрен, старшиналарын юмалау, алдау һәм хәтта өркетү юллары белән яңа хуҗаларга күчә барган. Мәсәлән, Тула промышленниклары Твердышев белән Мясников шушындый асыл йөз мең дисәтинә җирне нибарысы өч йөз сум бәрабәренә сатып алганнар. Зур капиталлы башка байлар да өлешсез калмаган, әлбәттә. Фәкать җирле халык вәкилләренә генә өлеш чыкмаган. Аларга мондый кәсепчелеккә юл байтак соң ачылган.

Әйе, Урал кәсепчелек тарихының икенче сәхифәсе байтак соң,

гасырлар үткәч, Твердышев, Демидов ише акулалар бу мал-хәзинәләрнең түшкәсен ботарлап бетергәч кенә башлана. Шулардан калганнар белән чемчену шулчак вак сәүдәгәрләргә дә рөхсәт ителә. Болары инде, билгеле, зур капитал таләп иткән андый зур-зур завод-крепостьлар салуга керешмиләр, җир өстенә якын яткан хәзинәләрне генә барларга тотыналар. Бу вакытта патша хөкүмәте җирләрне дә умырып-батырып түгел, чеметеп кенә сату, өләшү кәсебенә керешә: бер кулга берьюлы ике йөз дисәтинәдән дә артык өлеш тими. Әмма, уңган очракта, шул бер кишәрлек җир дә аның иясен әлегәчә хыялда да булмаганча байлыкка күмәргә мөмкин икән, дигән хәбәр бөтен Россия буйлап тарала. Киләсе караңгы көннәргә дип чүлмәк төпләренә туплана барган маяны чамалаган кешеләр, өстәп бурычка ала-ала булса да, «алтын җирләре»н сатып алырга керешәләр.

Әнә, шулай итеп, Орск өязенең даны еракларга тарала. Унбиш-егерме ел үтмәстән монда төрле акционер җәмгыятьләре, сәүдә һәм кредит банклары калкып чыга. Хәтта чит ил капиталы да тизрәк моңа борын тыгарга ашыга: катнаш кредит банклары, төрле җиһаз хәстәрләүче вак хуҗалыклар барлыкка килә.

Әлегәчә тын яткан тау һәм даланың елга-инешләре буенда бер-бер артлы бихисап алтын юу приискалары ачыла. Таналык, Үзән, Сөендек ише су буйлары, әмир Аксак Тимернең яу вакытларын хәтерләтеп, тагын бер җанланып алалар.

Бу чир, бәхеткә күрә, татар дөньясына да кагыла. Үзләрендә калын кесәле рус сәүдәгәрләре белән тиң тора алырдай көч-куәт һәм шундый катлаулы эшне очын-очка ялгап чыгардай оештыру сәләте тойган «бай»ларыбыз көрәш мәйданына ташланалар. Тиздән алар арасына чиратка Мөхәммәтсадыйк Габделкәрим улы Рәмиев тә барып баса. Әлегәчә җайлы гына аккан тормышын олы мәшәкатьләргә дучар итеп, өендә елаш-сыкташ мәхшәре тудырып, туган-үскән якларыннан кузгалып китүенең сәбәбе әнә шул чир йогудан була ди инде. Әлегәчә күз күрмәгән, колак ишетмәгән «караңгы як»-ка, Юлык ямы авылына сәяхәтнең сәбәбе әнә шунда.

Казан ханлыгының көнчыгыш өлешләрендә, тау-тезмәләр башланган Бөгелмә якларыннан алып Урал арты далаларына чаклы бер зур мәйданда, элек-электән үк җир асты байлыкларын казып чыгару, эшкәртү кәсепләре яшәгән. Бу хәлнең телсез шаһитлары булып хәзерге көндә Урал тау куеннарында һәм Урал арты дала-тигезлекләрендә бихисап күп борынгы казылма тау куышлары һәм җир асты җәһәннәменең караңгылыгына уелып төшеп киткән тирән кое калдыклары саклана. Бүген ил күләмендә иң бай бакыр ятмасы булган Орск шәһәре янәшәсендәге Гай ятмаларына да борынгы бабаларыбыз шундый коелар аша төшеп йөргәннәр икән. Үрмәләп төшкән, чыра тотып яктырткан, кәйлә белән чокып алган...

Юлык авылы янәшәсендә дә шундый бер борынгы хәзинә чокыры бар. Димәк, монда, әле авыл барлыкка килгәнче дүрт-биш гасыр элек үк, ерак бабаларыбыз эз калдырган икән. Хәер, мондагы якын-тирә җирләр элек-электән бакыр чыганагы сыйфатында гына түгел, алтынлы булу белән дә дан казанган җирләр икән. Ә инде «алтын бизгәге» кузгалган заманнарда әледән-әле биредә анда да, монда да яңа приискалар бер-бер артлы ачылып кына торган.

Менә нилектән Мөхәммәтсадыйк Рәмиев гаиләсе узган гасырның алтмыш икенче елы җәендә шушы бәрәкәтле туфракка килеп төпләнгән. Билгеле инде, уптым илаһи кузгалганчы әле Мөхәммәтсадыйк сәүдәгәр, Орск каласы тирәләренә килгәләп, кайда төпләнергә мөмкин икәнлеген чамалап йөри. Бу төбәкнең таулы өлешен дә, куе кылган тирбәлеп утырган дала якларын да, мөгаен, бер килүдә,

дә генә барлап, йөреп тә чыга алмагандыр.

Оренбург губернасы ул вакытта, Казан губернасы белән ике арага уелган яңа Уфа биләмәләренә үз «провинция»ләренең бер өлешен бүлеп бирүгә дә карамастан, әле барыбер зур мәйдан алып торган. Рәмиевләр көченгән чорда ул губерна зур-зур биш-алты өязгә бүленгән була. Ул өязләрнең дә иң зурысы исә — Орск шәһәренә буйсынганы исәпләнә. Шушы вакыйгалардан ярты гасыр соңрак яшәгән Мирхәйдәр Фәйзи фикеренә тукталу бу җәһәттән кызыклы булыр. «Башка җирләр белән чагыштырганда Орск өязе Курскиның бөтен губернасы кадәр, чит мәмләкәтләрдән Даниянең бөтен җире Орск өязеннән кечерәк икәнен белдем»,— дип сокланып яза ул 1917 ел февралендә, Орск җир управасында Хаҗиәхмәт Рәмиев кул астында эшләп алган бер дәверендә.

Ул вакытта, Октябрь революциясенә чаклы, Орск өязенә хәзерге Башкортстанның да Сакмар елгасының көнбатыш тарафка кинәт борылышына кадәрге югары өлешеннән алып, хәзерге Оренбург һәм Чиләбе өлкәләре чикләренә кадәрге бер зур кисәге кергән булган. Дөресен генә әйткәндә, монда, ул вакыттагы ил чигендә урнашкан бу губернада, географик иркенлек кенә түгел, беркадәр сәяси иркенлек тә күзгә ташлана. Беренчедән, монда, крепостной заводларга, ягъни, патша хөкүмәтенә турыдан-туры буйсынудагы заводларга караган чагыштырмача аз санлы крепостной эшчеләрдән кала, кемгә дә булса кол хәлендә буйсынган кешеләрнең юклыгы хас. Крепостной крестьян тотучы алпавыт җирләре биредә юк. Ә инде бу губерния биләмәләрендә көн күргән җирле татар, башкортларда андый коллык законнары борынгыдан ук булмаган — алар һәрвакыт ирекле җәмгыять рәвешендә яшәгәннәр; теләсә кем, түләнмәгән бурычы булмаган очракта, бер урыннан икенче урынга ирекле рәвештә күченеп йөри алган. Үзен бер кадәр хөр хис иткән. Һәрхәлдә, беркем дә берәүгә дә кол булмаган.

Мөхәммәтсадыйк Рәмиев, әнә шул Курск губернасына тиң Орск өязен аркылыга-буйга йөреп чыкканның соңында, төпләнү урыны итеп Юлык төбәген сайлый. Бердән, аңа бу җирнең табигате ошагандыр — кошлары сайрап торган урманы да, киек җәнлек иректә чабардай ачыклыклары да, фәлсәфәгә бирелеп, уйланып, ерак-еракларны күзәтеп торырдай тау түбәләре дә бар ич. Нәкъ менә Җиргән якларындагы кебек. Дөрес, якындагы япан дала сулышы монда ныграк сизелә, әлбәттә. Җиргән якларында урман-агачлар эрерәк кәүсәле, үләннәр куерак һәм сусылрак иде. Әмма монда җир тоташы белән бакыр да алтыннан тора ич!

Шулай, җирдәге хәзинәгә күзен төбәп, күңелен беркетеп килсә дә, башта ул, билгеле инде, тиз генә бу өметен тормышка ашыра алмый — күңеленә ошаган, хәзинә-байлыгы билгеләнгән урынны тапкач та бит әле югарыдан, ерак Петербургтан аны сатып алырга рөхсәт килүен көтәсе бар. Әлбәттә инде Мөхәммәтсадыйк аннан киләсе рөхсәтне кул кушырып көтеп утырмый: ике йортның берсе вактөяк белән алыш-биреш итеп көн күргән Юлык белән генә чикләнмичә, якын-тирә башкорт авылларында да үз сәүдә эшен җәелдерә. Башлыча әле күчмә тормыш белән яшәгән һәм кирәк-яракны күбрәк вакытта алдан бурычка алып та, көзге муллыкта гына исәпхисапны өзүче башкорт йорт-утарларына ул, тәвәккәлләп, малын бурычка өләшә. Шуның белән дә тирә-юньдә байның бае дигән шөһрәт казана.

Иң әүвәл ул, төпләнер урынын сайлагач та, бер Юлык сәүдәгәренең авыл читендәге сабын заводын — зур казан куелган иске йортын сатып ала. Анда җитештерелгән сабын белән үзе дә, кырык тартмачы вак сәүдәгәрләр дә сату итәләр. Үсә төшкәч тә Рәмиевнең

уллары да кул астына керә башлыйлар, әлбәттә.

Әйе, беренче тормыш сабакларын шагыйрь Дәрдемәнд тә, аның абыйсы Шакир да иң әүвәл менә шушы кечерәк бер татар авылында алалар. Димәк, алар уй-хисләре белән дә, тормыш-көнкүрешләре белән дә башка авыл балаларыннан әллә ни аерылып тормаганнар. Фәкать өйдә ана тәрбиясе көчлерәк булган, шул тәрбия яшьли аларда белемгә омтылыш хисен уяткан. Ә калганында инде гадәт-йолалар бер, фәлсәфәләр уртак — кеше үзара мөгамәләдә һәрчак гадел булсын, якыннарына даими рәвештә кул сузып, ярдәмләшеп яшәсен — төп тәрбия шул булган.

Аталары Мөхәммәтсадыйк та әле ул дәвердә, Максим Горькийның бер әсәрендә гәүдәләндерелгән карт сәүдәгәр Артамонов кебек, һәр эшне үзе башлап, өмәче һәм булышчылары белән бергә аны үзе башкарып йөргән. Берәр авырлыкны алып саласы булганда өмәчеләренә: «Әйдә, тоттык!» яисә, «Әйдә, күтәрдек!» — дип юл күрсәтә-күрсәтә, һәр эшне үзе әйдәп эшләтә торган булган.

Мөхәммәтсадыйкның уллары да алпавыт, бояр балалары кебек, эшсезлектән интегеп, бөтенләй иркәлектә генә үсмәгәннәр, көн белән төннәрен күпергән күпчек өсләрендә аунап кына үткәрмәгәннәр. Юлык авылында булсын, яисә Муллакай мәдрәсәсендә, Орск шәһәрендә булсын — бертуган Рәмиевләр үз яшьтәшләре белән аралашып, аларның уй-фикерләрен уртак тоеп үскәннәр.

Дөрес, байларны ярлыларга, хезмәт халкына каршы куеп тасвирлау модада чакта язылган бер мәгълүм повестьта буй җитеп, үзләре эш йөртә башлаган борадарән Рәмиевләрне ямьсез эксплуататорлар итеп рәвешләндерү истә калган. Әмма гомерләрен татар халкының аң-белемен күтәрүгә, тормышын көйләүгә багышлаган бу шәхесләрнең андый образлары белән бик үк килешәсе килми. Хәер, теркәлеп калган күп санлы истәлекләр дә алай фикер йөртергә җирлек тудырмый шикелле. Әлеге әсәрдә чагылган тормыш, бердән, гомумиләштерелгән бер образ булса кирәк. Икенчедән, бәлки, ниндерсәгәдер үпкәләү дә үзен сиздереп куйгандыр...

Инде шул яшьлек мизгелләрен, Юлык тирәсе табигатен күзаллардай бер-ике шигырь белән танышып китик.

...Бер заман чыгар идек без
Кырга дуст-ишләр илә;
Анда уеннар, көлүләр,
Сикерүләр бар иде.
Бер вакыт бунча рәхимсез
Дәгел иде кызлары;
Анда туташларда ымлар,
Күз кысулар бар иде...

(«Үткән көннәр»дән өзек.)

Көн кызды!.. Кызды һава монарланып,
Сагымлап, кыр белән дала чобарланып.
Һава тымык, шылт итми!.. Кысылды тын:
Ягъмур көтә җирнең йөзе комарланып...

(«Яңгыр»дан өзек.)

Язларның килде җитеп якты көне,
Ишетелде һавада аккош өне,
Талпынып салмак, авыр күк йөзендә,
Күренде килгән очып каз төркеме...

(«Яз» шигыреннән өзек.)

Бу шигырьләрне, әлбәттә, һич кенә дә Юлык чорында язылганнардыр дип раслау килешмәс. Мәгәр, нәкъ шул дәвердә, Юлык авылына, аның кешеләренә һәм табигатенә мөнәсәбәтле рәвештә, булачак шагыйрь күңеленә, мөгаен, беренче шигъри фикерләү дәрте иңгәндер. Хәер, еракта, Оренбург шәһәре янәшәсендәге Каргалыда яшәгән икенче бер олы шәхескә — шагыйрь һәм яшьләрнең остазы булган мулла вә мөгаллим Сибгатулла хаҗига багышлап язылган шигырьнең шушы Юлык ямы авылыннан юллануы безгә мәгълүм ич!

## Юлык авылы

Элек-электән башкорт ырулары көн күргән көнчыгыш Урал таулары уртасында бу татар авылының барып төпләнүе гаҗәп тә үзенчәлекле. Мәгълүм бер мәкальдә: «Һәр гаиләнең көнкүреше, яшәеше үзенчә»,— дигән фикер ятса, гореф-гадәтләр һәм йолалар нигездә уртак булган башкорт халкы арасына күченеп утырган татар авылларының да һәммәсенең үзенә бер тарихы, үзенчәлеге бар. Бер ишеләре чукындырудан качып, монда сыенып урын эзләп килгән; икенчеләре теге яисә бу уңай белән патша хөкүмәте, губерналар тарафыннан күчерелгән. Өченчеләре исә, үз илләрендәге имана җирләренең кысанлыгыннан иза чиккәнлектән, иркен җир эзләп шушы тирәләргә килеп чыкканнар.

Юлык авылы кешеләре дә ерак бабаларының Казан тирәләреннән бәхет эзләп монда килеп төпләнүен бәян итәләр.

Авылга кагылышлы истәлекләрне алтмышынчы елларда пенсионер-укытучы Гомәр Әбүбәкеров берничә аерым дәфтәргә теркәп калдырган. Шунда ук ул күрше Юмаш авылында яшәгән бер «бик белгеч карт»ның сөйләкләрен дә искә алуын белдерә. Гомәр Әбүбәкеров тумышы белән шушыннан; ерак бабасы Юлыкка килеп беренче төпләнүчеләр исемлегендә китерелә.

Гомәр ага 1910 елдан 1914 елга кадәр Орск шәһәрендә укытучылар хәзерләүче дәрелмөгаллимин мәдрәсәсендә укый. Герман сугышы башланган елда туган авылына кайта, Рәмиевләр салдырган таш мәчет карамагындагы Зур мәдрәсәдә укыта башлый. Димәк, ул Рәмиевләр заманы авылын да, совет чоры авылын да яхшы белгән кеше: гомере шушында узган. Ә инде авыл тарихын сөйләп калдырган күрше Юмаш карты исә тагын да өлкәнрәк яшьтә булган.

Менә ул ике авыл кешеләре күңелендә сакланган тарих.

Өч йөз еллар әүвәл, имештер, бөрҗән башкортлары яшәгән шушы төбәккә, җир эзләп, дүрт татар килеп чыгалар. Ул дәвердә бу тирә башкортлары әле күчмә тормыш белән яшиләр, утрак авыллар бик сирәк була. (Мирхәйдәр Фәйзи замандашы Садыйк Чанышев, әдипкә багышланган истәлекләрендә, мондый хәлнең әле 1922 елда да дәвам итүен, бу төбәк халкының ярым күчмә тормыш алып баруларын яза.)

Шулай итеп, аркаларына биштәр аскан, аякларына чабата кигән дүрт татар мондагы көмеш сулы елгачык буена хәл алырга туктаганнар икән. Йончыган кыяфәтле бу кешеләр бит-кулларын юып торганда яннарына, имеш, Юмаш исемле карт килеп чыккан.

— Кемнәр һез? Каян киләһегез?— дип ул сораша башлаган.

— Авылыбыз белән бу якларга күченеп утырырга ниятлибез, сатулык җир биләмәсе сайларга безне җыенибыз җибәрде,— дип җавап кайтара әлеге мосафирлар.

Бу Юмаш картның үз биләмәләре дә шушы тирәләрдән бик

ерак түгел, Кус елгачыгы буенда гына икән. (Хәзер ул урында зур гына Юмаш авылы, аннан Юлыккача ун-унике километр чамасы ара. Алтмышынчы елларда колхоз үзәге дә шул башкорт авылына күчерелгән.) Ә ыру башлыклары, аларның җир биләмәләре әлеге мосафирлар очрашкан урыннан егерме биш-утыз чакрымнар арырак булган. Җир белән алыш-биреш итү алар вазифасы, дип аңлата да, имеш, Юмаш карт бу мосафирларга болай дип әйтә:

— Беззә һату йере йук... Мәгәр, бер йомышыбызды үтәргә алынһагыз, йерһез калмаһһыгыз...

Һәм ул ак патшаның алар ыруына ям тоту йомышын йөкләгәнлеген сөйләп бирә.

— Ак батша безгә Ырымбур, Орск, Верхурал юлларында кырык дугадан ям тотарга боерзы. Беззә ул кадәр камыт-арба йук. Шул йомышты өстеңезгә алһаңыз, йер табарбыз,— ди бу карт.

Мосафирлар, имеш, аның фикерен хуплыйлар. Шуннан соң Юмаш карт аларны ыру башлыклары җәйләвенә алып китә. Шунда болар, имеш, сүздән вәгъдә куешалар: мосафирлар патша хөкүмәте ташырга кушкан йөкне һәм почтаны кирәкле урынга вакытында илтеп җиткерер күләмдә арба һәм аңа кирәк-ярак ат дирбиясе табалар, бөрҗәннәр аларга күпмедер ат бирә, авыллап утырырдай җир бүлә.

Шулай итеп, борынгы почта юлы буенда, әлеге карт биләмәләре янәшәсендә (хәзерге Башкортстанның Баймак районы мәйданында) Юлык авылына урын күрсәтелә. Казан губернасының Арча төбәге (юлы) авылларыннан шул ук җәйдә бу урынга егермеләп гаилә килеп төпләнәләр. Юлык ямын тотучылар, ягъни, кышын да, җәен дә гомерләрен юл йөреп, почта ташып яшәүче ямчы-юллыклар шәҗәрәсе шушыннан башланып китә инде. Шуңа күрә авыл исеме дә «Юллык» була.

Бу истәлекләрдә, нигездә, барысы да дөрестер сымак. Тик башкорт ырулары үзәгенә Мәгәш, Бикташ һәм Әдһәм мосафирларының җир эзләп очраклы килеп чыгуы гына шикләндерә. Асылда алар ул заманда Казан губернасының бер почмагы саналган бу тирәләргә ыру башлыкларының әлеге үтенече нигезендә алдан сайлап җибәрелгән кешеләр булганга охшыйлар. Губерна канцеляриясе исеменнән аларны юлга озатканда, мөгаен: «Барыгыз, урын-җирләрне карап кайтыгыз. Ошаса, күчәрсез»,— дип әйткәннәрдер.

Петр патша реформаларына чаклы губерналарның дүрт тарафтагы дүрт-биш «юл»га гына бүленеп йөртелүен искә төшерсәк, «Арча юлы» төшенчәсенә, гомумән, Казан арты авыллары кергәнлеген чамаларбыз. Тугандаш башкорт халкы яшәгән җирләрдә ямчы хезмәтен үтәргә алынучыларның да бер документта төгәл адресы теркәлгән икән: алар «Арча юлы Шары (Чары булса кирәк) сотнигы Кулеев Зиләлпунал авылыннан» булганнар.

Хак дөресе шул, киләләр болар, йорт-кирә булдыралар, яши башлыйлар. «Кырык дуга»га атлар җигеп төрле тарафларга почтаны һәм патша чиновникларын чиратлап йөртә башлыйлар. Шуның өстәвенә бу авыл кешеләре үз карамакларындагы юлларын тәртиптә тотарга, күперләрне даими төзәтеп торырга да тиеш булалар. Кышкы буранларда адашмас өчен юл буе маякларын утыртып чыгу да бу татар ямчылары хезмәте исәпләнә.

Юлык авылын камап, якындагы Сакмарга таба, ике елга агып ята. Шуларның зуррагына авыл урынын эзләүдә башлап йөрүче Мәгәш исеме кушылган, кечерәге Төгәл атамасын йөртә.

Монда килеп яши башлагач та, билгеле инде, бу фани дөнья белән алыш-бирешләрен өзүчеләр дә ишәя бара. Авыл очындагы үр кырыенда зират барлыкка килә. Гомәр ага Әбүбәкеров дәфтә-

ренә теркәлүенчә, беренче истәлек ташы анда 1668 елда куелган икән. Авылның озын манаралы агач мәчете 1768 елда салынган, аңа чаклы гыйбадәтне зуррак бер авыл өендә укыганнар булса кирәк. Беренче мулла-мәзиннәр Әдһәм баба токымыннан булганнар — Әдһәмовлар. Гомәр ага дәфтәрендә шулай ук манаралы мәчет нигезләнүдән алып 1900 елгача беренче мәхәллә имамнарының исем-фамилияләре китерелгән.

Юлык авылы тора-бара шушы төбәктәге бер зур сәүдә үзәгенә әверелә. Моның сәбәпләре авылның тарихына бәйле, билгеле. Аларга мин соңрак тукталырмын. Хәзер исә — ярминкә. Һәр җәйдә, июнь башларында, Юлыкта ун-унике көнгә сузылган кызыл мал ярминкәсе уздырыла торган була. Аңа үз сәүдәләре белән Орск, Оренбург, Троицк, Чиләбе, Каргалы, хәтта Эстәрлетамак якларыннан да кызыл малчылар җыелалар икән. Моннан тыш бу авылда һәр сишәмбе көнне атналык базар оештырыла, аңа инде башлыча тирә-як авыллардан сатып алучылар җыелалар. Сугым малын да шушы атналык базарда сата торган булганнар.

Шуңа күрә дә авыл тиз үсә, озакламыйча монда икенче мәхәллә дә ачыла. Егерменче гасыр башында, таш мәчет салынганда, Юлыкта дүрт йөз хуҗалык исәпләнгән. Бу вакытларда инде авыл халкы ике җәмгыятькә — ясаклылар белән мещаннарга бүленә, боларның старосталары да аерым-аерым сайлана торган була. Моның шулай булу сәбәбен Гомәр Әбүбәкеров авылда сәүдәгәрләр белән һөнәрчеләрнең күп булуыннан күрә. Язмасының бер почмагына: «Ясаклылар килмешәк мещаннарны кысрыкларга тырыштылар»,— дип тә өстәп куя.

Алда әйтелгәнчә, авылның шушы төбәктә базар һәм ярминкәсе белән дан тотуына, әлбәттә инде, һөнәрчеләре белән сәүдәгәрләре сәбәпче. Юлыкка җир биләмәсен билгеләгәндә башкортлар никтер бик саран кыланалар: авылдан бер чакрымнан ары китеп сабан борынын төртмәскә, дип кисәтәләр. (Әлеге факт шулай ук авыл халкының бу якларга үз ирке белән генә җир эзләп килмәгәнлегенә ишарәли.) Ә ул бер чакрым киңлектәге басуга атка дип солы чәчсәң, үз ризыгыңны чәчәргә урын калмый, үзеңне генә кайгыртсаң, озын юлга йөргәндә атыңа ни ашатырсың? Шушы мөшкел хәлдән чыгу өчен кешеләр һөнәрчелек кәсебенә керешәләр: чиккән калфаклар, кәләпүшләр тегәләр, балчык белән агачтан уенчыклар ясыйлар, йорт-кирәк ярагына дип башка төр әйберләрне күпләп җитештерергә керешәләр. Ә инде ям хезмәтен үтәргә дип юлга чыкканда шул әйберләрне үзләре белән алалар, кырык тартмачыга әвереләләр. Ә кайтышлый күрше башкорт җәйләүләрендә үтемле саналган башка мал-мөлкәт алып, шуларны авыл базарына чыгара торган булалар. Шулай итеп, бу авылда һөнәрчелек һәм сәүдә эшләре бик алга китә.

Рәмиевләр менә шушы авылга килеп урнашалар. Ул вакытларда Юлыкта Мастак карт Искәндәрев, Сөләйман Әдһәмов, Хәйбулла Әбүбәкеровлар зур кибет тотучы олы сәүдәгәрләр исәпләнгәннәр. Ә Мөхәммәтсадыйк бай килеп утыргач исә авыл сәүдәгәрләренә беркадәр кысрыкланырга туры килгән.

Мөхәммәтсадыйк Рәмиев Юлыкта да эшне зурдан башлаган. Килеп, тупланып, бераз баш-күз алгач та ул, бу якларда күрелмәгәнчә, таш пулатлар салырга ниятләгән. Ташчы осталарны Оренбург арты Каргалысыннан ялларга булганнар. Шуннан соң, авылны ямьләндереп, Юлыкның бер очында Рәмиевләрнең таш келәт, таш йорт, таш кибетләреннән торган пөхтә, матур утары күтәрелеп чыккан.

Монда килеп яши башлавының беренче елларында ук ул кешедән сатып алган сабын заводына өстәп күн эшкәртү цехы, «күн фабригы» да булдырып куя. Әмма аның төп хыялы, әлбәттә, башка эре сәүдәгәрләр кебек берәр алтын приискасы ачып җибәрү һәм шуның рәхәтен күрү була.

Юлык халкы инде андый эш белән бераз таныш була: авылдан дүрт-биш чакрымдагы Мәмерия дигән җирдә элек-электән әз-әзләп алтын комын юганнар икән. Ләкин Мөхәммәтсадыйк бай, билгеле инде, Мәмерия алтынчылары кебек бер кулга иләк, икенчесенә соскы тотып кына эш итәргә, алтынны бөртекләп кенә чүпләргә теләми. Зурдан эш башлардай бер мөстәкыйль биләмә-урын эзли. Эзли торгач андый урын да табыла — Юлыктан сиксән чакрымнардагы Ишбирде приискасына беренче казык кагыла, кирәкле кәгазьләр Оренбург белән Петербург түрәләре карамагына ышанычлы кешеләр аша җибәреләләр. Шуннан соң инде, 1869 елдан, «алтын приискалары тотучы Рәмиевләр» дәвере башлана.

Алга табарак алар ике-өч елга бер яңадан-яңа прииска ачачаклар. Хәер, шундый зур эшкә бер алынгач, ансыз мөмкин дә булмый. Чөнки бит патша хөкүмәтенең дә таләпләре кырыс: хәзинәле биләмәләрне бер кулга әз-әзләп кенә өләшә дә, шуны үзләштереп, дәүләткә файда китерсәң генә икенче калҗага сузылырга рөхсәт бирә.

Мөхәммәтсадыйк байның исә яңа кәсебе баштан ук уңышлы башлана. Беренче бөтендөнья сугышы башланыр алдыннан инде Рәмиевләр, кыр, дала буйлап китә-китә Юлыктан шактый ук ераклашалар — Троицк тирәләренә үк барып чыгалар. Алар эш йөрткән биләмәләрнең иңе-буе Европаның кечерәк дәүләтен сыйдырырлык мәйданга тарала. Ишбирдегә иш итеп Сәхра, Чуртан, Кумак, Кучкар, Балкан, Симунский, Шәйхан, Восьмой кебек егермеләп чыганак ачыла. Орск шәһәре халкы соңрак: «Тарта Орск егетләрен Рәмиевләр алтыны»,— дигән шаян такмак чыгарсалар да, әлбәттә, беренче чиратта бу эшкә Юлык ир-егетләре алына. Дөресен әйтергә кирәк, алар җир астына төшеп, кәйлә белән җир куышын чукучылар арасында бик алай ишле булмый. Ә менә исәп-хисап эше, йомышчы-булышчы, десятник, әртилче хезмәтләрен бик теләп башкаралар. Авыл булып оеша башлаганнан бирле мулла-мәзинлекне кулдан ычкындырмаган Әдһәм баба токымы бу җәһәттән аеруча шөһрәт казана: Рәмиевләрнең дүрт приискасының идарәчеләре шушы Әдһәмовлардан була. Мәсәлән, Күсәй авылы янәшәсендәге Ишбирдедә — Зариф Әдһәмов Троицк шәһәре тирәләрендәге бер приискада Камал Әдһәмовның баш идарәче булганлыкларын әйтәләр.

Мөхәммәтсадыйк Рәмиев тора-бара үз вазифаларын улларына тапшыра. Юлыктагы төп утар һәм приискалар эшен алып бару, исәп-хисап тоту Шакир Рәмиевкә йөкләнә. Моңа инде ул әкренләп әзерләнгән була. Чит-ят илләрдә алтын чыгару эшенең барышы һәм бу кәсептә кулланылган яңа җиһаз-техника белән танышу өчен ул Европа илләренә барып, анда күп нәрсәгә өйрәнеп кайта. (Дөрестерме, юктырмы, имеш ул, үләр алды елларында саташып, ишегалдындагы кош-кортка французча гына дәшә торган булган.)

Шакир прииска эшләрендә генә түгел, Юлык утарында да байтак үзгәрешләр кертә. Мәңгелеккә булсын дип, 1898 елда үз утарлары каршында зур таш мәчет салдырта башлый. Бу мәһабәт мәчет бүген дә авылга матурлык биреп тора: зур да, иркен дә, биек тә ул. Ерактан ук күңелне үзенә тартып, илһамландырып кояшта балкый сыман аның зур-зур тәрәзәләре...

Агалы-энеле Рәмиевләр тырышлыгы белән мәчеткә нигез салын-

ган елда ук авылда яңача белем бирүче мәдрәсә ачыла. Анда рус теле һәм әдәбиятын укыту классы да булдырыла. Орск өязенең мәгариф бүлеге карары нигезендә, бу класс укытучысына хезмәт хакын өяз түли. Юлык мәдрәсәсендә арифметика, алгебра, физика, география, тарих дәресләрен укытыр өчен заманына күрә белемле саналган, чит-ят җирләргә барып укып кайткан мөгаллим-хәлфәләр кайтарыла. Шундыйлардан Харис Әдһәмов, Фазылҗан Зәйнигабдинов, Гыймадетдин Әбүбәкеров, Хәбиб Гобәйдуллиннарны монда мактап телгә алалар.

Җәдид мәдрәсә ачылгач та тәүге ике уку елында рус классы дәресләрен Әмирхан Вәлиди дигән кеше алып бара. Ә 1900 елда бу эшкә читтән Каһарман Чанышев чакырып китертелә. Ул Совет власте елларынача Юлык балаларына русча белем бирә. Революциядән соңгы дәвердә Юлык, Темәс (бер ара Зәки Вәлиди җитәкчелегендәге Башкортстан җөмһүриятенең «башкаласы»), Баймакларны эченә алган Тангаур-Бөрҗән кантонында мәгариф һәм мәдәният эшләре башында торган, шул чорда драматург Мирхәйдәр Фәйзинең якын дусты булган Садыйк Чанышев — шушы «урыс хәлфә»нең улы инде.

Рәмиевләр мәчетенең мулласы һәм мәчет карамагындагы мәдрәсәнең башлыгы Барый Зайнигабдинов була. Шушы ук елларда аның бертуганы — Абдулла — Орск шәһәрендәге биш мәчетнең берсендә имам булып тора. Мулла Барыйга исә мәхәллә атасы Сәлих ахуннан кала. Ул урын бушаганчы Барый берникадәр вакыт Рәмиевләр кәнсәсендә дә эшләп ала. Авылдашлары күңелендә заманча карашлы кеше буларак истә калган. Аның варислары бүген дә аталары юлын дәвам итәләр — Юлык балаларын укыталар.

Билгеле, Юлык авылының Рәмиевләр дәвере мәдәни дөньясында иң якты эз калдыручы сыйфатында Гәүһәр Рәмиева гәүдәләнә. Гомумән, Рәмиевләрнең хатыннары үзләре яшәгән тирәлектә яшь буынга тәрбия бирү өлкәсендә зур эш башкаралар. 1897 елда, мәсәлән, Оренбург бае Гани Хөсәенев акчасына Каргалы авылында хатын-кыз мөгаллимәләр әзерләү мәктәбе ачыла. Аның җитәкчесе итеп шагыйрь Закир Рәмиев хатыны Мәһүбә ханым билгеләнә. Мәһүбә ханым тырышлыгы белән шулай ук аларның барлык прииска бистәләрендә дә диярлек малайлар һәм кызлар өчен аерым мәктәп-мәдрәсәләр булдырыла. Прииска мәктәп-мәдрәсәләрендә яхшы укыган ир һәм кыз балаларны аннары, Рәмиевләр хисабына, югары дәрәҗәле шәһәр мәдрәсәләренә, гимназияләргә белем арттырырга даими рәвештә җибәреп торалар. Бу җәһәттән шул ук Гани бай Хөсәенев тарафыннан Оренбург шәһәрендә 1902 елда оештырылган һәм нигездә ныклы белемле мөгаллимәләр әзерләүгә исәп тоткан кызлар мәдрәсәсе дә искә алып китүгә лаек. Мәһүбә Рәмиева бу мәдрәсәне оештыруда да бик теләп катнаша һәм дәвамлы рәвештә ярдәм итеп тора. Ә шул заман гимназия программаларына тартым белем бирергә ниятләгән бу мәдрәсәнең мөдире итеп Фатыйма Әдһәмова билгеләнә. Оренбург төбәге халкы телендә, русча сөйләмгә көйләнеп, «Адамова мәктәбе» дип йөртелгән мәдрәсәнең абруе ул заманда бик зур була. Шунлыктан ул мәдрәсә-мәктәп совет чоры кергәч тә яшәвен берничә ел дәвам итә. Аннан яңа тормыш төзүгә җиң сызганып катнашкан хатын-кызларыбызның чыканлыгы мәгълүм. Бу мәктәп-мәдрәсәдә иң абруйлы мөгаллимәләрдән саналган Багбостан Мөэминова, мәдрәсә мөдире Фатыйма Әдһәмова һәм башка укытучыларның да күбесенең башлангыч хәреф тану чорын әнә шул Мәһүбә, Гәүһәр ханымнар ачкан мәктәпләрдә үткәнлекләрен әйтү кирәктер.

Гәүһәр Рәмиева бу юнәлештә бигрәк тә Юлыкта бик зур эшләр

башкара. Бу авылда озакламыйча беренче баскыч кызлар мәктәбенә кызлар өчен һөнәр мәктәбе дә өстәлә. Ул мәктәптә кызлар чигү, тегү, бәйләү һөнәрләрен үзләштерәләр. Аның өчен читтән махсус белгечләр, укытучылар чакырыла. Гәүһәр ханым үзе дә бу ике мәктәптә дә дәресләр бирә. Дәрес вакытларында монда балалар өчен чыгарылган матур әдәбиятның яңа үрнәкләре белән танышу да тәртипкә салынган булган. Ә андый әдәбиятны исә авыл китапханәсенә Рәмиевләр даими рәвештә кайтартып торалар.

Китапханә димәктән, Юлыкта ул шулай ук Рәмиевләр тарафыннан оештырыла, китапка да, көндәлек газета-журналларга да бай була. Дөрес, 1919 ел февралендә монда Орскидан Мирхәйдәр Фәйзи эшкә җибәрелгәнче, «Уку йорты»ның аерым мөдире — китапханәчесе булмый. Бу эш әлек таш мәчет мәзине Зәһри Госмановка йөкләнгән була. Шуның өчен аңа Рәмиевләр өстәмә эш хакы түлиләр. Уку йортын ул һәркөнне билгеле бер сәгатьләрдә ачарга тиеш була. Ә хатын-кыз әдәбият сөючеләр өчен атнага ике көн билгеләнә, шул көндә китапханәче вазифасын мәзин хатыны башкара.

Герман сугышы алды елларында кызлар мәктәбендә Габбасова Әсма, Һибәтуллина Зәйнәп, Әдһәмова Гөлрух һәм Рәйхана исемле мөгаллимәләр укыталар. Рәмиевләр тарафыннан аларга егерме биш-утызлар сумнан айлык эш хакы түләнә. Һәр елны Гәүһәр Рәмиева, Оренбургка, Әдһәмова мәктәбенең чыгарылышына барып, Юлык мәктәпләре өчен иң сәләтле укучыларны сайлый ала икән.

Юлыкта да, прииска авылларында да мәктәп-мәдрәсәләрне тоту, аларны заманча уку әсбаплары белән тәэмин итү өчен Рәмиевләр акча жәлләмәгәннәр. Уку, тәрбия эше, әлбәттә инде, Юлыкта аеруча югары куелган була. Монда ай саен Гәүһәр ханым катнашында ир һәм кыз балалар мәктәп-мәдрәсәләрендә укучыларның җырлы-уенлы кичәләре оештырылып килә. Анда ялгыз да, күмәкләп тә җырлап һәм биеп, яисә төрле уен коралларында халык көйләрен башкарып балалар үзара ярышалар икән. Шигырь, әкият сөйләү осталары да үз сәләтләрен күрсәтәләр. Аннары кичәдә катнашкан һәркемгә бүләк өләшә торган булалар. Ә сәләт сынашта отучылар, билгеле инде, аерым затлы бүләк алалар.

Мондый тормыш дөньяларны пыран-заран китерүче афәт көннәренәчә — бер-бер артлы килгән сугыш-кырылышлар башланганчыга чаклы дәвам итә.

Дөрес, Рәмиевләрнең таштан гына койган иркен, мәһабәт утарына кайгы-хәсрәт чак кына иртәрәк тә төшә: 1912 елда, каты авырып, токымның тоткасы булып калган Шакир Рәмиев якты дөньядан китә. Аның үлемен якыннары гына түгел, Юлык авылы халкының күпчелеге дә бик авыр кичерәләр. Чөнки Шакир бай авылдашларына карата мәрхәмәтле һәм юмарт кеше була. Еллык зәкят өләшүне дә алар башка байлардан уздырып, «дин кушканнан бермә-бер арттырып өләштеләр»,— дип хөрмәтләп искә төшерә авылдашлары.

Шакир Рәмиев Юлык зиратына, әти-әнисе янәшәсенә җирләнгән. Аларның кабере өстендә дүртәр кырлы итеп эшкәртелгән бер үк зурлыктагы озынча ак мәрмәр истәлек ташлары тора. Алар дүртесе дә бик тә зәвыклы итеп татар нәкышләре белән сырлап бизәкләнгәннәр, өске өлешләрендә тигез йомры шарлар уелган. Шунлыктан ерактан алар кеше башын хәтерләткән сыман тоела. Бу мәрмәр сыннар миңа никтер борынгы кыпчак бабаларыбызның Көньяк Рәсәй далаларында күпләп утыртып калдырган серле таш балбал һәйкәлләрен хәтерләткән кебек булдылар... Ак төс гомер буе изге ак максатлар

белән яшәү билгесе. Шулай ук ул хәтер ташларыннан ерак аваз лар моңын алып килгән ниндидер серлелек һәм тарихилык та сир пелә сыман...

Бу авыл, бу таш ядкярлар белән әлегәчә ныклап кызыксынучыларның булмавы гына бик кызганыч, әлбәттә. Башкортстан галимнәре бу авыл язмышына бераз читсенеп, турыдан-туры үз халыклары тарихына катнашы әллә ни булмаган сымаграк карыйлардыр, күрәсең. Аңа «үтеп барышлый» гына кагылып китүләр сизелә. Ә Татарстан галимнәре һәм әдипләре өчен, мөгаен, бу төбәк бик еракта калган, әллә ни әһәмияте булмаган бер сәхифә рәвешендәрәк төсмерләнәдер. Идел төбәгеннән читтә, еракта калган андый татар авыллары бездә бихисап күп бит. Һәм һәрберсенең үзенә күрә бер гыйбрәтле язмышы бар. Әмма ләкин халкыбызның мәдәни күгендә якты нур балкытып узган Закир Рәмиев-Дәрдемәнд, Мирхәйдәр Фәйзи ише олуг исемнәргә бәйле Юлык кебек авылларны күңелләрдән бөтенләй сызып ташлыйсы килми шул. Баксаң, зур булмаган шушы бер авыл гына да төрле җепләр белән байтак кына танылган язмышлы кешеләргә барып бәйләнә икән ләбаса. Монда милли горурлыгыбыз саналырдай шәхесләрдән Нәкый Исәнбәт, Сәрвәр Әдһәмова, дөнья күләмендә танылган балет биючесе Ирек Мөхәммәдов эзләре дә ята...

Дөрес, әлегә мин дә Юлык авылын, язмышлары шушы авылга бәйле кайбер кешеләр тарихын өстән-өстән генә тасвирладым. Күңел түремдә һәрчак шагыйрь Дәрдемәнд һәм аның якыннары шәүләсе торса да, алар турында да әлегә бик тәфсилләп сөйләп бетереп булмый. Аларның теге яки бу эш-гамәлен яхшы хәтерләгән картлар авылда санаулы гына калган. Исәннәренең дә күпчелеге ерак-еракларга таралышканнар. Ни әйтсәң дә сәүдәгәрләр, «бай» һөнәрчеләр авылы бит Юлык, аның халкын Себер, Урал, Урта Азия буйларына таратып ташлардай әче җилләр монда шактый исканнәр. Хәзер биредә колхозның бер бригадасын тотарлык йөзләп хуҗалык исәпләнә икән.

Шулай да ышанам, укучы, бәлкем, шушы язмадан да бөек шагыйрьнең төп рухи бишеге саналырдай бу үзенчәлекле авылны төсмерләп кала алыр. Сөзәк үр буйлап сузылган хәтфә чирәмле шушы урамнарда булачак шагыйрь тәгәрәп, уйнап үскән, буй җиткән. Шушы Юлык авылының кечкенә мәктәбендә беренче мәртәбә хәреф танырга өйрәнгән, тәүге кат китап битләрен актарып караган. Киләчәктә ташка басылган ул серле язмалар аңа мәңгелеккә юлдаш булачаклар, тормыш ачкычларын бирәчәкләр, киң дөньяга алып керéп китәчәкләр. Шул дәвердән башлап ул изге китап сүзенә — үзеннән элгәре яшәгән фикер ияләре васыять итеп язып калдырган сүзләргә таянырга кирәклегенә иманып гомер кичерер...

Әйе, Юлык авылы — олуг шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең изге бишеге, зур дөньяга ул шушы бишектән атлап чыгып киткән. Без, аның укучылары, аның варислары бу хакта һич кенә дә онытырга тиеш түгелбез!..

Инде авылы белән саубуллашыр өчен сүзне шагыйрьнең үзенә бирик.

Тәгәрәп, уйнап
Буй үскән
Туган илем, исән бул!
Чәч кузгатып
Җай искән
Таңгы җилем, исән бул!
Иөгреп-йөгреп туктаган...
Яулык болгап

Сыктаган
Нәзкәй билем, исән бул!

(«Видагъ».)

## Ерак юллар, якын аралар...

Дәрдемәнд-Рәмиевнең Юлыктан кайчан китүе төгәл мәгълүм түгел. Мөгаен, ул башлангыч дәвердә кайта-китә генә йөргәндер, туган йорты белән араны бөтенләйгә өзмәгәндер. Истанбулда ике ел чамасы белемен үстереп, дөньяга карашын киңәйтеп кайтканның соңында ул бер ара Юлык белән Орск шәһәре арасында «гомер уздыра» шикелле. Бу көннәрдә ул Истанбулда чакта артык кара, тәрбия-мәдәниятләре чикле күренгән Борнаев кебек «кара байлар» йортында да үзе өчен ак сәхифәләр таба. Өяз каласының иң зур бае, якын-тирәдә сәүдә эшен иң киң җәелдереп җибәргән бу Борнаевлар белән ул тиздән якыннан аралаша башлый. Баксаң, шушы «кара бай» йортында заманына күрә укымышлы гына, төс-кыяфәткә сөйкемле генә кызлар да үсеп килә икән ләбаса! Мәһүбә Борнаева аның күңеленә аерата хуш килә. Яшьлек дәрте белән янган йөрәгенә мәхәббәт угын аткан нәзкәй бил Мәһүбәдән ерак йөрмәс өчен ул өяз каласы Орскида күпмедер вакыт яшәп тә ала булса кирәк.

Сәүдәгәрләр ул заманнарда бер кибет төбен саклап кына утырмаганнар. Шул җөмләдән Рәмиев, Борнаевларның да Орск шәһәреннән кала зур ярминкәләр узган башка төбәкләрдә дә сәүдә эшләре барган. Бүрене аягы ашата, дигән әйтемдәге кебек, ул бүрегә берәү дә ризыкны китереп алдына салмаган кебек, сәүдәгәрләргә дә аны үз аяклары белән йөреп, эзләп алу кирәк булган. Алар бүген Оренбург якларыннан урап, йөреп кайтсалар, ике-өч көн хәл туплаганның соңында ук Троицк, Чиләбе тирәләренә ат чаптыруны кирәк тапканнар. Шунсыз, йомшак ястык өстендә иркәләнеп ятып кына, «бай абзый» исемен күтәрү татар сәүдәгәрләренә һич тә мөмкин булмаган, билгеле.

Шакир белән Закир Рәмиевләр дә ул дәвердә, гәрчә инде урта кул промышленниклар исәбенә кереп барсалар да, әлегә сәүдә эшен ташламаганнар. Алар да ул заманнарда шәһәрдән шәһәргә, базардан базарга йөреп торганнар. Идел буе сәүдәгәрләре арасында Макарҗә ярминкәсе данлы саналса, Урал һәм Көнбатыш Себер төбәкләрендә исә алыш-биреш белән шөгыльләнүчеләр ешрак Эрбет ярминкәсендә очрашканнар. (Хәзер Свердловск өлкәсенә кергән кечерәк шәһәр.)

Әнә шундый сәяхәтләрнең берсендә, имештер, Закир әфәнде Рәмиевкә Эрбет ярминкәсеннән кызның атасы белән атна буе бергә кайтырга туры килгән. Шунда, имеш, алар җан ахири булып, дуслашып киткәннәр. Шул сәфәрдән соң, имеш, яшь бай шәһәргә килгән саен булачак каенатасы йортына — Борнаевларга кермичә китми башлаган. Шул килеп-китеп йөрүләрендә инде сылу яры Мәһүбә белән танышкан, имеш.

Моны, әлбәттә, Орск карчыклары — ата-аналары кайчандыр әлеге байларның ышанычлылары, йомышчылары булып йөргән кешеләрнең балалары сөйлиләр. Халык теленә кергән хак була, дигән мәкальгә ышансак, әлеге риваятьләрнең дә дөрескә чыгуы бик ихтимал.

Әле бәян ителгән хәлләр, билгеле, узган гасырның сиксәненче еллары уртасында ук булып үткәннәр. Шуннан соң инде яшьләр,

ярәшеп-өйләнешкәч, Оренбург шәһәренә күченеп киткәннәр. Ул заманда әле, билгеле, бу яклар паровоз, пароход гудокларын ишетми яшиләр: тимер юл мондагы тау араларыннан бик соңга калып салына, ашкын агымлы Урал елгасында пароходлар йөрми. Кайсы гына якка карап сәфәр чыксаң да, шөлдер-шөлдер килеп, шөлдер таккан дугалы җиңел арбалар йөгерә.

Ә Оренбург шәһәрендә, төбәкнең беренче генерал-губернаторы Неплюев исемен йөрткән үзәк урамда, Закир Рәмиев гаиләсе өчен дип бик җыйнак кына таш утар төзелә. Ат, арбалар белән кереп-чыгып йөрердәй иркен генә ишегалды, нык кул белән мәңгелеккә исәпләп салынган келәт һәм араннар, зур урамга карап, унлап тәрәзәсе аша сөйкемле генә елмаеп-көлеп торган мәһабәт кенә таш өй...

Хәер, йорт-утар төзелә торсын, без исә, бер-ике сүз белән генә булса да, күп мәртәбәләр телгә алынган шәһәрне беркадәр тасвирлап үтик. Бу таш кала ике зур елга кушылдыгында, Урал белән Сакмар-су култыгында утыра. Сакмар исә Урал-су агымының нәкъ урта бер җирендә, зур елга дугаланып казакъ далалары тарафынарак авышкан җирдә килеп кушыла. Сакмар тамагы сазламыклыдымлы булганлыктан, шәһәр аның агымы буенча өскәрәк, борынгы бабаларыбыз Актүбә дип исем биргән калкулыккарак тартылып утырган. Ә шәһәрнең үзәге текә маңгаен Урал елгасының киртләч ярына терәп тора. Яр буе скверыннан елганың иңкү ягындагы урман-әрәмәлекләргә матур күренеш ачыла. Анда элек, Азия ягының күңелгә рәхәт җиләс һавалы әрәмәлекләре арасында, анда-санда шәһәр байларының җыйнак-матур дача йортлары шәйләнә иде. Ә хәзер «Маяк тавы» дип йөртелгән элеккеге Актүбә калкулыгы, шулай итеп, шәһәрнең сырт өлешендәрәк калган.

Оренбург шәһәре салынганда ук булачак губерна үзәге һәм яулап алынган бу төбәктәге җир вә халыклар белән идарә итү урыны төсендә билгеләнә. Шул караштан чыгып төзелә. Кайчандыр тынгысыз Азия һәм Сакмар арты якларына каратып куелган рәхимсез туплар эзен саклаган крепость диварлары бүген дә шомландыра әле...

Әйе, шәһәр кайчандыр Рәсәй дәүләтенең форпосте саналган бер урынга — гомер-гомергә казак, нугай, башкорт ыруларының биләмә чикләре бәйләнешкән бер үзәккә «утыртылган».

Баштарак, «Оренбург экспедициясе» дип исемләнгән комиссиягә булачак беренче генерал-губернатор И. И. Неплюев җитәкче итеп билгеләнгәнче, губернаның башкаласы хәзерге Орск шәһәре урынында сайланган була. Неплюев исә андый карар белән килешми, Петербургка җибәргән хатларында: шәһәр урыны үзәктән еракта һәм бик җайсыз сайланган, үзләрен бик тынгысыз тоткан башкорт, казакъ ырулары уртасында ук, дип белдерә. Һәм Ор елгасы тамагындагы төзелешне туктатмастан, «губерна башкаласын» Рәсәй үзәкләренә якынрак торган Сакмар тамагы тирәләренә күчерергә рөхсәт ала. Шулай итеп, 1743 елда хәзерге Оренбургка нигез ташы салына. Моннан Урал елгасы аръягындагы казакъ далаларына — дистә ел чамасы элек кенә Россия белән «дуслык килешүе» төзегән Әбелхәер хан биләмәләренә дә, Сакмар-су артыннан төньяк-көнчыгыш тарафка сузылган ярым ирекле башкорт күчмәләре җирләренә һәм ике гасыр чамасы элек яуланып та, патша хөкүмәте тарафыннан хәзер генә ныклап үзләштерелә башлаган көнбатыш өлкәләргә дә якын була, билгеле.

«Оренбург экспедициясе»нең тарихчысы һәм географы П. И. Рычков Оренбургның элекке бер шәһәрчек урынында барлыкка килүен яза. Монда, ди ул, элек нугай ханнары биләмәсенең

чиге булган, Сакмар белән Урал арасындагы үрдә нугайларның чик буе шәһәрчеге Актүбә урыны бар. Бу биләмәнең би-ханы Басман дигән кеше мәгълүм сугышлар вакытында (Казан, Әстерхан ханлыкларын яулау чоры истә тотыла) яу кырында үлеп кала. Оренбург каласын төзи башлаганда аның каберлеге бар иде әле, ди. Моннан Сакмар буйлап бераз күтәрелгәч тә көнчыгыш тарафка таба «башкортларның ау биләмәләре башлана», дип яза галим Рычков.

Димәк, борынгы Актүбә шәһәрчеге урынында Оренбург каласы, шул кала үзәгендәге тыныч бер урамда — каһарманыбыз Рәмиевнең таш утары...

Озакламый ул утар бу шәһәрнең үзенә күрә бер мәдәни үзәгенә әвереләчәк, даны еракларга таралачак әле аның. Тиздән бу яңа утардан ике урам аша гына диярлек икенче бер мәдәни үзәк — атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсе шәһәрчеге калкып чыгачак. Бу таш утар әһелләре озакламыйча гыйбадәткә дип шул мәдрәсә мәчетенә йөри башлаячаклар. Бу мәчет-мәдрәсәнең хуҗалары — Әхмәт, Мәхмүт, Гани бай Хөсәеновлар — аралашкан кешеләр ич. Гани байның анасы Нәкыя абыстай — Юлык кызы лабаса! «Юлык балалары», ике бертуган Рәмиевләрне ул электән үк үз итә, якын күрә ич. Закир белән Мәһүбә Оренбургка килеп төпләнгәч тә Нәкыя абыстай аларны чит итми — шәһәрдә вакытында да, Каргалысына кайтып торган чакларында да еш кына аларны кунакка алып, яшьләрнең күңелен күрергә тырыша.

Шәһәр белән Каргалыда гына түгел, якын-тирә авылларда да мәктәп-мәдрәсәләрне күпләп ачу дәрте белән йөргән Гани бай Хөсәеневкә дә ерак Истанбулларда укып, белемен арттырып һәм дөнья күреп кайткан Закир әфәнде, аның тормышка карашлары хуш килә. Рәмиевләр дә Хөсәеневләр башлаган эшләрне бик хуплыйлар, милләттәшләрен укымышлы итү, һич югы аларга башлангыч белем бирү хыялы белән үзләре дә күптән хыяллана ич инде алар. Хөсәеневләргә бу изге эшләрендә матди һәм рухи ярдәм күрсәтергә биш куллап алыналар. Мәһүбә ханымның да бу эштән читтә калмаганлыгын беләбез инде. (Апасының йогынтысын тоеп булса кирәк, Орскиның Әхмәтҗан хәзрәт абыстае Маһруй Рәхмәтуллина-Борнаева да тиздән бу шәһәрдә кызлар өчен яңача мәктәп ачып җибәрә.)

Шулай итеп, «башкала» шәһәрендә дә Рәмиевләрнең абруе көннән-көн үсә, арта бара. Озакка сузмыйча гына Закир әфәндене «Хөсәения» мәдрәсәсенең «идарәче байлары» исемлегенә сайлап куялар. Генерал-губернатор канцеляриясе документларында мөхтәрәм мәдрәсәнең «Попечительләр Советы» дип теркәлгән бу идарәсе уку-укыту программасын даими тикшереп, аңа кирәгенчә юнәлеш бирүне дә кайгыртырга тиеш була. Бик җаваплы бу бурычны әлеге Совет, нигездә, Дәүләкән ягы «түмән»нәреннән чыкмыш Гайса морза Еникеев белән Закир Рәмиевкә йөкли.

Закир әфәнде Рәмиев, әлбәттә, бу дәвердә шәһәр һәм губерна күләмендәге башка төр җәмәгать эшләрендә дә катнаша. Губерна җәмәгатьчелеге тиздән аны Икенче чакырылыш Дәүләт думасына депутат итеп күрсәтә. Рәсәй халыклары язмышын, шул исәптән татар халкының да киләчәген хәл итәргә, һич югы шуңа омтылып карарга тиешле булган Дума депутатлары исемлегенә тагын Оренбургтан доктор Байбурин, Гайса Еникеев, Орск шәһәреннән сәүдәгәр Фәйзулла Мөэминов, Каргалы авылы мулла-мөгаллиме Хәйрулла Госмановлар теркәлә. Ләкин бу депутатларның бер ни дә эшли алмый калуларына, сайлануларыннан соң ярты ел үткәч тә патша хөкүмәте тарафыннан куылуларына алар гаепле түгел, билгеле. Эшләргә мөмкинлек тудырылса, киләчәк өметләрне гамәлдә

чагылдырырга сәләтле депутатлар сайланган ич!

Көндәлек тормышта, көнкүрештә Дәрдемәнд-Рәмиевнең гаҗәеп тыйнак булуын, бик йомшак табигатьле кеше икәнлеген күпләр билгеләп үтәләр. 1906 ел азагында, Думага депутат итеп күрсәтелгәч тә, ул беркадәр сабырлык сиздерә, хәтта икеләнеп кала сыман. Мондый олы вазифаны үз җилкәсенә күтәрердәй миннән мөхтәрәмрәк зыялылар бардыр, дип, үз дәрәҗәсенә түбәнсетебрәк карый. Әмма чордашлары, хаклы рәвештә, башка фикердә торалар һәм депутатлыкка аны сайлыйлар.

Закир әфәнде көндәлек тормышта тыйнак һәм артык сабыр табигатьле күренсә дә, үз алдына куйган максатка ирешү юнәлешендә — татар халкын белемле, укымышлы итү бурычын үтәгәндә — һәр эшкә җитди, максатчан тотына торган була. Татарча матбугат булдыру юнәлешендәге теләк-талпынышлары моңа шаһит. Бертуган Рәмиевләр татарча газета чыгару теләген белдереп узган гасырның сиксән-туксанынчы елларында берничә тапкыр мөрәҗәгать итәләр, андый эшкә ирек куелу белән үк максатларын тормышка да ашыралар — «Вакыт» газетасына рөхсәт беренчеләрдән булып, 1906 ел башында ук бирелә.

Оренбург шәһәрендә төпләнеп яши башлагач та шагыйрь белән аның хатыны һәр атнада әдәби-мәдәни мәҗлес, кич утырышлар оештырып җибәрәләр. Әдәбият, сәнгать һәм көндәлек яшәеш, сәясәт мәсьәләләрен арага салып сөйләшенгән ул кичәләргә Рәмиевләрнең таныш-белешләре генә түгел, шәһәргә килеп чыккан һәр яңа фикер иясе дә катнаша алган. Болардан тыш Дәрдемәнд-Рәмиев һәр атна кичендә төрле үтенеч белән мөрәҗәгать кылучы гади халыкны да кабул иткән. Моның өчен шул билгеле бер көндә бер сәгать вакыт билгеләнгән булган икән. Шул вакытка чамалап аның өенә авыл хәлфәләре, ярлылар, шәкертләр җыелганнар.

Бу уңайдан «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте, Галимҗан Ибраһимовның туганы Мохтар Ибраһимов истәлекләрен искә төшерү кызыклы, минемчә. Ул болай искә ала: «.... Бер язны без, шәригем Гомәр Нигъмәтуллин белән бергә... «Хөсәения» мәдрәсәсенә керү нияте белән Оренбургка киттек. Аркаларыбызда — капчык, кулларыбызда — таяк. Әле кар эреп бетмәгән, юл пычрак. Бата-чума барабыз... «Хөсәения»гә урнашканнан соң... без җәйгә авылга кайтмаска, Рәмиевләрнең алтын прииискаларында эшләп бераз акча табарга ниятләдек. Алтын приискаларының хуҗаларыннан берсе булган шагыйрь Закир Рәмиевнең Оренбургта яшәгәнлеген белә идек. Гомәр белән аның янына бардык, приискаларының берәрсенә эшче итеп урнаштыруын үтендек. Шагыйрь безне ачык йөз белән каршы алды, хәлләребезне, укуларыбызны сорашты, киңәшләр бирде. Ләкин эшкә урнаштырмады.

— Прииска эшләренә катнашмыйм, шуңа күрә урнаштыра алмыйм,— диде. Һәм, кесәсеннән акча чыгарып, икебезгә дә бишәр сум бирде. Без аннан акча сорамаган идек, шулай да шатланып, бик күп рәхмәт әйтеп алдык...»

Оренбург якларында йөргәндә мондый истәлекләрне телдән дә еш ишетергә туры килә. Шушындый ук эчтәлекле башка истәлек-язмалар да бар. Дөрес, шагыйрь дә бәлки килгән бер кешегә акча гына өләшеп утырмагандыр, кемгә киңәшен биргән, кемгә киләчәк юлын өйрәтеп чыгаргандыр. Әмма шәһәрдә яшәгән вакытларында һәр пәнҗешәмбенең бер сәгатен бары тик үз гозере белән килгән теләсә кемне кабул итүгә сарыф кылганлыгы күпләргә мәгълүм.

Мәрхүм Исмәгыйль абый Рәмиев тә бер мәртәбә Закир әфәнде йортына шул рәвешле эләккәнлеген сөйләгән иде. Ул да: «Мохтаҗлык кичергән һәркемгә Дәрдемәнд хәленнән килгәнчә ярдәм итәргә

тырышкан. Аның янына бигрәк тә шәкертләр еш йөри иде. Анда татар, башкорт кешеләреннән тыш Урта Азиядән килгән үзбәк, казакъ халкы вәкилләрен дә, авыл муллаларын да очратыр идең»,— дип, алдан китерелгән сүзләрне тагын бер кат раслаган иде.

Үзе исә ерак кардәшенә андый үтенеч белән бармый, әлбәттә, Галимҗан Ибраһимовның бер йомышын йомышларга дип бара. Ә эш болай була. 1917 елның декабрь башларында Оренбургта башкортларның беренче Корылтае ачыла. Анда бик җитди мәсьәләләр куела: башкорт халкының мөстәкыйль автономияле мәмләкәтен төзү һәм шул автономияне тану-танымауларын белдерүне үтенеп большевиклар башкаласына һәм Себер ягы директориясе җитәкчеләренә мөрәҗәгать итү. Шул зур җыенга, татар җәмәгатьчелеге вәкиле буларак, Уфадан Галимҗан Ибраһимов та бара. Ә үзенә ярдәмче-адъютант итеп Уфа гарнизонындагы бер полкта писарь вазифасын үтәгән якташы Исмәгыйль Рәмиевне дә ала. Исмәгыйль абый бу очракта аның мылтыклы сакчысы да, йомыш үтәүчесе дә була. Оренбург шәһәре уртасындагы Кәрвансарайда, Зәки Вәлиди җитәкчелегендә ике атна дәвамында бик бәхәсле барган ул Корылтай утырышларында, димәк, Исмәгыйль абый да ахырынача диярлек катнаша. Анда кемнең нәрсә сөйләгәнен, ни-нәрсәләр даулаганлыкларын ул әле илле ел үткәч тә бик яхшы хәтерли иде. Бәлки архивында бу вакыйгаларга кагылышлы язма истәлекләре дә сакланадыр. Хәтеремдә әле, бер шундый әңгәмәдән соң Әмирхан Еники аңардан боларны куен дәфтәренә теркәп куюын бик тә үтенгән иде.

Менә шушы Корылтай көннәрендә Галимҗан Ибраһимов шагыйрь Дәрдемәнд белән күзгә-күз карашып кына сөйләшәсе сүзләре туганлыгын белдерә. Якын арада очрашу вакытын билгеләмәсме икән, дип белешү өчен Исмәгыйльне Закир әфәнде йортына җибәрә.

Шушы урында мин, әңгәмәдәшемне туктатып, аңа мондый сорау биргән идем:

— Дәрдемәнд белән Галимҗан Ибраһимов элек якыннан таныш булганнармы, очрашканнармы.

— Очрашкан да, сөйләшкән дә булырга тиешләр, — диде Исмәгыйль абый. — Хәер, Галимҗан абый китапларының байтагы башта Рәмиевләр матбагасында басылып таратылу да моны раслый. Аннары тагын икенче... ярыйсы ук четерекле дәлилем дә бар...

Шулай дип, ул Галимҗан Ибраһимовның революция алды елларында шагыйрьнең бер кызына гыйшык тотып йөрүен дә «сер итеп кенә» сөйләп алды. Әмма аның анык кына кемгә күңел биреп йөргәнлеген әйтмәде. Бәлки кызның исемен үзенең дә оныткан чагы булгандыр. Тик шунысы хак, шагыйрьнең зур кызы Зәйнәп бу вакытта инде күптән кияүдә була. Кияве Ярулла Вәли шулай ук үрчемле генә бер язучы, байтак кына повесть һәм хикәяләр авторы. Тумышы белән шул якның Бозаулык буе татар авылларының берсеннән. Соңгы язмышы да әдип Ибраһимов язмышына тиң — 1937 елда кулга алына һәм эзсез юкка чыга.

Гөлнур Рәмиева... Аның язмышы миңа таныш түгел. Дөрес, Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләрендә аның исеме дә теркәлгән. Гөлнур туташны ул кызның бик моңсу бер вакытында, 1921 ел көзендә Темәс авылы клубында очрата да: зур, зиннәтле залларда, зыялы кешеләр арасында йөрергә күнеккән кыз иң гади халык арасында моңсу, сабыр гына утыра иде, дип язып куя.

Шөкер, якындагы атна кичендә, шагыйрьнең гади халыкны кабул итү вакытында Исмәгыйль Рәмиев Дәрдемәнд өенә юнәлә. Аңа Галимҗан Ибраһимовның үтенечен белдерә. Киләчәк көрешү көнен билгелиләр дә кайтып та китә.

Аннары, озаклап кич утыру өчен, алар билгеләнгән вакытта шагыйрь өенә икәүләп киләләр. Монда шагыйрь белән әдип, каршы утырып, Октябрь революциясе алып килгән үзгәреш-яңарышлар хакында фикер алышалар. Галимҗан Ибраһимов әңгәмәдәшенә Корылтайның аерым Башкорт автономиясен төзергә карар кылуын, Орск өязенең төньяк өлешенә кергән Юлык авылының да шул мөстәкыйль мәмләкәт карамагына күчәчәген белдерә, әлбәттә.

Гомумән, Исмәгыйль абый хәтерләвенчә, сүз йомгагы башлыча Галимҗан Ибраһимов кулында була, шагыйрь әңгәмәгә ара-тирә генә кушылгалап, үз фикерен белдереп куйгалый икән. Исмәгыйль Рәмиев исә ул сөйләшүгә бөтенләй дә катнашмый диярлек.

— Алар янәшәсендә бераз утыргач та мин торып киттем. Китап киштәләре бик бай иде, шуннан үземә бик кызыклы күренгәнен алып актарырга керештем дә онытылдым, — дип искә төшергән иде ул.

Шушы вакыйгалардан соң инде Дәрдемәнд-Рәмиев Оренбургтагы өендә озак яшәми. Галимҗан Ибраһимов та катнашкан Корылтай утырышлары декабрьнең егерме икеләрендә төгәлләнә. Ә бер айдан соң, 1918 елның 23 гыйнварендa Оренбургта Совет власте урнаштырыла. «Буржуйлар — долой!» дигән лозунг кичекмәстән эшкә ашырыла башлый. Байларның мал-мөлкәте конфискацияләнә.

Бу көннәрдә Дәрдемәнд-Рәмиевнең үз иреге белән алтын приискаларыннан ваз кичүе, аларны Совет оешмаларына тапшыруы мәгълүм. Шул исәптән «Вакыт» газетасы, «Шура» журналы һәм әдәбитарихи китаплар басыла торган яхшы җиһазлы типографияне дә Совет вәкилләре карамагына тапшыра ул. Бу типографиядә шул көннәрдә Заһид Шәркый-Иосыпов редакторлыгында «Мөхбир» газетасы, бераздан соң «Эшчеләр дөньясы» һәм башкалар басыла башлыйлар. Заһид 1913 елдан бирле «Хөсәения» мәдрәсәсендә укуын ташламастан, «Вакыт» типографиясендә хәреф җыючы булып эшләгән эшче. Шунлыктан Совет власте урнашкач та Оренбург большевиклары бюросы аңа басмаханәләр эшен җайга салу һәм газета чыгару бурычларын йөкли.

Ә моңарчы еллардагы соңгы чорда «Вакыт» басмаханәсенең хакыйки җитәкчесе булып Дәрдемәнднең кияве Ярулла Вәли исәпләнә, шул исәптән «Яңа вакыт» газетасы да аның кул астында чыга.

Бу басмаханәнең соңгы көннәренә кагылышлы бер кызыклы истәлекне мин 1964 ел кышында Олы Кайбыч авылында язып алган идем. Аны миңа инде урын өстеннән тора алмыйча яткан элеккеге хәреф җыючы Хәбибулла абый Яруллин сөйләгән иде. Хезмәт юлын ул гражданнар сугышы елларында хәреф җыючы ярдәмчесе буларак башлаган икән. «Вакыт» басмаханәсенә багышланган хатирәсе бик кыска булса да, бик гыйбрәтле тоелды миңа. Чөнки сүз типографияне Дәрдемәнд-Рәмиевнең ни рәвешле яңа власть вәкилләренә тапшыруы хакында бара. Февральнең соңгы көннәре була бугай. Чөнки шагыйрь ул көнне җылы, йомшак туннан килә типографиягә.

Килә дә, барлык хезмәткәрләрнең бер җиргә тупланауын үтенә кыскача гына җыелыш уздырылачагын әйтә. Хәреф җыючылар, хезмәткәрләр бергә тупланып беткәч тә кыскача гына итеп болай белдерә:

— Бүгеннән үк үз арагыздан бер җитәкче сайлагыз, монда булган барлык җиһазны, кәгазь, буяуларны барлыгынча кабул итеп алыгыз, — ди. Аннары куеныннан зур бер төргәк акча чыгара да: — Бу төргәктә сезгә киләчәк ике атналык эш хакы һәм басмаханә чыгымнарын капларлык акча булыр. Анысын да рәхим итеп алыгыз, — дип өсти.

Шуннан соң инде барысына да рәхмәт әйтә дә, хушлашып чыгып

та китә. Димәк, дистә ел буе күңел юанычы биргән, якты уйлар тудырган, яшәткән бер зур эше белән ул менә шулай гади генә саубуллаша сыман. Гомерен халык бәхетенә багышлады, шуның өчен күпме көчен һәм малын түкте. Инде халык вәкилләре ул йөкне үз җилкәләренә күтәрмәкчеләр икән, мәйле, юллары уң булсын, дип уйлагандыр шагыйрь бу мизгелләрдә, мөгаен.

Шагыйрьнең Оренбург каласы белән хушлашу хатирәләреннән берсе шушы... Күңел биреп эшләп килгән вазифасын халыкның үз вәкилләренә тапшыру... Хуш, якты дөньям, дип үк үкенмәгәндер, бәлки.

## Соңгы көннәр

Рәмиевләр гаиләсе озакламый Орск шәһәренә күченеп китә. Дөрес, ул күченүне әле бөтенләйгә дип уйламыйлар, Неплюев урамындагы йортта барлык нәрсә дә үз көенчә кала диярлек. Шагыйрьгә, билгеле инде, бу йортта тупланган бик тә бай китапханәдән аерылып торуы аеруча аяныч һәм үкенечле тоелгандыр. Әмма әле аның күңелендә берничә айдан, һич югы берәр елдан соң, үз утарына кабат кайту, үз китапханәсе һәм җайлы-көйле элекке тормышы белән кабат күрешү өмете яшәгәндер. Гражданнар сугышы озакка сузылмас, тәртип урнашыр да, яңа властьларга бернинди дә зыян китермәгән, аларга каршы көрәш алып бармаган шәхес буларак, аңа тыныч кына үз өендә үз картлыгы белән ялгыз калырга рөхсәт бирелер дип өмет иткәндер.

Ләкин, төрле сәбәпләр аркасында, ул өмет-юраулар чынлыкка аша алмый. Егерменче еллар соңында «бай утары»на башка кешеләр хуҗа булып калалар. Шагыйрьнең гомер буе туплаган бай китапханәсе ишегалдына, утын сараена чыгарып өелә. Бөек Ватан сугышы башлангач, шәһәр утын кытлыгын кичергән зәмһәрир суык кышларда ул кыйммәтле хәзинә көл һәм төтен булып һавага оча...

Рәмиевләр, билгеле инде, Орскига күчкәндә затлы тройкалар җигеп, кирәк-ярак җиһаз һәм кием-салымны ишле-санлы олауларга төяп юлга чыга алмыйлар. Бердән, ул хәтле еракка озатырдай олаулар һәм олаучылар юк заман; икенчедән, юллар да тыныч түгел вакыт бит — бер авылда кызыллар булса, янәшәсендә аклар, кемнең кем белән сугышканын да чамалап бетерерлек түгел. Шунлыктан Рәмиевләр Ташкент тимер юлы белән Актүбә шәһәренә кадәр поездда барырга ниятлиләр. Борнаевларның ышанычлылары аларны анда каршы алырга, дала юлы белән Орскига кадәр озатып куярга тиеш була.

Рәмиевләр Орскида беренче елны Мәһүбәнең туганы Мәхмүтҗан Борнаевларда яшиләр. Мәхмүтҗан белән Габдуллаҗан Борнаевлар ул вакытта шәһәр үзәгенең Зур урамындагы ике катлы таш йортларында торалар. Йортның аскы катында кибет, келәтләр була. Совет чорында исә монда төрле учреждениеләр туплана. Сугыштан соңгы дәвердә Совет урамындагы ул иркен йортта зур ашханә эшләде. Тарихи бу йортны 1984 ел башында, «Орский рабочий» газетасы типографиясен киңәйткәндә сүттеләр.

Рәмиевләр Орскига күчеп килгәндә Борнаевларның Рәшит һәм Шамил исемле ике уллары була. Берсенә сигез, икенчесенә биш яшь. Шушы күченү вакыйгаларыннан соң илле ел үткәч тә аларның олысы белән миңа бер очрашырга туры килгән иде. Аның белән мине Орскида туып-үскән, яше белән әлеге малайларның кечесенә яшьтәш булган Абдулла абый Исәнбаев кавыштырган иде. (Совет урамындагы Борнаевлар сәүдә йортының фоторәсемен бүләк итүче дә ул — чөнки шул

заманда шәһәрнең оста фотографы санала иде.)

Рәшит Борнаев миңа «шагыйрь баба»сы турында әллә ни күп мәгълүмәт бирә алмады. Сиртмәле тарантаска утырып берничә мәртәбә җәй көннәрендә балыкка барганлыкларын гына искә төшерде.

— Шагыйрь бабай балыкка йөрергә бик хирыс иде. Кармак, кәрҗиннәрен тотып үзе арба читәненә терәлеп утыра, мин кучер янәшәсенә кунаклыйм да, шәһәрдән чыгып китәбез. Урал буе әрәмәләре ышыгына, Ущельегә барганыбыз хәтердә, — дип сөйләде.

«Тарлавык» дигән урын — Урал елгасының, ачык кырдан агып килеп, тауга барып төртелгән урыны. Кайсы бер язларда шул тарлавыкка боз өеме килеп тула, Урал суы шәһәр урамнарына күтәрелә. Ә ул тау башына күтәрелсәң Иске шәһәр дә, елга аръягындагы ерак казакъ авыллары да уч төбендә кебек күренәләр.

Кече Борнаевның сөйләвенчә, балыкка бер баруда алар әнә шул кызыл кыя-ташлы тау иңенә дә күтәрелгәннәр, шагыйрь бабай шуннан озак кына тирә-якны күзәтеп торган икән.

Сигез яшьлек бала шуннан да артыгын исендә калдырмаган иде.

Борнаевлар өендә бер кыш чыкканның соңында Дәрдемәндләр башка чыгалар. Хәзер дә Поль Лафарг тыкрыгында (өченче йорт) исән-имин булган бер катлы агач өйне берәүләр, ике-өч елга дип, алар карамагына тапшырып, үзләре якындагы бер авылга кибет тотарга китәләр. Ул тыкрык Иске шәһәрнең Урал елгасы янәшәсендәге урамына төртелеп тора. Дәрдемәнд соңгы көннәрен яшәгән өй Урал буенда ук диярлек, теге урам чатыннан икенче генә йорт. Шуннан соң язын-көзен каргалар кунаклап, кар-кар килеп биек-биек топольлар рәте китә, шул мәңгелек агачлар ышыгына сыенып кына, борылышларда чак кына җыру авазлары чыгарып, бик алай киң булмаган Урал агып ята. Матур табигать, матур күренеш! Җанга рәхәт бирә торган урын, әлбәттә.

Бер катлы ул агач өйнең ишегалды иркен, ишле тәрәзәләре елмаешып кыйблага карап торалар. Бәпкә үләне мул үскән тыкрык киң дә, тыныч та: күңелең тартса хет шунда чыгарып ак тирмә куй да сәхра оештыр.

1921 елның октябрь соңнарында шагыйрь Дәрдемәнд-Рәмиев әнә шул тын бер почмакта, шул агач өй түшәгендә вафат була, шушыннан соңгы юлына озатыла. Монда аның соңгы кигән киемнәре, кулына каләм тотып утырган урындык-өстәле, соңгы мирасы кала. Соңгы мәртәбә кулына алган китаплары, язган кәгазьләре шушында кала. Үкенечкә, 1922 елның язында Урал елгасы тагын ташый, шәһәрнең түбәндәрәк утырган урамнарын су баса, кешеләр йорт түбәләре өстеннән көймәләрдә йөзеп йөриләр. (Шундый ук күренешкә 1957 ел язында шаһит булган идем.) Билгеле инде, яр буенда ук утырган теге сөйкемле агач өй дә су астында кала. Фәкать шагыйрьнең иң кадерле әйберләрен генә Борнаевларның тау өстендәге йортына ташып өлгерәләр. Хәер, Искәндәр Рәмиевнең ике катлы өе дә өстәрәк урнашкан була. Кайбер әйберләрне бәлки аңа да ташыганнардыр. Орски халкы «Искәндәр йорты» дип йөргән ул өйнең асты таштан, өске каты бүрәнә. Гадәттә, хәллерәк байлар Орскида йортны шулай салырга тырышканнар. Купчелегенең аскы катында кибет булган.

Шакир Рәмиев 1912 елда вафат булганның соңында прииска эшләре белән җитәкчелек итү шушы Искәндәргә йөкләнә. Ул инде махсус белемле алтын чыгаручы була, Бельгиядә укып бугай, инженер дипломы ала. Совет хөкүмәте 1921 елда «буржуй белгечләр»не эштә кулланырга кирәк дип тапкач, Искәндәр Рәмиевне дә «Башкорталтын» трестының җитәкчесе итеп билгелиләр. Ә инде патша чоры белгеч-инженерларын ил күләмендә эзәрлекләүләр башлангач, аны да 1927 елда кулга алалар. Шуннан соң ул эзсез югала.

Димәк, шагыйрь үлгән көннәрдә Искәндәр Орскида булмый. «Башкорталтын» тресты идарәсе бу вакытта кантон үзәге Темәс авылында була. Соңрак ул трест Баймак шәһәренә күчерелә. Шулай да бер вакыт матбугатта мондый бер хәбәр күренеп калган иде: имеш, шагыйрь Дәрдемәнднең вафатыннан соң Искәндәр, аның язма мирасын ике чемоданга сала да, Орскидан алып китмәкче була. Ул мирасны әлегә Оренбурда яшәп яткан Зәйнәп апа Вәлиеваларга илтеп тапшырмакчы булгандырмы, яисә үзенең Темәс-Баймак фатирына кайтармакчымы, билгеле түгел. Тик шунысы хак, имеш, ике чемоданны күтәреп поездга төшә бу да... поездда барганда ул чемоданнардан колак кага. Юлда, имеш, «бай Рәмиев» артыннан даими күзәтеп йөргән караклар шагыйрь мирасын, башка байлык дип уйлап, урлап качалар. (Шуны да белеп торыйк, Орскига тимер юлы 1923 елда гына барып җитә, пассажир поездлары берәр елдан соң йөри башлыйлар.)

Исмәгыйль абый Рәмиев тә шагыйрь мирасының шулай югалган булуын ишетеп белә иде. Ә дөреслектә ул хәл шулай булганмы, әллә Закир әфәнде Рәмиев язмалары Искәндәр язмышын кабатлаганмы, әйтүе читен. Һәрхәлдә, ул ике чемодан кульязманың Искәндәр Рәмиев белән бергә 1927 елда зинданга барып эләгүе дә бик мөмкин бит.

Ярый, хуш, борадарән Борнаевлар, Искәндәр Рәмиев Орск шәһәрендә Дәрдемәнд белән аралашканнар. Гражданнар сугышы кискенләшеп, шәһәрдә хәлләр мөшкелләнгән бер дәвердә, 1918 ел җәендә, Закир әфәнде Рәмиев атна-ун көн чамасы кечерәк кенә Җүнәй дигән татар авылында да торып китә. Җүнәй — Мортаза Фәйзуллинның ике энесе һәм өлкән ир балалары барып оя корган авыл — Столыпин чоры хуторына тартым бер биләмә. Бик үзенчәлекле, тук, көр күңелле авыл. Гөберлә тауларыннан агып төшкән саф сулы Гөберле елгасы буенда урнашкан. Ул елгада элек балык та мул тотылган. Мортаза карт улы Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләреннән күренгәнчә, Орск байлары сугыш алды елларында монда сәхрага чыга, «дача» алып яши торган булганнар икән. Дәрдемәнд-Рәмиевне исә анда сугыш афәте куып җибәргән.

Шагыйрьнең соңгы яшәү дәверендә даими рәвештә аралашкан тагын бер танышы — Габдулла Дәүләтшин дигән кеше була. Мөгаен, алар бер-берсен Оренбургта яшәү дәверендә дә белгәннәрдер. Бердән, Дәүләтшин әз-ким каләм тибрәткәләгән шәхес — «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыган һәм хәлфәлек иткән дәверендә «Вакыт» газетасына хәбәр, мәкаләләр язгалаштырган, катлаулы 1917-18 елларда да татар-башкорт халыкларының милли йөзен, киләчәген билгеләргә омтылган уй-фикерләрен «Яңа вакыт» аша белдергәләгән кеше. Шуңа өстәп ул бер ара бер зур эштә дә танылып ала: «сатлык» Зәки Вәлиди хөкүмәтен тотып төрмәгә яба һәм Совет Башкортстаны автономиясенең беренче рәисе итеп билгеләнә.

Менә шул Габдулла Дәүләтшинны, ни сәбәпледер үзе дә зиндан тәртипләре белән танышып чыкканның соңында, 1919 елның көзендә Орскига комиссар итеп җибәрәләр. Ул монда, аклар белән кызыллар аяусыз көрәш алып барган киң бер мәйданга, зур гына вәкаләт белән җибәрелә: Орск төбәге оборона командирының милли эшләр буенча урынбасары рәвешендәрәк була. 1920 ел башыннан ук бу Дәүләтшин Орскида татарча атналык «Ирек йолдызы» газетасын чыгара башлый. Газета ул Орскидан киткәнче — 1921 ел җәй урталарына чаклы чыгып килә. (Шәһәр музее фондларында бу газетаның 1921 ел җәендә басылган бер нөсхәсе саклана.)

Дәрдемәнд менә шушы Дәүләтшин белән уртак тел таба, бер ара аралашып ала.

Габдулла Дәүләтшинның хатыны, драматург Мирхәйдәр Фәйзинең сеңелесе Хәлимә апа ул елларны болай дип сөйләгән иде: Габдул-

ланың төп эш урыны татарларның элек-электән мәдәни үзәге саналган бинада урнашкан була. (Иске шәһәрнең үзәгендә, хәзер ул урында «Октябрь» кинотеатры.) Шунда акларга каршы көрәшүче кызылармеецлар, командир-комиссарлар да килеп йөриләр, шунда ук мөселман хәрбиләр һәм шәһәр халкы өчен лекцияләр, концерт-кичәләр оештырыла икән. «Ирек йолдызы»на мәкаләләр дә шунда ук туплана. Ул газетаның беренче битендә, гадәттә, хөкүмәт карарлары, төрле әмерләр татарчага тәрҗемә итеп басылалар. Боларның барысын да диярлек Габдулла Дәүләтшин оештыра. Ә аңа, хәленнән килгәнчә, Хәлимә апа булышып йөри. Ул яңарак кына гимназия тәгәлләгән.

Минем хәтерләвемчә, дигән иде Хәлимә апа, 1920 елның җәеннән башлап бу йортка шагыйрь Дәрдемәнд килгәләп йөрде. Дөнья хәлләре белергә дип, шундагы газеталар белән танышу өчен дә килгәндер инде. Еш кына алар Габдулла белән сөйләшеп китәләр дә, комачауламас өчен мин ул бүлмәдән чыгып тора идем.

— Дәрдемәнднең берәр шигыре «Ирек йолдызы»нда басылмадымы икән, хәтерләмисезме? — дип сорадым, бүлдереп.

Хәлимә апа:

— Хәтерләмим, аңа күп гомер үтте бит инде, — диде.

Дәүләтшинар Орскидан 1921 ел август азакларында китәләр. Аларның икесен дә Мәскәүгә, Коммунистик университетның шәрекъ халыклары бүлегенә укырга җибәрәләр. Бу вакытта Оренбург губернасында аяусыз ачлык башлана, урыннарда аңа каршы көрәшү өчен комиссияләр һәм комитетлар төзелә. Үзе теләпме, әллә Дәүләтшин киңәше беләнме, бу эшкә Дәрдемәнд-Рәмиев тә алына. Һәм нәкъ шул мәшәкатьләр белән йөргәндә, Оренбургтан Орскига кайтышлый, ул авырып китә һәм ваба чиреннән үлә. Хәлимә ападан мин:

— Дәрдемәнднең ачлык комиссиясендә эшләве берәр җиргә теркәлдеме икән? — дип сорадым.

Ул миңа:

— Белгәнегезчә, Казакъстан автономиясе башкаласы соңыннан Кызыл Урдага күчерелде, шул чор газеталары да, документлар да шунда булыр, бәлки, шул архивларда... — дип җавап бирде.

Нишләп Кызыл Урда архивындамы? Чөнки 1920—25 елларда Оренбург, Орск икеләтә буйсынуда тордылар: РСФСР да җитәкчелек итте, шул ук вакытта Казакъ-кайсак автономияле республикасы хөкеме дә үтәлде. Бу автономиянең башкаласы итеп Оренбург билгеләнгән иде.

Орскида шагыйрьнең соңгы көннәрен хәтерләүче тагын бер кеше яши — Мәрьям апа Бикбова. Урта хәлле сәүдәгәр кызы. (Ул Муса Җәлилне дә яхшы хәтерли — шул ук мәдәният йортында хәтта бергә халык алдына да чыкканнар, Мәрьям җырлаганда Муса аңа мандолинада уйнаган.) Апа-җизниләре, туганнары — җәмәгать эшләрендә бик катнашучан булганнар. Элек байтак еллар мәдәният йорты мөдире дә аның җизнәсе була. Орск зыялылары рәсемнәре, шулай ук Маһруй Борнаеваның ире белән төшкән фотосы да Мәрьям апа альбомында саклана.

Мәрьям апа «бик пөхтә киенеп йөрүче, бик тә итагатьле карт шагыйрь»не шәһәрдә күргәләп йөргән, әлбәттә, олы класс укучысы буларак аның шәхесе белән кызыксынган. Ә Дәрдемәнд үлгәч инде алар, берничә кыз, саубуллашырга дип аның өенә дә барганнар, шагыйрь җеназасын Урал елгасы аша чыкканчы озатып килгәннәр. Чөнки, авыр вакыт булуына карамастан, шагыйрьне шәһәр халкы елга аръягындагы зыялылар зиратына илтеп күмгән. (Шәһәр читендәге гомуми зират кайбер елларны су астында калганлыктан, зыялыларны атлы татар казаклар авылы Ильяс утарына илтеп күмә торган булалар. Габдулла Дәүләтшин да шул Ильяс утары мулла токымыннан.)

Соңыннан Дәрдемәнд кабере өстенә затлы гына кабер ташы да

куела. Әмма утызынчы елларда башланган зур төзелеш ул тыныч зиратка да кагыла. Зыялылар каберлеге Яңа шәһәр уртасында кала. Илленче еллар соңында, «Совет әдәбияты» журналыннан Вил Ганиев үтенгәч, без, Мулланур Вахитов исемендәге татар китапханәсенә йөрүче яшьләр, шагыйрь каберен бер эзләп караган идек. Зыялылар каберлегенең номерлы завод коймасы эчендә калганлыгы ачыкланды. Берничә елдан соң мин шагыйрьне күмүдә катнашкан Мәсгут бабай Шәмсетдиновны эзләп таптым. (Элекке приказчик, унынчы елларда Мирхәйдәр Фәйзи оештырган драма түгәрәге кешесе.) Без әлеге завод коймасы буена бардык. Ул:

— Шагыйрь Дәрдемәнд кабере менә шушы төштә була, — дип асфальт юл белән биек койма арасындагы бер тар җирне күрсәтте.— Сугыштан соңгы елларда кабер ташы да шушында аунап ята иде, утыртып, рәтләп киткән идем, — диде.

Ул кабер ташы, мөгаен, шушындагы берәр төзелешкә кирәк булгандыр. Яисә якындагы төзүчеләр бистәсендәге берәр өйнең нигез ташы хезмәтен үтидер. Никадәр аяныч хәл!

Инде сүземне шагыйрь белән чирек гасырдан артык бергә яшәгән, якыннан аралашкан бер зыялыга биреп тәгаллисе килә. Үзе дә әдәбият тарихында якты эз калдырган, мәдәниятыбыз күгендә беренче рәшә, беренче елдырымнардан булган олы әдип Фатих Кәрими шагыйрь турында мондый сүзләр язып калдырган: «Дәрдемәнднең кешелек ягы бик югары булып, ул гади татар байларына бер дә охшамый иде. Сүзендә, мөгамәләсендә соң дәрәҗәдә туры. Ул алдау, хәйлә, риялану, икейөзлелек итү шикелле нәрсәләргә дошман...»

Димәк, кылган эшләре белән генә түгел, кешелек сыйфатлары белән дә ул безнең барыбызга да үрнәк. Шул сыйфатлары өчен генә дә без, бүгенге варислары аны олыларга тиешбез!

Закир Рәмиев-Дәрдемәнд шәхес буларак билгеле бер чорда калыпланган, шул дәвердә ул бай сәүдәгәр дә, киң колачлы җәмәгать эшлеклесе дә, шагыйрь дә булган. Аны үз заманыннан, үз иш-фикердәшләре арасыннан һич кенә дә аерырга ярамый сыман. Шул ук вакытта ул замандашларыннан беркадәр аерылып та тора кебек. Чөнки, заманының һәр олы шәхесе кебек, ул үзенә генә хас олуг мирас тудырып калдырган. Без аны хәзер шул күркәм эшләренә, олы мирасына карап бәялибез. Шуның өчен аны ихтирам итәбез.

1989 ел.

## ПУБЛИЦИСТИКА

**Рахмай Хисмәтуллин**

# АҺ, СЫЗЛЫЙ, СЫЗЛЫЙ ҖАНЫМ...

Кызыл Мәйданның туристлар, чит ил хәбәрчеләре, һәртөрле фотографлар, тагын әллә кемнәр белән кайнап торган бер мәле иде. Ачыграк төштә сакаллы бер ирнең кулындагы дипломаты кинәт басмакка әверелде һәм ул аңа: «Әфганстандагы сугышны туктатыгыз!» дигән плакат элеп куйды. Аннары тиз-тиз генә ике як кесәсеннән шешәләр чыгарып башына койды һәм кычкырып та җибәрде:

— Балаларыбызның гомерен саклап калу хакына мин үземне яндырам! Уян, халкым, уян!

Аңа шундук гөлт итеп ут кабынды. Сакаллы кеше утка чорналгач кына, мин исемә килдем: бу бит минем күршем Гата яна! Җырчы Гата яна! «Нишләп карап торасыз, сүндерегез! Сүндерегез!» дип кычкырмакчы булам, ләкин тавышым чыкмый, бугазыма нидер тыгылган, урынымнан да кузгала алмыйм. Мине ниндидер кара көч баса, изә. Бөтен җаным-тәнем шабыр тиргә бата. Ут Гатадан миңа да килеп кабына, аннары инде Кызыл Мәйдандагы башка кешеләргә дә ялкын үрли...

Сулышым кысыла һәм мин уяным китәм...

Улымның хәрби хезмәт еллары да әфган сугышы чорына туры килгәнлектәнме, бу төш мине бик озак эзәрлекләде.

Әфганстанда инде сугыш та туктады. Ләкин йөрәктәге теге әрнү-үкенүләр һаман да төзәлми. Шул кичерешләрне әйтеп бирәсем килә.

...Яз башының сүрән, ямьсез бер көне иде. Әфган корбаны Рәис Гайнуллинның әти-әниләре яшәп яткан Новый поселогына юл тоттым. Чаллыдан 15 чакрымдагы бу поселок минем язучылык юлында элек тә очраган исем иде инде. Нәкъ шул төбәктә урнашкан Әҗмәкәй, Калмашлар турында язган очеркымны мин: «Менә күрерсез, биредә төзелеп яткан яңа поселокка Тукташ исеме кушарлар!» — дип чиксез ышаныч һәм пафос белән тәмамлаган идем. Ләкин минем алсу өметләрем чынга ашмады. Табеев заманнары иде. Саф татар авыллары уртасына китереп корган таш саланы тоттылар да, оялмыйча, «Новый» дип ататтылар.

Барып төшкәч тә бик исем китте. Беренче күрүем. Йә аллам, монда килгән безнең өч күренекле язучыбыз ни максаттан шушындый поселокны мактап китап язып киттеләр икән? Булса да булыр икән шыксыз дөнья! Ни архитектурасы, ни бизәге, ни милли йөзе юк. Татарлар яшәгән таш салада урамнарга, биналарга ник бер татарча язу элемсен! Калын каш астыннан Брежнев сыман, үтә канәгать булып, маемлап карап торган гел бер төрле таш йортлар. Бер үк төрле рәшәткәләр, тәрәзәләр, бер үк төрле язулар...

Автобуста ук миңа Рәис Гайнуллинның классташы очрап, өйләрен өйрәтеп җибәрде. Бераз яшь чакларын сораштырмакчы идем, аның бер дә җәелеп китәсе килмәде. Ашыга, үз дөньясы, үз кайгысы көчле иде. Ни сөйлисең, үлгән-беткән инде, дигәндер.

Мин авыр уйга батып, югары очка атладым. Нигә барам инде? Ата-ананың күңел яраларын гына әрнетәчәкмен бит. Үземнең дә менә хәзер җан өзгәләнә. Мин бит аларга берничек тә ярдәм итә алмаячакмын...

Хәтергә 1979 елның декабрь ахырындагы кичерешләрем килеп төште. Кич иде, кар ява иде. Яңа ел алды, Әфганстанга гаскәр кертүнең беренче

көне иде. Шунда ук бу хәбәрне ишеткәч: «Пычракка, хурлыкка баттык, их, харап булдык!» — дидем. Йөрәктән әллә нәрсә сызланып өзелеп төште. Бу гүя булачак корбаннарны алдан тою иде. Ул шомлы торгынлык елларында мин бу уйларымны кемгә дә булса сөйләп йөрәгемне бушата алмадым, куркыныч иде. Түз, кәгазем, дип, хәсрәтемне аерым бер дәфтәргә язып, кеше кулы җитми торган урында сакладым. Тапсалар, эш харап иде. Мондагы һәр юл йөрәгемнән өзелеп төшкән бәгырь кисәгем, халкымның кычкырып әйтә алмый торган аһ-зары иде. Ливония, француз, төрек, герман, япон сугышларында патша Рәсәе өчен инде халкымның күпме уллары харап булганнар. Менә тагын... Әфганстан... Таныш пропагандистлар белән очрашсам, каты бәхәс куба.

— Синең чигеңне бәреп керүчеләргә каршы сугыш кына гадел була ала, анда үләргә дә ярый. Әмма бу Әфган — хата, хата! — дим мин, бик каты кызып китеп.

— Син җүләрме әллә? — диләр алар, мәңге дә ялгышмас кешеләр сыман.— Әгәр без кермәсәк, Америка керә иде. Ул безнең көньяк чикләребезне саклар өчен кирәк!..

Канлы адымны әнә шулай аклыйлар иде.

Әле Әфганга кергәнче дә халкымның кара хәсрәтләре җитәрлек иде. Колакка чалынганнардан берничәсен генә санап үтәм:

1976 ел. Әгерҗедән Куян авылы егетен кургаш табутка салып кайтарганнар. Актаныш районы Айман авылыннан ике егет шул ук язмышка дучар булган. Кытай чигеннән кайткан Пучы егете сөйләнеп торды: «Белмим, мин анда ничек исән калганмындыр. Көн саен үлем иде анда».

Кавказ хәрби өйрәнүләрендә Азнакайдан ике татар егете һәлак булды. Әлмәт якларына алты татар солдаты кургаш табутта кайтты.

1977 ел. Саба районы Алан авылына бер подполковник хәрби хезмәтен тәгәлләп кайткан. Бичара подполковник өйләнә алмый икән. Вакыйгасы болайрак булган: Урта Азиядә хезмәт иткәндә бервакыт моның солдатлары йоклап китәләр дә уяна алмыйлар. Шуларның бер-икесен генә, шул исәптән подполковникның үзен, аңнарына китереп, госпитальгә салалар. Бу икесе дә көч-хәл белән генә терелеп аякка баса. Ләкин акылларына зур зыян килә. Ә солдатларның күбесе йоклап һәлак була. Сәбәбе: биредә солдатларның үзләренә әйтмичә кешене йоклатып үтерә торган яңа төр корал сыныйлар.

Инде авылга кайткан подполковникны яңадан Мәскәүгә чакыртып алалар да: «Әйдә, син яңадан хезмәткә кайт, без сиңа өстенлекләр бирәбез»,— диләр. Ә бичара офицер: «Ә ни өчен яңа корал сынауны миңа әйтмәдегез? Сез безне алдадыгыз, сез җинаять эшләдегез. Мин сезгә хезмәт итәргә теләмим! Менә коммунист билетым»,— дип билетын ташлап чыгып китә. И-и, әгәр дөньяда тәртип булса, бүген подполковник телевизор төзәтеп ялгыз яшәр иде мени?!

1978 ел. Туктаусыз корбаннар биреп торган туган халкымны милли яктан азат итеп, мәдәниятын үскән итеп күрсәсе килә. Әнә бүген 7 ноябрь бәйрәмендә, «Зәңгәр ут» тапшыруында Ренат Ибраһимов үзебезнең телдә: «Хәерле кич, кадерле иптәшләр!» — диде. Бөтен Союзга бит бу!

1979 ел. Соңгы сугышларның гарип яшь ветераннары күбәеп китте. 1957 елда венгр вакыйгаларында катнашкан Мизхәт дустым, җанына тынычлык таба алмыйча, эчкечелеккә бирелеп, һәлак булды. Чехословакия бәрелешләрендә катнашкан райондашым Имамиев кебекләрнең дә шактыйлары яшәү ямен югалтты. Имамиев 18 мәртәбә парашют белән сикерә һәм солдаттан «җиңеләеп» кайта. Бергә хезмәт иткән дусты, өйләнгәч, озак та тормый, паралич сугып, үлеп китә дә, аны җирләгәндә, кабергә салгач, Имамиев, аның йөзен кайсы якка карраттылар микән, дип төшеп карый. Чөнки дустының хатыны марҗа була. Шул кабердән ул тагын да зәгыйфьләнеберәк күтәрелә. Психиатрларда дәвалана башлый. Тормышы тәмам ватылды, таркалды...

Ир-егетләр корбан була тора, ә шул халыкның мәдәниятына һаман төкереп карыйлар. Безгә хәерче сыныклары гына тия. Үзәк телевидениедән Азнакай балаларының «Ләйсән» җыр-бию ансамбле чыгышын берничә тапкыр тапшырдылар...

Үзбәкнең «Хәмзә» киносында татар театрының үзбәкләргә беренчеләрдән булып яктылык алып баруы бөтен Союзга күрсәтелде. Алар фургоннарда «Сарман»ны җырлап узган чагында, нигәдер, күздән сыгылып-сыгылып яшьләр акты...

Янәсе, ике-өч дистә ел таләп иткәннән соң идеолог Суслов татар халкы

өчен «Идел» яшьләр журналын чыгарырга рөхсәт биреп кул куйган, диләр. Башка төрле вак-төяк хәбәрләр белән дә имезлек капкан бала сыман юанабыз. Пермьдә мәчет эшли... Кайдадыр бер ансамбль оешкан...

1980 ел. Татар халкының мәдәниятын күтәрү өчен монда кыл да кыймылдатмаган Табеев Кече Азияне яуларга Әфганстанга китте. Кайда кыен, кайда яна, шунда, барыбер, татар кирәк.

Польшада да коточкыч хәлләр: эшчеләр эш ташлыйлар...

Әфганстаннан Түбән Камага җиде табут кайтты...

Бер солдат хатыннан: «Бу хатны таныш шофер аша гына биреп җибәрәм. Моннан, Әфганнан, бернинди дә хәбәр чыкмый, диләр. Өч ай инде адәм рәтле ятак күргән юк. Кайта алырбызмы-юкмы, белмибез. Башлар исән-имин кайтсак, дип нәзерләр әйтәбез».

Бакча күршем Рюмочкинның шәһәрдәге күршесенең улын, әнисе үлгәч, биш айдан соң кайтарганнар. Сөйли икән: «Базарларда ашамлыклар агулы, һәр почмактан пычак белән кадап үтерүләре мөмкин. Безнекеләр, десант белән төшеп, аларны авыллары белән кырып чыгалар».

Балтач районы ягында өч солдатны табут белән кайтарганнар.

Әфган чигендәге Гөлстаннан авылдашым Тәүдиха яза: «Теге яктан эшелон-эшелон мәет кайта, ә бу яктан тереләр китеп тора».

Саратовта хәрби завод шартлаган. Хирург Гомәрнең малае шуннан газдан зарарланып кайтты. Нервы авыруыннан саташып вафат булды.

Телевизордан Саратов ягында Фәхретдинов дигән кешене, милли кысуга каршы чыкканы өчен, ун елга төрмәгә хөкем итүләре турында сөйләделәр...

Рәис Гайнуллин яшәп киткән йортка барып кергәч, мине юан гәүдәле, чал чәчле алтмыш яшьләрдәге бер агай каршы алды. Аның пошынкы һәм сүзсез кыяфәте минем болай да басынкы күңелемне томалап ук куйды. Чөнки бай итеп җиһазланган, иркен фатирның һәр почмагы сагыш-хәсрәт тулып, Әфганстанда үлеп калган улын сагына һәм шул дулкын әллә ничек миңа да тәэсир итә иде сыман. Бу агай Рәиснең әтисе булып, өйдә ялгызы моңланып ятуы икән. Илле өч яшендә генә булса да, пенсиядә инде. Уралда Кизеледә шахтада эшләп чыккан. Тумышы белән Мамадышның Шүләнгер авылыннан.

Әфган корбаны Рәис ике капма-каршы идеология җимеше буларак дөньяга килә. Коммунист Заһидулла райком секретаре булып эшләп, биш малай, ике кыз калдырып вафат була. Райком секретаре мин сөйләшеп утырган кешегә, Рәиснең әтисенә, «модный» революцион исем дә бүләк итеп китә: Фрунзе Гайнуллин... Әлбәттә, алдымда командарм Фрунзе түгел инде, ә гап-гади татар ире — Фәйзулла яисә Фәхретдин кебек җанга якын исемнәр бик тә муафыйкъ булырлык кеше. Аңа Фрунзе, дип дәшүе бөтенләй дә ят һәм читен. Нишлисең бит, ул кара Сталин заманнарында Заһидулла агай да бу исемне тормыш җиңеллегеннән куймагандыр. Моңсу...

Икенче яктан...

Без шулай моңсу гына сөйләшеп утырганда шау-гөр килеп хатын-кызлар кайтып керде. Таныштык. Фрунзе агайның хатыны Салисә ханым, кызы Роза, оныгы һәм ханымның апасы Халисә иде болар. Рәиснең туган көне уңаеннан мәктәптә чаңгы ярышлары үткәргәннәр, шуны карап кайтып килешләре. Әйе, икенче яктан, Рәиснең әнисе Салисә ханым көчле рухлы муллалар ягыннан. Балтач районының тау-таш токымнарына тартым җирән чәчле, сипкеллерәк йөзле бу ханым әңгәмә түгәрәгенең бер ягына килеп кунаклагач, бөтен тирә-якны сагыш күмеп киткәндәй булды. Кайдан ул, нинди үзәк өзгеч моңлы сагыш бу? Моны аның апасы Халисә ханым аңлатып бирә алды сыман. Рәиснең әнисе ягыннан бабасы Мөхәммәтгариф Хәмбәл — Балтачның Сасна авылындагы борынгы муллалар токымыннан. Ул әле анда мулла булып торырга да өлгереп кала. Ә инде культ чорында аның гомере хәсрәт-газап белән тула. Аны гаиләсе белән туган ягын ташлап Нижний Новгород якларына күченеп китәргә мәҗбүр итәләр. Әмма Мөхәммәтгариф ага иманына хилафлык китерми. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул дин юлыннан читенми. Аракы эчми, тәмәке тартмый, килгән хәерләрен Уфага диния нәзарәтенә җибәреп тора. Мәскәүгә барып хаҗга юл тотучыларны озатып, кайтучыларны каршы алып йөри. Аның тагын бер гүзәл сыйфаты була. Ул халык медицинасы ысулы белән авырулар карый, корым белән корчаңгыны юкка чыгара, сулышы белән теш авыртуын туктата, зәгъфран белән дә авыруларны сихәтләндерә.

Бугазга-бугаз килеп көрәшкән менә шушы ике дөнья уртасында туган

Рәис, әлбәттә, бабаларының ни белән янганнары турында кызыксынырлык туфракка төшми. Аны бөтен тирә-як бары тик «кызыл» итәргә тырыша. Бу турыда язуы да авыр. Ул үзе гашыйк булган татар кызына да бары тик русча гына эндәшә, шигырьләрен дә русча гына яза:

Я каждое утро в школу спешу,
Пока в коридорах стоит тишина.
К доске подхожу я и мелом пишу:
«Наташка, я ж тебя люблю».

Яраткан герое да — рус китабыннан Тюленин гына. Татар поселогында яшәвенә карамастан, гүя аңардан татарлык бөтенләй куптарылган, бәреп чыгарылган диярлек. Әллә шуңа да инде бүген әнә әнисе минем каршымда хәсрәтен күтәрә алмагандай бөкрәеп утыра. Аңа карап алганда, аның тетрәндергеч сагышы тәнем буйлап ток булып йөгереп үтә. Алдымда яткан альбомдагы шигырьне дә сөекле улы, әлбәттә, аны сагынудан язып җибәргәндер, әмма... һаман шул бер тойгы мине һич тә ычкындырмый. Мөселман җирен бастырырга киткән татар егете, мулла оныгы Рәис газиз анасына язган шул сагыну шигырен дә русча гына иҗат итә. Бу хәл әллә нигә бөтен җан-тәнне тагын да ватып, мәсхәрәләп ташлый сыман.

Поздравляю, мама, с днем рождения
И желаю долгих лет.
Написал тебе стихотворение,
Хорошо, а может быть и нет...
Пожелать тебе хочу я много,
Только все не выразить в словах.
Вот когда вернусь, родная мама,
Все расскажу, не в письмах, а в словах.

Чит телдә бу шигырьдә әйтелгән сагыну, әйтерсең лә, броня капчыкта ята. Ул броняны ватасы һәм Рәиснең сагынуын туган теленә кайтарып, ирекка чыгарасы, ананың йөрәк түренә илтеп җиткерәсе килә. Әмма бу ят броня инде мәктәптә чакта ук коела башланган. Бервакыт рус теле укытучысы Роза Николаевна русча укучы татар классына мондый сорау куя:

— Балалар, ни өчен сез укытучыларны тыңламыйсыз? Сез бит мондый түгел идегез. Ни булды сезгә?

Шунда барысы өчен дә Рәис җавап бирә:

— Ә без, Роза Николаевна, бер буыннан икенче буынга күчәнәбез.

Юк, минемчә, алай гына түгелдер. Бөтен кешелек бер буыннан икенче буынга күчәнә тора. Бу табигый. Рәис тирәнрәк тойгыны — фаҗигалерәк хәлне — яшерен мәҗбүриятле рәвештә бер милләттән икенче милләткә күчәнү тойгысын, үз теленнән җирәнә башлаган, димәк, тәртипләргә дә төкереп карый торган авыр язмышлы яңа буын килүен әйтергә тырышкандыр. Шигъри җанлы, баянда да оста уйнаучы моңлы егет милли рухның броняга каплану фаҗигасен, яшьли үләсе кешеләргә хас булганча, әүлияларча, алданрак, ныграк сизенгәндер. Кем белә, Рәис, бәлки, шагыйрь дә булып китәр иде.

Әмма... «Вот когда вернусь, родная мама», дип язган талантлы егет инде башка беркайчан да кулына каләм тота һәм беркайчан да терелеп анасы каршына кайтып баса алмас...

Мин монда тагын яшерен көндәлекләремә кайтырга мәҗбүрмен.

«1982 ел. Төрле хәбәрләр, гоманлаулар, имеш-мимешләр белән дөнья тулды. Якын танышлар Әфган турында сөйләгәндә, борчылып, кисәтүле сораулар биреп узалар: «Сизәсеңме, тегендә дә, монда да мөселманнар кырыла. Яңа, мамыклы союздаш республика була инде, тик мамыгы гына канлы булачак».

Класстшым Фәрвәй сөйли: «Малаем армиядән ялга кайтты. Берни сөйләми. Шулкадәр кызганыч, тагын китә инде. Исән-имин кайта алырмы, алла гына белә. Бер диган егет, их, харап кына итмәсәләр ярый инде».

Хатынымның апасының улы Саба районы Күкчәгә аягы яраланып кайтты. Кеше белән сөйләшми, йомыкыйланган. Авыр тәэсир калдыра.

Улым Азат укыган татар мәктәбеннән киткән өч егетне кургаш табут белән кайтардылар. Улым әйтә: «И әти, син гел йөрисең ул, татар, татар, дип. Ул бит беркемгә дә кирәкми. Әнә аны үтерәләр дә кайтаралар, үтерә-

ләр дә кайтаралар. Татар мәктәбе дә бетәчәк ул болай барса...»

— Син, улым, алай төшенкелеккә бирелмә әле. Мәктәбе бетсә дә, татар бетә дигән сүз түгел бит әле ул... Иртәме-соңмы, татар, барыбер, үз дөньясына кайта башлаячак,— дип ышандырырга тырышам.

1983 ел. «Кама таңнары» әдәби берләшмәсендә яшь язучы Гыймаев сөйли: «Әфганнан безнең Баулы районы Акчишмә авылына ике солдат кайтты. Берсе яралы, рәтләп йөри алмый. Ә икенчесе... икенчесе җәен, чаңгы киеп, печән чабарга чыгып китә. Берни дә эшләми. Әфганда анда солдатларга ашарга юк икән. Өс-аяк киемнәрен ит-ипигә сатып туенып яшиләр, өсләре тулы бет икән. Наркомания, эчүчелек таралган. Янәсе, башта солдатлардан: «Сез һөҗүмгә барырга ризамы?» — дип сорыйлар икән. Яртысы риза, яртысы кала икән. Кара чәчлеләрне бик үк атмыйлар, ә инде сары чәчле кеше күренсә, хәтта Кабул урамында да шундук юк итәләр икән».

Мин аптырыйм: ничек шулай булуы мөмкин икән соң? Безнең илдә алай булырга тиеш түгел иде. Илебез әйбәт дип мактана идек бит...

1984 ел. Өч мең әфганлы безнең алты йөз солдатны кырып китә. Шулар арасыннан ике табут Түбән Камага да кайтты. Ачарга рөхсәт итмәделәр.

Анда татарның да асыл уллары һаман харап булып тора. Ә монда милләт үз телен югалтып зар елый. «Азатлык» радиостанциясеннән безнең татар хәлләрен биреп яталар: «Татарча нәфис фильмнар чыгару хыял гына булып кала бирә. Татарстанда һәм Башкортстанда милли мәктәпләр елдан-ел кими бара. Патша Россиясе эшли алмаганны бу система алтмыш елда эшләп ташлады. Төрекмәннәр Мәхтүмколыйның ике йөз еллыгын Мәскәүдә билгеләп үттеләр. Анда СССР җитәкчеләре дә катнаштылар. Ә татар халкының бөек шагыйре Кол Галинең сигез йөз еллыгын шулай зурлап үткәрүне кирәк тапмадылар».

Түбән Камадан Сәлимә Җамалиеваның малае Әфганнан авырып кайткан. Ярты елдан ярты елга врачта тикшереп торалар. Элек бик күп китап укый торган була, хәзер укымый. Музыка куймыйча, йоклап та китә алмый. Рәтләп кеше белән сөйләшми икән.

Әфганнан кайтканнарга льготалы рәвештә квартира бирә башларга, дигән карар кабул иткәннәр. Ләкин урыннарда моны бик үк үтәмиләр икән. Шуның аркасында, безне алдадылар, дип, фатир бирмәгәч, үзләрен харап итүчеләр, хәтта яндыручылар да бар икән... И аллам, нинди хәл соң инде бу? Ил таркала бит, ил бетә, дәшми ничек түзәсең?

1985 ел. Язучы Разил Вәлиев Әфганда булып кайтты.

— Кайчан җиңәбез соң инде анда, Разил? Бик озакка суздык түгелме соң инде?

— Анда бу эш тагын да озакка барачак. Җитмеш биш процент территория «дошман» кулында. Алар таш астына яшеренгәннәр. Домкрат белән ташны күтәртәләр дә һөҗүм итеп алалар. Аннан тагын, ташны төшереп, яшеренәләр. «Дошман» ягында — илле меңлек армия...

Менә шушы мәхшәр дөньяга ташланган Рәистә татарның уңай сыйфатлары ныграк чагыла. Ул инде армиягә киткәнче үк басу-кырларда эшләп, Мактау грамоталары алган була. Бәлки, шушы ике дөнья көрәше уртасында туган яңа бер дуамал токым вәкиле булырактыр да, ул үзенең армия хезмәтенә ашкын бирелгәнлеге белән бөтен тирә-якны, бар командирларны шаккаттыра. Без әңгәмәләшеп утырган арада боларның туганы Резидә исемле кызда саклана торган гаҗәеп бер хат алып кайттылар. Заманның бу тетрәндергеч документын хисләргә-уйларга бирелеп, туктап-туктап укырга туры килде.

«Ул монда, безнең коллективта, бик тиз үз кеше булып китте,— дип яза иптәш солдаты.— Мин аның белән шундук дуслашып киттем. Рәис миңа энергияле, белемле булуы, теләсә нинди коллективта үзенең бәясен саклап тота белүе белән ошый иде. Безнең дуслыкның бик кыска гомерле булуы гына кызганыч.

Ул безнең частька сиксән өченче елның ахырында килгән иде. Бик тиздән аны танк командиры итеп куюларына беркем дә гаҗәпләнмәде. Югыйсә, бездә андый урынга тәҗрибәле солдатларны гына куялар иде. Аның танкы ротада иң яхшыдан саналды. Һәрвакыт пөхтә, шат күңелле, аралашучан — ул безнең хәтердә мәңгегә шулай булып калды».

Моны гап-гади солдат дусты яза. Әфган мәхшәреннән торып яза. Шунысы белән дә ул күңелне әллә нишләтеп җибәрә сыман.

«Ул көн гүзәл иде: күге зәңгәр, җиле рәхәт, яшисе дә яшисе иде әле. Әмма табигатьнең гүзәл көнен мәхшәргә әвереләдереп сугыш бара. Сугыш кырында дошман снаряды тиеп, бер транспортер сафтан чыга. Бернигә кара-

мыйча, андагы яшерен документларны һәм яңа приборларны алып чыгарга кирәк була. Рәис танкы шуны коткарыр өчен туктаусыз бомба явып торган тәмугка кереп китә. Транспортер янына килеп җиткәч, төшеп, аның эченә үтәргә тырышалар. Ләкин люк ачылмый. Рәис механикны лом алып килергә җибәрә. Ул арада кышлактагы дошманнар ут яудыруны тагын да көчәйтәләр. Бөтен яктан туктаусыз автоматтан аткан тавышлар яңгырап тора. Шулчак бер снаряд алар танкысының башнясын алып ата. Рәиснең ярты гәүдәсе бер тонналы башня бронясы астына кысылып кала...

Шуннан соң безнекеләр кышлакка артиллериядән туктаусыз ут койдылар, өстән вертолетлардан да көчле бомбалар яуды. Шуңа карамастан басмачылар утка каршы ут белән җавап бирүләрен дәвам иттерде. Мондый шартта Рәисне өстән люкны ачып чыгаруы бик куркыныч иде. Аны безгә кул белән дә, автомат кабы белән дә бик озак интегеп астан казып чыгарырга туры килде. Егетләр иртәнге сәгать унберда һәлак булды, ә без Рәисне үлем кырыннан бары тик караңгы төшкәч кенә алып чыктык. Караңгыда башта аның йөзен ачык күреп булмады. Аннары фонарь яктысында карадык: йөзендә, башында бер тырналу әсәре дә юк иде. Чәчләре дә янмаган, тик йөзе генә бик каты агарган иде. Күкрәге бераз эчкә батып кергән, ике кулы да исән иде. Ә менә аяклары... уң аягы тулысынча изелеп сытылган, ә сулы берничә урыннан сынган иде. Димәк, әле ул башня астында кысылып ятканда да исән булгандыр, бахыр. Ярдәмгә чакыргандыр...»

«Рәисне Союзга алып кайтып китүчеләр аны озатырга лаеклы кешеләр түгел иде. Аларның мондый командировкага хаклары юк иде. Алар — кабәхәтләр. Мин аларны башкача атый да алмыйм. Алар Союзга эләгеп, аракы белән тыгыныр өчен генә кайтып киттеләр. Озатучы прапорщик үз гомерендә бер мәртәбә дә автомат тоткан кеше түгел иде. Ә кайткач, Рәисне әти-әниләренә тапшырудан хурлыклы төстә качып киткән. Кабәхәт, тыл күсесе! Мин ул явыз мертәтне үз кулларым белән атып үтерер идем. Рәис өчен һәм бу каһәр суккан әфган сугышында һәлак булган барлык иптәшләребез өчен, Резидә, без һичшиксез үч алачакбыз. Рәисләргә аткан кышлакның инде көлен күккә очырдык. Башта төне буена аңа «градлардан» (реактивный артиллерия установкалары камилләштерелгән «Катюшалар») аттылар, пыр туздырдылар, ә иртәгесен без бөтен рота белән шунда ташландык һәм артиллерия утыннан соң исән калган һәр җан иясен кырып үтереп чыктык.

Мин бу язда армиядән кайтам. Әмма хәзергә әле монда хәрби хәрәкәтләрдә катнашам, һәлак булган дуслар өчен үч алам. Бу минем генә карарым түгел, ә бөтен рота шулай ди. Без ул хәшәрәтләрне инде бик күп кырдык. һәм без сугышлардан чыкканчы бөтен әфганын кырып үтереп барачакбыз».

...И газиз адәм балалары! Ватанпәрвәрлек хисе белән исергән урысы, татары, украины һәм башкасы «Бөек Союз! Союз!» — дия-дия, сез күпме кан койдыгыз, гомерләрегезне дә җәлләмәдегез. Ә торгын Брежневлар, ялагай Сусловларның хәйләкәр, астыртын өере сезнең гомерләр өстеннән, газиз улларыбызның язмышлары өстеннән идиотларча каһкаһә белән көлде.

Менә еллар үтте... Сезнең үтереп йөрүегез дә, үзегезнең һәлак булулар да илгә һич тә кирәк булмаган бит. Аңыбызны томалаучы коточкыч икейөзле пропаганда тәэсирендә сез үзегез чит илгә бәреп кереп, үз җирен саклап изге сугыш алып баручыларны бандитлар дип атарга, кабәхәтләр, дип сүгәргә мәҗбүр булдыгыз. Шуңа да әнә исән калып туган җиргә кайткач та, алданганлыгыгызны аңлагач, шактыйларыгыз, хәтта, үз-үзенә кул салуга кадәр барып җитте»...

Көндәлеккә соңгы тапкыр сүз бирик.

«1986 ел. Казан. Автовокзал. Мари республикасының Бәрәңге районында бер егет ике Кызыл Йолдыз ордены тагып кайта. Бер кызны көчли. Хөкем итәләр. Психикасы какшаган дип табылу нәтиҗәсендә генә төрмәгә утыртмыйлар. Бу егетнең дусты әфганда үлеп кала. Әти-әнисенә Казанда дүрт бүлмәле квартира бирәләр. Күченәләр. Ләкин икенче көнне әтисе авыр кайгысыннан йөрәге ярылып үлә.

1987 ел. Коточкыч хәлләр китте бит әле. Әллә ниләр, әллә ниләр булып тора дөньяда, әнә Мәскәүдә кырым татарлары туган илләренә кайтаруны сорап ялваралар. Тик кайтармыйлар.

Нигә шулай икән? Көн саен меңләгән кешеләр пулядан кырылып тора. Бер дә исебез китми. Әмма менә Әфганда бер солдат үлсә дә, әллә нигә бик авыр, бик читен һәм ямансу. Берәр вакыт бу хәлләргә чик куелырмы?

Күптән түгел Карадуган авылына, китүенә өч айдан соң, улларын кургаш табутка салып кайтарганнар. И бу дөньясын...

Түбән Камада Әфганнан кайткан бер егет этисен, энисен балта белән чабып үтерә. Энесе генә качып котылып кала. Соңыннан, ни өчен алай эшләдең, дип сорагач, «Тегеннән кушып кайтардылар»,— ди икән. Коточкыч хәл!

Әфганнан ике егетне печеп кайтаралар. Дошман ягына әсир булып төшкән булганнар. Берсе Мамадышныкы, икенчесе Түбән Каманыкы. Түбән Камадагысы асылынып үлә. Сәбәбен иптәшемнән сорагыз, дип язу калдыра. Мамадыштагы иптәшенә барсалар, ул да асылынып үлгән була.

Түбән Камага берничә табут кайта. Берсен ачып карасалар, эченнән мамык кына чыга. Әтисе моны күреп акылыннан шаша».

Солдат хатын дәвам итик. «Син, Резидә, Әфгандагы хезмәт турында тулырак язуымны сорыйсың. Ни яза алам соң инде мин моннан? Биредә һаман сугыш бара әле. Әлбәттә, туктаусыз яу, кырылыш кына түгел. Гаскәрләрнең шактый өлеше сугышта катнашмый. Союздагы сыман эшлиләр, нарядларга йөриләр. Ә без — разведчиклар. Безнең хезмәт башка.

Миндә Рәиснең бер фоторәсеме дә юк. Ул соңгы операциягә китәр алдыннан без аның белән палатка янында рәсемгә төшеп калган идек. Якташым белән төшкән фотоны альбомыма куярмын дигән идем. Кызганычка каршы, пленка фотоаппарат белән бергә танк эчендә янып юкка чыккан. Резидә, мин синнән Рәиснең фотосын җибәрүеңне бик үтенәм. Гомумән, миңа гел язып тор. Рәиснең әти-әниләренә әйт: әгәр аларның Рәис турында ни дә булса беләселәре килсә, язсыннар. Без бит монда бер дус гаилә булып яшибез, башкача булдыра да алмас идек. Чөнки теләсә кайчан безнең һәрберебез белән шул хәл булырга мөмкин. Без сезнең хатларны һәрвакыт шатланып кабул итәрбез. Әлбәттә, без берничек тә сезнең кайгыгызны җиңеләйтүдә ярдәм итә алмыйбыз, Рәисне терелтеп булмый. Әмма сезнең гаилә өчен без булдыра алганның бөтенесен дә чын күңелдән һәм бик зур теләк белән эшләр идек. Солдат хезмәтем беткәч, мин һичшиксез Рәиснең каберенә барып чәчәкләр куячакмын әле...»

И-и, бәхетсез адәм балалары!.. Сезнең ротадан бары тик бер генә солдат, Калмаш егете Рамил Двояшкин гына исән калган шул. И хат авторы! Син дә башкача хат яза алмагансың инде, кайтып, Рәиснең каберенә чәчәкләр дә сала алмагансың. Никадәрле үкенеч! Синең истәлегең булып менә хәзер инде саргаеп беткән шушы игелекле хат кына торып калган. Ичмаса, хат ахырында исемеңне дә язмагансың. Рәхмәт инде, бик киң күңелле кеше булгансың син. Сагынган саен Рәиснең ата-аналары Резидәдәге шушы хатны алып кайтып укыйлар. Укыйлар да елыйлар... Менә хәзер ике ягымда минем бу хатны күчереп алуымны карап утырган моңсу ата-анага күз салам да тагын үз эшемне башкарам.

«Рәис бик кыска, әмма пакь, гадел гомер кичерде,— дип дәвам итәсең син.— Ул намуслы яшәде, намуслы хезмәт итте. Ул шәп командир, тәртипле, кушканны үтәүчән солдат иде. Ротада барысы да Рәисне хөрмәт итәләр һәм яраталар иде. Ул Ватан алдында үзенең гражданлык һәм интернациональ бурычларын ахырынача үтәп, батырларча һәлак булды. Аның истәлеге мәңге яшәсен! Менә, Резидә, синең барлык сорауларыңа да җавап бирдем, ахры. Барысын да пөхтә итеп яза алмаганым өчен гафу ит. Почтаны безгә кич белән алып киләләр. Ә синең хатың, фамилия дөрес язылмаганга, безгә отбойдан соң гына килеп җитте. Әмма мин түзә алмадым, электр утлары юк, дип тормадым, кичкенә генә керосин лампасы яктысында язарга тотындым. Иртәнге көтеп тору мөмкин түгел иде, йөрәгем тирәннән кайный иде. Синнән хатлар көтеп калабыз, Резидә.

Беренче рота разведчиклары. 4.03.1984 ел.

Хатны «Рәис Гайнуллинның дусларына», дип яз.

Хушыгыз».

Керосин лампасы яктысында бер утыруда тетрәнү-ярсу тулы сигез битле хат язар өчен нинди көчле рух кирәк булгандыр бу солдатка! Менә кайда ул гуманизм! Менә кайда ул чын дуслык!

Улларының гәүдәсе салынган кургаш табут кайтып төшү Фрунзе агай белән Салисә апаны дөньяда моңарчы күрелмәгән авыр хәсрәт белән тетрәндерде. Зиһеннәре томаланды, күзләре берни күрмәс булды, колаклары да әллә ишетте, әллә юк, һушлары-исләре югалды. Икесен дә бер яктан күрше-күлән, икенче яктан мәетне озата килгән хәрби комиссар гына җитәкләп йөртте. Улларының һәлак булуына һич тә ышанасы килмәде. Табутны ачып карыйсы, расларыйсы, күңелне ни беләндер юатасы, тынычландырасы килде. Әмма туган-тумачалар да, озата килгәннәр дә

— Күңелегезне җәрәхәтләмәгез, ачмагыз. Элек күз ул алдыгызда ничек елмаеп торган булса, шулай булып калсын, зинһар,— дип ялындылар. төрле яктан үгетләделәр, ачтырмадылар. Ичмаса, Әфганнан ук озата килгән әнә теге прапорщиклар монда булса, ничек-ничек булганын сөйләшерләр иде. Юк шул, кайдадыр әчеп егылганнар, кабәхәтләр. Югыйсә, беләсе, сораштырасы, ачыклыйсы, әчкәйләрендәге утларны басасы иде.

...Ачыкланмаган, яшәлмәгән, шатлык-бәхетләр татый алмый калган уллары җир куенына китте...

Дөрес, мәктәптә аның партасы, аның исемендәге дружина, поселокта аның исемендәге урам бар. Аңа багышлап спорт ярышлары уздыралар. Бәлки торабара бүген мәгънәсез яңгыраган Новый поселогы да бүтәнчә, бәлки Гайнуллин дип аталыр. Ләкин Рәиснең үзе юк бит, аны берни дә алыштыра алмый. Бу исемнәр, чаралар алар бар да алдау-юану гына. Рәиснең үзе юк!.. Аның яшәешен мәңгелеккә дәвам итәргә тиешле мәхәббәте, гаиләсе, балалары юк. Аның тамыры мәңгегә өзелде. Аның белән бергә Фрунзе агайның ир нәсел җебе дә юкка чыкты. Акыл бик соң килә икән. Фрунзе агай шахталарда, зимагурлыкта йөреп, нәсел җепкәйләрен рәтләп ныгыта алмый калды шул. Рәисе аның бердәнбер якты өмете иде. Тәтенле Урал шахталарында туды да, утлы Әфган далаларында шартлап өзелде. Аның бердәнбере хәзер туфракка, суларга, болытларга, җилләргә әверелеп ята...

...Ә бит ул да сөйгән кызына багышлап шигырьләр яза иде. Ул да, күзкәйләрен киң ачып, Шәм, Ут, Кояш, Сөю, Мәңгелек дип, бөтен дөнья каршында басып тора иде. Бүген инде, әнә, зираттан, аның моң-зарлы агачларыннан, бу газиз туфраккайдан Рәиснең ятим, мәңге дә кавыша алмас Сак- Сок тавышы яңгырый. Русча яңгырый:

«Я пишу тебе записки,
А ты рвешь их, не читая,
И домой тебя не я,
А Сережка провожает».

Әйтерсең лә иртә үләсе, яшьли бетәсе кешеләр үзләренең югаласыларын алдан ук белеп, әнә шулай җан әрнеткеч, тетрәндергеч юллар калдыралар:

«Все смеются надо мною,
Неужели ты не видишь,
Как мне больно,
О, как мне больно!»

Бу сүзләрдә гүя бөтен дөнья сызлануы. Нинди бәхетсезлек! Туган телендә бер тапкыр да: «Яратам», дип әйтә алмаган татар егете, гөнаһсыз татар баласы, мәгънәсез фәрманнарга буйсынып, мөселман җиренә сугышка китә дә, туган җиренә кайтарылып, мәңгелеккә юкка чыгуга, мәңгелек авыртуга әверелдерелеп, билгесезлеккә иңдерелә...

...Ниһаять, гаделсез сугыш тәмам. Безнең гаскәрләр — Әфганстаннан, газиз улларыбыз афәттән котылып, туган җирләренә кайтты. Язгы кояшлы урамнардан үтәм: йөрәктә барыбер сызлану. Күпме яшь кенә бәгырькәйләр инде бу кояшлы көннәрне мәңге дә күрә алмаячаклар. Элек җыелышларда, зур залларда төкерекләрен чәчә-чәчә»: «Без — дөрес юлда, без хаклы! Без интернациональ бурычыбызны үтибез!» — дип күкрәк каккан, лаф орган, миләре катып беткән пропагандистлар очраштыргалый. Аларның да күзләре ачылыр икән! «Кара әле, синең, дөрес кермәдек, дигән сүзең хак булган икән бит, ә?» дип шаккаткан булалар. Әмма бу каты маңгайларның карашын үзгәртер өчен күпме корбаннар китерергә туры килде.

Россия башка халыкларның җирен үзенә куша барып, әлбәттә, иң беренче чиратта рус халкына җиңеллек китерергә тырышкандыр. Вакытында аңа ул җиңеллек килгәндер дә. Безнең Татарстанда гына да иң уңдырышлы җирләр, иң сутлы уңай су буйлары, иң уңдырышлы печән-болынлыклар руслар кулында иде. Әмма «кешене хезмәт тудырган», дигән бөек сүзне искә алсак, гел генә башкалар җире, башкалар хезмәте хисабына яшәүнең дә бер чиге бар икән. Бу процесс кешене пычрак упкынга мәталдерергә мөмкин. Башка беркем дә гаепле түгел, әнә шул башкалар хезмәте хисабына яшәүләр, әнә туктаусыз басып ала барулар, ниһаять, беренче чиратта рус халкын упкын чигенә китереп терәде. Ни әйтсәк дә, халык бит ул, үз бит ул, кызганыч бит ул. Бөек рус халкының шундый халәттә калуы җанымны әрнетә.

Хәзер аның гасырлар буена басып алган җирләрне тотарга, йотарга, үзләштерергә рухи көче калмады. Әфганстан соңгы калҗа булды. Ул аны йота алмады. Әгәр аны йотарга рус халкының хәле калган булса, әгәр ул аңа кирәк булса, анда күпме корбаннар салуыбызга да карамастан, без анда җиңәргә тырыша идек һәм җиңә идек. Тик әлек яуланган, йотылган, эшкәртелгән дип исәпләнгән җирләр дә ахырынача йотылмаган, эшкәртелмәгән булып чыкты. Инде башын игән, халыклары үз язмышлары белән тәмам килешкән дип исәпләнгән, «советлашкан» дип уйланылган җирләрдә әле анда, әле монда төп халыклар терелеп, үзләренең дөньяда барлыкларын белдерергә, үз асылларына кайтырга тотындылар. Союздаш, автономияле дип аталган, искергән бәйләнеш баулары бер-бер артлы шартлап өзелә башлады. Уяна барган халыклар борынгы эзләрен, телләрен, гореф-гадәтләрен, ата-баба акылын, элекке дәүләтчелекләрен эзләргә тотындылар.

Үз өең янганда читтәге янгынга кысылырлыкмыни?!

Әнә шулай биш-алты гасыр буена гел чит җирләрне, чит халыкларны үзенә буйсындыра барган гаҗәеп зур ил, бөтендөнья революциясе ясап, бөтен җир шарына киңәергә хыялланган уникаль, катлаулы Советлар Союзы, көтмәгәндә диярлек, әҗәл сызыгына килеп басты. Үз илендә Алма-Ата, Грузия, Якутия, Балтыйк буе вакыйгалары кайнап торганда, тагын да башка халыкларны яулап алуны дәвам итәргәме, әллә соң акыллы юл сайлап, өзелә-таркала башлаган союз җеп-бауларын яңабаштан ныгытырга карарга керешергәме? Әлбәттә, һавадагы торнага үрелгәнче, кулыңдагы чыпчыкны саклап калу хәерлерәк иде.

Шушы дилемма торгынлыкны үзгәртеп коруга алыштыртты.

Әнә шундый шартларда моңарчы җиңелү белмәгән империя, Әфганстанның кабылмый калган беренче һәм соңгы калҗа икәнлеген танып, тугыз еллык сугышта җиңелеп артка чигенде. Әнә шулай итеп Әфганстан, бөек илгә бөек тетрәнү китереп, аның күзен ачты. Халыкларны бәхетсез иткән империянең беркемгә дә кирәге калмавын аңлап, ил ирекка таба моңарчы күрелмәгән демократик хәрәкәт башлады.

Бу күз ачылуда Әфган корбаннарының да, шул исәптән Рәиснең дә кайнар каны саркып тора...

*5.05.90.*

Флора Әхмәтова

# КАЗАНДА ТАҢНАР НИ ТӨСЛЕ?

Бу мәкаләне мин быелның март аенда, Бакый ага Урманче каты авырып, яз башының алты төнен Казанның чокыр-чакырлы урамнары буйлап «Ашыгыч ярдәм» машинасында чапкан көннәрне яза башлаган идем. Эпиграф итеп Тукаебызның Х. Ямашевка багышлаган шигыреннән:

...Бармыни бездә, гомумән,
Чын кеше кадерен белү.
Без аны каян белик,
Мискин үлеп аңлатмагач? —

дигән юлларны китереп, милләт һәм мәдәниятебезнең вәкаләтле затларын, хөкүмәт әһелләрен кисәтебрәк кую иде исәбем...

Әле көн саен илнең төрле почмакларыннан, Америка, Англия, Австралия, Төркия, Финляндия, ФРГдан килә торган телеграммалар, өйдә хәл белешеп телефон аша әйтелгән тәгъзияләрдә, үтә зур кайгы уртаклашу белән рәттән: «Бу ничек болай булды соң әле? Бик таза, көр, шат, дәртле йөри иде бит»,— дип, йөзгә житүенә һич шик тотмаган дусларыбыз, милләттәшләребез һәм, гомумән, тарих өчен мин моны язып калдырырга һәм, форсаттан файдаланып, кайбер башка мәсьәләләргә дә кагылып үтәргә булдым. Бу уңайдан хәзер Татарстан республикасы яңа статуска — мөстәкыйльлеккә ирешкән һәм Бакый ага ул шатлыклы хәбәрне ишетә алмыйча берничә көн элек китеп баруы сәбәпле, язмамның таң атуга бәйле исемен калдыруны да мәгъкуль күрдем.

Былтыр кыш грипп эләккәч, Бакый ага, гадәтенчә креслосында утырып, яраткан «За рубежом» газетасын укый-укый: «Быелгы грипп Бөекбритания королевасы һәм Рим папасына да эләккән», дип куйган иде. (Андый зур кешеләр белән бергә авыргач, жиңелрәк үтәр, дип уйлаган, күрәсең). Әмма грипп икебездә дә пневмония белән катлаулангач, һәм ул чирдән Мадридда Д. Ибаррури да дөнья куйгач, мин олы кеше сәламәтлеге өчен шактый хәвефләнгән идем. Шөкер, һәм табиб Калерия Николаевнага рәхмәт, 33 көн 2-РКБда дәваланып, өйгә кайттык.

Бер атнадан төн саен аның борыны каный башлады. Әлбәттә, мин тагы шул РКБга — «спец»ыбыз дежурныена шалтыратам һәм... «Гафу итегез, без инде сезгә килә алмыйбыз. Хәзер монда Бөек Ватан һәм Әфган сугышында катнашканнар гына калды»,— дигән хәбәр ишеттем. Димәк, привилегияле хастаханәне «чистарту» эшен, иң перспективасыз карт итеп, Урманчедан башлыйсы иткәннәр. Менә шунда белдек инде без шәһәрнең башка шифаханәләре нәрсә икәнен! «Ашыгыч ярдәм» машинасы алып килә берәр клиникага, борынына тампон тутыралар да кире алып китәргә кушалар: нигә кертеп салсыннар каны агып яткан бер картны?!

Гөнаһ шомлыгына, 8 март бәйрәме көннәре туры килеп, эш көне 11 мартта гына башланды. Министрлар Советына шылтыратып, профессор М. Х. Хәсәнов иҗтиһады белән, РКБга салырга булдык. Урманче бинһая мәгърур иде бит. Репрессияләнгән кеше буларак, 1949 елда Мәскәүдән сөрелүен ул 1929 елда Соловкида алынуына караганда да авыррак кичергәнен сөйли иде. Теге шифаханәбезгә дә инде һич барасы килмәде.

РКБда, чыннан да, караш та үзенә башкача, анда аны беләләр, олылыйлар, тиешенчә ярдәм күрсәтергә тырышалар. Баш табип урынбасарларының берсе Гыйлаҗ Зарипов үзе төн уртасында коляскада алып киткәндә: «Киемнәре канлы, борыны бәйле бу нинди карт?» — дип сораучыларга: «Бу безнең Андрей Дмитриевич!» дип кенә узып китә. Ул Сахаровны күрергә махсус барып йөргән кеше икән. Чит илдән килгән милләттәшләребез Бакый аганы күрергә рөхсәт сорасалар, төн уртасы булса да, үзе китереп китә иде.

Лор бүлеге мөдире Азат Ногманов, борынга кагылып та тормыйча, кан китү сәбәбе бавырда икәнлеген ачыклап, аны шунда ук үз бүлегендәге сугыш инвалидлары палатасына урнаштырды, шәһәрнең иң мәртәбәле белгечләрен чакыртып, төрле яклап дәвалап чыгарды. Ул да бит: «Инвалид түгел, борын авыруы түгел»,— дип, башка бүлеккә озата ала иде.

Ике айдан аденома авыруы кузгалгач, тагын шунда ятарга булдык. Бик мөлаем һәм оста хирург Ренат Галиев аңа уңышлы операция ясады. Ике ай дәвамында, ял вакытында

да өйгә килеп дәвалап йөрде. Тәшәккердән гаҗизоез: һәм менә аның бер [illegible]үендә — бизгәк. Эсселеге — 39,7°. Тагын пневмония. Тагын «Ашыгыч ярдәм» белән инде 2-РКБга китерделәр. Барасы килмәде аның. «Вакытында тиешле дәва бирерләр, пневмонияне өйдә дәвалап булмый»,— дип көчкә күндердем. Чыннан да, бер атна үткәч, шифаханәдә үпкә ялкынсынуы бетә башлады, дигән иде Галина Михайловна. Үзе дә әйбәтләнеп, ныгып киткәндәй булды. Кешеләр күп килә, укый. Соңгы укыган һәм ошаткан әсәре И. Юзеевның «Өзелгән тәсбих» шигыре булды. Телевизорны, гомумән, карамый торган кеше бу җәйне Римдагы футбол, Сиэтлдагы яшь спортчылар ярышын карап рәхәтләнде. Мин хәтта үзенең кайчандыр: «Кыш килә, карт Урманче урыны — ямьшек диван да телевизор»,— дигән шигырен исенә төшерәм. Әшли алмавына борчылгач: «Кышкы нур», «Кышкы пейзажлар» нәкъ шул шигырь язылган елларда эшләнде бит, быел да, насыйп булса, әллә нинди шедеврлар ясалыр әле!» — дип тынычландырам.

Шифаханәдә иң соңгы һәм озак сөйләшеп утырган кешесе Гомәр ага Бәширов булды. Өйдән китәр алдыннан исә Батулланы сагынып, озак әңгәмә корып утырган иде. Мөхәммәт Мәһдиев шифаханәдә иде, курешергә керде, аңа: «Элегрәк килергә иде. Сезнең белән сөйләшәсе сүзләр күп, чөнки һәр язганыгыз мәгънәле, барысын укып барабыз»,— диде. Мин: «Йә, күрешерсез әле, остаханәгә килеп утырасы бар бит аның»,— дип, чын күңелдән ышанып әйтәм. Мөхәммәт: «Исәнлектә күрешергә насыйп булсын, Бакый ага!» — дип чыгып китте.

Алдагы төндә дежур табиб Мәхәббәт ханым күп карады. Иртән аңа кешелекле каравы өчен рәхмәт әйтеп, исеменә карата Дәрдемәнд «Хәят»ыннан Сәүдә турында шигырь әйтте:

> Сурды ул гөл, кем нидер Сәүдә?
> Дидем: «Сәүдаи — гыйшык!»
> Тамды гөлләр, түкте ул дөрләр —
> керәм уртагына!

«Безнең халык Мәхәббәт урынына күбрәк Сәүдә дигән исем куша, мәгънәсе бер»,— диде. Мәхәббәт ханым елап чыгып китте. Мин шигырьдән әсәрләнгәндер, дип уйлыйм, шулай уйларга телим, күрәсең. Врачлар бит миңа өзеп бернәрсә әйтмәделәр. Мәскәүдән улы Илдар килеп китте. Айдарны бер атналык юлга җибәргән идек, ул җирләүгә дә 10 сәгать соңарып кайтты.

6 август, иртән уянуга, Бакый ага бер мизгел мине танымыйчарак торды. Бу аны хафалады. «Магнитофоның еракмы? Языйк әле!» — диде. Мин аны көйләгән арада: «Юк, калэм белән яз»,— дип, берничә сүз әйтеп торды. «Ниндидер яңа халәт, яңа хәят башлана»,— кебек иде сүзләре. Мин һаман: «Димәк, яңа иҗат ысулы башлана»,— дим, янәсе ул әйтеп торганны мин язачакмын. Шуңа кулын куйды, аннан кәгазь алып, тиз-тиз үзе минем турыда ярты бит әйбер язып куйды.

Юыну, намаз-нияз, ашау-эчү гадәттәгечә. Әмма күп йоклады ул көнне. Баш табиб кереп: «Уятмагыз, йокласын»,— дигән иде. Юк, мин йокыдан уянмавын теләми идем, йокы даруы да бирдермәдем. Үзем йоклап калудан да бик курка идем. Кичке бишләрдә сулышы әкренәюен сизеп, уятып алдым. Җиделәрдә тагын ятты. Унынчы яртыда үзе торып:

— Чәй эчәбезме? — диде.

— Эчәбез! Бал беләнме, лимон беләнме?

— Бал белән, сөт белән! — диде.

Бу аның соңгы сүзләре булган икән, чөнки ул, ашаганда, сөйләшми иде соңгы вакытларда. Бер кисәк карлыган бәлеше ашады, бал белән бер чынаяк чәй эчте. Дога кылып, юынып, уң ягына ятты да соңгы сулышын алды. 31 июльдә дә бер сулыш, пульс, басым тәмам беткән иде. Шәфкать егете студент Ренат чабып килеп, укол биреп, бер атна гомерен озайткандай итте. Бу юлы да ул дежур иде — кайтара алмадык.

Ничек яшәсә, шулай дөньядан китә, диләр кешене. Ул, югарыга карап фикер ит, түбәнгә карап зекер ит; иртәгә үләм, дип гыйбадәт кыл, мәңге яшим, дип мал җый, кебек мәкальләрне ярата иде.

7 апрельдә күңелдән «райдөш дәһрә мөхтәдифән я дүре вә ля хөзнен я думе вә ляссоруры» (заманны күрдем: һаман тәрлечә әйләнә, кайгы да дәвам итми бер туктамыйча, шатлык та) һәм «къәрар бәр кәффи азаткян нә гирәт мал, нә сабыр дәрдеми гашыйк, нә аб дәр горбал» (азат кеше кулындагы мал, гашыйк кеше күңелендәге сабырлык һәм иләктәге су кебек үк — тормый) дигән гарәп, фарсы шигырьләрен яздырып, тәрҗемә итеп куйган. 14 майда: «содур әл әхрар, кобур әл әсрар» (хөр ирекле күңел — серләр кабере) — гарәпчә.

Күп шигырьләре язылмый калды, башларга, тәмамларга уйлаган күп эшләре эшләнми калды. Аларга аһ итеп офтанмады, эшли алганын эшләп барды. Шатланса гына соңгы вакытларда, күңеле нечкәреп, күзенә яшь килә иде. Берәрсе үлгәнен ишетсә: «Иннә лилләйһи вә иннә иләйһи раҗигун»,— дип дога кыла, яхшы сүз белән искә

алып, тиз-тиз «КХ» (кыска хатирәләр) дигән мемуар дәфтәрләренә нәрсә дә булса язып куя. Мәснәви Хәйретдинов кинәт үлгәч, яшь түгеп, зыяраттә, ел ашында көчле сүзләр әйтеп, газетага тәгъзия мәкаләләре тәкъдим итеп, зур кайгы кичергән иде.

Үзе турында, үлем турында һич сөйләшми, дәресрәге, мин сөйләтми идем. Бары: «Мөселманча булсын!» — дип катгый әйтә иде. Аны Илдус Садыйков дигән яшь дусларының берсенә дә әйтеп куйган икән.

Мөселман йолалары шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек белән берләштерә халыкны. Ул йолалар тәртибен, ярдәмне беренче төннән үк Фәния Хуҗәхмәтова, Румия Вахитова оештырып йөрделәр. Төн чыгу, юу, кәфенләү, җирләүдә туганнар белән якыннан Батулла катнашты. Түбән Камадан, «Тойота» алып, гаиләсе белән Азат Зыятдинов килеп житте. Коръән укучылар Хәбир хәзрәт, Камил мөәзин, Разия ханым Монасыйпова, Хәдичә ханым Йосыпова, Халидә һәм Фәридә Ибәтуллиналар булды. Мәскәүдән — улы, сеңлесенең гаиләсе, Төмәннән, Омскидан — минем туганнар, җеназа вакытына туган һәм үскән җире Буа, Кама Тамагы районнары кешеләре килеп җиттеләр. Әллә кайчан Балхаш заводларында бергә эшләп йөргән һәм бер дә күрмәгән кешеләр дә бәхилләшергә килде.

Г. Камал театрында моңлы музыка уйнап торды. Хөкүмәт тарафыннан оештырылган озату комиссиясе башлыгы профессор М. Хәсәнов: «Татар мәдәниятенең иман баганаларыннан берсен яшен сукты. Татар халкының иң олы рәссамы Бакый Идрис улы Урманче вафат булды... Татар мәдәнияте күгендә өч йолдыз яна. Аларның берсе — шигърият йолдызы Габдулла Тукай. Икенчесе — татар халкының музыкаль җаны Салих Сәйдәш, өченчесе — сынлы сәнгатьтә Бакый Урманче йолдызы. Бу өч йолдызның икесе бездән ерак, алар инде илаһи, мәгънәви йолдызлар, ә өченчесе безнең арада, безнең белән янәшә иде. Аны күреп, аның белән сөйләшеп, фикерләшеп була иде. Менә хәзер бу өченче йолдыз да шул ике йолдыз янына — Г. Тукай, С. Сәйдәшләр янына атылды»,— дип гаҗәеп сурәтле, йөрәктән чыккан сүзләр белән матәм мәрасимен ачты. Композитор Ә. Бакиров, артист Р. Таҗетдинов, язучылар Ә. Еники, Т. Миңнуллин, Р. Мөхәммәдиев, «Компрессор» заводы директоры Ә. Галиев, Кама Тамагы райбашкарма комитеты рәисе Ф. Барыев һ. б. бәгырьгә үтә торган, кайгылы һәм мәгънәле гыйбарәләр белән Урманченың бу дөньяны бизәгән урынын билгеләп, мәңгелеккә озату, бәхилләшү сүзләрен әйттеләр.

Өч ел элек, шаулатып 90 яшен билгеләгән шушы театрдан: «Җегет тә чакларым, ай, бар иде!» — дип җырлап торган рәссам табутын ир-егетләр, иңнәренә куеп, Татарстан урамы буйлап, Мәрҗани мәчете ихатасына китереп керттеләр. Хатын-кызлар, автобуслар, машиналар Насыйри урамында тезелеп көтеп торды. Хәбир хәзрәт җеназа укыганнан соң татар зиратында Тукай, Кариев, Ямашевлар янында җирләү булды. Тагын моңлы һәм ялкынлы сүзләр әйтелде. Ләхеткә энесе Фәрит Еникиев, минем энем Әкрәм Ибраһимов һәм дустыбыз Азат Зыятдинов иңдерде. Дәфен Коръәнен Камил мөәзин укыды. Чардуган һәм вакытлыча куелган тимер һәйкәлне Ленин районы эшчеләре ясаган. Алар Б. Урманченың З. Бәширов төшергән фотопортретын зурайтып куйганнар. Сул кулы белән ияген учлаган, «Сагыш»ына охшап, киләр буыннарга моңаеп карап торган Бакый Урманче. Сынчы, җырчы, тарихчы, язучы, көрәшче. Халык рәссамы. Мәхәббәтле зур гаиләдә туып-үскән бала, мәхәббәтле гаилә башы, ата, мәхәббәтле ил агасы.

Яраткан, белгән шул аның кадерен иле, халкы. Үзе аны исәнендә дә сизеп тора, шуның белән куәтләнә иде. 7, 8, 9, 10 августта «Татарстан», «Азатлык» радиосы, телевидение кайгылы хәбәрне һаман белдереп тордылар. Ул яраткан һәм аңа багышланган көйләрне уйнаттылар. «Социалистик Татарстан» газетасы җеназа репортажын, күмү мәрасимен, Күл Черкене авылы мәчетендә Урманче рухына багышлап намаз укылуын да яза торды. «Яшь ленинчы» газетасы кыска һәм үтемле итеп болай язган иде:

«Хуш, Бакый ага!

Татар халкына күтәрә алмаслык кара кайгы иңде: халкыбызның бөек улы Бакый ага Урманче дөньядан китте...

Бакый ага Урманче — никадәр илаһи мәгънә сыйган әлегә исемгә! Канлы елларда да иманын сатмаган, намусын пакь саклаган гали зат иде ул. Йөрәгендә халык гамен йөрткән, «көнем өчен түгел, денем өчен!» дип татар сәнгатенә гомерен багышлаган зыялы кеше иде ул. Без аның дөньялыкта йөз яшен тутыруын теләп дога кыла идек... Бөек рәссам, бөек сынчы туксан дүртенче яшендә фани дөньядан бакый дөньяга күчте...

Хуш, Бакый ага!..

Татарның намусы, вөҗданы булып яшәгән ил агасы!

Хуш!..»

«Азат хатын» журналы, без — фольклорчылар Г. Тукай бүләге алу бәхетенә ирешү-

кәч, «Бер гаиләдә — ике лауреат» дигән мәкалә оештырырга йөргән иде. Мин һаман риза булмыйча, ул менә соңлады, үзе аны күрә алмады, мәкалә сентябрьдә һәм, гаҗәп, шул ук мәгънәдәге бәхилләшү сүзләре булып чыкты.

Әмирхан ага Еники театр бинасындагы мәрасимдә сүзен елый-елый: «Хуш, газиз, рухи атабыз!» — дип тәмамлады һәм Тукай «Васыяте»ннән бер юл шигырь китерде. Бары бер юл. «Кайт, и нәфсе мотмәиннәм (тынычлык тапкан күңелем), бар, юнәл, кит Тәңреңә!» Аның икенче юлы болай: «Бирдең арканңны моңарчы, инде бир бит әмреңә». Соңыннан мин мөхтәрәм язучыбыздан: «Нигә икенче юлын да укымадыгыз?» — дип сорадым.

— Ул бик динле иде бит һәм гомере буена иманына аркасын бирмәде,— диде.

Әйе, иман — аның бөтен барлыгы иде. Ислам динен, татар тормышын белмичә, аның бер генә әсәрен дә аңлата алмаслар. Һәм ул 4-5 кенә ел элегрәк вафат булса да, мөселманча озату, җирләү башка юнәлеш алыр иде. Шулай итмәгәндә исә, аның рухын, сикәлтәле тормыш юлын соңгы тапкыр нихәтле көчләү, явызлык кылу булыр иде. «Әллә китикме?» — диде ул берничә ел элек, Петербург мәчетенә имам итеп чакырганнарын әйтеп. Ул чагында Урманче — рәссам дигән сүз булмаячак иде. Бәлки шул вакытларда ул Коръәнне махсус укыгандыр. Ислам дине сәнгатьне тыямы, дигән сорауга җавап эзләп. Онытылмас «Җидегән чишмә» кичәсендәге очрашуда шул сорау бирелгәч, ул рухланып китеп: «Мин бу соравыгызга җавап эзләп, Коръәнне ике тапкыр укып чыктым!» — дигән иде. 700 кешелек зал: «Тыю тапмадым»,— дигән җавабын да көтеп тормыйча (димәк, Коръән укуы өчен генә) шаулатып кул чапты. Шунда ул «ислам сәнгатьне тыймый» икәнен аңлаган. Соңыннан ул шул ук фикерне Риза Фәхретдин мәкаләсендә дә тапканын әйтте.

Мин моны язып китәргә тиеш табам, чөнки кайбер руханиларыбыз әле дә исламның сәнгатьне тыймавын белеп бетермәүләре мөмкин. Дин-ислам мәсьәләсендә Б. Урманче белән фикерләшердәй кеше, яшьрәк имамнар гаеп итмәсеннәр, булса, мөхтәрәм Зәки хәзрәт кенә булгандыр Казанда. Берәр мәҗлестә очрашсалар, бик рәхәтләнеп сөйләшеп утыралар иде. Мөфтиләребездән Галимҗан Баруди, Риза Фәхретдин, тагы башкаларны күреп белгәнчә, Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, мөфти булгач та, Бакый ага аны өйгә чакыртты, күреште. Мөсәхәбә кыскарак булса да, канәгать калды, бик ихтирам итә иде аны.

Габдулла хәзрәт Галиуллинның портретын ясыйсы килә иде. Ул, шәкерт чагында ук, Каравай мәчетен салуга рөхсәт алу өчен көрәшеп йөргән елларда әле Бакый ага янына килә, киңәшә иде. Мунча кертеп, өендә кунак та итте. Бакый аганың Каравай мәчетен төзекләндерүгә түләүсез эскизлар ясап, якыннан катнашырга исәбе бар иде. Вафа хәзрәт күп көч куйса да, бу эш никтер барып чыкмады. Рәссам Коръән сурәләрен язып, дивар бизәвенә урнаштырмакчы иде. Соңыннан «Әлхәмделиллаһ», «Аллаһе җәмилен хөббел җәмал» (Аллаһе гүзәл, гүзәллекне ярата) дигән шамаилләрен Әҗем мәчетенә, Саратов мәчетенә, Чаллыда, Түбән Камада салына торган мәчетләргә бүләк итеп җибәрде. Алар шулай ук Америка, Финляндия мәчетләрен дә бизәп тора дигән хәбәрләр ишетәбез.

Мин «Урманче һәм фольклор» дигән мәкаләмдә Бакый аганың төрле диннәргә мөнәсәбәтен киңрәк ачыклап, һәм, иң әһәмиятлесе, үзенә укытып, төгәлләп, русча язып бастырган идем. Әлбәттә, әле үзебез дә күп нәрсәне белмибез, сукыр көе капшанабыз, бик кирәкле йолаларны да тиешенчә үти алмыйбыз. Ул турыда, шөкер, газета-журналлар да ачык яза башладылар...

Өчесен, Җидесен Коръән укытып уздырдык. «Кырыгын йөрү» дигән нәрсә бар икән — 40 көн буе һәркөнне аның рухына ясин чыгу, диделәр. Анысы берничә кешегә әйтелде. Җидесендә икенче табын төзеп, урыс-улак, түрә-кара, дус-иш, шәкерт-рәссамнарын җыйдык, яхшы сүзләр белән искә алып, һәммәсе ихтирам, мәхәббәтен изһар итеп, исемен мәңгеләштерүгә эшлекле, нигезле тәкъдимнәр әйттеләр, рәхмәтләр белән таралыштылар.

Менә инде, зинһар, мистика йә кара ышану дип тә уйланмасын, авырганында үзем һәм якыннарыбыз төшләр дә күргән, тешләр дә төшкән. Идрис мулланың алмагачын да кисеп аударганнар һ. б. Булган бит элек мәшһүр «Төш-тәгъбирнамә»ләр, әдәбият һәм фольклорда гына төшкә нигезләнеп, шул ук «Кыйссаи Йосыф», «Сәйфелмөлек» һ. б.ларда ниди сюжетлар тумаган?! Әмирхан ага Еники бервакыт төшләрен теркәп баруы һәм кайберләренең гаҗәеп рас килүе турында язып чыккан иде. Хәзер фәндә дә төш күрүләрне тәфсилләп тикшерәләр. Менә бер айга якын инде ник бер төшемә керсен, диюемне: «Рухы тыныч, 40 көн Коръән укылганга»,— дип аңлаталар.

Әмма бер төшме ул, саташу булдымы, анысы да кызыклы әле. Бакый аганың бик яратып, ихтирам итеп аралашкан академик К. Ә. Вәлиев җеназага килә алмады. Хатыны Венера ханым һәм үзе: «Бераз ял да итәрсең, сөйләрсең, күрешик»,— дип, мине Мәскәүгә чакырдылар. Дачаларына барасы, мунча керәсемне мин уйламыйм, белмим дә, ә төштә Бакый аганың, киемнәре белән, ваннага кереп утырганын күрәм. Ул бит мун-

ча бик ярата иде. Нindидер хикмәт белән минем мунча керәсе ана рухы тыныч булганда да барып ирешкәнме әллә?

Шөкер, Тукаебыз бар, тагын ул искә төшә:

> Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен;
> Ядыма Тәңрем төшә, бәхетем кара булган саен.

Ничек гүзәл, шул ук вакытта ничек гади әйтелгән! Бакый ага үзе, әлбәттә, гарәпчә, фарсыча башка шигырьләрне (әйтик, әлеге кайгы да, шатлык та туктаусыз дәвам итми дигән шигырь һ. б.) Коръән Кәримне алып укыр иде. Ә без ни әйтә алабыз?

Тагын Тукай. Әле күптәнме миңа аны да Бакый ага яттан яздырып, китап киштәбезгә беркетеп куйган идем:

> Гомернең иң читен, җайсыз, уңайсыз бер минутында,
> Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында,
> Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗәеп сурә Коръәндән,
> Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җандан...

Шундый заманда үстек без. Мин Троицк Дарелмөгаллиминен 1916 елда тәмамлап, Тоболына кайткан һәм, әлбәттә, 1937 дә алынган мөгаллим Ваһап мулла кызы идем (безнең якта указлы мулла гына түгел, гомумән мөгаллимнәрне дә мулла дип йөртәләр). Дога китаплары түгел, «троцкист» Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы»н да бездән калтырана-калтырана яшергәннәрен хәтерләп калам. Бакый ага да эшен мине гарәпчәгә өйрәтүдән башлаган иде. Аның катлаулы, бай иҗат тормышына чуммасам, тагын үземнең фәнни эшемне алып бармасам, мин бу өлкәдә уңышларга да ирешкән булыр идем. Ул минем йә дин тәгълиматын, йә сәнгать белемен тирәннән өйрәнүемне бик тели иде, әмма мин фольклорымны ташлый алмадым.

Хәер, бу авыр йөктән азат булу өчен Тукайның үзе кебек бөек, Мәрҗани кебек «бөтен кеше», Ямашев кебек «чын кеше» һәм Урманче кебек гали зат булу зарурдыр ул. Һәм андый «бөтен кешеләр» укымышлы һәм хисле татарлар, җан газапларыннан арындыра торган мәгънәви кул табарлык буыннар, бәлки, безнең оныкларыбызның балалары була алыр. Республикабызда мөстәкыйльлек таңы атып килү шундый өмет чаткылары очындыра.

Ә мин елыйм. Толлар эше шулдыр инде... «70 яшендә чыгып, 93 кә хәтле тор-
гач...» — диючеләр дә булыр. Әмма гади бер карт түгел иде бит ул. Үкенеч. Аяныч.
Кызганулардан елыйм. Аның кодрәте, дәрте, изге җанына бәрабәр, тиешле шартлар
булмыйча, һаман кысылып, куырылып та, яңа юнәлешләр алып эшләп баруы, бер як-
тан — үкенеч, икенче яктан — соклангыч: һаман бирешмәде. «Җегет тә чаклар»ын ул
90 яшендә түгел, аннан 5 ел элек, 1982 елның 3 мартында, 85 еллыгына багышлан-
ган күргәзмәсе ачылганда җырлап җибәрәсе килгән иде. «Ярамый! Урыны түгел.
Өйдә йә банкетында җырлар», — диделәр. Шул ук юбилейга әзерләнгән телевизор тап-
шыруны «Тыйнаграк кирәк!» дип төзәттергәннәр һәм кунакка Чыңгыз Айтматов,
Давид Көгелтдинов, Мостай Кәримов һ. б. ларны чакырырга теләүне «Хатынының кирә-
геннән артык олылатырга тырышуы» дип бәяләделәр һәм чакырттырмадылар. Шушы
үтә дә тыйнак, аз сүзле, дәрвишсыман талымсыз, нурлы йөзле бер татар сәнгать-
кяренең эше, халкына мәхәббәте белән олыланып, «милләтче» булып китүеннән аны
бик тә сакладылар.

Мине хәзер бигрәк тә шул яклары көендерә. Үзе ул явызлык кылган бер ке-
шегә карата да нәфрәтләнмәде, начарлык эшләү түгел, авыр сүз дә әйткәне булмады.
Аның гына түгел, ничә милләтнең язмышын пыран-заран иткән Сталинның да исемен
атыйсы килмичә, Джугашвили яисә «Мыек» дип кенә йөртә иде.

«Елаудан ни файда?» — дияр иде үзе булса. Гади генә, тыныч кына әйтер иде ул
сүзен. «Зияудан ни файда!» — дип. Айдар да яшен сөртеп, кояштай балкып, йөгереп
уйнап китәр иде, шулай дигәч. Бөтен кешегә кояштай нур чәчте. Әлбәттә, субъектив-
мындыр. Бәхетле гаиләдә әниләре тирәсендә кояшка карап әйләнгән көнбагыштай
балаларны, өйгә кайтып керүенә балаларын, гаиләсен күреп, кояштай балкып киткән
аталарны беләм. Ә мин хәзер елау түгел, янына барып кына ятар идем. Улым
үскән, үз көнен үзе күрер. Мәскәүдә чыгасы «Бәетләр», Новосибирскида — «Себер
фольклоры», Казанда фольклор җыелмасының 14 нче томы итеп әзерләнәсе «Идегәй»-
не дә яшь фольклорчылар миннән башка тәмамлап чыгар иде. Узган елның сен-
тябрендә Америкага «Үзәк Азия буенча IV халыкара конференция»га чакырулы идем.
Бик теләде Бакый ага минем анда булып кайтуымны. Кайтып аңа сөйлисе булмагач,
барасым да килмәде. Әмма күпме гомер калгандыр (мин дә бит Урманче янында гына
яшь булып йөргәнмен, инде пенсия яшем җитте), шул вакытта миннән башка беркем эш-
ли алмас, дигән эшләрен эшләп калдырасы иде. Күргәзмәләрен ясау, китапларын чыга-
руны да башкалар булдырырга мөмкин. Миңа үзем белгән бөтен әйберләрен бер җир-
гә туплап, музей өчен әзерләп китәсе иде. Болай да аның иҗат байлыгы гаҗәеп да-

рәҗәдә яшәү шартларына бәйләнгән. Скульптура белән шөгыльләнүен, пенсиягә чыгып, Казанга кайткач кына башлавы үзе ни тора!

Гипста 25 ел тора торган Мәрҗаниен — граниттан, Сәйдәшне, Риза Фәхретдинне мәрмәрдән чабып куясы, В. В. Радловны, Д. Көгелтдиновны бронзадан коядырасы, кемнәрнедер агачка күчерәсе бар иде. «Соцгород»тагы остаханәсе ишек алдында эшләп торса, аның мәрмәр эшләре тагын да күбрәк буласы иде. 1977 дә ул йорт урынына (нәкъ шул урынга!) Горбунов исемендәге завод поликлиника саласы итте. Остаханә дип, квартирабыз астындагы 35 квадрат метрлы бер квартирны бушатып бирделәр. Анда инде мәрмәр чабып булмый иде, агач, балчык белән эшләгәләде. «Сөембикә», «Тулпар», Ш. Маннур, С. Сәйдәш, М. Гафури һ. б. шунда тәмамландылар. Г. Исхакый балчыкта килеш калды. Нәгышь һәм график портретлар, «Күл Черкене», «Салтык болыны», «Сабантуй» һәм соңгы пейзажлар шунда эшләнде.

90 еллык юбилеенда вәгъдә ителгән квартир-остаханә өчен адрес — 400 квадрат метрлы бина диварларын, ике ел ярым үткәч, табып биргәннәр иде. Шәһәр советы аны төзекләндерер, рәтләр өчен худфондка тапшырды. Министрлар Советы рәисе 150 000 сум акча да табарга булган. Ул арада әлеге өйне (нәкъ шул өйне) әле ветераннар өчен дип Кызыл хач җәмгыяте, әле табибларга квартир өчен дип ортопедия-травмотология институты директоры, әле видеосалонмы алырга дип тагын кемнәрдер йөри башлый. Ниһаять, үтә дә актив бер директор ханым (фамилиясе дә Аитова бит!), мәктәп өчен дип, ул өйдә ремонт эшләре дә башлап җибәрә.

Ә без? СССР халык депутаты Т. Миңнуллин һәм РСФСР халык депутаты Р. Мөхәммәдиев, Татарстан һәм шәһәр Советы депутаты Р. Вәлиев, КПСС өлкә комитеты җитәкчеләре Р. Идиятуллин һәм Р. Харис, Профсоюзлар өлкә комитеты бүлеге башлыгы Р. Кәримуллин, Министрлар Советында М. Хәсәнов, шәһәр советы баш архитекторы М. Агишев, ИЗО музей директорлары А. Иншаков һәм А. Сластунин белән, СССР Фәннәр академиясенең Казан Үзәге башлыгы В. Алемасов, аның ике институты директорлары М. Зәкиев һәм К. Салихов, Культура Фонды мөдире Г. Ахунов, Татар иҗтимагый үзәге, Мәрҗани исемендәге җәмгыять, яшьләр коммерция банкы, ничәмә-ничә кооперативлар, дистәләрчә аерым кешеләр белән сөйләшеп, киңәшеп, хатлашып йөрибез: салыйк инде, күтәрик инде шул бинаны, ясыйк берәр ничек Казан халкы һәм кунаклары өчен бер бизәк — белем, сәнгать үзәге, дибез. Урманче шунда үзе коляскага утырып булса да йөрер, планлаштырыр, эшләп алыр, дип уйлый идек.

Вафатына бер атна калгач, шифаханәгә мәдәният министры М. Таишев килде: «Анда эшли башлаганнар инде»,— дип, башка бер өй тәкъдим итте. «Юк,— ди Урманче,— мин башка өйгә риза түгел. Ул өйне үзем барып карадым, урыны әйбәт. Аның ишек алдына да павильон салып, минем бөтен әйберләремне җыярга мөмкин»,— диде. Өр-яңа йорт салып, 100 еллыгына өлгертүне тәкъдим итүчеләр дә бар иде. Тик, бирелгән өйне дә эшли белмәгәч, бу һаман да сузу, булдырмаска тырышуга охшап кала. Күрәсең, нәкъ шул көннәрдә (чөнки, мин барып караганда, һәммәсе урынында иде) ИЗО музей ишек алдында, куаклар астында, беркемгә дә комачауламыйча һәм кайберсенең акчасы да түләнмичә торган берничә зур скульптура эше тәмам ватылып, эзе дә калмыйча каядыр чыгарып ташланган. Г. Ибраһимов, Х. Ямашев, В. Ульяновның гипс скульптуралары иде алар. Ә музей запасникларында Кол Гали, Г. Ибраһимов, «Нәфисә», «Язгы моңнар», «Сагыш», «Гөлсинә» һ. б. әллә яхшырак хәлдәме? Соң Казанда Тукай, Такташ, Туфан, Кол Гали, Ибраһимов урамнары кайда да Пушкин, Толстой, Гоголь, Горький, Маяковский исемендәге урамнар кайда? Болар бөтенесе бер җепкә тезелә түгелме? Казан уртасында Ф. Шаляпин, Баратынский, К. Васильевларга музей булмыйча торып, Урманчега булырмы? Тукайның Кырлай музеен карарга 80 чакрымга кем йөри дә, Казандагы өе биек, өйрәсе сыек чит-чатка кем йөри?.. «Менә безнең кемебез ул — Тукаебыз!» — дип горурланып күрсәтерлекме соң ул куыштагы гипс, кәгазь-картон, фотокопияләрне?

Урманче музее булса, иң әүвәл Тукай һәм аның заманы сәнгатьчә күрсәтелер иде. Тукайның Урманче ясаган берничә скульптур һәм нәгышь портреты. «Исемдә калганнар», «Шүрәле», «Кисекбаш», «Казан вә Кабан арты», «Су анасы» кебек һ. б. иллюстрацияләр, ул заманның этнографик экспонатлары — үзе бер экспозиция, үзе бер музейлык!

Ә Татарстан табигатен тасвирлаган пейзажлары, мәшһүр татар һәм башка халык мәдәният әһелләренең нәгышь һәм график портретлары, 19-20 еллардан алып 90-елларга хәтле ясаган зур картиналары, акварельләре ничә зал алып торыр һәм татарны бөтенләй белмәгән кешеләр өчен өр-яңа дөнья ачар иде ләбаса. Ә Башкортстан, Казахстан, Үзбәкстан, уйгур дөньясы — үзләре берничә залны биләрлек.

Йөзләгән кием эскизлары тагын бер бүлмәне алса, берәмтекләп, яратып җыйган сөлге һәм сөлгебашлары, алъяпкыч, читекләр, тула оек, эшләпәләр, читек һәм чабата, күкрәкчә һәм хаситә, ирләр, хатыннар күлмәк-ыштаны, камзул, яка, чулпы, алка,

беләзек, йөзек, калфак, каләпүш, ашъяулык, корамалар... Нигә аларга бер урын тапмаска?!

Фототека (меңнәрчә фото гына түгел, меңнәр түләп төшерелгән слайдлар һ. б.), фототека (җырлары гына түгел, мәшһүр кешеләр белән әңгәмәләре дә ничә километрлы магнитофон тасмасында), китапханә (русча, татарча, гарәпчә, фарсыча, төрекчә, инглизчә, французча, немецча китаплар гына түгел, сәнгать, тарих, филология буенча меңнәрчә журнал, җыентыклар һ. б.), дистәләрчә папкаларда архив (шуның эчендә бүселергә торган ничәмә папка шигырь, шигырь...), тагын гаҗәеп тәртип вә саклык белән җыйган инструментлары оста эш үрнәге булып, пыяла тартмаларда торса, ниһаять, ишек алдында павильондамы булсын, Кол Гали, Мәрҗани, Насыйри, Дәрдмәнд, Тукай, Әмирхан, Ямашев, Ибраһимов, Гафури, Усманов, Муса, Сәйдәш, Яруллин, Җиһанов, Камай, Батыев һ. б. ның скульптуралары куелса,— татар халкына һәм тарихи, һәм антропологик, һәм этнографик, шул ук вакытта югары сәнгатьчә эшләнгән һәйкәл булмас идемени?! Дөнья сәнгате белән яхшы таныш кешеләр 90 яшенә багышланган күргәзмәдә: «Бу әсәрләр — көнбатыштагы теләсә кайсы музейда урын алырлык»,— дип, чын күңелдән сокланып киткәннәр иде. Бәлки без үзебез генә белеп бетермибездер әле аны. Шунда ук видео, слайд, диапозитив әйберләрне карап, җыелып, сөйләшеп, музыка тыңлап утырырдай берәр зал да булса, һәм аннан чыгып, халык Сәйдәш музеена юл алса, анда чын татар музыкасы тыңлап ләззәтләнсә, шул булыр иде «шигърияттә — Тукай, музыкада — Сәйдәш, сынлы сәнгатьтә — Урманче» кебек өч йолдызның гомер, заман үзе шулай урнаштырган (зиратта гына түгел!) мәгънәви халәте.

Тарих һәм антропологик дип әйтүем дә әсассыз түгел: музейны хронологик тәртиптә оештырганда Урманче биографиясе татар халкы тарихын бер тамчы саф чык суында яисә раушан көзгедәге кебек чагылдырмасмыни?! Гомер башының дүрт елын үткән гасыр ахырында уздыруын сәнәткә утыртулары аркасында исендә калдырганын әйтеп, ул 90 еллык юбилеена килгән халыкны бер рәхәтләнеп, җанландырып алган иде. Шуннан соңгы Күл Черкене, Салтык болыннарында аунап үткән балачак, Тукай, Әмирхан, Печән базары янәшәсендә узган «Мөхәммәдия» шәкерте чагы, Урал заводларында эшләү, Тамбов авылларында укыту һәм патша армиясендә хезмәт итү, ВХУТЕМАС һәм Лазарев институтында укып, Мәскәү татарлары белән Асадуллаев өендә кичәләр үткәрү, НЭП еллары Казаны, Сәнгать мәктәбе, 1929 («бөек борылыш елы») һәм Черек күл белән беренче 30 еллыгы тәмамлану...

Инде икенче иң көчле, иң дәртле 30 еллыгы шул аты үчкере Соловкида 5 ел уздыру аркасында Казанда «халык дошманы» дип танылу, Мәскәүдән куылу, тагын 39 шәһәрдә тора алмау «ирегe» белән горбәттә — үзбәк, таҗик, казакъ, уйгур, Балхашта немецлар һ. б. халыклар өчен иҗат итү. Һәм менә, пенсиягә чыгып, илгә кайту, соңгы 30 еллыкта Казанда бөтен иҗади эшләренең 90 процентын эшләү. Дәртләнеп, алны-ялны белмичә, адәм күтәрә алмаслык таш блоклар кайтартып кисү, чүкү, уймалау, нәгышь итү, уку, язу, җырлау, театр, концертларга, фәнни һәм кунак мәҗлесләренә йөрү, милләте эчендә кайнау татар халкының гаҗәеп эшчән икәнен күрсәтү — аерым алганда, бер шәхеснең шул хәтле эш майтаруы феномен булмасмы?!

Антропологик дигәннән, соңгы елларда Б. Урманче альбомы чит ил кешеләре кулларына кергәли һәм татарның визит карточкасы дип таныла башлады. Безнең милләтне белеп бетермәүчеләр Бикбулатов, Шафигуллин, Рәхимова, Булатова, Мәхмүтов һ.б. портретларын күреп: «Татарлар шундый буламыни?» — дип сорашалар икән. Инде минем портретларга да карап, «татарлар монголоид шул» дип уйлаулардан аеручa үз илебез татарлары курыкмаса, күп этник төркемнәрне (себер, әстерхан һ. б. татарларны да) үз эченә алган Татарстан республикасы «Әйе, татарлар күп төрле шул» дигән фикерне дәлилләр, иншалла...

Өчесен, Җидесен уздырганда һәм болай да халык теленнән, берәр урамга, колхозга аның исеме бирелсә иде, дигән теләкләр ишетелде. Аның Идел пароходларында йөрергә яратканын белеп, Уфа-Казан арасында йөри торган берәр пароходка «Бакый Урманче» исемен биреп, шунда елга бер тапкыр татар-башкорт җыр фестивале, күргәзмәләр, фәнни укулар һ. б. оештыруны да тәкъдим иттеләр. Казан өчен аның «Сагыш»ын зурайтып, башка материалларга күчереп, һәйкәл куюны да әйттеләр. Рәссамнар беренче татар студенты булып укырга кергән, беренче югары белемле профессиональ рәссам-укытучы булып укытырга кайткан һәм яңадан татар балаларыннан беренче студентлар алу, ниһаять, шуннан Соловкига озатылган икәнен истә тотып, Казан сәнгать техникумына Бакый Урманче исеме бирергә кирәклеген дә дәлилләп сөйләделәр, нигезле тәкъдимнәрен Татарстан республикасы хөкүмәт комиссиясенә язып илткәннәр.

Инде минем еламыйча яза алмаган тагын бер маузугым калды: Идел...

Аһ, ул Идел! Горбәтләрдә йөргәндә илен, Иделен сагынуларымы?! «Судан яралганмындыр»,— дип, көн саен иртән салкын душ алуларын кайчан гына туктаткан иде әле

ул?! Бервакыт бит күптән язган «Мине Иделнең Казанга каршы ярында күмегез!» дигән шигырен дә укыган идек. Идел исеменә аның Агыйделе дә, Чулманы да. Зөясе дә керә иде. 1917 елда патша армиясендә хезмәт иткәндә Коканд якларында ул «Ямьле Агыйдел буйлары» дигән рәсем ясаганын әйткән иде.

Печән өсте. Идел аръягыннан 27-28 яшьләрендәге Габделбакыйның җырлавын авылдашлары кайда тыңлап рәхәтләнделәр икән? Салтык кечүе булса, Идел шундый тар булганмы? Яшьлектә тавышы шундый көчле булганмы? Аны сорашып, язып куясы бар сеңелләре Нәҗибә һәм Сафия апалардан.

Әле кәгазьләре арасыннан шундый язмалар килеп чыга: «Салихҗан! (Батыевка) яисә «Мансурҗан! (Хәсәновка) Бер алачык! Куыш кына табып бирегез миңа Идел буенда! Иделне язасым килә! Мин — Идел баласы, суында коенып, ярында аунап үскән!..» Белмим, ул хатлар җиткәндерме адресатларына, гарәпчә язылган кәгазьләренә кызыл карандаш белән кыеклап сызылган: йә сөйләшенгән, йә күчереп җибәрелгән, дигән сүз.

Үзем нәрсә дә булса сорап йөз суы түгүен яратмый идем. Алган идек Васильевода бер бакча. Идел дә аңа рәтләп күренмәде, су да басты үзен. Агачларын төпләп, яңаларын утыртып саттык без аны. Шуннан Түбән Осланда танышларында торып, берничә гаҗәеп матур Идел пейзажы язды һәм без ни булса да, ничек булса да, Идел ярында йә сатып алырга, йә салып маташырга урын эзләп йөрдек. 1987 ел язында туган районы Кама Тамагы хуҗалары, искерүе тәмам җиткән бер финский өйнең эчен-тышын буяп, тирәсен тотып, беседка ясап, Урманчега җәйләрен торырга ярар, дип тапшырдылар, рәхмәт яусын! Май аеннан сентябрьгә хәтле торып, ул шунда үтә дәртләнеп эшләде. Иделгә төшеп су коенмакчы, «тау астында салкын чишмәдән» миңа су ташырга булышмакчы була иде (Айдар улыбыз ул елны армиягә алынды). Якташлары килеп утыралар, сөйләшеп сүзләре бетми, яисә комачауламыйк, дип, читтән артыннан гына эшләгәнен карап торалар. Мунча керергә Кече Салтыкка Гайсә Җәләлов алып кайтып йөрде. Элек елга 1-2 пейзаж яза, бик канәгать була иде, биредә ул 3 айда 30 лап нәгыйшь эше язды.

Әмма шул елны йөрәген дә бик каты авырсындырды, уңайлыклары булмаган дымлы өйдә үпкәләрен дә зәгыйфьләндерде. Шуннан бирле авырулары ешайды, хәлсезләнә барды. Шуңа минем аягым да тартмый хәзер анда йөрергә. Бигрәк тә Мәскәү янында М. Горький, И. Эренбург, И. Ойстрахларның 50 шәр сотыйлы утарларын күргәч, җаным әрнеде. Юк, кызыгу да, ымсыну да түгел бу кеше малына. Кемгәдер үпкәләү дә түгел. Нәкъ әрну. Ниндидер язмыш булган, күрәсең. Васильевода су басканч: «Миңа дача алу килешми»,— дигән иде. Сугышка хәтле Кунцевода зур уңайлы дача алган булган, беткән ул сугыш вакытында. Сараенда Коненковның ниндидер эше торган, аны өй бәясеннән кыйммәт дигән иде. Инде бусы үзенең сәламәтлеген үк алып китмәде микән, дисәң, торак өйләре белән дә шул ук хәл бит: «-39» тамгасы белән йөреп, берәр шәһәрдә үзенә квартир алу түгел, гостиницаларда да кача-посарак куныш үтүенә шатланып йөргән кешегә «Ташкентта — өй һәм остаханә бирүгә — монда кайтырга чакыралар. Барысын ташлап, Казанына кайта. «Соцгород»та өй сатып ала — ул поликлиника салыр өчен ваттырыла! Алмашка квартирына якын коттеджларның берәрсен сораган иде, алар да ватылырга тиеш, диделәр. Ә хәзер аларга икенче катны һәм янкормалар өстәп яшәп ята әнә кешеләр. Инде бу Аитова ханым һәм башкаларны талаштыра торган К. Маркс урамындагы 44 нче йорт мәрхүмнең соңгы теләге һәм васыятенә карамастан, мәктәпме, шифаханәме хезмәтен үти башласа, Кече Салтыктан Урманчеларның конфискацияләнгән өйләрен Кама Тамагына тартып китерергә кирәктер. Ул менә 50 елдан артык совет авылына медпункт һәм китапханә булып хезмәт итә. Музейны шунда ясарга, икенче Кырлай итәргә мөмкин.

Иншалла, киләчәктә кешеләр Урманче музеена килеп хозурланырлар. Ихтимал «Бакый Урманче» дигән теплоходта Идел, Чулман, Агыйдел буйлап та йөрерләр. Китаплар язылыр, кинолар төшерелер, диссертацияләр якланыр. Күргәзмәләре дөнья буйлап йөрер, татар халкы яшәгәндә, Урманче эшләре дә яшәр, дип өмет итик.

Кама Тамагындагы («Чулман Тамак» дия иде) куышыбызны «Сандугач оясы» дип йөртә идек. Берәр ай гына сайрый икән алар, гөләп чәчәк аткач туктый, диләр. Аннан басуларга тургай сайравын тыңларга, Салтыктан күчеп киткән Яшелчә авылларын, Идел буйларын күрсәтергә дип машинасына утыртып алып китә иде Гайса. Төш-хыял кебек булып калды алар да. Әмма булды! Аларны бихисап дәфтәрләренең берсендә бик матур итеп тасвирлап, теркәп тә куйгандыр, йә шигырь язгандыр. Һәммәсе килеп чыгар. Кулы тигән бер генә әйберен дә жуймыйча, пыран-заран китермичә җыясы, туплыйсы, киләчәк буыннарга җиткерәсе иде.

**Үтенеч:** «Истәлекләр» китабын да сузмыйк, чыгарыйк! Теләгән кешеләр, мәкаләләрен язып, безгә җибәрә торсыннар иде. Адрес: 420039, Казан, Мөхәммәдьяров урамы, йорт 29/8, кв. 21.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

## Миргазиян Юныс

# ИСАБӘТ

(ТУРЫ ГАМӘЛ, ТУРЫ СҮЗ ТУРЫНДА)

I

Бөек пролетар шагыйре Владимир Маяковский үзенең бер шигырендә каләмне штыкка тиңли һәм шушы метафора, сталинизм чорында рәсми декларациягә әйләнеп, штык совет язучыларының эш коралы булып хезмәт итә башлый. Әле бүген, хәбәрдарлык чорында да Маяковский тәкъдим иткән эш коралы белән язу көн тәртибендә тора.

Совет шагыйренә штык белән язу нигә кирәк булган? Нәрсә соң ул штык һәм ул нинди эштә кулланыла? Штык — винтовка очына кигертелә торган сөңге. Сугыш кырында аның белән дошманнарны кадап үтерәләр, ә инде тынычлык чорында штыклы мылтык белән идарә итүчеләрне, аларның сәясәтен тышкы һәм эчке дошманнардан саклыйлар. Тифлис һәм Бакуда булган вакыйгалар бу фикергә мисал булып хезмәт итә ала. Чыннан да, совет язучылары, шул уңайдан, безнең татар әдипләре дә, инде менә җитмеш өч ел партиягә һәм совет хөкүмәтенә тугрылыклы рәвештә хезмәт итеп киләләр. «Безнең яклы булмаган кеше — безнең дошман...», «әгәр дошман безгә буйсынмаса юкка чыгарырга кирәк»... Каләм-штык белән коралланган «кеше рухы инженерлары Ежов, Берия, Жданов, Сусловлар җитәкчелегендә, ЧК, НКВД һәм идеология өлкәсендә хезмәт итүче солдатлар белән бергәләшеп, «безнең яклы» булырга теләмәгән эчке һәм тышкы дошманнарны тар-мар итә килделәр. Революция елларында, патша хөкүмәте, алпавытлар, аристократия юкка чыгарылды. Гражданнар сугышында — аклар, буржуазия, зыялылар. Колхозлашу елларында — кулаклар, хәлле игенчеләр. «Бөек борылыш елларында — троцкичылар, зиновьев-бухаринчылар, солтангалиевчеләр, промпартия әгъзалары, иске чор белгечләре. Ватан сугышы елларында исә — кырым татарларын, Идел буе немецларын, Төньяк Кавказ халыкларын, әсирлеккә эләгүчеләрне, ачтан үләргә риза булмыйча, колхоз кырыннан кесәләренә башак салып алып кайтучыларны юкка чыгару максат итеп куелган иде. Сугыштан соң да, 1985 елның апреленә кадәр үз милләтенә тугрылыклы шәхесләрне, мөстәкыйль фикер йөртүчеләрне, административ-боерык режимына буйсынудан баш тартучыларны кыру, юкка чыгару дәвам итә килде. Кулларына каләм-штык тотып идеология фронтының алгы сафында сугышып йөрүчеләр үзләре дә Сталин-Берия террорыннан исән кала алмадылар. Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Мәхмүт Галәү язмышлары, кызыл комиссар Шамил Усмановның НКВД палачына нәфрәт йөзеннән каләм-штык белән үз-үзен кадап үтерүе тетрәндергеч символ булып яңгырый.

Ярты гасырдан артыкка сузылган бу террордан кемнәр исән калырга тиеш булган соң? Ялагайлар. Шымчылар. Талинкә тотучылар. Кол табигатьле бәндәләр... Заманында Ирод патша безнең эраның беренче елында туган барлык ир балаларны үтереп бетерергә боерык бирә. Үтерәләр. Ләкин нимдидер илаһи көч Иисус Христосны саклап кала... Явыз Иван патшаның боерыгы буенча «басурманнар» да тулысынча юкка чыгарылырга тиеш булганнар. Аллага шөкер, телебезне, динебезне, иманыбызның шактый өлешен югалту бәрабәренә булса да, без әзме-күпме исән кала алганбыз. Кешелек җәмгыятенең бер үҗәт үзенчәлеге бар бит: геноцид генотипны тулысынча юкка чыгара алмый. Шаблон канунына таянып сайланган шәхесләр арасында соңыннан сайлану критериена сыймый торган кешеләр барлыгы мәгълүм була. Сталин палачлары, Брежнев опричниклары азатлык тәмен тоючы-

ларны, хакыйкатькә омтылучыларны һәм мөстәкыйль фикер йөртүчеләрне юкка чыгаруны максат итеп куйсалар да, Советлар Союзында яшәүчеләрне тулысынча манкортка әйләндереп бетерә алмадылар. Сахаров, Юрий Домбровский, Варлам Шаламов, Борис Пастернак, Александр Солженицын... Тукта! Шушы урында укучы бездән: «Татар язучылары арасыннан нишләп Солженицынга охшаш кеше чыкмады икән?» — дип сораячак. Бу сорауга җавап бирмичә, татар әдәбиятының үзенчәлеген аңлатып булмас, дип уйлыйм мин. Көч җиткән кадәр шушы хәлне ачыкларга тырышып карыйк әле.

Хәбәрдарлык чоры килде. Бу чорда безнең кулда нинди корал булырга тиеш? Сталин чорының каләм-штыгы, торгынлык вакытында кулланылган күз буяу, буйсынырга теләмәүчеләрне юләрләр йортына ябып, хакыйкать сүзен әйтергә теләүчеләрнең авызларына цензура йөгәне ташлау бүгенге көндә шактый катлауланды. Шуңа карамастан, без әле һаман Үзәк Комитетта утыручы идеология маршалы, әйтик, өлкә комитетындагы сәясәт полковнигына: «Слушай, татар әдәбиятын хәбәрдарлык чорында кулланырлык итеп көйлә инде»,— дип боерык бирер дә, икенче көнне безнең әдипләребез бөтенләй башкача яза башларлар рәвешендә көтеп утыру әле һаман дәвам итә. «Безнең әдәбиятыбызда нишләп Солженицын юк?» — дигән сорауда мәнә шушындый беркатлылык та бар.

Әдәбиятның нәрсә икәнлеген ачыкламыйча, без аны үзгәртә, бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек итеп камилләштерә алмаячакбыз. «Нәрсә соң ул әдәбият?» — дигән сорауга җавап эзләгәндә, без һәр очракта «Нәрсә соң ул яшәү?» — дигән катлаулы мәсьәләгә килеп төртеләбез. Чыннан да, яшәү нәрсә соң ул?

Адәм баласының җирдә калган эзен, аның кичерешләрен, мөнәсәбәтләрен, тормышын һәм, ниһаять, кешенең үзен тарих, этнография, философия, социология, психология, дин гыйлеме, антропология, политология, экономика, медицина, юриспруденция — тагын әллә ничә дистә катлаулы фәннәр өйрәнә. Шуларга тагын мең төрле яңа фән өстәп, меңләгән фәнни тикшерү институтлары ачылып, дөньядагы барлык компьютерларны эшкә җиксәк тә яшәүнең эчтәлеген, максатын, сыйфатларын — аның үзен аңлау мәсьәләсен хәл итеп булмас иде. Кеше язмышын нинди фән аңлата ала? Бәхет һәм бәхетсезлекне? Мәхәббәт һәм нәфрәтне? Инану һәм үчне? Кешелек дөньясы ничә мең еллар бай һәм мул яшәргә омтыла. Ә нигә соң яшәү шартлары яхшырган саен үзен-үзе үтерүчеләр саны арта бара? Яшәешнең фән теше үтми торган урыннары бинихая.

Яшәешне яшәү үзе генә аңлата ала. Әдәбиятның барлыкка килүенә нәкъ менә шушы феномен сәбәпче. Китап укыганда син бераз әсәр геройлары белән яшәп аласың. Алар шатлыгы белән шатланасың, аларның хәсрәтләрен уртаклашасың. Уку процессы синең тойгыларны тәрбияләү, аларны камилләштерү белән генә чикләнми. Хакыйкать кануннарына таянып иҗат ителгән чын әдәби әсәр әзерлекле укучыны тетрәндерә. Шул тетрәнү көндәлек тормышка ярашу юшкыннарын — комсызлык, икейөзлелек, куштанлык шикелле иманга хилафлык китерә торган сыйфатларны җуеп төшерә. Шушы изге тетрәнүне борынгы юнан галимнәре к а т а р с и с атаганнар. Катарсис процессы булып тормаган очракта тойгылар тупаслана, җан бирчая. Соңгы вакытта андый кешеләрне еш кына телевизордан күрсәтеп торалар. Җаны, вөҗданы бирчәйгән кешегә нәрсә кирәк? Корсак һәм җенес ихтыяҗы, өстенлек, күз комсызлыгын тәэмин итәрлек дөньяви атрибутлар. Дөрес, үзләренең чор таләпләреннән артта калмаганлыкларын исбатларга ярарлык, гавам культурасы ысулында язылган китаплар да кирәк. Алда бу мәсьәләгә тукталырбыз әле. Катарсис проблемасын дәвам итик.

Социалистик реализм илле елдан артык әдәбиятка юл күрсәтеп килде. Татар әдәбияты дошман дзотыннан атучы пулеметның утын күкрәге белән каплаган матросовчылар, ардуан батырлар, дөнья күләмендә беренче урынга чыккан сыер савучылар белән тулды. Шул уңай геройлар арасында бүгенге көндә безгә үрнәк күрсәтерлек кем калды? Шул геройлар тәҗрибәсенә таянып, бүгенге көндә тормыш мәйданына чыккан яшь буын вәкиле үзенә киләчәк төзи аламы? Хәбәрдарлык чорында без социализмның әдәбият өлкәсенә кертелгән академик Лысенко тәгълимәте икәнлеген аңлый башладык. Үзәк Комитет карарын кыйбла итеп, өлкә комитетының идеология бүлеге күрсәтмәсенә таянып язылган әсәрләребез тормыш чынбарлыгыннан ерак торганга күрә, укучыларыбызны тетрәндерә алмадылар, шунлыктан аларның тәрбияви тәэсирләре дә нуль тирәсендә булды. Гомер, Шекспир, Достоевский, Джойс, Габриель Маркес шикелле төрле эпохада яшәгән әдипләрнең иҗат алымнарын бергә җыеп, шуларның тәҗрибәләренә таянып фикер йөрткәндә, әдәбиятта бер искерми торган канун яшәгәнен аңлый башлыйсың. Әдәбият — аерым шәхесләрнең, халыкларның һәм гасырларның ялгышу тарихы. Кешелек дөньясының кануннарын бозып, гөнаһ эшне савап, изелүне ирек, төрмә шартларында яшәүне азатлык итеп күрсәтүне фаш итү — әдәби әсәрдә әзерлекле укучыны мәнә шушы

реалийлар белән очрашу тетрәндерә. Ә без күпме еллар укучыны ялганга, күз буярга өйрәткән әсәрләрне әдәби әсәр дип исбатлап килдек. Дөрес, укучы яңа фикергә, яңа информациягә дә мохтаҗ, ләкин фикер һәм информацияне укучы башка чыганаклардан да таба ала. Тетрәнүне бары тик әдәбият, театр һәм сурәт сәнгате шикелле иҗатлар гына тудыра. Нигә кирәк ул безгә катарсис-тетрәнү? Укучы аңлый алырлык итеп, мин бу процессны магнитофонга язу белән чагыштырыр идем. Иске язуны кырып ташламыйча, магнитофон тасмасына яңасын язып булмый. Кеше күңеленә дә, тетрәнү аша иске эзләрне җуйдыртмыйча торып, яңа тойгылар урнаштыруы кыен. Күз алдына китерергә тырышып карыйк: ярты гасыр эчендә укучы күңеленә әдәбият аша күпме ялган, күпме икейөзлелек, күпме халтура язылган. Хәбәрдарлык, яңару үтеп керсен өчен аларның барысын да кырып, сөртеп ташларга кирәк.

Әдәбият административ-боерык системасының хезмәтчесе булып яшәгән чорда без: «Партия — ум, честь, совесть нашей эпохи» дип фирканы алладан да югары күтәреп, шуңа табынып яшәдек. Тик соңгы елларда гына шуны аңладык: безнең партия дип табынган нәрсәбез — партаппарат, аның алдынгы отряды дип инанган төркем — партбюрократия булып чыкты! Безнең коммунизм төзү эшендә туккән хәләл көчебез шул бюрократларның яшерен дачаларын, кибетләрен, Дүртенче идарә шифаханәләрен тоту, «шәүлә экономикасы» мафиозларының кәеф-сафа кылуларын тәэмин итү өчен түгелгәненә төшендек без. Әгәр безнең әдипләребез өсләренә пәйгамбәрлек вазифасын алып, иҗатларында шул юлдан тайпылмыйча эшләп килсәләр, без шушы хакыйкатьне инде күптәннән,— моннан ярты гасыр элек аңлаган була идек.

Чын әдәбият хакыйкать белән ялган, яхшылык белән яманлык арасындагы чикне аерырга өйрәтә. Бу чик чорның сәясәтенә иҗтимагый актив көчләр тәэсир итүе нәтиҗәсендә туктаусыз үзгәреп, эзен яшереп тора. Шуңа күрә, тормыш аренасына чыккан һәр яңа буын хакыйкать белән ялган арасындагы чикне үзе эзләп табарга тиеш. Шушы эзләнүдә чын әдәбият навигация картасы хезмәтен үтәп килә. Безнең әдәбият шушы вазифаны үтәрлек хәлдә идеме соң? Татарстан административ бәрәмлек буларак мөстәкыйль эш итә алмаган шикелле, безнең әдәбиятыбыз да тулысынча үзәк әдәбиятка буйсынып, шуның иярчене, койрыгы хезмәтен үтәп килде. Татар әдәбиятын аңлар өчен башта рус совет әдәбиятын анализлап карыйк.

II

Беренче тапкыр Европа илләре белән танышканда мине бер гаҗәп хәл тетрәндерде. Без бит озак еллар буе, капиталистик илләр изүче һәм изелүче сыйныфлардан тора, ә бездә сыйныфлар юк, дип ышанып йөрдек. Менә шул сыйныфлы капиталистик илләрнең тимер юлларында бары тик ике төрле вагоннар йөри: беренче класс һәм икенче класс. Аларның аермасы исә — утыргычларның бәрхет яиса дермантин белән тышлануында. Ә безнең сыйныфсыз илебездә вагоннар алты төрле: гомуми, комбинированный, плацкарт, купе, люкс һәм халыкара вагоннар. Сыйныфлар революция вакытында юкка чыгарылган булсалар да, рус совет әдәбиятына хезмәт итүче язучыларны да биш сыйнфый катламга бүләргә була.

Беренче катлам — партия һәм хөкүмәт башында утыручылар белән бер ялгаштан ашап яшәүче генераллар. Бу катламга эләгә алган әдипләр китапларын теләсә нинди нәшриятта, теләсә ничә миллион тираж белән, теләсә кайчан бастыра алалар. Әсәр чыгу белән берничә дистә рецензия басылып чыга, телевидениедән реклама ясала һәм шул ук әсәр тиз вакыт эчендә киносценарийга әйләнеп, экраннан күрсәтелә башлый. Бастыру, рецензия һәм сценарий ясауга көч түгеп азапланасы юк. Акула тирәсендә ерткыч балыктан калган азык белән туклланучы вак балыклар йөргән шикелле, әдәбият генераллары тирәсендә дә ялагайлар өерелеп йөри. Бу катламга кергән язучылар Дүртенче идарә шифаханәләрендә дәвалана, теләгән чит илгә командировкага йөри, аның түшендә депутатлык билгесе, дисталәгән нәшриятта редколлегия әгъзасы һәм берничә дистә комитетта — әгъза. Кырыклар тирәсендә аларга лауреат значогы тагалар, илле-алтмышка җиткәч — Хезмәт Герое. Дөрес, генераллар арасында талант ияләре дә юк түгел, ләкин аларга талантлы булуның ул кадәр кирәге юк. Яза белмәгәннәргә әдәби негрларны кулланырга мөмкин, тәрҗемә мәсьәләсе китап язылып беткәнче үк хәл ителеп куела һәм китап СССР халыкларының күп телләрендә, чит илләрдә басылып чыга. Әдәбият өлкәсендәге сәясәтне шушы катлам ясый. Язучылар союзындагы аппаратны, союз һәм автоном республика оешмаларының җитәкчеләрен дә алар ярдәмендә сайлап килделәр.

Икенче катлам. Бу катламга кергән язучылар хатыннарына, якын дусларына әдәбият акулаларының комсызлыгы, аларның гаделсезлекләре турында сөйләп эчләрен бушаталар. Җыелышларда теге әдәбият акулаларының тегермәненә су коюлярен бушаталар.

чыларның докладларын тешләрен кысып булса да тыңлыйлар. Сайлау вакытында каты газап кичереп шул акулалар сәясәте тормышка ашсын өчен кул күтәрәләр. Җыелыштан соң, агай-эне җыелган җирдә, әдәбият дөньясындагы гаделсезлекләрне тетеп ташлыйлар. Мондый язучыларның фәнни фантастика, детектив жанрга күчә алмый калганнары үзләренең цензура тарафыннан «бабага утыртылган» әсәрләрен редакторлар белән ызгыша-бәхәсләшә әзме-күпме бастырып килә алдылар. Тираж, билгеле, теге беренче катлам язучыларныкы белән чагыштырырлык булмады. Лауреатлыкның да бик нык ялагайланып, йөк аты шикелле озак еллар җәмгыять йөген сөйрәп килгән очракта гына бәләкәе эләгеп куйгалый иде. Хезмәт Герое җизе мондыйларның төшләренә дә кермәде. Дубулты, Күктүбә, Пицунда иҗат йортларына путевка, көне-төне Литфонд бусагасын таптап йөргән очракта да, «бәрхет сезон» узгач кына эләгә иде. Союз валютасына чит илгә командировкага бару да берәр әдәбият генералына кирәкле йомыш башкарган очракта гына эләгеп куюы мөмкин иде. Шуңа карамастан, бу катлам әдипләре авыр елларда да дубленка һәм күн пиджак киеп йөри алдылар. Сәясәт җиленә каршы төкермәгән очракта хатыннарына каракүлдән теккән пальто кигерттеләр.

Хәбәрдарлык чоры башлангач, бу төркем вәкилләренең кайберләре публицистикага күчеп, зур аудитория яулап алуга иреште. Әзчелеге хәтта теге беренче катламга күчә алды. Яңару бу катламга бик зур зыян китерде. Әдипләрнең күпчелеге югалып калды. Цензураның корыч кулы синең бугазыңнан тотып тормагач, бюрократиянең тимер маңгае каядыр яшеренгәч, көрәшкә өнди торган стимул юкка чыкты. Стимулсыз ничек иҗат итәргә?

Татар язучыларының күпчелеге шушы катламга керә. Автоном республиканың аренасы чиктән тыш тар булганлыктан, татар халкының яртысы туган телен югалткан, балаларыбызның бары тик җиде проценты гына туган телдә белем алганга күрә, татар әдипләренең иҗади язмышлары бөтенләй башка төрле. Культ һәм торгынлык елларында әдәбиятыбызда «бөтенсоюз аренасына чыгу» дип аталган хәрәкәт барлыкка килде. Татар телендә язылган әсәр әле чыгып та өлгермәгән, әле аның нинди икәнлеге, укучы аны ничек кабул итәчәге билгеле дә түгел — автор аны тизрәк Мәскәүгә, үзәк нәшриятка урнаштырырга ашыга. Дөнья әдәбиятында мондый хәлнең булганы юк иде әле. Һәр әдип үз халкы өчен яза, әсәрдә халык язмышы, бүгенге көн тормышының катлаулы проблемалары чагыла, шуңа күрә халык белән язучы арасында уртак мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Дөресен әйткәндә, рус укучысы татар язучысыннан яңалык көтми. Аның үзендә язучылар җитәрлек. Дөрес, һәр халыкта милли әдәбият чигенә сыя алмыйча бөтендөнья укучыларын яулаган әдипләр бар. Алар әз, һәр чорга бары тик бер генә була. «Бөтенсоюз аренасына» омтылу, минемчә, татар әдәбиятының авыр кризис кичерүен чагылдыра. Язучылар күбәйгән саен укучылар әзәя. Укучылар әзәйгәнгә күрә, татар әдәбиятының даирәсе тарая. Татар әдәбияты укучыны чит даирәдән эзләргә мәҗбүр.

Нәрсә икән ул Татарстанга сыя алмыйча, татар укучыларына гына канәгать була алмыйча, җир шарының алтыдан бер өлеш җирен биләгән «бөтенсоюз аренасына чыгу»? Бәлки, чыннан да, безнең татар язучыларын «бөтенсоюз укучысы» түземсезлек белән көтеп торадыр?

«Бөтенсоюз аренасына чыгу» дип без Мәскәүдә китап бастыруны атыйбыз. Башкаладагы нәшриятларда китап бастыру өчен татарча язылган әсәрне русчага тәрҗемә итәргә кирәк, тәрҗемә итү өчен әсәрнең әдәбилеген җимереп, подстрочник ясарга кирәк. Бу процессны аңлау өчен, әйтик, йорт салу белән чагыштырып карыйк. Татарның милли ысулындагы корылмага әйләндерү өчен башта аны сүтеп ташларга кирәк һәм шул сүтелгән йортның бүрәнәләреннән яңаны әмәлләргә. Тәрҗемә күп очракта талантлы әсәрне харап итә, халтура исә тәрҗемәдән соң, киресенчә, яхшыра.

Мәскәүдә китап бастыру «бәхетенә» ирешкән язучы үзеннән-үзе «зур язучы»га әйләнеп китә. Без бүгенге көнгә кадәр шушы сафсатага ышанырга тырышабыз. Укымыйлар андый китапларны, ышанмыйлар тәрҗемә аша үткән әсәрнең укырга ярарлык булуына! Һәм рус укучысы күп очракта ялгышмый. Туган телендә чын шедевр булуына карамастан, тәрҗемә аша узган әсәр зәгыйфьләнә, йөзен, сулышын, хәтта җанын югалта. Ышанмасагыз — Тукаебызның русчага тәрҗемә ителгән әсәрләрен укып карагыз!

«Бөтенсоюз аренасына чыгу» нияте татар әдәбиятына искиткеч зур зыян китерә. «Союз күләмендәге укучы»ны күздә тотып иҗат итү бүгенге көндә иң актуаль мәсьәлә саналган милли проблемалардан баш тартырга яисә аларны урап узарга мәҗбүр итә. Милләт буларак, без, татарлар, инде юкка чыгып киләбез. Телебезне югалттык дисәк тә ялган булмас. Татарларның яртысы гына туган телен белә, җиде процент татар баласы туган телендә белем ала, дидек. Өстәвенә, әдәбиятыбыз союз

күңелендәге абстракт укучы ихтыяҗына эшли. Бармы соң ул андый укучы? Кем соң ул? Социология фәне китап укучыларны өч төргә бүлә: маскульт (китч) вәкилләре, популяр культура катламы (конформистлар) һәм әсәрнең әдәби камиллеген, сыйфат җитешлеген аңлый һәм бәяли алырлык зәвыклы укучы. Яңа басылып чыккан әсәрне шушы өч төрле укучының берсе кабул итә, калган ике укучы төренә бу әсәр чит, ят тоела. Маскульт укучылар төркеменең иң талымсызы. Аңа нервыларны кытыклый алырлык манзаралар — эротика, йозак тишегә аша гына күреп була торган вакыйгалар, гавам аңы белән чишеп була торган көндәлек тормыш шаблоннары булсын. Рус совет әдәбиятында андый укучыларның кумиры — Валентин Пикуль. Популяр культура укучысына исә реклама кирәк. Ул түшенә лауреат билгесе таккан, телевизордан күрсәтелгән, матбугатта күп санлы рецензияләре басылган авторларны сайлый. Конформист буларак, ул һәрвакыт җәмгыять фикеренә колак салып йөри һәм аның яраткан әдибе — популяр язучы. Татар әдәбиятында мондый укучыларны Габдрахман Әпсәләмов һәм торгынлык елларында Гариф Ахунов шикелле язучылар тәрбияләде. Зәвыклы укучы — талымлы, шунлыктан, ул бик аз һәм әдәбиятның үсүенә, югары сыйфатлы әсәрләр барлыкка килүгә сәбәпче кеше. Культ һәм торгынлык елларында мондый укучының саны шактый азайды. Мәктәпләрдә әдәбият һәм туган тел өйрәнү искиткеч примитив, түбән сыйфатлы булу аркасында, зәвыклы укучы әзерләү елдан-ел катлаулана килде. Өстәвенә, әдәбиятның язмышы китч һәм популяр культура әдипләре кулында булу да әдәбиятыбызга зур зыян китерде.

Культ һәм торгынлык елларында татар әдәбияты читтә яшәүче укучыларын тулысынча диярлек югалтты. Ә чит илдәге өлеше туган әдәбият белән элемтәне йөз процентка өзде. Татар язучылары «бөтенсоюз аренасына чыгу» нияте белән эшли башладылар. Безнең әдипләребез, татар телендә укучыларны күздән югалтып, тәрҗемә өчен эшләргә тотындылар. Русчага тәрҗемә итүчеләрнең иң талантлылары чит ил язучыларын тәрҗемә итә. Аннан кала — союздаш республикада яшәүче язучыларны. Һәм өченче чиратта (тәрҗемәчеләрнең дә өченче рәттәгеләре) автоном республика язучыларына эләгә. Культ һәм торгынлык чоры союздаш республика вәкилләрен автоном республикалылардан зуррак, культуралырак, алдынгырак итеп күрергә өйрәтте. Без өченче сортлы милләт булып яшәргә күнектек һәм тигезлеккә омтылу хәрәкәте әле һаман бик тә зәгыйфь, бик тә куркак һәм кыюсыз! Шушы хәл әдәбиятта даими чагылып тора.

Өченче катлам. Рус совет әдәбиятының бу катламын хакыйкать эзләүчеләр тәшкил итә. Утызынчы елларда аларны тулысынча кырып бетергән булсалар да, XX съезддан соң барлыкка килгән «җылымса еллар» тагын бер буын хакыйкать көрәшчеләре бирде. Бу дулкынның максаты цензура золымыннан котылу, әдәбиятны партия тырнагы астыннан тартып алып, иҗат азатлыгына, чынбарлыкны сурәтләргә юнәлтү иде. Бу — репрессиягә эләккән тоткыннарның кайта башлаган чоры. Ул елларның атмосферасында азатлык җиле исә башларга җыенганы сизелә иде. Әдәбиятта азатлык хәрәкәте башланып китте. Ләкин аңа киңәергә, борылыш ясарга ирек бирмәделәр. Хакыйкать эзләүчеләр тулысынча диярлек дәүләт чигенең теге ягына, эмиграциягә сөрелде. Революциядән соң сөрелгән «беренче дулкын» әдипләре һәм Икенче бөтендөнья сугышыннан соң барлыкка килгән «икенче дулкын», тагын шуларга җитмешенче елларда сөрелгән рус совет язучылары килеп кушылды. Европада, Америкада һәм җир шарының башка төбәкләрендә рус телендә газеталар, журналлар һәм дистәләгән нәшриятларда русча китаплар әле һаман чыгып килә. Соңгы вакытта әдәби журналларда эмиграциядә яшәгән рус язучыларының әсәрләре басыла башлады. «Беренче дулкын» вәкилләре Владимир Набоков, Евгений Замятин, Борис Зайцев, Нина Берберова, «өченче дулкын» булып киткән Василий Аксенов, Сергей Довлатов, Владимир Войнович, Эдуард Лимонов, Георгий Владимов — ватанына кире әйләнеп кайткан мондый исемнәрне санап та бетерерлек түгел.

Александр Солженицын югарыда күрсәтелгән өченче катлам язучылар төркеменә керсә дә, масштаблылыгы, иҗат программасының тәвәккәллеге белән башкалардан аерылып тора. Солженицын, күкрәге белән амбразураны каплаган Александр Матросов шикелле, турыдан-туры тоталитар системага каршы ташланды. Шушы пәйгамбәрлек вазифасын өстенә алыр өчен ул иң әзерлекле һәм иң лаеклы әдип иде. Репрессия һәм ГУЛАГ лагерьлары, газета-журнал битендә, радио, телевидениеләрнең массированный яла-әзәрлекләүләре һәм, ниһаять, аяусыз рәвештә чит илгә сөрелү... Язучыны пәйгамбәр итү өчен аңа карата барлык чара күрелде. Ә соң ул шушы кара болыт булып ябырылган аяусыз һәм пычрак көчкә каршы ничек чыдый алды? Рус әдәбиятында һәм ул чорның әхлакый атмосферасында Солженицынны исән калдырырлык көчләр бар иде. Рус совет әдәбиятының вөҗданы саналган Александр Твардовский, академик Лихачев, Ростроповичлар, алдынгы карашлы интеллигенция һәм хакыйкать көрәшчесенә көч, егәрлек биреп торучы зәвыклы укучы. Боларның барысы да Солженицын ягында иде.

Әдип бит ул, әгәр графоман һәм бизнесмен түгел икән, күзгә күренмәс җепләр белән укучыга бәйләнгән. Әдиплекне пәйгамбәрлек вазифасы итеп алган язучы иҗаты — вөҗданы, ялганга, гаделсезлекләргә түзә алмыйча сыкранган укучы иманының тавышы гына. Укучының изге теләкләре ни кадәр зур, ни кадәр көчле булса, язучының иҗаты шул кадәр уңышлы һәм сыйфатлы. Бүгенге көн мәсьәләләрен алыйк. Илдә бөек борылыш башлангач, барлык халыклар уянып, үзләренең теләкләрен һәм максатларын турыдан-туры белгерттеләр. Минем халкымның гына тавышы әле һаман ныклап ишетелми. Ул нәрсәдәндер курка, өркә һәм котә! Әгәр мин үземнең мөстәкыйль халык икәнлегемне белгертсәм, кемгәдер ошамас, кемнеңдер ачуын китерер, дип уйлый ул. Тарих тәҗрибәсе безне ирекко, азатлыкка һәм мөстәкыйльлеккә ымсынмаска өйрәткән. Менә шушы шартларда татар әдәбиятында өченче катламның барлыкка килмичә калуы табигый хәл. Әдәбиятыбызда хакыйкать эзләүчеләр булмады дип әйтсәк, әдипләребезгә яла ягу булыр иде. Әмирхан ага Еники һәм Нурихан Фәттах иҗатларын алыйк, Хәсән Туфанны, Равил Фәйзуллиннар, Зөлфәт һәм Мөдәррис Әгъләмовлар дулкынын тикшереп карыйк. Турыдан-туры тоталитар көчкә каршы чыгу мөмкинлеге булмаганга күрә, татар әдәбиятында хакыйкать эзләү нонконформизм рәвешендә яшәп килде. Әмирхан Еники әсәрләрендә сез туган туфрагыбызның канын суыручы нефтьчеләргә мәдхия, КамАЗ төзү сылтавы белән милли гореф-гадәтләр һәм милли тормыш исән сакланган төбәккә этрәк-әләм китереп тутыруга кул чабу таба алмыйсыз. Нурихан Фәттахның иҗатын гына алыйк. Ул конъюнктурага баш бирмичә, халкымның ерак тарихын яктыртырга кереште...

Татар әдәбиятында хакыйкать эзләү Махатма Гандиның инглиз колонизаторларына каршы кулланган ысулы — пассив каршылык рәвешендә яшәп килде. Безнең җирлектә башка реаль мөмкинлекләр юк иде. Дөрес, «хакыйкать эзләүчеләр» арасында дөреслеккә, ирекко өндәүче бер-ике әсәр язып, бераз сатулашканнан соң лауреатлык билгесе алып, конъюнктура лагерена күчүчеләр дә булмады түгел.

Рус совет әдәбиятында дүртенче катлам да бар. Бүгенге көндә матбугатта шактый киң тарала башлаган андерграунд (әдәбиятчылар аны «другая литература» дип тә атап йөртәләр) торгынлык елларында барлыкка килде. Вячеслав Пьецух, Людмила Петрушевская, Зөфәр Гәрәев, Татьяна Толстая торгынлык чорының тынчу, черек атмосферасын җәмгыятебез халәтен дөрес чагылдыра алдылар.

Бу мәкаләдә без татар әдәбиятын рус совет әдәбияты белән чагыштырып карадык. Рус әдәбиятын дүрт эшелонга тупланган, укучы күңеленә дүрт төрле юл белән якынлашучы гаҗәп зур, көчле һәм мөмкинлекләре чикләнмәгән язучылар армиясе хәл итә. Рус телендә язылган китаплар русларның үзләренә, рус телендә сөйләшеп дөнья көтүче башка милләтләргә һәм җир шарының төрле почмакларында яшәүче рус эмигрантларына тарала. Рус әдәбияты белән Европа, Америка, Азия һәм Африка континентында яшәүче халыклар кызыксына. Соңгы вакытта рус әдәбиятының үсүе һәм көчәюе өчен чиктән тыш зур әһәмияткә ия бер хәл булып алды: метрополиядә һәм эмиграциядә яшәүче рус язучылары берләштеләр. Дөрес, алар арасында бәхәс әле һаман сүнмәгән, ләкин бу үсәргә, ныгырга ярдәм итә торган файдалы һәм шифалы бәхәс.

Ә татар әдәбияты нинди хәлдә? Татар әдәбияты вәкилләренең күпчелеге әле дә иске рухта яшәвен дәвам итә. Татар язучысы әле һаман милли проблеманы тиешле дәрәҗәдә күтәрергә курка. СССР Югары Советы съездларындагы чыгышларны тыңлап карагыз. Советлар Союзында яшәүче барлык халыкларның тавышлары ишетелеп торганда, безнең татар әле һаман өнсез, әле шушы көнгә кадәр «үземнең нинди хәлдә икәнлегемне белгертсәм, милләтче итәрләр» дип куркып яши. Бу бигрәк тә кичәге җитәкчеләребезгә карый. Нилектән безнең кайбер иптәшләребез, җитәкчелеккә ирешү белән, халыктан тулысынча аерылалар? Аңлашылмый. Алар нигә халыкка зыян китерә торган эш белән шөгыльләнәләр? Аларга ияреп, безнең дә кайбер язучыларыбыз халыкны юкка чыгарырга көйләнгән эшләргә мәдхия җырлап йөри.

Татар халкы Советлар Союзының төрле төбәкләренә таралган. Чит илләрдә күпме милләттәшләребез яши. Татарстаннан читтә яшәүче татарлар белән рухи элемтә, культура бердәмлеге тулысынча диярлек өзелгән, әдәбиятыбыз аларга аркасы белән борылган. Рус әдәбиятындагы шикелле метрополия һәм эмиграция уртаклыгы, әдәбиятның киләчәге турында бергәләп кайгырту бармы соң бездә?

Рус язучылары үз укучыларының күңеленә яңа юл эзләүдән Сталин терроры, торгынлык елларында да туктап тормадылар. Жданов инквизициясе Ахматова, Зощенко, Мандельштам һәм башка язучыларның язмышларын сытып киткәннән соң, рус язучылары һәм рус укучылары арасында шәфкать хәрәкәте уянды.

Әдәбиятыбызның киләчәге турында кайгыртканда без рус язучыларыннан үрнәк

алып эшләргә тиешбез. Татарчага тәрҗемә итүне күздә тотып язган рус әдибен очратканым юк минем. Рус әдәбиятының диапазоны искиткеч киң, анда секретарьлар прозасыннан алып андерграундка, сала язучыларыннан алып Нью-Йоркта яшәүче, «Азатлык», «Америка тавышы» радиостанцияләрендә даими эшләп килүче авторларга кадәр урын җитә. Рус язучысы кайда гына, кем арасында гына булмасын, үзенең туган телендә сөйләшә. Оялмый ул башка милләт арасында русча сөйләшүдән, киресенчә, горурланып сөйләшә! Халык язмышы, аның киләчәге, милләтенең иминлеге өчен көрәшүне, рус әдибе пәйгамбәрлек вазифасы итеп алган. Нәкъ менә шушы халык мәнфәгатенә тугрылыклы булу бөек әсәрләр тууына сәбәпче көч! Чыннан да, әдәбиятыбызның киләчәге турында кайгыртканда без рус язучыларыннан үрнәк алырга тиешбез. Аларның тәҗрибәсе безне таралып, таркалып, милли йөзен, горурлыгын югалту хәленә килеп җиткән татар халкын уяту һәм берләштерү эшендә уңышка китерәчәк.

Бүгенге көнгә кадәр без штык белән яздык. Көн тәртибендә башка корал. Ә без, татар язучылары, нәрсә белән язарга тиешбез? Бүгенге көн чынбарлыгына яман шеш булып үскән рухсызлык, кыйбласызлык һәм манкортлыкның күзәнәкләрен алып ташлар өчен кулга скальпель алырга тиешбезме? Әллә тапталган, ялган астында калган тарихыбызны эзләп табу өчен археологлар инструменты — кәрәк кирәкме безгә? Бәлки, татар әдәбиятын бүгенге көн таләпләре биеклегенә күтәрер өчен безгә саф, гайрәтле иман кирәктер?

Минемчә, кулына каләм алучыга иң кирәкле, катгый рәвештә тиешле корал — пакь вөҗдан.

*Мәскәү.*

## Рафаэль Мостафин

# ТӘНКЫЙТЬЧЕНЕҢ АКЫЛЫ...

Татар акылы төштән соң, диләр...

Бүген без бик күп күренешләрне бөтенләй башкача бәялибез, үткәннәргә яңа караш ташлыйбыз, булган хаталарны фаш итәбез, гаепләләрне эзлибез... Ә үзебез — шул чор кешеләре? Торгынлык атмосферасын тудыруда безнең берниндн катнашыбыз да булмады микән? Барысын да аңлап, алдан уйлап, дөрес юлдан гына бардыкмы соң?

«Идел» журналының 1990 елгы беренче-икенче саннарында Нурихан Фәттахның «Кырык дүртнең май аенда» исемле повесте дөнья күрде. Әсәр 1965 елда ук язылып, заманында «Казан утлары»нда басылып та чыккан иде (1965 ел, 12 нче сан). Ләкин шактый «редакцияләнгән», йомшартылган вариантта һәм «Артта калган юллар» дигән башка исем астында. Хәзер язучы исә укучыларга әүвәлге, имгәтелмәгән нөсхәсен тәкъдим иткән.

Дөресен әйтим, мин бу әсәрне шактый каршылыклы хисләр белән яңадан укып чыктым. Бер яктан — авторның кырыс реализмына соклandым... Алтмышынчы еллар уртасында ук ул безнең стройның гади кешегә никадәр чит-ят булуын, кешене ничек изүен, намусын таптавын, алай гына да түгел — юк итүен искиткеч тәэсирле итеп күрсәтә алган. Шуңа күрә дә повесть нәкъ бүген, яңарыш заманында язылгандай укыла. Икенче яктан исә — ачы үкенү хисе... Әсәрнең теге елларда ясалма финал һәм ятышсыз исем белән басылып чыгуында үземнең дә катнашым булмады түгел бит...

Мин ул вакытта «Казан утлары» журналының җаваплы мөхәррире булып эшли идем. Н. Фәттах әсәре кулыма килеп кергәч, тетрәнеп тә, сокланып та бер утыруда диярлек укып чыктым... Әйе, мондый рәхимсез, туры язылган әсәрнең журналда гына түгел, гомумән, ул чор әдәбиятында булганы юк иде әле. Әмма шул ук вакытта бер нәрсә минем өчен көн кебек ачык иде: бу көенчә әсәр цензура иләге аша бер-ничек тә үтә алмаячак. Минем фикерне редколлегиянең башка әгъзалары да хуплады. Дөрес, арада әсәрне басуга кискен рәвештә каршы чыкканнары да булды. Ләкин

күпчелеге әсәрне яңадан эшләп, төзәтеп, ахырын һәм исемен үзгәртеп бастыру ягында иде. Башка чакта бик үзсүзле булган автор бу юлы әллә ни карышып тормады: әсәрне алып китеп, тиз арада яңадан эшләп, алып та килде. Һәм әсәр ничектер шома гына, цензура аны-моны абайлаганчы, дөньяга да чыкты.

Дөрес, соңыннан сүзе күп булды. Гадәттәгечә, таякның авыр башы авторга да, редколлегия әгъзаларына да түгел — мөхәррир башына төште. Ул обкомга чакыртып вәгазь укулар... Ул ябык киңәшмәләрдә аякка бастырып сүгүләр... Эштән дә алып ташлаган булырлар иде — яшь мөхәррир булуымны искә алып кына (ул вакытта мин әле ярты гына ел эшли идем) вакытлыча калдырып тордылар. Тагы берничә шундый рухтагы «хата» кабатлангач, анысын да эшләделәр. Н. Фәттах әсәре исә шуннан соң аерым китап булып та чыкмады, язучының берниндн җыентыгына да кертелмәде...

Шулай да үз-үземне акларга яки чор каһарманы итеп күрсәтергә җыенмыйм. Язучыга әсәрнең азагын үзгәртергә, «оптимистик рух» өстәргә, «кара буяулардан арындырырга» киңәш биргәнмен икән — хәйлә өчен генә түгел. Уй-фикер дәрәҗәм дә шундыйрак булган, күрәсең. Моны 1969 елда шул ук «Казан утлары»нда басылган «Яшьләр прозасы хакында уйланулар» исемле мәкаләм мисалында күрергә була.

Мәкалә авторы (ул вакытта әле яшь, каләмен яңарак шомарта башлаган тәнкыйтьче) шул чорның яшь талантларын шактый сизгер тоеп, сайлап алган. Мәкаләдә сүз Н. Фәттахның «Артта калган юллар», Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим», А. Гыйләҗевның «Берәү», М. Мәһдиевның «Без кырык беренче ел балалары», В. Нуруллинның «Шинельсез солдатлар» повестьлары турында бара. Ул вакытта әле әдәбият мәйданына яңарак аяк баскан һәм тәнкыйтьче тарафыннан «иң талантлы», «иң өметле» дип табылган яшь көчләр, чирек гасыр үтүгә, бу өметне тулысынча akладылар, прозабызның әйдәп баручы көчләренә әверелделәр.

Тәнкыйтьче аларның әдәбиятка алып килгән яңалыкларын авыл темасы мисалында тикшерә, алардан алдагы буын әсәрләре белән чагыштырып анализлый. Әйтик, Г. Әпсәләмов, Г. Баширов, М. Әмир, Ф. Хөсни һәм башкалар, Ватан сугышы чоры авылы турында язганда, игътибарны күбрәк җиңел чыккан халыкның батырлыгына, героик характерына юнәлткән булсалар, яшьләр исә бу җиңүнең халкыбызга нинди бәягә төшүенә, сугыш елларында халык җилкәсенә төшкән авырлыкларны күрсәтүгә юнәлдерәләр.

«Мәгълүм сәбәпләр аркасында өлкән буын әдипләре мәсьәләнең бу ягына игътибар биреп җиткермәделәр,— дип яза яшь тәнкыйтьче.— Сугыш елларына багышланган күп кенә әсәрләрдә авыл халкы күргән кыенлык-авырлыклар кичерәйтеп күрсәтелде, үткен конфликтлар һәм тормыш каршылыклары шактый шомартылды, хыялда гына булган нәрсәләр чынбарлык төсендә сурәтләнде».

Дөрес язган бит, каһәр! Чыннан да, ул чор әдәбиятында без хыялый геройлар белән дә, тормыш белән берниндн уртаклыгы булмаган күренешләр белән дә, артык куе итеп кулланылган алсу буяу белән дә шактый еш очрашабыз.

«Мондый кимчелекләр ул еллар әдәбиятының «Намус» романы шикелле иң гүзәл әсәрләрендә дә очрый,— дип дәвам итә тәнкыйтьче.— Шуңа күрә яшьләрнең сугыш чоры күренешләрен ничек тә тулыландырырга тырышулары, өлкән буын язучылары игътибарыннан читтәрәк калган әйберләр турында сөйләргә омтылулары табигый хәл».

Монысы белән дә бүгенге көн тәнкыйтьчесе тулысынча килешә ала. Илленче еллар уртасында исә башлаган саф җилләр безнең әдәбиятны да читләтеп үтмәде: халык та, әдәбият та,— тулы күкрәк белән үк булмаса да,— шулай да иркенрәк тын ала башлады. Яшь язучылар үзләре белән әдәбиятка яңа геройлар, яңа тема-проблемалар гына түгел, яңа чынбарлык, алдаусыз-буяусыз күрсәтелгән чын дөреслек алып килделәр.

Бу күренешне тәнкыйтьче Н. Фәттах әсәре мисалында аеруча игътибар белән анализлый. «Яшь авторның үзеннән алдагылар белән бәхәсе әсәрнең төп каһарманын сайлаудан ук күренә,— дип яза Р. Мостафин.— Әгәр Нәфисә («Намус») — алдынгы бригадир, Миңлекамал («Миңлекамал») — колхоз рәисе, Сания («Саф күңел») — шәһәр советы рәисе, икенче төрле итеп әйткәндә, алар барысы да билгеле бер мәгънәдә башкалардан өстен торган, абруйлы, билгән постлары белән үк мактаулы һәм хөрмәтле кешеләр булса, Хәмдия... иң гади бер колхозчы. Алай гына да түгел, ул качак, хезмәт фронтыннан качкан дезертир, шул чорның кырыс законнары буенча аны суд, төрмә көтә. Хәмдия качып-посып яшәргә, хәтта күршеләреннән дә яшеренергә мәҗбүр. Ул — төшенке рухлы, алданган татар кызы; җилдән тапкан баласы белән ялгыз калган, шуның өчен үзен коточкыч гаепле санап, оялып-кызарып яшәргә мәҗбүр булган мескен кеше».

Фикерем нигездә дөрес булса да, Хәмдияне «мескен» дип бәяләү белән бүген һич килешеп булмый. Әйе, ул алданган, изелгән, намусы да, ышанычы да тапталган кеше. Ләкин ул һич тә «төшенке рухлы», «мескен кеше» түгел. Ул горур, тыйнак, эш

сөючән, заманында колхозның терәге булган алдынгы хезмәтче. Әгәр ул «хезмәт фронтыннан», ягъни, чын тәмугтан качып киткән икән, «ак пирчәткә» дә, «ирка» булудан да түгел — артык түзәргә тәкате калмаганнан. Авылга да ул теләсә нинди иң авыр эшкә дә риза булып кайта — колхозга да эшче куллары җитешми ич. Шуңа күрә ул колхоз рәисе белән дә мескенләнеп түгел, үз бәясен белеп, аяк терәп сөйләшә. Әгәр дә инде шундый тыйнак, түземле, аек акыллы кешене акылдан язуга хәтле җиткергәннәр икән — монда аны түгел — шул чорның рәхимсез шартларын, кешеләрен, Сталин режимын гаепләргә кирәк...

Әлбәттә, бу сүзләрне без бүген генә әйтә алабыз — 60 нчы елларда идеологик калыплар барыбызның да миләрендә бик көчле иде әле. Әйтергә кирәк, тәнкыйтьче әсәрнең эстетик кыйммәтен аңлап эш итә, авторның кыюлыгына соклана. Аныңча, сугыш чоры авылы хакында «моңарчы берәүнең дә бу рәвешчә кыю язганы булмагандыр, ихтимал». Бүген мин бары тик «ихтимал» сүзен генә алып ташлап, «булмады» дип кырт кисәр идем...

Югарыда әйткәнемчә, әсәр турында басылганчы да, басылып чыккач та бәхәсләр шактый булды. Берәүләр аны бөтенләй танымаса, әсәрне дөньяга чыгаруга ук каршы чыкса, икенчеләр исә әсәрне яклап чыкты, аның реалистик көчен тоеп эш итте. Тәнкыйтьче дә, һичшиксез, соңгылар рәтендә (ә бәлки, рәтендә генә түгел, башында да). Ул әсәрне юк итәргә, әдәбияттан сызып ташларга теләүчеләр белән аяк терәп бәхәсләшә, «никадәр генә кимчелекле булмасын, Н. Фәттахның бу повесте дә яшәргә хаклы»,— дип яза.— Чөнки ул Ватан сугышы чорындагы авыл тормышының нинди-дер яңа якларын ача, аны яңа штрихлар белән баета». «Әдәби әсәрләрне «безнеке булганга» һәм «безнеке булмаганга» (Н. Фәттах повестен кайберәүләр нәкъ шулай бәяләделәр) гына бүлеп утырудан, аны йә күккә чөеп мактау, йә аяк астына салып таптый торган заманнардан уздык шикелле».

Кайда ул узулар! Бүген дә моңа өмет кенә итәбез! Тәнкыйтьче әсәрне бөтен катлаулылыгында аңларга, аның көчле һәм көчсез якларын диалектик бердәмлектә күрә һәм бәяли белергә чакыра.

«Кыен мәсьәләләргә җиңел җаваплар биреп котылырга теләгән, чынбарлыкның ниндидер якларын юри читләтеп узарга тырышкан, тормыш күренешләренә алсу күзлек аша гына карарга гадәтләнгән әдәбият, телиме-теләмиме, котылгысыз рәвештә вагаячак, түбәнгә тәгәрәячәк».

Афәрин! Ничек төгәл, дөрес итеп әйткән бит! Шулай да, нинди «кимчелекләрне» истә тота икән ул? Мәкаләмне җентекләбрәк укып карыйм да уңайсызланып куям. Әсәрнең төп кимчелеге — «берьяклылыкта» икән. Аның (ягъни, ул чактагы «мин»ем) фикеренчә, повестьта «тулы дөреслек түгел, шуның бер кыры, бер өлеше генә» чагылыш тапкан икән. Алай гына да түгел, Н. Фәттах әсәрендә «кыенлыкларны сурәтләү үзмаксатка әйләнебрәк киткән». «Н. Фәттах әсәрендә без фактлар дөреслеге белән очрашсак та, гасырның олы хакыйкатен күрмибез...»

Үзем укыйм, үземнең ояттан колакларым яна. Нинди «олы хакыйкать»не истә тота соң тәнкыйтьче? Әллә авыл халкының рәхимсез изелүе, ач үлемгә, бетүгә дучар булуы олы, рәхимсез хакыйкать түгелме? Көчләп үткәрелгән күмәкләштерү, халыкны налоглар белән талау, «мобилизацияләп», чәнечкеле тимер чыбык артында эшләтү дөрес түгелме?

Турыдан-туры әйтергә кирәк: Н. Фәттах, сәләтле язучы буларак, ул чорда ук әлеге кырыс хакыйкатьне тойган, аңлаган, образлы рәвештә күрсәтеп тә бирә алган. Тәнкыйтьче исә, «социалистик реализм тәгълиматы»на таянып, язучыны ниндидер пропорцияләрне сакламауда, кара буяуны күбрәк куллануда, перспективаны күрә белмәүдә гаепли. Әмма дөреслек тәнкыйтьче ягында түгел, язучы ягында булып чыкты.

Әлеге мәкаләне бүгенге күзлектән укыганда тәнкыйтьченең башка җитди хаталарын да күреп була.

Әйтик, А. Гыйләҗевнең «Берәү» повесте турында язганда тәнкыйтьче, бер яктан, аның кырыс реализмын хуплый. А. Гыйләҗев «тормыш кыенлыкларын шомартып һәм бизәп күрсәтми торган, дөресен, бары дөресен язган әдәбият кына яшәргә һәм ихтирамга лаек», дип уйлый, үзе дә әнә шундый дөреслеккә омтыла,— дип яза тәнкыйтьче.— Ачы, хәтта күпмедер дәрәҗәдә күпертелгән рәхимсезлек белән ул хезмәт кешенә нибары йөз грамм арыш оны тигән, халык күтәрә-түли алмаслык налоглардан иза чиккән, дуамал колхоз председательләре йорт саен кереп эшкә куып йөргән еллардагы авыл тормышы турында яза».

«Берәү» повестеның төп идеясен дә тәнкыйтьче дөрес тотып алган: колхозга булган ышанычның юкка чыгуы. Әсәрнең төп герое Исхак агроном булырга хыяллана, җаны-тәне белән, җиң сызганып, эшкә тотына. Ләкин аның дәртен бик тиз сүндерәләр — ул чор өчен үзен хуҗа итеп хис иткән кеше түгел, сүз тыңлаучан, берсүзсез барына да

риза булып, баш иеп торган кол гына кирәк булып чыга. һәм Исхакның колхоз строена булган ышанычы әкренләп сүнә, күңеле кайта. Ул туган якларын, яраткан эшен ташлап китәргә мәҗбүр була.

Тәнкыйтьче фикеренчә, А. Гыйләҗев «үз героеннан әллә ни югары күтәрелә алмаган» (ягъни, үзе дә шулай дип уйлый), «герое характерындагы тискәре сыйфатларны һәм Исхак сайлаган позициянең ялгыш булуын ышандырырлык рәвештә күрсәтә алмаган». Ә мондый позициянең ялгыш булуында тәнкыйтьче, күрәсең, һич шикләнмәгән. Югыйсә, 60 нчы елларда бер Исхак кына түгел, меңләгән-миллионлаган кешеләр туган авылларын ташлап, теләсә нинди юл белән шәһәргә күчеп киттеләр, монда төпләнделәр. Язучы бу аяныч күренешне шул вакытта ук тотып алган һәм тәэсирле итеп тасвирлаган. Тәнкыйтьче исә аңа вәгазь укый: имештер, язучы «үз героеның кимчелекләренә сокланып утырмаска, аннан өстенрәк, акыллырак, зирәгрәк булырга тиеш». (Димәк, тәнкыйтьче үзен язучыдан «акыллырак» та, «өстенрәк» тә, «зирәгрәк» тә дип саный). Имештер, «әгәр тормыш китек күңелле герой манарасыннан гына торып тасвирлана икән, тарихи перспективаның котылгысыз рәвештә бозып күрсәтеләчәген көт тә тор». Монда да шул ук социалистик реализм таләп иткән «тарихи перспектива»! Тик язучы аны тәнкыйтьчегә караганда тирәнрәк сизгән, дөресрәк аңлаган. Бүген, чирек гасыр вакыт узгач, без А. Гыйләҗев тасвирлаган күренешнең ни дәрәҗәдә дөрес булуын, ниһаять, аңладык, шикелле. Тик... вакыт кына үткән булып чыкты.

Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» повестена бирелгән анализга карата да шундый ук сүзләрне әйтеп булыр иде. Әсәрнең төп фикере: мондый гади авыл малае Әнис Бадигинда зур художник, чын музыкант, туып җитә алмаган Бетховен үлә. Моңа кем гаепле? Автор безнең бөтен җәмгыятебез, аерым кешегә, аның сәләтен ачуга игътибар бирмәгән, аның намусын таптаган строебыз гаепле дип уйлый. Әлбәттә, яшь тәнкыйтьче мондый караш белән килешә алмый, авторның «идея позициясе тайгаграк» булуы хакында яза. Аныңча, Әнис Бадигин, «һичшиксез, тормышчан образ». «Әмма, повестьтагыча, аны якларга, акларга тырышу белән берничек тә килешеп булмый. Билгеле, аны аңларга мөмкин, ә гафу итәргә һич тә мөмкин түгел».

Бу сүзләрне укыганда шулай ук колакларым яна. Ихлас күңелдән ышанган булсам да — барыбер оят. Тормыш үзе бу догматик карашлардан арындырды, акылга өйрәтте. Хәер, бүген без барыбыз да аек акыллы, барыбыз да үткәнгә башкачарак карыйбыз. Мин, мәсәлән, элеккe бик күп карашлардан баш тартып, яңача фикер йөртә башладым.

Тәнкыйтьченең акылы да кайчак төштән соң була, күрәсең...

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ Ф. ӘМИРХАНГА ХАТЫ

*Былтыр «Социалистик Татарстан» һәм «Татарстан яшьләре» газеталары Гаяз Исхакыйның туган көнен февраль аенда ел саен билгеләп үтү мәсьәләсен күтәреп чыкканнар иде. XX йөз башы татар тормышының үзәгендә торган бу зур шәхес — әдип, публицист, җәмәгать эшлеклесенең 65 ел буе «онытылып» торганын искә алсак, мондый башлангычны хупламый мөмкин түгел. Бу дата уңае белән ясалган публикацияләрнең Г. Исхакыйны өйрәнүдәге әһәмиятен искә алып, «Казан утлары» да һәр елның февраль санында әдипкә кагылышлы материал бирен барырга уйлый. Бу санда укучыга Г. Исхакыйның Ф. Әмирханга язган бер хаты тәкъдим ителә. Хат сүзгә - сүз бирелсә дә, хәзерге орфография һәм пунктуация кагыйдәләренә буйсындырыла.*

Хөрмәтле Фатих!

Мин сиңа бу хатны зур бер йомыш берлән язам. Максим Горький «Алдым-бирдем» вә башка минем берничә нәрсәләремнең тәрҗемәсен җыеп, шуңарга тагы берничә татар мөхәрриренең әсәрләренә, шигырене кушып, «Татар мәҗмугаи әдәбиясы» исемендә бер китап бастырырга димләп хат яза. Мин бу эшне үз тарафымнан кабул итеп, җавап бирдем. Хәзер сүзне эш итеп чыгарырга гына кала. Шуның өчен сездән Казандагы мөхәррирләрдән сиңа, Габдулла Тукаевка, Әстерхан Сәгыйть Рәмиевкә мөрәҗәгать итәргә уйладым. Син шул фикерне ничек табасың?

Беренче мәсьәлә бу. Менә, син, Габдулла, Сәгыйтькә башка рус галәменә күрсәтерлек әсәр ияләре юк дип уйлыйм. Син ни фикердә? Бәлки мин белми торган, мин читтә торып күрми калган берәр мөхәррир, шагыйрь бардыр. Булса, шул кем?

Икенче. Син үзең шул мәҗмугада бастырыр өчен әсәрләреңнең иң яратканыңнан бер, йә берничә хикәяләреңне тәрҗемә иттереп бирә аласыңмы? (Өч формадан[1] күп булмаска тиеш).

Әлбәттә, гонорар дигән нәрсә булачак, ләкин алары әле тәгаен ителмәгән. Бәлки шул китап үз файдамызга бирелеп, күпме килә, шул кадәр бүлешергә тугъры килер.

Өченче сөаль. Шагыйрьләремездән Габдулла берлән Сәгыйть кенә булып, аларны син кабул итә аламсың, минем шул карашымда мин белмәгән шагыйрьләргә каршы берәр җинаять юкмы? Бәлки хакыйкатән дә зур шагыйрьләремез бардыр да, мин аларны укымаганмын, күрмәгәнмен генәдер.

Дүртенче сөаль. Татар әдәбияты хакында кыска гына мәкалә язып, мөкатдимә урнында шул китапка куярга кирәк, ди. Шуңарга м а т е р и а л т а б ы п  б у л а м ы, син табыша аласыңмы?

Бишенче. Габдулла Тукаев кайда? Аңарга син шул мәсьәләне аңлатып хат яза аласыңмы? Мин гәзитләрдә әллә кая китте дип укыганга, кая язарга белми торам. Әгәр яза алсаң, яз.

Менә шул сөальларга тиз җавап бирүне, әгәр үзеңнең әсәрләрең берлән бергә иштирәк булсаң, тиздән тәрҗемә иттерә башлавыңны үтенәм. Материаллар булса, шуларны җыештырып, миңа җибәрергә тиеш булыр. Чөнки ул мәкаләне мин язачакмын йә яздырачакмын**. Бу бетте.

«Урталык»ны укып чыктым. Матур башлана, ләкин «Хәят» аңардан «тормышлы»рак. Аңардан куәтлерәк тел берлә язылган. Хәсәнең әле бик уртача кеше, бара-бара бәлки ачылыр, татар тормышының чәверүчеләре[1] арасына керергә хак казаныр. Икенче, өченче җөзәләре[2] чыкса, әлбәттә, җибәртерсең. «Хәят»ны тизрәк бетер.

Синеңчә, Габдулла Тукаевның нинди шигырьләре мәҗмугага керергә тиеш? Миндә аның шигырьләре хәзер берсе дә юк. Минемчә, шул әсәрләр-

[1] Форма — басма табак мәгънәсендә булса кирәк.

дән кирәк шигырь булсын, кирәк нәсер булсын, татар исе, татар тормышы аңкып торырга тиеш. Шуның өчен тәрҗемәләр дә, Лермонтовка, Пушкинга тәкълидән[3] язылган нәрсәләр кермәскә кирәк. Булдыра алсак, шул эшне эш итеп чыгара алсак, шактый зур хезмәт булыр иде. Шуның өчен, әлбәттә, синең тырышуың бик зур шарт. Фәкать минем шул хатымны серрәк тотып, хәбәрең бик (бер сүз танылмый — И. Н.) тырыш. Үзем сәламәт торам. Тормышны шәп дип булмый. Ләкин тәмуг да түгел. Менә хәзер бер атна чамасыннан бирле бездә кояш батмый. Ике йөз дә ничәнче сәгатьтер инде бер туктамаенча, күзене алмаенча, безгә карап тора (әлбәттә, миңа акшам, ястү намазларыны казага калдырырга тугъры килә). Иптәшләр бар. Читтән килгән хатлар, җирле газитәләр берлән яшимез. Ләкин мин үзем татар общественоның юклыгын бик ачы иттереп татыйм. Татар агымының эчендә булмаганга, кая таба дулкын типкәнен, кая таба су үзәк салганын, нинди елгаларны ташлап, яңа юл алганын күрә алмыйм. Шул күрә алмау минем өчен, әлбәттә, бик авыр, бик уңайсыз. Бәгъзе мәсьәләләрдә артка калырга, бәгъзеләрендә алга сикерергә мәҗбүр итә. Тагы татар тормышының янында утырып тормау әллә нинди баткаклар (?) (монда бөтен бер юл аңлашылмый — И. Н.) аның буяуларын уңдырып китерә. Казаннан беркемнән дә хат алмыйм. (Гомәрләрдән*** генә). Шуның өчен Казанны тагы бер дә белмим.

Әлегә хуш. Дус-ишкә сәлам.

Хатны тиз яз.

Хөсәен Ямашев хакында бер «Йолдыз» чыгаргансыз, ди****. Шуның бер номерын табып миңа җибәреп булмыймы?

Коръән тәрҗемәчеләргә синең вә синең иптәшләреңнең вә яшьләрнең ноктаи назары ничек? Ул мәсьәләгә әһәмият бирәләрме, әллә юкмы? Вакытың булса, иренмәсәң җавап яз.

Гаяз. 13 нче июнь 1912 нче.
Мезень.*****

Адрес: Мезень, Исхаков.

Бер читтә: «Материаллар заказной бандероль берлә генә җибәрелсен. Посылка полица кулыннан үткәнгә, андый нәрсәләр күп вакыт жандарм кулына төшеп югалалар».

## Искәрмәләр

* «...димләп хат яза». А. М. Горькийның бу хаты сакланмаган. Бүтән чыганаклардан бөек әдипнең 1910-12 елларда җәмәгатьчелекне Россиядәге милли әдәбиятлар белән таныштыру өчен рус телендә җыентыклар чыгару уе белән яшәве, эшлекле чаралар күрүе мәгълүм. Ләкин, берме-икеме җыентыкның чыгуын искә алмаганда, бу эш, кызганычка каршы, ныклап тормышка ашмый. Татар әдәбияты җыентыгы да чыкмый калган. Ф. Әмирханга шушы уңай белән язылган тагын ике хатыннан күренгәнчә, Г. Исхакыйның «Тормышмы бу?» романы, «Кияү» повесте, «Сөннәтче бабай», «Шәкерт абый» хикәяләре һәм «Алдым-бирдем» пьесасы, тәрҗемә ителеп, Петербургка озатылган булган. Араларыннан «Шәкерт абый» Петербургта чыга торган «Современник» журналының 1913 елгы 11 санында, ә «Алдым-бирдем» (русчасы — «Брачный договор») «Заветы» журналында (1914 елның июнь саны) — Горький тәкъдиме белән булса кирәк — дөнья күргән.

** «...яздырачакмын». Андый мәкаләне журналист, тәнкыйтьче, прозаик Нәҗип Гасрый язган, һәм ул «Современник»ның 1911 елгы 4 санында «Россия татарларының уянуы һәм аларның әдәбияты» дигән исем астында басылып чыккан.

*** «...Гомәрләрдән» — меньшевиклар позициясендә тора торган социал-демократ һәм язучы, Октябрьдән соң эмигрант Гомәр Терегулов турында сүз бара.

**** «...«Йолдыз» чыгаргансыз, ди» — «Йолдыз» газетасының Х. Ямашев үлеменә багышлап чыгарылган 1912 елгы 15 март саны күздә тотыла.

Г. Исхакыйның Казан татар укытучылар институтында Х. Ямашев белән дүрт ел бергә укуы, самодержавиегә каршы көрәштә аның белән бер аяктан атлап баруы, күрәсең, бушка китмәгән: ул Ямашевның үлемен авыр кичергән. 1907 елның гыйнварында төрмәдән котылгач, беренче эше итеп, «Таң йолдызы» редакциясендә йомыш-юлга йөрүче малайны Хөсәенне чакырырга җибәрүе, Ямашев, С. Рәмиев һәм Ш. Мөхәммәдьяров белән ресторанда ашап-эчүе һәм Ямашевларга барып кунуы да шул фикерне куәтләсә кирәк. (Бу мәгълүмат «Зиндан» повестеннан алынды).

***** Мезень — Архангель губернасындагы бер шәһәрчек. 1908 елда качып китеп, Төркиядән урап кайткан Исхакый, 1911 елда Петербургта тотылып, сөрген мөддәтен (срогын) тутыру өчен шунда озатылган.

*Текстны әзерләүче һәм аңлатмалар белән тәэмин итүче — профессор Ибраһим* ***НУРУЛЛИН.***

---

[1] Чәверү (төрекчә) — үзгәртү. [2] Җөзә — кисәк; [3] тәкълидән — ияреп.



# ЛАТИН ӘЛИФБАСЫ

Соңгы елларда, үзгәртеп кору һәм хәбәрдарлыкның шифалы җилләре тәэсирендә, милли тарих, мәдәният белән кызыксыну бермә-бер артты. Укучыларыбыздан килгән хатлар арасында бездә утызынчы елларда кулланышта булган латин язуы белән таныштыруны үтенгәннәре дә бар. Укучыларыбызның теләген канәгатьләндерү йөзеннән, түбәндә латин әлифбасына нигезләнгән татар язуы турында кыскача мәгълүмат бирелә.

Мәгълүм ки, халкыбыз үзенең күп гасырлы вә гыйбрәтле тарихында берничә язу-әлифба кулланды: борынгы төрки руник язу, гарәп, латин һәм хәзер гамәлдә булган кириллицага нигезләнгән әлифба. Болар арасында татарга иң озак хезмәт иткәне — мең ел — гарәп әлифбасына нигезләнгән язу. Гарәп әлифбасы татар теле белән чагыштырганда бөтенләй башка авазлар системасын тәшкил иткән телгә — гарәп теленә яраклаштырылган. Шуңа күрә бу язуны куллану күп кыенлыклар тудырган, бигрәк тә татар телендәге сузык авазларны язуда билгеләү шактый катлаулы булган. Гарәп әлифбасын татар теле кануннарына яраклаштыру, үзгәртү өлкәсендә XIX йөз ахыры — XX йөз башларында, аеруча Октябрь революциясеннән соң мәгълүм күләмдә эш башкарылса да, ул тәмамланмыйча кала. Егерменче елларда татар язуын латин әлифбасына күчерү хәрәкәте көчәеп китеп, 1927 елда язуыбыз рәсми рәвештә латин графикасына күчерелә. Шунысын да әйтергә кирәк, татар язуын латин графикасына күчерү буенча беренче тәҗрибәләр Октябрь революциясенә кадәр үк ясалган була. Күренекле азәрбайҗан язучысы, мәгърифәтче М. Ф. Ахундов башлап җибәргән латинчылык хәрәкәтенә татарлардан башлап шагыйрь Сәгыйть Рәмиев кушыла. Әстерханда нәшер ителгән «Идел» газетасында ул, татар язуын латин алфавитына күчерүне кулайрак күреп, мәкаләләр бастыра, латин алфавиты нигезендә татар әлифбасы проектын төзи. Әмма, татар җәмәгатьчелегендә бик зур тавыш-гауга куптарган латин әлифбасы мәсьәләсе бездә Азәрбайҗан һәм Төркия латин графикасына күчкәч кенә хәл ителә. Татарстан республикасы Халык Комиссарлары Советының 1927 ел, 3 июль карары белән латин алфавиты татар теленең рәсми алфавиты дип игълан ителә.

Латин алфавиты рәсми рәвештә кабул ителгәч тә аңа нигезләнгән татар орфографиясе берничә тапкыр зур үзгәрешләр кичерә, тагын да камилләштерелә бара. Бу өлкәдә 1937 елда тагын да кайбер үзгәрешләр күздә тотылса да, мәктәптә укучы татар баласын берьюлы ике алфавит өйрәнүдән коткаруны сылтау итеп, татар язуын кириллицага (рус) нигезләнгән алфавитка күчерү хәрәкәте башлана һәм ул 1940 елда тормышка ашырыла.

Шулай итеп, татар язуы өчен иң кулай булган алфавит гамәлдән чыгарыла. Кыска гына вакыт эчендә берничә тапкыр әлифба-язу алыштыру нәтиҗәсендә буыннар арасында өзеклек туды, яшь буын мең ел буе тупланып килгән рухи байлыгыбыздан, кадерле мирастан аерылды.

Җәүдәт МИҢНУЛЛИН

| 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| а – | Aa | *Aa* | й – | Jj | *Jj* | ш – | Şş | *Şş* |
| б – | ʙʙ | *ʙʙ* | к – | Kk | *Kk* | ү – | Yy | *Yy* |
| җ – | Çç | *Çç* | л – | Ll | *Ll* | т – | Tt | *Tt* |
| ч – | Cc | *Cc* | м – | Mm | *Mm* | у – | Uu | *Uu* |
| д – | Dd | *Dd* | н – | Nn | *Nn* | в – | Vv | *Vv* |
| е – | Ee | *Ee* | ң – | Ꞑꞑ | *ꞑ* | х – | Xx | *Xx* |
| ә – | Əə | *Əə* | о – | Oo | *Oo* | з – | Zz | *Zz* |
| ф – | Fƒ | *Fƒ* | ө – | Ɵɵ | *Ɵɵ* | ж – | Ƶƶ | *Ƶƶ* |
| г – | Gg | *Gg* | п – | Pp | *Pp* | ы – | Ьь | *Ьь* |
| гъ – | Ƣƣ | *Ƣƣ* | къ – | Qq | *Qq* | ый – | Ьj ьj | *Ьj ьj* |
| һ – | Hh | *Hh* | р – | Rr | *Rr* | | | |
| и – | Ii | *Ii* | с – | Ss | *Ss* | | | |

Беренче графа — гамәлдәге татар хәрефләре
Икенче графа — латинча басма хәрефләр
Өченче графа — латинча язма хәрефләр

## JƏŞ DIŊGEZENDƏ

Mazlumnarnьŋ[1] jəşen dingez jasap
Kəjmələrdə jəzə zalimnar,
Kəclelərneŋ çəвren xaqlь jasap
Fətva вirə вik kyp ƣalimnər.

## TUQAJ

Ləƣnət əjtep dənjasьna ylde Tuqaj,
Atьlьp kitkən joldьz keвek synde Tuqaj.
Matur kəjne şьnƣьratьp ujnaƣanda
Өzelep qalƣan qьl şikelle buldь Tuqaj.
Dərtlelərne şatlandьrьp çьrlattь ul,
Taş kyneine monlandьrьp jьƣlattь ul,
Jarlьlarƣa, meskennərgə serdəş buldь,
Jьƣьlƣanƣa, jardəmsezgə ul suzdь qul.
Telsez idek, Tuqaj вezne telle itte,
Çьrsьz idek Tuqaj вezne çьrlь itte,
Kygeвezdə balqьp torƣan joldьz вulьp
Qara təndə əsteвezgə ençe sipte.
Bez Tuqajnь hər vaqьtta saƣьnьrвьz.
Çьrlarьnьŋ dərte вelən qaвьnьrвьz,
Səƣadətkə həm də ƣali əmidlərgə,
Jaqtь kəŋgə jarsьp qanat qaƣьnьrвьz!..

*1917*

## TYGEL!

— Çьrla, disəŋ iptəş, çьrlar idem —
Çьr-çьrlavь qisn eş tygel,
Əmma, gəlsez səxra, jəmsez çirlər
Sanduƣaclar sajrar təş tygel!

*1916*

---

[1] Mazlum — izelgən.

## Яшь

Мәзлумнарның яшен диңгез ясап
Көймәләрдә йөзә залимнар,
Көчлеләрнең җәбрен хаклы ясап
Фәтва бирә бик күп галимнәр.

## Тукай

Ләгънәт әйтеп дөньясына үлде Тукай,
Атылып киткән йолдыз кебек сүнде Тукай,
Матур көйне шыңгыратып уйнаганда
Өзелеп калган кыл шикелле булды Тукай.
Дәртлеләрне шатландырып җырлатты ул,
Таш күңелне моңландырып егълатты ул,
Ярлыларга, мескеннәргә сердәш булды,
Егылганга, ярдәмсезгә ул сузды кул.
Телсез идек, Тукай безне телле итте,
Җырсыз идек, Тукай безне җырлы итте,
Күгебездә балкып торган йолдыз булып
Кара төндә өстебезгә энҗе сипте.
Без Тукайны һәрвакытта сагынырбыз,
Җырларының дәрте белән кабынырбыз,
Сәгадәткә һәм дә гали өмидләргә,
Якты көнгә ярсып канат кагынырбыз!..

*1917*

## Түгел!

— Җырла, дисең, иптәш, җырлар идем —
Җыр җырлавы кыен әш түгел,
Әмма, гөлсез сәхра, ямьсез җирләр
Сандугачлар сайрар төш түгел!

*1916*

*Сәйфи Кудашның 1940 елда Казанда басылган «Сайланма шигырьләр» китабыннан (31 б.).*

## ҮЗ АКАДЕМИЯБЕЗ БУЛАЧАК

Татарстан Республикасы Министрлар Советы Президиумы утырышында Татарстан ССР Фәннәр академиясен булдыру турындагы мәсьәлә тикшерелде. Бу мәсьәлә буенча республика Министрлар Советы карары кабул ителде, ул ТССР Югары Советы Президиумы каравына кертеләчәк.

Оештыру комитеты тәкъдиме белән «Татарстан Фәннәр академиясен төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру концепциясе» расланды. Анда, ТССР Фәннәр академиясе фәнни оешма булып тора, дип күрсәтелә. Үз әгъзалары сыйфатында ул республиканың матди һәм рухи мәдәниятен, халык хуҗалыгын үстерү мәнфәгатьләрендә фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр алып баручы күренекле галимнәрне берләштерәчәк.

Республика Фәннәр академиясе СССР Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәгендәге фәнни учреждениеләре, шулай ук вуз һәм тармак фәне нигезендә оештырыла. Шул ук вакытта Казан фәнни үзәге мөстәкыйль фәнни берәмлек буларак саклана.

ТССР Фәннәр академиясендә өч бүлек: гуманитар һәм иҗтимагый фәннәр, техник һәм технологик фәннәр, табигать-математика фәннәре бүлекләре булачак. ТССР Фәннәр академиясе составына ТССР Фәннәр академиясенең хакыйкый членнары (академиклар) һәм член-корреспондентлары керә. 30 хакыйкый әгъза һәм 50 член-корреспондент вакансиясе ачыла. Академиянең гомуми җыелышы Президенты, өч вице-президенты һәм Президиумның 8 әгъзасын сайлый. Президиум каршында үзәк фәнни китапханә, «Гыйлем» нәшрияты, татар энциклопедиясенең баш редакциясе, кульъязмалар һәм архив фонды бүлекләре, докторантура һәм аспирантуралар оештырыла. «Татарстан Фәннәр академиясе хәбәрләре» дигән журнал чыгарылачак.

## «ҖӘМӘГАТЬ ФИКЕРЕ» КЕМГӘ ФАЙДАЛЫ?

«Комсомольская правда» газетасының 7 февраль санында «Вокруг суверенитета» дип аталган мәкалә чыкты. Авторы — ВЦИОМ (Җәмәгать фикерен өйрәнү буенча Бөтенсоюз үзәге) хезмәткәре Б. Дубин. Әлеге язма турыдан-туры Рәсәй мәнфәгатьләрен күздә тотып язылган, шовинистик рух белән сугарылган, анда Татарстанның төп халкы, хуҗасы булган татар халкына яла ягыла, ул надан халык рәвешендә сурәтләнә. «Җәмәгать фикере» дигән рубрика астында дөнья күргән бу мәкалә хаклы рәвештә татар милләтендә нәфрәт уята. Татарстан Югары Советының өченче сессиясе бу фактны Татарстанның мөстәкыйльлегенә каршы күренеш дип бәяләде һәм бу уңайдан махсус карар кабул итте.

## «ИТТИФАК» СҮЗЕН ӘЙТӘ

9 февральдә ТССР Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында «Иттифак» Татар милли бәйсезлек партиясенең конференциясе булып узды. Казан, Бөгелмә, Карабаш, Ленино-Кокушкино, Кукмара, Чаллы, Лениногорск, Алабуга, Түбән Кама, Пермь һәм Сембердән җыелган 41 делегат партия уставына үзгәрешләр кертү, беренче корылтайны җыю, 17 мартта СССРны саклап калу максатында үткәреләчәк референдумга бойкот игълан итү мәсьәләләрен тикшерде. Конференция «Иттифак»ның беренче корылтаен 1991 елның 13-14 апрель көннәрендә Казанда җыярга дигән фикергә килде. 30 мартта исә, әлеге зур җыенга әзерлек йөзеннән, эшчел конференциясе узачак.

Делегатлар референдум үткәрүгә каршы чыктылар һәм шул уңайдан татар халкына мөрәҗәгать кабул итеде. 10 мартта, «Иттифак» бүлекләре эшләп килгән урыннарда, протест митинглары үткәрү күздә тотыла.

## ТАРИХНЫҢ ҖИДЕ ТОМЫ

Җиде томнан торган «Татар халкының тарихи-этнографик атласы» — Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәрләре коллективының күп еллык иҗат җимеше.

Кызганыч: әлегә кадәр аны нәшер итәргә алынучылар юк. Хәлне, күрәсең, тексттан тыш басмада карталар, сызымнар, рәсемнәр рәвешендәге гаять зур күләмдә белешмә материаллары булуы да катлауландыра. Болардан башка тарихчы галимнәрнең, этнографлар, сәнгать белгечләренең тикшеренүләре шактый ярлыланачак.

Атласның максаты — Идел һәм Урал татарлары тарихына, теленең, дин һәм мәдәниятнең бар булган мирасына җентекле анализ ясау, чынлыкта инде күбесе онытылган халык һөнәрләрен, һөнәрчелекне торгызу һәм саклап калу. Бу зур хезмәтнең аерым бүлекләре, хәтта томнары торак һәм йорт-җир төзүгә, игенчелеккә, терлек асрауга һәм шулай ук өй шартларында тукучылык белән шөгыльләнүгә багышланган. Милли өс киемнәре, бизәнү әйберләре, аяк киемнәреннән торган бай

коллекция бик матур итеп бизәлгән.

Татар халкының йолалары аерым томга тупланган.

Бәяләп бетергесез хезмәт әлегә киштәләрдә ята. Чират — нәширдә. Бу изге эшкә кем тотынып икән?

## МӘДӘНИЯТ ФОНДЫ — ЯҢАРЫШТА

8 февральдә Казанның Актерлар йортында Бөтенсоюз мәдәният фонды Татарстан бүлегенең отчет-сайлау конференциясе булып узды. Идарә рәисе, язучы Гариф Ахунов Фонд бүлегенең өч еллык эшенә җентекле анализ ясады.

Конференциядә яңа идарә әгъзалары сайланды һәм бу оешмага «Татарстан республикасы мәдәният фонды» дигән яңа статус бирелде. Аның рәисе итеп профессор А. А. Халиков сайланды.

## ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

14 январьда К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында классик шагыйребез Һади Такташ истәлегенә багышланган кичә уздырылды. Аны кереш сүз белән шагыйрь И. Юзеев ачты. Һ. Такташның тормышы һәм иҗаты турында шагыйрь Р. Гатауллин сөйләде. Кичәдә профессор Ш. Сарымсаков, композитор Ә. Бакиров шагыйрь турында истәлекләр сөйләделәр.

Соңыннан сәнгать көчләре тарафыннан шагыйрьнең әсәрләреннән төзелгән зур концерт булды.

* * *

14 январьда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында Һади Такташның тууына 90 ел тулуга багышланган фәнни конференция уздырылды. Аның эшендә республикабыз җитәкчеләре, язучылар, галимнәр, студентлар катнашты. Килгән кунаклар арасында Һади Такташ апасының улы — техник-инженер Әхәт ага Богатов та бар иде.

## ЯЗУЧЫ ЮБИЛЕЕ

28 январьда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында күренекле әдип Гомәр Бәшировка 90 яшь тулуга багышланган тантана булды.

Татарстан Республикасы Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары, профессор М. Хәсәнов язучы иҗаты турында сөйләде.

Тантанада Татарстан Язучылар берлеге рәисе Р. Мөхәммәдиев, язучы Г. Ахунов, филология фәннәре кандидаты Ф. Галимуллин, Түбән Камадан «Җидегән чишмә» әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе А. Зыятдинов, КПССның Арча райкомы секретаре Н. Габдрахманов, мөхтәрәм әдибебезнең туган авылы Яңа Саладан килгән Ә. Исмәгыйлов һәм сәнгать осталары Г. Бәшировның бай иҗаты, тормыш юлы турында мавыктыргыч итеп сөйләделәр.

## АФЗАЛ ТАҺИРОВКА — 100 ЯШЬ

Күренекле язучы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Афзал Таһировның тууына 100 ел тулды.

Афзал Таһиров — Әлмәт районының Габдрахман авылында туып, соңгы елларын Башкортстанда эшләгән һәм 1938 елда шәхес культы тарафыннан корбан ителгән трагик шәхесләрнең берсе.

22 ноябрь көнне Габдрахман авылында әдип туган нигездәге йорт стенасына куелган мемориаль тактаны ачу тантанасы булды.

## КЫРЫМ ТАТАРЛАРЫ — РЕФЕРЕНДУМ ТУРЫНДА

Үзбәкстанда яшәүче 300 мең кырым татарының Кырым АССРны торгызу мәсьәләсе буенча референдум үткәрүгә карашы нинди?

Ташкентта кырым-татар телендә чыга торган «Яңа дөнья» газетасының 3 нче санында референдум алдыннан куш сәхифә бирелде. Анда Үзбәкстанда һәм башка республикаларда яшәүче кырым татарларының хатлары урнаштырылды.

Журналистлар һәм газета укучыларның мөнәсәбәте шундый:

— 1921 елгы Ленин декретына әйләнеп кайтырга, чөнки бу декрет нигезендә РСФСР составында күп милләтле Кырым автономияле республикасы игълан ителгән иде;

— Кырым татарларын куып тараткан, репрессияләнгән халыкларның хокукларын чикләгән указларны юкка чыгарырга;

— СССР Югары Советы Президиумының Кырымны РСФСР составыннан УССР составына тапшыру турындагы 1954 ел, 19 февраль Указын юкка чыгарырга;

— референдум Кырымнан куылган барлык кешеләрнең, шул исәптән кырым татарларының яңа буын вәкилләренең — хәзер аларның күпчелеге Россиядә, Үзбәкстан, Таҗикстан, Кыргызстан һәм башка республикаларда яши — катнаштыруны тәэмин итәргә.

20 январьда үткәрелгән референдум нәтиҗәләренә килгәндә исә, Үзбәкстанда яшәүче кырым татарлары бу чараның барлык сәламәт көчләрне туплауга китермәвен, киресенчә, аларны бер-берсеннән ераклаштыруын әйтәләр. Ә бу, үз чиратында, алдан әйтеп булмый торган нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

## УФА: ХӘЛ ИТӘСЕ БУРЫЧЛАР

26 январьда Башкортстан Татар иҗтимагый Үзәге мәҗлесе республика конференциясен уздырды.

Конференциядә өч төп мәсьәлә каралды: Башкортстан Татар иҗтимагый Үзәгенең программалары (максимум һәм минимум), телләр буенча закон проектлары, Башкортстан татарларына мөрәҗәгать.

Төп докладчылар Үзәкнең рәис-координаторлары Р. Мөхәммәтҗанов, М. Хуҗин,

Үзәкнең җаваплы сәркатибе Кәрим Яушев һәм Үзәкнең җирле филиалларыннан чыгыш ясаган 21 делегат бүгенге көндә республикада татар җәмәгатьчелеге алдында торган бурычлар, максатлар һәм шул юлда көн саен очрап торган авырлыклар хакында сөйләделәр.

### БЕРЕНЧЕ ҖЫЕН

11 декабрьдә Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры бинасында «Татар-мишәр фольклоры» дип аталган фәнни җыен һәм III Бөтенсоюз халык иҗаты фестиваленең зур бәйрәм кичәсе булды.

Җыенда мишәр татарларының тарихына, килеп чыгышына, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә төпле фәнни бәя бирелде. Мишәр-татар җырларының поэтик үзенчәлекләре, мишәр диалектында халык йолалары, Пенза һәм Сары тау (хәзерге Саратов) мишәрләре кием-салымнарының чигү үзенчәлекләре турындагы чыгышлар аеруча әһәмиятле иде.

Кичәне Сары тау, Пенза, Волгоград, Киров, Нижний Новгород өлкәләреннән килгән җыр-бию һәм фольклор ансамбльләрендә катнашучылар башлап җибәрде. Татарстанның — Буа шәһәре, Чувашиянең — Комсомол районы Урмай авылы, Башкортстанның Балтач авылы мишәрләре чыгышлары да нур өстенә нур булды. Тумышлары белән мишәр төбәгеннән чыккан шагыйрьләр Рөстәм Миңгалим, Ркаил Зәйдулла, җырчы Ания Туишева, баянчы Рамил Курамшин, сәхнә ветераны Әзәл ага Яһудин, фольклор кичәсендә хөрмәтле кунаклар буларак, чыгыш ясадылар.

### ЯШЬ ИҖАТЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

10 январьда Мөслим урта мәктәбендә районның әдәби иҗат белән шөгыльләнүче укучылары иҗатын тикшерүгә багышланган конференция уздырылды. Әлмәт язучылар оешмасы һәм район мәгариф бүлеге оештырган бу конференциядә уналты мәктәпнең яшь иҗатчылары катнашты. Арада Күбәктән Гөлназ Мәүлиева, Усыдан Саша Смелов, Рузәл Мортазин, Вәрәшбаштан Румия Ханова һәм тагын кайбер укучыларның иҗатына язучылар К. Булатова, А. Минһаҗева, Ф. Садриев, Ф. Гыйльми, Н. Әхмәдиевлар уңай бәя бирделәр. Симәк урта мәктәбеннән 6 класс укучысы Алзирә Садированың самими шигырь вә хикәяләре һәркемдә соклану уятты.

### ЧИТ ИЛЛӘРДӘН КИЛӘЛӘР

Финляндиядә яшәүче милләттәшебез, Казан дәүләт университетында укып, 2 ел буена туган телнең нечкәлекләрен өйрәнеп киткән иде.

Инде менә Австралиядә яшәүче кардәшләребез: бер кыз, ике егет — Мөшәрәф, Азат, Шәһрәт — каникуллары вакытында Казанга килде. Аларның максатлары — татар телен ныклап өйрәнеп, Австралиядә татар балалар бакчалары, мәктәпләр булдыру.

### ТАТАР КИТАПЛАРЫ БҮЛЕГЕ

Пермь шәһәренең беренче номерлы иң зур китап кибетендә татар китаплары бүлеге ачылды. Киштәләрдә татар теленең өч томлы аңлатмалы, фразеологик сүзлекләре, М. Гафури, Ә. Фәйзи, Н. Исәнбәт, Ф. Кәрим, К. Нәҗми томнары, үткән гасыр шагыйре Г. Кандалыйның шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы, хәзерге авторларның китаплары бар.

Әдәбият-сәнгать эшлекләренең тормышы һәм иҗаты белән кызыксынган укучылар китаплар бүлегендә «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән татар композиторы, танылган «Шүрәле» балетының авторы Ф. Яруллин, татар совет поэзиясенең классигы Һ. Такташка багышланган китапларны сатып алалар.

### «СЕМБЕР ҖЫРЫ-90»

Ульяновскида беренче мәртәбә «Сембер җыры-90» исеме белән татар җыры конкурсы уздырылды. Конкурсның беренче турын «Өмет» газетасы редакциясе, «Чишмә» милли телетапшыру программасы һәм «Туган тел» җәмгыяте узган елның 20 — 21 октябрендә үткәргән иде. 1 декабрьдә узган икенче турында җиңүчеләр билгеле булды. Конкурста беренче урынны Иске Кулаткы районыннан Олег Егоров яулады.

# АЛКАЛЫ ЧҮЛМӘК

Яшел үлән белән капланган, кеше аягы басмаган җансыз урамнар, як-якта кайчандыр йортлар торган урыннарда балчык, таш, вак кирпеч, савыт-саба ватыгы өемнәре... Әйтерсең лә ят планетада күптән хәрабә хәленә килгән билгесез цивилизация калдыклары.

Бу — Идел белән Тын (Дон) елгаларының үзара якынайган җирендәге борынгы Бәлҗәмән шәһәре. Җанлы сәүдә юлына урнашкан бу шәһәрдәге архитектура алымнарында болгар, хәтта борынгы хазар чалымнары да тоемлана. Соңрак Бәлҗәмән Казан патшалыгы җирләренә кергән.

Уттай яндырган кояш нурлары астында без казыну эшләре алып барабыз. Иделдән бертуктаусыз пароходлар үтә. Җилкәнле көймәләр җил эзләп әле бер ярга, әле икенче ярга сугыла. Болар Бәлҗәмәннең шаулап-гөрләп торган чакларын күз алдына китерә, җанлы сәүдә юлларын яңарта кебек.

Казыган, саклык белән генә җир катламын алган саен яңа күренешләр ачыла. Менә таш плитәләр җәелгән идән астында җылылык юллары. Таштан ясалган бу торбалар барысы унсигез булып бернечә бүлмәле зур йортны кыш-ларын җылытып торганнар. Кайбер плитәләрдә бур белән катырылган су-үткәргеч торбалар табылды. Алар җылыту торбаларына янәшә куелган. Димәк, өйләрдә кайнар су да булган. Соңрак без яр буендагы бернечә өйне берьюлы җылыта торган 4X4 метрлы мич калдыклары да табып алдык.

Әйткәнемчә, шәһәрдә савыт-саба калдыклары күп. Журнал тышлыгында сурәтләнгән алкалы чүлмәк һәм аның янындагы кечерәк чүлмәккә игътибарлырак карасагыз, кара таплар күрерсез. Алар — фаҗигале янгын эзләре, чүлмәккә сеңгән корым. Бәлҗәмән шәһәре Идел буендагы башка шәһәрләр кебек үк 1395 елны Аксак-Тимер гаскәрләре тарафыннан яндырыла, җимерелә, халкы кырып бетерелә. Экспедициягә беренче тапкыр барган елны миңа бер йорт янында үтереп ташланган кызчыкның сөякләрен чистартырга туры килгән иде. Аның бармагында бакыр йөзек, беләндә көмеш каптырма иде... Табылган һәр нәрсә Бәлҗәмәндә югары матди культура, сәнгать һәм һөнәрчелекнең чәчәк атуы турында сөйли.

Бернечә ел элек без монда борынгы татар самавыры табып алган идек. Кызыл бакырдан эшләнгән, киң авызлы чүлмәкне хәтерләтүче бу җайланманың төбенә борынгы төрки тамгасы — «б» хәрефе сугылган. Чүлмәктән аермалы буларак, аның эчендә күмер салу торбасы, төтен юлы, гомумән, хәзерге самавырларга хас система бар.

Бәлҗәмәндә савыт-саба, гадәттә, үзле кызыл балчыктан яндырып эшләнгән. Шундый ук типтагы савытлар Казанда, Сөембикә манарасы янындагы казулар вакытында да табылды. Димәк, борынгы традицияләр гасырлар буена дәвам итеп, Казан ханлыгында тагын да үстерелгәннәр. Тышлыктагы рәсемдә шулай ук йорт бизәү өчен кулланылган, яндырып эшләнгән таш бизәк үрнәкләрен дә күрергә мөмкин.


Әзһәр **МӨХӘММӘДИЕВ.**

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле татар язучысы Мөсәгыйт Хәбибуллин.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотолары.

Бәясе 1 сум 50 тиен.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРСТАНА
(на татарском языке)